ISSN 0206-4189
Индекс 73210

# КАЗАН УТЛАРЫ

10.2011





**Кави Нәҗми**
**(1901—1957 )**

# Казан утлары

# Qazan utları

2011

**10**

**(1068)**

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:
«ТАТМЕДИА»
ачык акционерлык җәмгыяте

*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Габдрахман улы Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Зилә Вәлиева**
**Разил Вәлиев**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Дамир Исхаков**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Рөстәм Галиуллин, Марат Закир, Камил Кәримов, Алмаз Хәмзин.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Флера Сабирова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Гөлнара Галиева** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

✉: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎☎: Баш мөхәррир—562-10-62.
Баш мөхәррир урынбасары—292-93-16.
Җаваплы сәркәтип, компьютер үзәге—562-11-28.
Шигърият, публицистика, фән һәм сәнгать бүлеге—292-39-63.
Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63.
Гамәли хезмәткәрләр—562-11-28.
Исәп-хисап бүлеге—222-09-80.
**Факс**—(843) 562-11-28.
**E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ–НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ–СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА


## Бу санда


**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Нур ӘХМӘДИЕВ. Бәгырьдә бар–ташлар. *Шигырьләр.* ... 5
Рауль МИРХӘЙДӘРОВ. Җәяүле татар. *Бәян.* ... 9
Гарифҗан МӨХӘММӘТШИН. Безнең гомер. *Шигырьләр.* ... 108
Фәнзаман БАТТАЛ. Альтернатива. *Хикәя.* ... 112
Әнвәр ШӘРИПОВ. Күкрәгемдә көн дә бер яңара... *Шигырьләр.* ... 122

**САТИРИК ӘСӘРЛӘР КОНКУРСЫ**

Әхәт САФИУЛЛИН. Тормыш җае. *Хикәя.* ... 125
Рүзәл МӨХӘММӘТШИН. Яңа тормыш. *Шигырь.* ... 128

**ПУБЛИЦИСТИКА**

Ирек САБИРОВ. Татулык та, горурлык та кирәк! ... 129

**СӘНГАТЬ**

Идрис ГАЗИЕВ. Граммофон тәлинкәләре ни сөйли? ... 134

**ХӘТЕР**

Рамил КУРАМШИН. Онытырга хакыбыз юк. ... 146
Фәнис ЯРУЛЛИН. Хәтер төпләрендә утлы күмер. *Көндәлекләр.* ... 180

**ФӘН**

Рәшит ГАЛЛӘМ, Нәҗип НӘККАШ-ИСМӘГЫЙЛЬ. Беренче татар басмасы. ... 149
«Манифест»ның хәзерге татар әдәби теленә тәрҗемәсе. ... 158
Фирдәвес ГАРИПОВА. Авылларыбыз тарихы. ... 156
«Татар энциклопедиясе» битләреннән. ... 159

**ЮБИЛЕЙЛАР**

Ләбиб ЛЕРОН. Зыялы матурлык. *(Р.Хәмидкә 70 яшь)* ... 162
Марсель Зариповка 80 яшь. ... 166
Мансур Шаһимәрдәновка 60 яшь. ... 167

**АК ҖИЛКӘН**

Фәнзил ГАЛИЕВ. Мәхәббәт хатирәсе. *Хикәя.* ... 168
Саимә ИБРАҺИМОВА. «Агым уңаена йөз!» ... 170
Алмаз МАНСУРОВ. Сине сайладым. *Шигырьләр.* ... 172
Алисә ЗАРИПОВА. Ике канәфер. ... 174

«Казан утлары» архивыннан. ... 132
Иҗтимагый–мәдәни тормышыбыздан. ... 191

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: повесть Р. МИРХАЙДАРОВА «Чти отца своего», рассказ Ф. БАТТАЛА «Альтернатива»; стихи Н. АХМАДИЕВА, Г. МУХАМЕТШИНА, А. ШАРИПОВА.
«Сенной базар»: Конкурс сатирических произведений. Рассказ А. САФИУЛЛИНА «Хочешь жить—умей вертеться»; стихотворение Р. МУХАМЕТШИНА «Новая жизнь».
«Публицистика»: И. САБИРОВ. «Жить дружелюбно и гордо».
«Искусство»: И.ГАЗЕЕВ. «О чем говорит граммофон?»
«Память»: статья Р. КУРАМШИНА к 100-летию татарского певца Ф. Насретдинова; дневниковые записи Ф. Яруллина.
«Наука»: Р. ГАЛЛЯМ, Н. НАККЯШ-ИСМАГИЛ. «Первое татарское издание»; «Манифест» на современном татарском языке.
Страницы из «Татарской энциклопедии»: Ф. ГАРИПОВА. «История наших деревень».
«Белый парус»: рассказ Ф. ГАЛИЕВА «Воспоминания о любви»; С. ИБРАГИМОВА. «Плыви по течению»; А. ЗАРИПОВА. «Две гвоздики», стихи А. МАНСУРОВА.
«Наши юбиляры»: статья Л. ЛЕРОНА к 70-летию драматурга Р. Хамида; в номере отмечаются 80-летие М. Зарипова и 60-летие М. Шагимарданова.
Из фотоархива журнала.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: Черная палата в Булгарском историко-архитектурном заповеднике; писатель Рустем ГАЛИУЛЛИН.

## IN THIS ISSUE:

«Prose and poetry»: story by R. MIRHAYDAROV «Honor your father», story by F. BATTAL «Alternative», poetry by N. AKHMADIEV, G. MUHAMETSHIN, A. SHARIPOV.
«Hay Bazaar»: Competition of satirical. Story by A. SAFIULLIN «Want to know how to live-spin», poem by R. MUHAMETSHIN «New Life».
«Journalism»: I. SABIROV. «Live friendly and proudly».
«Art»: I. GASEEV. «What does phonograph speak about?»
«Memory»: article by R. KURAMSHIN to 100th anniversary of Tatar singer F. Nasretdinov; diaries by F. YARULLIN.
«Science»: R. GALLYAM, N. NAKKYASH-IISMAGIL. «First Tartar edition,» «Manifesto» in modern Tatar language.
Pages from «Tatar Encyclopedia»: F. GARIPOVA. «History of our villages.»
«White Sail»: story by F. GALIEV «Memories of Love»; S. IBRAGIMOV «Go with flow»; A. ZARIPOV. «Two studs,» poetry by A. MANSUROV.
«Our jubileers»: article by L LERON to 70th anniversary of playwright R. Hamid, in issue are celebrated 80th anniversary of M. Zaripov, and 60th anniversary of M. Shagimardanov.
From the photo archives of magazine.
Diary of a social-cultural life.
On our covers: Black Chamber of Bulgar historical and architectural reserve, author Rustem Galiullin.

*The magazine edits monthly*

★ Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★ Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★ Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 03.10.2011, график буенча 03.10.2011.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108 $^1/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ Р–1449. Тираж 4011.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча Федераль хезмәтнең Татарстан буенча идарәсендә, 2010 елның 1 апрелендә теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ №ТУ 16-00337
Индекс 73210 (физик затлар өчен), 16262 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

«ПИК «Идел-Пресс» ААҖ «ТАТМЕДИА» филиалы типографиясендә басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2011 ел.



Нур
Әхмәдиев

# БӘГЫРЬДӘ БАР—ТАШЛАР

## Минем халкым

*Мәшһүр тарихчы*
*Л.Н. Гумилев истәлегенә*

**Татарларга күпме яла яккан**
**Мөтәтарихчылар—оялмый...**
**Тик онытмыйк: ничек тырышсаң да,**
**Саф алтынга шакшы йогалмый.**

**Һәр халыкның була чын асылы,**
**Кан коюдан тора—кемнеңдер...**
**Яулап алган җирдә баскынчылар**
**Чиркәүләрен салып өлгерер.**

**Китапларын җыеп учак ягар,**
**Җылынырга түгел, туңмаган...**
**Илбасарлар шулай халыкларның**
**Тарих ДНКасын «тунаган».**

**Китаплары янса, хәтер калган,**
**Сеңеп калган хәтта ташларга.**
**Хакыйкатьне аңлау кая инде**
**Мәңге айный белмәс башларга!**

**Хәтер яши һәрбер күзәнәктә,**
**ДНКасын алып карагыз.**
**Меңьеллыкның инде яңасына**
**Исән килеш кереп барабыз.**

**ДНКалар гына җитми икән,**
**Кояш шаһит, шаһит җилләр дә.**
**Алар әйтер татар булдыклы дип,**
**Санамагыз аны юләргә!**

Нур ӘХМӘДИЕВ (1946)—*шагыйрь, прозаик; «Аһәң», «Мөнирстан» һ.б. күпсанлы китаплар авторы. Әлмәттә яши.*

Шакшы түгү һаман дәвам итә,
Татар ерткыч, имеш, кыргыйдыр.
Укый калсаң, чәчләр үрә торыр,
Таш балбаллар хәтта сызгырыр.

Шовинистлар иртә куанмасын
Татарларга диеп кич җиткән.
Белсен алар: хакыйкатьне ачар
Арысланнар[1] чыкты читлектән.

Татарларым бакыр, көмеш түгел,
Борынгыдан затлы алтын ул.
Ничә тапкыр кылыч аша үтеп
Исән калган газиз халкым ул!

## Төркиләр

*(урыс тарихчыларына)*

Тауларны да тез чүктерде алар,
Кочакларын җәйде далалар.
Төркиләрнең тояк тавышына
Капкаларын ачты калалар.

Җир читеннән гүзәл Римгә кадәр
Җилдерепләр узды атларда,
Тояклардан очкын сибелеп калды
Җир тетрәтеп үткән чакларда.

Буйсындырды илләр, халыкларны,
Курыкмыйча керде орышка.
Тарих тәгәрмәчен борып булмый,
Кире боралмыйсың, тырышма!

Буйсындырган,
Кайчак җиңелгән дә,
Майлы калҗа гел-гел эләкми.
Барны бар дип язу гына дөрес,
Уйдырмалар фәндә кирәкми!

Шушы хакта сөйли таш кыялар,
Тузлар сөйли, тузлар бу хакта.
Борынгылар сүзе—
хакыйкатьнең үзе,
Язылган бит, кергән китапка.

Елкы ите пешкән учакларны
Җиз кылганнар һаман онытмый.
Ул учаклар күптән сүнгән инде,
Бүген көле аның җылытмый.

Мин татармын,
Рәсми кәгазьләрдә
Гомер бакый шулай теркимен.
Мин татармын,
Димәк, бер баласы,
Газиз балакае төркинең.

---

[1] Л.Н.Гумилевның мәхбүслектән котылуы күздә тотыла.

Атиллалар, Кубратлар белән
Җай чыкканда йөрим мактанып...
Их, җиләсе иде Римгә кадәр
Берәр дөл-дөл атка атланып.

Хыялланыр өчен туган кеше,
Алдашырга ләкин хакы юк.
Без күптәннән инде мокытландык,
Ә мокытның юньле аты юк.

## Чиркәү чаңы

### I

Даң-доң, даң-доң,
Суга чиркәү чаңы,
Тыныч кына тыңлап булмый аны.
Чиркәүләрсез нинди Рәсәй булсын
Һәм чиркәүсез булсын нинди даны?!

Тиккә түгел: һәрбер шәһәр белән
Чиркәү арты чиркәү калыкты да.
Чиркәү чаңы тәре походына
Рухландырды гади халыкны да.
Даң-доң!

Ил-дәүләтнең көче артсын өчен
Шәһәрләрне күбрәк төзү кирәк.
Шәһәр—кальга,
Шәһәрләрдә—чиркәү,—
Хөкемдарга алар һәрчак терәк.

Терәк булыр яулар чапканда да,
Кирәк булыр җиңеп кайтканда да,
Һөҗүмнәрне кире какканда да,
Базарында коллар сатканда да,
Кәеф-сафа корып ятканда да...

### II

Балкып тора чиркәү гөмбәзләре,
Яуга чыга чиру, кенәзләре.
Ымсындыра Казан, Кырым, Нугай,
Күчем ханда байлык чутсыз бугай.
Даң-доң!

Һәм башланды тәре походлары
(Сугышлардан Рәсәй бер туктармы?)—
Көне-төне чиркәү чаңнар какты,
Елгаларда, тулып, каннар акты.
Даң-доң!

Тәре йөрде кылыч белән бергә,
Күпме шәһид керде кара гүргә.
Исәннәрен чукындыру өчен,
Чиркәү басты яулап алган җирдә.
Даң-доң!

Фәхешләнеп бара бөтен дөнья,
Татарымның рухы сау булса да...
Чукындыру һаман дәвам итә,
Яулап алыр җире калмаса да...

Даң-доң!
И Илаһым, мәдәт бир!

## Каракош

Каракошлар таныш миңа
Ишетеп тә, күреп тә:
Сокландырганы һавада,
Шом салганы—гербта.

Гербта ул ике башлы,
Күз өстендә каш сыман.
Кемгәдер каш, миңа исә
Бәгырьдәге таш сыман...

## Дөреслек

Дөнья шундый: дөрес сүзгә кытлык,
Кем иренми—барсы алдаша.
Түрәләрнең биргән вәгъдәсендә
Пәйгамбәрләр хәтта адаша.
Ә күпчелек кыла тамаша,
Чын дөреслек саркый кан аша...

## Өзелмәгән өмет

Яшь чакларда затлы кием киялмәдек,
Ә шулай да дөл-дөлләрне иярләдек.
Ут чыгардык баскан җирләрдән,
Эш курыкты гаярь ирләрдән!

Кабатланмас яшьлек тантанасы,
Төпкә җикте күптән заманасы,—
Куаныргамы, әллә зарланасы?

Тынычландык, мисле алаша без,
Хөкүмәтне эчтән эттәй сүгеп,
Хатын белән тәмләп талашабыз.

Тик кайвакыт күңел алгысый да
Килә
гайре табигый бер эш эшлисе:
Яшен булып ук яшьнәүләр кая,
Һич югында
айгыр кебек бер кешнисе!

Димәк, базда дары бетмәгән,
Ком коелыр картлык җитмәгән...



Рауль
Мирхәйдәров

# ҖӘЯҮЛЕ ТАТАР

БӘЯН

## I бүлек

«Кайчандыр монда нинди матур сиреньнәр бар иде!»—дип уйлады Исламов. Ул, моңсуланып, кичке эңгердә караңгыланып калган бакчага күз ташлады. Шәп тактадан сугылган, кырыйлары буй-буй тимер белән читләнгән нык, биек койма янына якынрак килергә теләге булса да кире уйлады. «Нәрсә кирәк?»—дигән усал тавыш ишетелер, йә булмаса, тимер чылбырын зыңлатып, алагаем зур эт капкага ташланыр күк тоелды.

Ә шулай да бакчага күз саласы, соры күзле ябык кызчыкның тавышын ишетәсе килде. Аның сагыш белән: «Май аенда бигрәк иртә яктыра»,—дип әйтеп куйганын, үзенә генә мәгълүм нindидер сер өчен гаепле елмаеп, бите буйлап тәгәрәгән күз яшьләрен кайнар учы белән сыпырып төшергәнен күз алдына китерде. Бу ел фасылы аңа бер-бер күнелсез вакыйганы хәтерләтте булса кирәк, кыз, дулкынлануын сиздермәскә тырышып, читкә борылды. Аннары капыл гына: «Мин сиңа букет өзәм, сирень чәчәкләре мине исеңә төшереп торсын,—диде.—Бүген якшәмбе, без бик озак—көн буе күрешмәячәкбез, май аенда бик соң караңгылана бит...»,—дип тә өстәде.

Исламов бәхетле иде, шуңа кызның сәер сагышка бирелүен аңлап житкермәде....

Сөйкемле, ягымлы Натальяның юраганы юш килде. Сирень очраттымы, сагышлы елмаеп, ул күз алдына килеп баса. Тик шунысы кызганыч: Гаяз йөргән якларда бу чәчәкләр сирәк очрый, өстәвенә, әйләнеп карарга да өлгермисең, куак инде чәчәген коеп бетергән була.

Йорт, капка-койма өр-яңадан эшләнгән, иркен, унайлы, нindидер купшылык та бар. Күренеп тора: үзгәлек—архитектурасында, жирле халык алай төземи. Коймасын гына кара—әйләнә-тирәдә бар да буяулы, ә монда морилка өстеннән лак йөгертелгән. Матур, ел саен яңартып торуы да ансат.

Тик Гаязның башында: «Сирень һаман да үсә микән?..»—дигән сорау бөтерелде. Ай-һай, кайчандыр бакча тутырып, таралып үскән сирень нык куллы яңа хужага ошады микән?

Шакыргамы? Бәлки сорашыргадыр? Тик нәрсә турында? Ул Натальяның

---

Рауль МИРХӘЙДӘРОВ (1941)—*язучы; төрле телләрдә чыккан дистәләгән китап авторы. «Иртәләгән сагыш», «Кара аксөякләр» («Карга короле»), «Һәрнәрсәгә—акчалата» романнары, «Игълан буенча танышу» повесте, байтак хикәяләре «Казан утлары» журналы битләрендә дөнья күрде. Мәскәүдә яши.*

монда яшәмәвен белә. Ә кызның әти-әниләре мондый зур хуҗалыкны тоту яшеннән узган.

Хәтерендә: Натальяның әтисе—ул елларда бистәдә бердәнбер баянчы—туйлардан, бәйрәмнәрдән кайтып керми иде. Күңел ачу мәҗлесләрендә ул күзгә күренеп яшәрә, бөркеткә әверелә. Аның трофей аккордеоны халыкны җырлатты да, елатты да, ул башкарган көйләр Күлленең берничә буынын үстереп таратты.

Әйе, буыннар... Алар берсен-берсе алмаштыра... Күлледә хәзер Гаяз Исламовны хәтерләүче бар микән? Дус-ишләре күптән, ныгып та җитмәгән канатлары белән төрле якларга сибелделәр. Җитлегергә ашыккан күңелне җилкендерү өчен, гәҗиттә басылган бер юл житте—бар да зур төзелешләргә агылды. Ни заводы, ни фабрикасы булмаган Күлле һәр кешесен эшле итә алмады: шуңа алар киткән якларда тормыш бөтенләй үзгә, бистәнекенә охшамагандыр кебек тоелды.

Шулай итеп, тормыш аларны аерды, төрлесен төрле тарафка ташлады. Гаяз да кубесенең исемнәрен, йөзләрен онытты, хәтереннән җуйды...

Элегрәк, әле яшьрәк чагында, Гаяз, кайткач су буйларына төшә, танцыга бара иде. Кечерәк бистәләрдә, шәһәрдәге кебек, яшькә игътибар итү юк, паркта үтә торган танцы кичәләренә гаиләләләр дә яратып йөрделәр. Ә хәзер кырыкны узып барганда, Күлленең үзәк урамында, сине танып, очратуына куанучы юк. Куану дисең тагы, кайсы көнне «исәнме» сүзен дә ишетмисең.

Авыр сумка тоткан берәр тулы гәүдәле хатын, юлында очрап, күз ташласа, кич буе: «Кем иде соң ул?» дип газапланасың. Исенә төшерә калсаң: «Электәге шаян-шук җырчы кызга ни булган?!»—дип шаккатасың. Үзен дә яшьлегеңне онытмаган чуар таплы иске көзгегә күз саласың һәм күңелеңне күтәрмәкче булып: «Әле кояш баемаган»,—дигән буласың.

Борчылырга сәбәп юк сыман, әмма атна була инде—Гаязның күңелен сагыш кимерә. Әнисе дә сизенде, ахры, тик әлегә сүз катмады. Бәлки, улының сагышы якты икәнен чамалагандыр, анда, зур шәһәрдә, тыны кысыладыр, яшьлеген искә алырга вакыты да юктыр, әйдә, бер бушансын, дидер.

Көндәгечә әнисе аны капка төбендә каршы алды.

—Әни, Козыревларның сиреньнәрен хәтерлисеңме?—дип сорады Гаяз. Ул әле уйлары белән еракта калган теге май көнендә иде.

—Ничек инде хәтерләмим, улым, хәтерлим, билгеле. Игътибар итмәдеңмени, безнең ишегалдында да сирень үсә бит. Әти-әнисе вафат булганнан соң, Наталья иске өйләрен сатарга кайтты, шунда безгә берничә үсенте китерде, әгәр үсеп китсәләр, истәлегем булыр,—диде.

—Барысы да тамырландымы?—дип сорады Исламов.

—Әйе. Башкалар да үсентеләрне миннән алалар. Сорты белән кызыксынгач, баштарак шаяртып: «Наталья» дигән идем, ә хәзер куанып туялмыйм. Ник дигәндә, бездә башка сортлар төпләнә алмый.

—Димәк, Наталья үзе турында истәлек калдырган.—Әллә әйтте, әллә сорады Гаяз—аңлашылмады.

Әнисе җавап кайтармады, аның күз карашы карангыга—чәчәктә утырган сиреньнәр ягына төбәлгән иде. Ишегалдында корылган табын янында бик озак, күктә йолдызлар кабынганчы утырдылар, аннары Гаяз үз бүлмәсенә юнәлде.

Күлледә яшәүчеләрнең күпчелеге кебек, Исламовлар да өйләрен өрянадан торгыздылар. Соңгы егерме елда, һава шартлары уңай килгәнгә, күрше районнарны көнләштереп, аларда уңыш югары булды . Гаязның әтисе Нури абый исә районда гына түгел, өлкәдә танылган комбайнчы иде.Уныш иң мул елны, урак өстендә, аның портретын үзәктә чыга торган гәҗитнең

«Россия алдынгылары» рубрикасында бастырдылар. Ә көзен ВДНХга чакырып, исемле «Волга» белән бүләкләделәр. Дөрес, машина алар өчен әллә ни зур яналык булмады. Гаяз үзен-үзе белгәннән бирле, алар ишегалдында һәрвакыт нинди дә булса ватык—«Эмка» йә «Победа», кайчакларда трофей «Мерседес» торды. Әтисе тирә-юньдә билгеле механик булганга, хәтта шәһәрдән дә ярдәм һәм киңәш сорап киләләр иде. Күлленең бар техникасы диярлек әтисенең кулы аша узган. Кем белә: шуңа вакытында чәчелгәндер, урылгандыр, тирә-якта Күлле—уңышка бай як дип танылгандыр.

Гаяз үзе дә әтисе янында комбайнда эшләде, гаилә бюджетын калынайтуда аның да өлеше керде—бишенче класстан штурвал артында булды. Студент еллары еракта, Омскида үтте. Иптәшләре каникулда Казакъстанга, чирәм җирләргә киткәндә, ул туган ягына кайтты, чөнки комсомолның җирле райкомы кече Исламовны үзләренә билгеләүләрен үтенеп, институтка ел саен чакыру җибәрде. Укуын тәмамлаганнан соң, әтисе улын үз якларына кайтырга үгетләде. Оренбург төзүчеләрне колач җәеп каршы алса да, Гаяз, төрле сәбәпләр табып, әтисенең үтенечен кире какты. Аның яшендәгеләр өлкәннәр ышыгына түгел, ил-җир күрергә, үзләрен күрсәтергә дип ераккарак юл алдылар.

Ул әтисен ихтирам итте. Сугышның башыннан ахырына кадәр катнашып, рейхстаг стенасына үзенеке белән янәшә батырларча һәлак булган өч кече туганы өчен дә Исламовлар фамилиясен дүрт тапкыр сырлаган кеше бит ул Нури абый! Тыныч тормышта да өлкән Исламовның тырыш хезмәте орденнар белән бәяләнде. Партия сафларында тормаса да, күп еллар өлкә советына депутат булып сайлануы белән горурланды...

Исламовлар өендә хезмәт төбе хөрмәт икәнен белеп үстеләр, шунадыр Гаяз, мәктәптә укыганда ук, үз алдына беренче орденын утыз яшендә алырга дигән максат куйды.

—Кара син аңы, утыз яшендә орден, имеш,—дип көлемсерәде Гаяз, үткәннәрне искә төшереп.—Курсташлардан Силкинга гына насыйп булды ул.

Әнисе, бүлмәгә кереп, аның белән янәшә, диванга утырды.

—Комачауламадыммы, улым?

—Юк,әни, янымда утыр әле.

—Әтиеңне күмәргә кайткач, синең белән рәтләп сөйләшеп тә булмады. Берни хәтерләмим, ничек түзгәнмендер ул көннәрдә. Әмма йөрәгем синең өчен бик өзгәләнде: бик борчылган, алҗыган идең. Күрәсең, баштагы елларда Ташкентта синең хәлләрең ул чаклы шәптән булмагандыр.Син бит хатларыңны да туктаттың, шалтырату да, котлау телеграммалары белән генә чикләндең. Аллага шөкер, хәзер бар да башкача кебек. Әнә, кыз туганнарың, бигрәк тә безнең Күлле кыланчыгы—кечесе нәрсә ди: «Ниһаять, башкала безнең абыйны юнып шомартты, костюм-күлмәкләре инә-җептән чыккан кебек...»

Фәридә белән Халияр, син киткәч, бар кием-салымыңны таманлап карадылар. Аһ та уһ килделәр: «Фирма! Чын фирма!»—диештеләр. «Нәрсә соң ул фирма?»—дип сорыйм—көләләр генә. «Әни, син карт инде, барыбер аңламыйсың»,—диләр.—Менә безнең Гаяз, янәсе, бу өлкәдә белгеч, бар да искиткеч—иң югары дәрәҗәдә.Ә миңа барыбер: бармы ул фирма синдә, юкмы, иң мөһиме—таза-сау, шат күңелле бул. Шулай да балаларның синең турыда җылы итеп сөйләүләрен ишетү рәхәт. Хәзер бит,әнә, кешегә бәһа бирү үзгәрде, кайберәүләр белән санлашып та тормыйлар... Менә шулар турында әйтәсем килгән иде, улым. Рәхмәт, кайтуың белән сөендердең. Синнән, нәкъ әтиең кебек, әллә ни алып булмый, икегез дә аз сүзләр. Ярар, сине артык йөдәтмим. Теләсәң, үзең сөйләрсең, югыйсә, Ташкенттагы тормышың турында берни белмим». Әнисе, диваннан күтәрелеп, бау белән бәйләнгән төенчек алып килде: «Яна өйгә күчкәндә, синең барлык иске

кәгазьләренне, фотография, хатларынны жыеп куйдым. Теге вакытта, әтиенне жирләгәндә, алар турында уйларлык ара булмады; ал, кара, бәлки арасында кирәклеләре бардыр...

Әнисе чыгып киткәч, Гаяз күзе белән иркен бүлмәне айкап чыкты. Өй, уңайлы булсын дип, уйлап төзелгән: суның кайнары да, салкыны да агып тора, пар белән жылытыла. Жылыту системасы бик хәйләкәр—инженер була торып Гаяз да аңлап бетерә алмады. Әтисе, үзе әйтмешли, андый нәрсәләргә һәвәс иде. Йорт ике биеклектә төзелгән, Нури абыйга, нигезгә салу өчен, күршеләрен генә түгел, бар Күллене шаккатырырлык балчык ташырга туры килде. Өлкән Исламов, мыек астыннан гына көлеп: «Сабыр итегез, күрерсез, шәп өй булачак»,—дип йөрде. Ярты Европаны жәяүләп үткән Нури абый, крестьян һәм хужа буларак, тормыш-көнкүреш өчен ничек файдалы икәнен анлап, акыл белән эш итә белде. Шуңа күрә мөмкинлек туу белән, ашыкмыйча гына төзү эшләрен башлап жибәрде. Күршеләреннән аермалы буларак, Исламовларда гына шундый иркен, чиста ишегалды: анда авыл жиренә хас тыгызлап торган бернинди артык корылма—мунча, сарай ишеләрне күрмәссең. Барлык ярдәмче биналар бетонланган идән асты (анда Нури абый элекке гадәт буенча елгадан бер машина шакмаклап киселгән үтә күренмәле боз алып кайтып сала ) белән бергә йортның аскы нигрәсенә урнашкан иде. Бу кайтуында Гаяз йортны яңабаштан карап чыкты. Ике ел элек кайтканында өч кенә кич кунарга туры килде. Хәер, ул вакытта өй кайгысы идемени. Бар уе әтисе турында булды. Ул әтисен ярата иде, бары тик бөтенләйгә югалткач кына, соңгы вакытларда аның белән бик аз аралашканын анлап уфтанды. Кая инде аралашу—ул аннан ераклашканнан-ераклаша гына барды. Һәм хәзер өйгә таң калып ихлас күнеленнән соклану кичергәндә, кайсыдыр сенлесе уйлаганча, йорт Гаязны варис буларак та, бәясе-хакы ягыннан да кызыксындырмады. Юк, варислык турында уена да кертмәде, чөнки акылы һәм йөрәге белән шуны тойды: ул ата йорты өчен инде өзелгән кисәк, ул монда бернәрсәгә дә дәгъва кыла алмый. Сирәк-мирәк кенә кунакка, йә булмаса ял вакытларын әтисе махсус улы өчен тәрәзәләрен бакчага каратып салган бүлмәсендә үткәрәм дип кайтса гына инде.

Өйгә соклануы һәм аны яшермәве—әтисенә, аның зирәклегенә, ныклыгына, алтын кулларына соклануы икәнен, соңлап булса да аның белән аралашуын сенлесе каян анласын инде? Үзе турында түгел, инде нәселе, аннан соң нәрсә калачагы хакында уйлар яшькә житкәч, ул үзен әтисе һәм аның буыны белән чагыштырды. Һәм тирән ышаныч белән кабатлады: «Әйе, нык буын». Без, тыйнак кына акчага лаеклы ялга китүчеләр белән янәшә яшәүчеләр, бу турыда уйланырга, соңга калмыйча аларга тиешлесен бирергә бурычлыбыз.

Ир кеше агач утыртырга, өй салырга һәм ир малай үстерергә тиеш, диләр. Бу бик күп тә, аз да сыман: әтиләр буыны авыр сугыш елларын кичеп һәм жимерелгән илне аякка бастырып кына калмады—алар балаларын тәрбияләп кеше итте. Ә еллары соң нинди иде, Ходай күрсәтмәсен...

Нури абый улыннан башка өч кыз карап үстерде, барысын да аякка бастырды. Гаязны югары белемле итте, кызларын кияүгә бирде. Тик, ни кызганыч, бик теләсә дә улының туен гына күрә алмады.

Йортын да ул кемнедер көнләштерү уе, йә булмаса кешедән аерылып тору максаты белән түгел, бары тик Гаяз кайтыр да барыбыз бергә яшәрбез дип житкергән иде. Эшкә беренчеләрдән булып тотынучыларга һәрвакыт авыр—аның әтисенә дә төзелеш барышында күпме мыскылны ишетергә туры килде. «Ә менә хәзер,—ди әнисе,—кемдер төзергә тотынганчы, иң әүвәл безгә килә, карый, кайберләре хәтта планын да сызгалап ала...»

Колхозда да әтисеннән соң дипломлы механиклар берсе артыннан берсе алмашынып кына торды. Бар да: «Ә менә Исламов вакытында...»—дип, бик еш искә алалар. Әлбәттә, яхшы яктан искә алалар...Менә агачны гына алыйк...

Исламовларның бакчасы башкаларныкы кебек. Ә бит дала җиле исеп торган кырый җирдә бакча үстерү җинелләрдән түгел. Үз гомерендә Нури абый өч тапкыр курортка барды. Өчесендә дә Цхалтубога. Дөрес, өлкән Исламовка юлламаны сайлап алырга тәкъдим итүче дә булмады, Нури абый үзе дә вакчылланып маташмады: биш елга бер тапкыр ияләшкән курортка юл тотты. Ерак җирләрдән, һичшиксез, гаҗәеп искитмәле яна үсентеләр алып кайта иде. Кызганыч, тропик өлкәләрдә үсә торган назлы үсентеләрнең күбесе кырыс табигатьле Күлледә тамыр җәя алмадылар. Ләкин зәнгәр чыршы, барысының да тырышлыгы нәтиҗәседерме, сабый баланы карагандай тәрбияли торгач, яңа җирне үз итте—күтәрелде.

Әнә, әле дә Исламовлар ишегалдында, күрше балаларын сөендереп, Яңа елга чыршы-матурны бизәп куялар.

Үз тормышын әтисенеке белән күпме чагыштырмасын—Гаяз файдасына булып чыкмый. Ә бит вакыт таулар артында түгел, нәтиҗәләр ясар чак житкәч, «әле барысы да алда, өлгерермен» дигән коткару кагыйдәсе дә ярдәм итә алмас. Шунадырмы, соңгы араларда аны бик еш кына бер уй эзәрлекли: сонармадыммы?

Тыгыз Европада Исламовлар нәселе күмелгән, өсләрен төрле үлән каплаган каберләр вакыт үтү белән югалгандыр, йә сукалап ташлангандыр. Менә әтисе дә китеп барды инде, Исламовлардан син берүзең калдың! Кайда син салган йорт? Син утырткан чыршы? Әгәр әтисе исән булса, мөгаен, түзә алмас, сорар иде: ничек яшисең, улым? Ни өчен синдә үз ыруың өчен горурлану дигән нәрсә юк? Үзеңнән соң ни калдырасың? Сүз дә юк, без гасырлар буе нәсел-нәсәпләре өйрәнелгән граф та, кенәз дә, дворяннар да түгел, ләкин без сиңа гомер биргән, исем куйган, зиһеннән өлеш чыгарган. Гомер кешегә җирдә тормыш итәргә, нәсел-ыруыңны дәвам итү өчен бирелә. Әйе, әтисе сорар иде... Ә ни дип җавап бирергә?..

Ул кичтә Исламовны җанын кимерә торган әнә шундый уйлар чорнап алды, йокы эленгән күзләре йомылганда да: «Әти җирдә үз эзен, кешеләр күңелендә яхшы истәлекләр калдырырга өлгерде. Ә мин?»—дигән уй эзәрлекләде.

Иртән соң гына уянды, тик күңелне тырнап торган борчу һаман да үтмәде. Бакча ягындагы ачык тәрәзә янына килеп сөялде. Әле кояш бик югары күтәрелмәсә дә, күңелгә ятышлы иртәнге җиләслек юкка чыккан инде: эссе көн котелә, күрәсең. Өендә,Ташкентта, иртәнге күнегүләр урынына ул йөгерә иде. Ләкин монда, вакыты һәм теләге булуга карамастан, нигәдер кыймады... Иртән спорт костюмы киеп урам буйлап йөгергән өлкән кешене күреп, Күлле халкы: «Эшсезлектән маена чыдый алмый»,—дияр иде. Менә шул тоткарлады, ахрысы.

Такталардан корылган җәйге коену бүлмәсендә кичтән тутырып калдырылган бактан талгын су алып, Гаяз өстенә койды һәм, ниһаять, иртәдән биләгән тынгысызлык, июль аеның җиңел болытлары кебек таралып, юкка чыкты.

Ишегалдында аны самавыр көтеп тора, торбасы янында ятса да, күмере сүнмәгәнгә, ул әкрен генә гөжли иде әле. Гаяз бала чагында бу иске бакыр самавыр парында чиле-пешле итеп йомыркалар пешергәннәрен, аларны бик яратканын исенә төшерде, аның үзенә генә хас тәмен тойгандай булды.

—Хәерле иртә, улым. Иртәнге аш әзер. Кояш бүген бигрәк нык кыздыра, әйдә, өстәлне алмагач төбенә күчерик әле.

Иртәнге аш вакытында ул әнисеннән Халиярның кем булып эшләвен сорады. Әнисе, ниндидер килешмәгән эштән араланырга теләгәндәй, кулын селтәде:

—И-и, жакяй!

Гаяз җентекләбрәк сорашуның мәгънәсе юклыгын абайлады. Кече сеңлесенең ире ни белән шөгыльләнә—төшенеп җитмәде. Кем соң ул жакяй?

Ике кияүләре урыс булганга, өйдә татар теле белән урыс теле бер үк хокукта йөрсәләр дә, әнисе бу юлы, нигәдер, русчага күчте. Ул, тырыша-тырмаша, туган телендә бу сүзнең нәрсә аңлатканын исенә төшерергә маташты, әмма ни кызганыч, соңгы елларда онытыла бара икән шул ана теле.

Янгырашы буенча ул «кәҗә» сүзен хәтерләткән шикелле, тик әнисе нәкъ менә шул мәгънәне күздә тоткан дип ышана алмады.

«И-и, кәҗә!..» Нишлисең, заман таләпләреннән чыгып караганда, Халиярдан көтәргә бик мөмкин, охшаган аңа, охшаган. Тик әнисе ни әйтергә теләде соң? Татар телендә андый жаргон сүзләр юк, бигрәк тә гади авыл сөйләшендә. Ә бәлки заманга яраклашып ниндидер модага иярүдер? Гаяз астан гына әнисенә күз салды һәм инде менә ничә елга беренче мәртәбәдер рәхәтләнеп көлеп җибәрде. «Әх, кәҗә!..»

Озакламый сеңлесе килде. Капка төбендә почта тартмасыннан гәҗитләр алып торган Гаяз аннан:

—Фәридә, ирең Халияр кем булып эшли ?—дип сорады. Аны бу сорау шул тикле кызыксындырды ки, ул үзе сеңлесен эзләп барырга җыенган иде инде.

—Жокей!—дип җавап бирде ул, горурланып. Кыска буйлы ябык хатын бу мәлдә өлкән класс укучысына охшап калды, тик чәчләрендә купшы бантиклар гына җитешми иде.

—Нәрсә, сездә ипподром ачтылармыни?—дип гаҗәпләнде Гаяз.

—Фу!..—Җирәнгәндәй, матур йөзен чытып куйды сеңлесе. Әйтерсең пөхтә,чиста ирен күбеккә баткан ат өстендә күрде.—Юк инде, юк. Нинди ипподром? Ул—диск-жокей . Аңлыйсыңмы—диск-жокей. Фәридә, балкып, җилле һәм шул ук вакытта бик нәфис хәрәкәт белән кулын өскә күтәреп бер адым алга атлады. Ул яктырткычның көчле нурлары астында калган кебек тоелды. Аның «жакяе» үзенең чыгышын шулай башлап, шулай тәмамлый торгандыр, күрәсең.

—Йә Аллам, Күлледә сезгә дискотека гына җитми торгандыр. Акылдан шашу монда да килеп орынган икән.—Гаязның йөрәге кысылып куйды.

—Кара-кара, күпсенүче табылган!—дип ташланды аңа сеңлесе. Ул, күз ачып йомганчы, матур ерткыч кошка охшап калды, мөгаен, аннан начар актриса чыкмас иде.—Ташкентында—ресторан, бар, театрлар, ә безгә, димәк, ярамый!

Иртәнге аш вакытындагы кебек, Гаязның кычкырып көләсе килсә дә, барысын да йөрәгенә якын алган сеңлесенең кәефен бозмас өчен, шаяртып:

—Син хаклы,төнге клублардан башка ничек яшәр идем—белмим,—диде. Беркая барырга җыенмаган булса да урамга чыкты.

Ул өй түрендәге эсседән әлсерәгән аулак бакчалар буеннан бара һәм тавышсыз гына көлеп: «Әх, кәҗә, әх, жакяй...»—дип кабатлый иде.

Вакытны абайламый, шактый ерак китте. Алда, авыл читендә, урман полосасы тимер юлга таба йөгерә. Ул мәктәпкә кергән елны утыртылган полоса урманга әйләнгән. Дөрес, Россия һәм Белоруссиянең ерак почмакларындагы очсыз-кырыйсыз котырып үскән урманнар белән

чагыштырып булмый. Шулай да дала яклары өчен хәйран зур. Җанлыдан җанлы туа, диләр. Үсмер чагында, әле агачлар күтәрелеп кенә килгәндә, монда карга һәм чыпчыклардан гайре бернинди кош-корт, хайваннар юк иде. Күке тавышы да ишетелми иде бугай. Унынчы класста укыгандамы, кайсыдыр берсе керпе очратуы турында әйткәне хәтерендә, әмма аңа берәү дә ышанмаган иде.

Ә хәзер! Куян, төлке, бүре, бурсык, борындык, хәтта кабан һәм мөгезлеләр дә бар.Урманга аларны берәү дә җибәрмәгән, югыйсә. Менә сиңа табышмак, табигать могҗизасы.

Урман да эсседән әлсерәгән төсле. Юл буена калын стена булып баскан агачларның яфраклары иренеп кенә кыштырдап алгалый; бу яшел дивар иксез-чиксез казакъ далаларының кызу коры җиленнән ышыклап тора. Шундый тынлык, хәтта, кечкенә җиләс һаваны күтәп, кошларның чыр-чуы да тынып калган. Гаяз урман эченәрәк атлады һәм матур, чиста аланга килеп чыкты. Аның беркем таптарга өлгермәгән яшел үләне өстенә, спорт курткасын җәеп, җайлап кына утырды.

Ерактан, мөгаен, ике тукталыш чамасы бардыр, поезд тавышы ишетелде. Юк, бу якынлашып килә торган составның дөбердәве түгел, ә чиксез иркенлек һәм тынлыкта эреп югалучы гаҗәеп чиста, тигез кабатланган аваз шикелле. Мондый тавышны кешеләре таралышып урнашкан, очып барган составның алдында уннарча чакрымга сузылган бушлык булган, юл читендә комачау ясарлык гаять зур корылмалар төзелмәгән урыннарда гына ишетергә була.

Бу тавыш кечерәк авылларда яшәгән һәркемнең йөрәгенә килеп кагыла, ачык һәм яшерен хыял-өметләр кузгала, юлның якынлыгын тойган күңелләр аңлаешсыз, тынгысыз, әмма куанычлы үзгәрешләр көтә.

Зеңгелдәп торган урман тынлыгы, килгән һәм киткән поездларның тыгыз зур агачлык аша фильтрдан үткән кебек тигез, чиста тавышы Гаязны истәлекләргә этәрде...

Гамьсез балачак, кыюсыз һәм фәкыйрь студент еллары. Күлле кебек кечерәк урыннардан чыкканнарны бик озак—өченче курска кадәр диярлек, колхозчылар дип кенә йөрттеләр. Кайберәүләр бу сүзгә күралмаудан башлап үзләренә генә билгеле булган төсмерләрне туплаган санга сукмау мәгънәсен салсалар, икенчеләре исә, гадәт буенча, начар карашка ияреп кыландылар гына; тик ике очракта да күңелгә исkиткеч авыр булды. Әле дә хәтерендә: беренче курсны тәмамлап кайткач, ул, ничектер, оялуыннан кызарып, сүзләрне бора-бора, буталчык итеп бу турыда әтисенә сөйләде. Әтисе аны аңлады, игътибар белән улына карады, мыегын сыйпаштыргалап—ачулы һәм нәрсәдәндер канәгать булмаганда гел шулай итә иде,—тыныч кына җавап бирде:

—Бу очракта, улым, сиңа берәү дә ярдәм итә алмас. Егет кешегә, чын егеткә дию ем, беркем, беркайчан намусына тия торган сүз әйтмәс. Гади генә әйткәндә, сез әле беркем түгел...—Һәм бераз сүзсез торганнан соң искәртте:—Туган җир—шәһәрме ул, авылмы, кайсы милләттән булуың—тормышта үз урыныңны табарга комачау итми. Кеше бары тик үзен эше белән генә күрсәтә ала, шуннан чыгып аңа бәһа бирелә.

Нури абый инандырырлык итеп белем, укымышлылык турында сөйләде, кызганычка күрә, Гаяз боларын анык кына хәтерләмәде. Менә хәзер, үзенең яшеннән чыгып, әтисенең нигә улын укытырга, инженер итәргә теләвен аңларга тырышты. Ә ул чакта тырышып, армый-талмый эшләсә дә, шундый ишле гаиләне ( әби-бабасы да исән иде әле) туйдыру җинелләрдән булмагандыр. Ай-һай, ничек кенә бөтерелергә туры килмәде Нури абыйга! Автомобиль ремонтлау гына түгел, теләсә кайсы һөнәрне үзләштерерсең!

Инде әзер булышчыны—олы улын ерак Омскига биш елга озатканда, аны кешедән ким итмәс өчен кирәк-ярак белән тәэмин иткәндә, үз җилкәсенә тагын күпме йөк алды. Улын укырга җибәргәндә аны бөтенләйгә югалтасын аңлады микән ул? Ә бәлкем, белем эстәү сәяхәтен Мәккәгә хаҗ кылуга тиң күргәндер, аннан гомереңнең соңгы көннәренә кадәр яраклы булган «маңгайда аерым тамга» белән кайталар бит. Әллә аның чордашлары белеме һәм дипломы булмау сәбәпле исерек, тупас, эчкерле, ялкау, йә булмаса карьерага омтылгангамы, әтисе бары тик уку гына кешене кеше итә дигәнгә ышангандыр. Бәлкем, иле һәм халкы алдындагы җаваплылык хисен белем, мәгърифәт белән бәйләп карау аны шуңа этәргәндер?

Үзе дә сизмәстән, Гаязның уйлары бүтән эздән китте. Җаваплылык? Кем җаваплы? Укыганнармы? Аларны укытучылармы? Безнең рәхәт яшәвебез өчен белгечләр барлаучы, билгеләүчеләрме? Уйлар чәчелде, аның вак кисәкчекләре тагын да ваныкчеле, сызлата торган иде—болары инде Гаязның күңел тынычлыгын алды. Менә диск-жокей Халияр—дипломлы агроном, белгечлеге буенча бер ел да эшләмәгән. Аннан соң Фәридә сеңлесе—югары белемле юрист, шулай ук гадел хөкем алласы Фемидага бер көн хезмәт итмәгән. Район башкарма комитетының сәркатип кәнәфие аның өчен заманча һәм җайлырак тоелган. Бу исемлекне, таныш-белеш, дус-иптәшләр, күршеләрне санамыйча, якын туганнардан гына төзесәң дә очы-кырые күренмәс иде. Торган җире Ташкентта республиканың нииндер зур Госплан начальнигында сәркатип булып эшләгән таныш кызы бар иде. Берничә тапкыр танышы һәм аның иптәш кызлары белән Госпланның шәп ашханәсендә төгам җыярга туры килде. Мондагы чисталык: өстәлләрдә ап-ак эскәтерләр һәм көз явын алырлык тере чәчәкләрдән букетлар—сөйләп бетергесез. Төрледән-төрле, бик тәмле ашамлыклар өчен генә түгел, үзара аралашуның искиткеч булуы белән истә калды ул төшке ашлар. Гаяз—бердәнбер ир-ат—танышының яшь көяз дус хатын-кызлары белән бер компаниядә тукланды. Алар үзара бик күңелле утырдылар: шаярыштылар, акыллы һәм житди нәрсәләр турында сөйләштеләр, уй-фикерләре нәзберек, әмма алар нәзакәтлелек һәм уен-көлкедән дә мәхрүм түгелләр иде. Кызганнан-кыза барган әңгәмәләр учагына теләсә нинди теманы ыргыт, уты кимемәс, хәтта ялкыны дертләп тә куймас; менә шул дәрәҗәдә барын да аңлый, фикерле иде күз явын алырлык әңгәмәдәшләр.

Ничектер, берара танышына аның дусларына карата соклануын белгерткән иде Гаяз: кара, янәсе, гади генә сәркатипләр, ә үзләрендә нинди акыл, укымышлылык, тирән белем, кызыксынучанлык һ.б. Тегесе тәкәбберләнми һәм чытлыкланмый гына әйтеп салды:

—Рәнҗетәсең, Исламов. Минем иптәш кызларым бар да югары белемле, кайберләре ике дипломга ия, кайсылары аспирантурада укый, чит телләрдә сөйләшә.

Исламовка әллә кызның ачыктан-ачык үз-үзеннән канәгать булуы ошамадымы, әллә инде үзенең сөмсере коелган вакыты туры килдеме, кинәт кызып китте:

—Ә миңа калса, югары белемле кешегә—әле ике диплом белән— сәркатип булу—юл куймаслык хәл. Сезнең хезмәтегезне аз гына да кечерәйтергә, түбәнсетергә теләмим. Әмма сәркатипләр өчен бер айлык курслар җитә дип уйлыйм. Госплан кебек зур оешмада, югары белемле кадрларның ни өчен әзерләнүен белә торып та, аларны сәркатип, машинисткалар итеп тоту—әдәпсезлек кенә түгел, җинаять дип саныйм.

Шуның белән Исламов өчен күңелле төшке ашлар бетте. Бары тик күпмедер вакыттан соң гына, ул дипломга ия кызларның, ашкынып, «мөмкинлекләре зур булган» җитәкчеләргә сәркатип булып баруларына

төшенде. Әйе, хезмәт хакы күпмедер, Алла белсен, тик сүз уңаенда, яңа гына эшли башлаган укытучы яисә инженерныкыннан калышмыйдыр, ә мөмкинлекләре зур, әлбәттә. Һич югында, шәп кабинет, беренче дәрәҗәдәге ашханә, тораклы булу өмете, сәүдә белән элемтә, тагынниләрдер...

Бу мәсьәлә Гаязны бик борчыды, түзә алмады—сикереп торды да алан тирәли йөгереп килде. Гаязны күптәннән күзәтеп торган җирән тиенкәй, үртәгәндәй, аның хәрәкәтләрен кабатлады; тик үз уена баткан Исламов кына аны шәйләмәде.

Чираттагы ялына җыенганда, Гаязның бердәнбер теләге—онытылырга иде. Һәрхәлдә, бу сорау аны монда да эзәрлекләр дип һич башына китермәде. Кирәк бит... Хәзер ул аның үзенә генә түгел, бәлки туганнарына, кияү-кызларга да кагыла иде. Юк, өлкән абыйлары буларак, Халиярга да, Фәридәгә дә акыл сатарга, вөҗданнарында казынып, мисаллар китерергә уйламады—барыбер аңламаслар иде. Гаяз үзләренең «төрле телләрдә сөйләшүләр»енә төшенде инде. Һәм күптән нәтиҗә ясады: күпләр белемне һөнәрле булу, алдагы тормышларына максат кую өчен түгел, ә дәрәҗә, үз-үзен сөю, эти-әниләрнең, балаларның дан-шөһрәт яратуы аркасында ала дип аңларга кирәк икән. Кемнеңдер Халияр белән Фәридәне җәлләп, биш ел институтта укып, үз белгечлекләре буенча эшли алмыйлар дип борчылуына алар бары тик гаҗәпләнер генә иде. Алар фикеренчә, иң мөһиме—дипломнары бар. Дипломлы булу өчен кайда, кем булырга укысаң да ярый. «Медицина, журналистика, консерваториягә ыргылуларын әле ниндидер тышкы сөйкемлелеккә, омтылышка, табигый сәләткә бәйләп, гәрчә бу ялган булса да, аңлатырга була,—дип уйлады Гаяз.—Ә менә «Сууткәргеч һәм канализация» факультетында укучыларның алтмыш проценты тышкы кыяфәтләре белән Софи Лоренның яшь чагыннан аз гына калышмаган чибәр, сылу кызлар булуына ышануы кыен: хыяллары шушымы, ә тормышта аларны канализациядә эш көтә бит!

Кайчакта Гаяз әтисеннән көнләшеп тә куя: депутат буларак, аның трибунадан сөйләү мөмкинлеге булды, җае чыккан саен, ул моннан файдаланды. Кайвакыт, тирән уйланулардан соң, ачыктан-ачык, һәркемгә ишетелерлек итеп, Гаязның да проблемаларны трибунадан игълан итәсе бик килә. Нәрсә турында әйтер иде ул? Нәрсә турында сорар иде? Мөгаен, шул ук Госпланга, кайбер таксопарклардагы эшчеләрнең өчтән бере нигә югары белемле, дигән сорауны куяр иде. Ә сәүдә, хезмәт күрсәтү өлкәсе, гомумтуклану—боларда андыйлар ничә процент?

Югыйсә, кемдер белергә тиеш: кайларда алар—югары белемлеләрнең искиткеч зур армиясе, ел саен кая китеп олагалар алар—югары уку йортларын тәмамлаучылар?! Ә бит алалар, һаман кабул итәләр. Әле тагын шуны сорар иде: безгә елның-елында шулкадәрле тел белгечләре, журналистлар, музыкантлар, театр-сәнгать белгечләре кирәк микән? Тагын бернечә «нигә?»не яшьләргә һөнәри-техник белем бирүче Комитетка бирер иде. Билгеле, яшьләрне ГПТУларга чакырып, зур эш эшлиләр, әмма аларның бурычлары институтларга абитуриентлар әзерләү булмаса да, иң беренче итеп, бездән югары уку йортларына туп-туры юл, дип игълан итәләр. Менә шуңа да кичәге «өчле капчыклары», мәктәптән соң берәр ел ГПТУларны «урап», мәрхәмәтле агайлардан тиешле аттестатны алу мөмкинлегенә тиз төшенеп алдылар. Ә аннары инде эшче класс исеменнән бик кыю гына җаннары теләгән уку йортларының ишекләрен каерып ачып керделәр һәм тагын биш ел буе, үзләрен станок артыннан, йә булмаса мартен миче яныннан килгән эшчеләр дип, күкрәкләрен кагып, «койрыкларыннан» котылу өчен сессиядән—сессиягә кабат имтихан бирергә рөхсәт ала-ала, дипломга кадәр сөйрәлделәр. Ул, мөгаен, тагын

бернәрсәне искәртер иде: бездә белем алу бушлай, ләкин моны укучыларның шәхси эшләре дип карамаска кирәк, чөнки акча бит дәүләтнең уртак кассасыннан чыга һәм җәмгыять акча нәрсәгә «салынган»ын белергә тиеш: капризлы теләк өченме, әллә нииндидер исәп белән тотыламы? Тик эш акчада гынамы икән? Бүтәнен санарга да вакыт: буйга җиткән кеше биш ел буе эшчәнлек өлкәсеннән читләштерелә, биш ел буена аны җәмгыять, сарыф ителгәнне йөзләтә кайтарыр, дип ашата. Ә ул институттан туры диск-жокей, сәркатип, официант йә таксистлыкка китсә? Сүз дә юк, бик әйбәт һәм кирәкле һөнәрләр, тик болар өчен халык хисабына биш ел буе дәүләт җилкәсендә югары белем алу кирәкме соң? Кайчан диген тагын: бар коймалар «чакырабыз», «чакырабыз», «чакырабыз» дигән язулар белән чуарланган чакта бит...

Трибунадан ул сораулар биреп кенә калмас, ә соңгы елларда ничек итеп инженерлык һөнәренең югала, дәрәҗәсе төшә баруы турында да сөйләр иде. Мисалны шәхси тәҗрибәсе, үз язмышыннан китерү дә җитә...

Юк, урман Исламовка тынычлык индермәде: ял итә, хәл җыя алмады. Киресенчә, тагын да ярсып, җитмәсә, тиенкәйне дә куркытып, шпаллар буйлап кире Күллегә атлады.

Бистәгә җитәрәк, Гаяз соңгы елларда бу хәлләрнең районлагы бик күп комбайнчыларга остаз булган әтисен дә борчыганын исенә төшерде. Бервакыт авыл хуҗалыгы алдынгылары делегациясе составында Нури абый чит илдә булган иде. Анда аларга төрледән-төрле фермалар, сөт комплекслары, катнаш азык заводлары, тавык фермалары күрсәткәннәр. Нигәдер пыяла заводына да алып барганнар. Тыштан әллә ни искитәрлек күренмәгән бу предприятие кул сузымында булгангамы, әллә бик билгеле эшләнмәләр чыгаргангамы—анысын аңлап җиткермәгәннәр. Аларны якты, чиста, тулысынча автоматлаштырылган цехлар буйлап йөрткәндә, бер нәрсәгә игътибар иткәннәр: эшләүчеләр бик аз, һәркайда конвейер системасы, әзер эшләнмәләр әкрен генә чеңләп складларга агылалар. Соңыннан пыяла өрүчеләр янында да булганнар. Менә бу эштә инде вакыт һәм автоматлаштыру әллә ни үзгәреш кертә алмый; монда заводны бар дөньяга таныткан продукция җитештерелә. Тыштан ялтырау, үтә чисталык булмаган анда һәм кирәкмәгән дә.

Әлбәттә, Нури абыйның тылсымчы пыяла өрүчеләр турында ишеткәне булган, ә инде аларны үз күзләренң белән күрү... Мастерларны күзәтеп кенә өлгер: күз ачып йомганчы әкәмәт шарлар, вазалар хасил була, авызыңны гына ачып калма—агып торган сыек пыяла бер мизгелдә салават күпередәй катып та китә. Фокус күрсәтүчеләр, мең дә бер кичә әкияте!

Һәр мастер янында укучысы һәм ярдәмчесе. Алардан башка теләсә кайсы оста-виртоузның эшен күз алдына китереп булмый. Делегатларга аңлатканнар: бу мастер ярдәмчеләренә 14-15 яшь икән. Цехта эссе, корым, сөрем, күлмәкләре тишкәләнгән малайлар арыган күренәләр. Делегация составында үзләрен бик җитди тоткан берничә хатын-кыз булган. Алар бу колхозчылар төркеменә ничек килеп эләккәндер, һич кенә дә авыл хуҗалыгы алдынгыларына охшамаган була алар. Менә шулар Нури абыйның күңелен кайтарган. Бу хатын-кызларны ни пыяла, ни пыяла өрүчеләрнең виртоуз осталыклары кызыксындырмаган—аларны бары тик бер нәрсә борчыган: ничек кенә үзләренең ачык төстәге пальтоларын буямаска! Билгеле инде, танышу тәмамланып фикер алышканда, алар берни әйтә алмаган.

—Бичара балалар, мескен балалар. Карагыз әле, нинди пычрак алар, арыганнар...—дип такмаклаган берсе. Икенчесе аңа кушылган:

—Ә пыяла кайнар, пешәргә дә мөмкин.

—Аллага шөкер, бездә мондый нәрсәләр юк. Хезмәт буенча законнар

каты. Унсигез яшь тулганчы андый цехларның бусагасыннан да атлатмыйлар,—дип тәмамлап куйган беренчесе, зур горурлык белән. Нури абый исә аны бүлдергән:

—Мин бернинди куркыныч хәл күрмим. Шушы яшьтә дә өйрәнмәгәч, кайчан тотынырга соң? Үндүрттә берәр мәртәбә артыгын бөгелү гөнаһ түгел. Өлкәннәргә хезмәт күрсәтүнең, белмәгәнне кайтарып сорауның гарьлеге, ояты юк—әле ул яшьтә горурлык комачауламый. Мондый мәктәпнең бәһасе искиткеч, көт тә тор: 5—6 елдан менә дигән мастер чыга алардан, барысын да белә, эшли, күмер кисәген дә яндыра, әзер эшләнмәләрне дә төрәчәкләр. Сүздә түгел, ә эштә үзләштерергә туры килә. Карагыз, аларның мастерлары ничек яшьләр—күбесенә әле утызга бик ерак. Ә эшләре—карап туйгысыз.

Эшкә никадәр иртә өйрәтә башлыйсың, шулкадәр яхшы. Ә без үзебезнекеләрне унсигезгә кадәр төрле күрсәтмә-фәрманнар ярдәмендә кайгыртабыз, алар исә укучы булып йөрүләреннән тарсыналар—тагын бер-ике елдан гаилә корып җибәргәннәре дә күп бит. Шуңа да кыска вакытлы укулар белән чикләнәбез, ә аннары инде тамаклар карлыкканчы бәхәсләшәбез: нишләп безнең җитештерелгән әйберләрнең сыйфаты начар, имеш.

—Юк, юк, сез хаклы түгел,—дип ташланган аңа хатын-кызлар.—Сез урта гомумбелем бирү сәясәтен бөтенләй аңламыйсыз. Менә сез—депутат, значоклы кеше булсагыз да, бездә балаларның аерым хокукка ия булулары турында берни белмисез!

—Болар бар да коры сүзләр генә,—дип кызып киткән Нури абый.— Сезнеңчә, картлыкны кайсы төркемгә кертергә алайса, ни кызганыч, балачакта да бернинди аерым өстенлеккә ия була алмаган картлыкны? Балачак—озын-озак чак, сүз дә юк, ул истә калырлык үтәргә тиеш, тик безнең бурычыбыз—пионер белән үндүрт яшьлек комсомол арасындагы аерманы күрә белү.

Бәхәс кунак йортына кайткач та дәвам иткән һәм Нури абыйның кызыклы, файдалы сәфәреннән алган тәэссирләрен бозып ташлаган.

...Иртәгесен—шимбә көнне мунча яктылар. Мәшәкате күп булганга, җәй көне сирәк ягалар: елга кул сузымында гына, күрше урамда казна мунчасы, һәркемнең ишегалдында җәйге коену җайланмалары. Инде яңа мунчада берничә тапкыр чабынганы булса да, Гаяз кайту хөрмәтенә ягу сылтавы белән балаларының барысын бергә—бер өстәл артында күрәсе килде әнисенең. Кызлары Гөлфия белән Әлфия бистәнең ике ягында аерым көн күрәләр. Әтиләре исән чакта ук мунча көнне барысы бергә җыелу гадәте кергән иде.Ул көнне әнисе итле-дөгеле бәлеш пешерү өчен камыр куя, ә әтисе боз салынган баздан салкын кымыз алып менә.

Мунча ягарга олы кияү—Гөлфиянең ире килде. Алексей—озын буйлы яшь кенә ир-егет әтисе белән колхоз мастерскоенда бергә эшләгән иде. Халияр өйдә иде ( Гаяз аннан файда юклыгын аңлап алган иде инде), әнисе аны кибеткә кирәк-ярак алырга җибәрде, кайткач, ишегалдын җыештырырга кушты.

Кияүләре сүзгә хирыс түгел. Мөгаен, ул мунчаны Нури абый белән бер генә якмагандыр, бу эшне ашыкмыйча, җиренә җиткереп, үзенә генә билгеле тәртиптә башкарды. Гаяз монарчы әтисе башкара торган гадәти, җиңел мәшәкатьләрдә аңа бик теләп булышты.

Алексей аңлатуынча, мунча үзара бер-берсенә туры килми кебек тоелган берничә системаны берләштерә: урысныкын, соңгы елларда модага кергән финнныкын һәм японныкын. Ул чабына торган бүлмәгә куелган калын стеналы мичкәне күрсәтеп көлемсерәде.

Кияү Гаязга каенатасы гадәткә керткән юыну тәртибен аңлатты. Беренче булып әзер мунчага хатын-кызлар бара, аннары ир-атлар. Алары өстәл әзер булганчы чабыналар. Пилмән һәм бөккәннәрне Нури абый кайнар килеш ярата иде. Ә аннары чәй эчү башлана—йолдызлар калыкканчы, төн уртасы җиткәнче.

Хатын-кызлар балаларын алып, көлә-шаяра, мунчага киткәндә, әниләре йоклар алдыннан гына керәсен әйтеп, никтер, алар белән бергә барудан баш тартты. Моңа аптырамадылар: чөнки Исламовларның мунчалары җылысын бик озак саклый. Кияүләре Федор: «Их, сыра булсын иде...»—диюгә, барысы берьюлы нигәдер Халиярга карап куйдылар.—Әһә, сыра табу—Халияр эше икән,—дип ачыклады Гаяз.

—Сыра заводына шактый ерак, велосипед белән сәгатьтән артык барасы, минем дә мунчада парланасым килә,—диде Халияр, каенанасына карап.

Әниләре дәшми генә өйгә кереп китте дә озакламый гараж һәм машина ачкычлары алып чыкты. Халияр аңа таба омтылды. Җир астына кертеп ясалган гараждан әкрен генә әтиләренә ВДНХда тапшырылган теге ак «Волга» килеп чыкты. Гаязның аны беренче тапкыр күрүе иде әле. Федор түзә алмады: «Искитмәле...»—дип куйды. Ул Гаязның моңарчы машинаны күрмәгәнен белә: кайтканына атна булса да, ул бер тапкыр да аның белән кызыксынмады, сорашмады: елгага велосипедта бара, ә Күлле буйлап җәяү генә тәпили иде.

—Кайнатай безне—кияүләрен машинасына утырта иде дә җилдәй җитез итеп, кая да булса—елгагамы, урмангамы алып бара иде. Ә хәзер син, Гаяз, иң өлкәнебез буларак, безне Күлле буйлап бер җилдереп кайт әле. Машинаның күптән урам күргәне юк, алайсам кайберәүләр, әнә, Исламовның машинасын кияүләре сатып, акчасын эчеп бетергәнннәр, дип сөйлиләр икән. Без дә әти исән вакыттагы күңелле чакларны искә төшерербез,—дип, Алексей Федор белән Гаязны машина янына чакырды. Халияр теләр-теләмәс кенә руль артыннан торды да ачкычларны сузды.

Федор белән Алексей артка урнаштылар. Халияр исә, машинаны әйләнеп чыгып, Гаяз янәшәсенә утырды һәм, бүртенеп:

—Мин сиңа юлны күрсәтермен,—диде.

—Таптың күрсәтер кеше,—дигән көлү катыш тавышы ишетелде Федорның.

Гаяз машинаны кабызды да салмак кына кузгалып китте. Әнисе капканы ачты һәм пыяласы яртылаш төшерелгән тәрәзәдән күренгән Алексейга кул болгады.

Ни өчендер Гаязның башына: «Алексей, мөгаен, әтинең яраткан кияве булгандыр»,—дигән уй килде һәм, борылып, аңа елмайды.

Халияр заводта озак тоткарланды. Гаяз инде, ала алыр микән—җәй, җитмәсә, бүген шимбә, дип икеләнә башлаган иде.

Әмма Алексей, каенатасына охшатып, мыек астыннан гына елмайды:

—Безнең Күлледә Халияр танылган кеше—диск-жокей, аның күпчелек биючеләре сыра заводында эшлиләр,—диде.—Шуның өстенә Фәридә район башкарма комитеты аша сыра бары—кечкенә генә ресторан ачмакчы була, мөдире, шәт, Халияр буласыдыр. Шуңа ул мондагылар өчен күптән үз кеше.

—Менә сиңа агроном...—Гаяз авызын ачарга да өлгермәде, капкада, кош тоткандай куанып,тартмасы белән сыра күтәргән канәгать чырайлы Халияр күренде.

Әти машинасындагы кыска гына сәяхәт Гаязны кияүләр белән якынлаштырды да куйды.

Шулай да иртәгесен бик күңелле утырылган пилмәнле-бәлешле мунча

арты мәжлесен искә алганда, Гаяз кыз туганнары тарафыннан ниндидер киеренкелекне сизми калмады. Әниләре менә-менә кабынырга торган талашны, әнгәмәне бик оста гына итеп икенче юнәлешкә—уен-көлкегә борып, туктатып кала алды. Гаязнын гаиләсе белән бәйләнеше күптән өзелгән, шуна әнисенен тел төбен тәгаен анлап бетермәсә дә, хәлләр ал да гөл түгел иде—ул моны сизде. Сенелләрен анлый алмады. Кызларның артык шау-шусыз балачакларын хәтереннән үткәрде—ул вакытта, яшь аермалары шактый булганга, алар өчен олы абыйлары булды. Мөселман гаиләләрендә өлкәннәр ихтирамга лаек, тик Исламовлар гаиләсендә—үз кагыйдәләре: аларда нәселне дәвам итүче ир-ат, туйдыручыны олылау өстенлек итә. Дөрес, сенелләре һәрдаим абыйлары күз унында булмады, чөнки ул каникулларда гына кайта алды, әйдә кызлар хужа иде. Анын исеме, бигрәк тә студентлык елларында, еш искә алынса да, читтәге абыйлары ничектер хыялда гына яши иде шикелле, шунадырмы, алар өчен ул хокуксыз зат кебек саналды.

Кайсыдыр минутларда һичбер кинаясыз, мангаена бәреп, анардан: нәрсәгә кайттын? нәрсә кирәк сина? фамилияннән башка Исламовлардан нәрсә калды синдә? дип сорарга җыеналар кебек тоелды. Кем белә: бәлки сораулары тагын да кырысрак янгырар иде.

Әмма башына килгән андый уй-фикерләрдән ана ничектер оят булып китте: «Ничек шулай үземнең кан-кардәшләремнән шикләнә алам?»—дип, уйларын тиз-тиз читкә куды.

«Мин—арыган, йончыган, гомер юлында буталып калган бер шәһәр кешесе—туган йортыма ял итәргә, хәл җыярга кайттым. Әллә нәрсә табуым, нәрсәне югалтуымны анларгадыр? Бәлки ары таба ничек яшәргә дигән сорауга җавап эзләвемдер? Мина бит инде кырык яшь, ә мин ни агач утыртырга, ни өй салырга, ни ул үстерергә өлгермәдем. Монда кайтып үземне, кардәш-ыруымны барлармын, анлармын дип уйладым. Мин ниндидер нәсел-нәсәпсез, ботак-тармаксыз агач, йә булмаса өермә үләне түгел—тамырларым монда, Аллага шөкер, әлегә кипмәгән. Күлле дигән авыл, әйдә, дингездә бер тамчы булсын, барлык картадан да эзләп табып булмасын, ди—ләкин монда да кешеләр яши һәм алар минем Нури Исламов улы икәнлегемне беләләр һәм юкка гына бу җирдә басып йөрмәвемне анлыйлардыр, мөгаен».

Үзенең кыз туганнарына Гаязның шуларны житкерәсе килде, тик берсе дә кешечә сорашасы итмәде, мәкерле, астыртын сораулар, киная-ишарәләр, сүзләргә төреп кадап-чәнчеп алулар...—ничек телисен, шулай анла. Әнисе кызларының ымнарындагы астыртын явызлыкны сизә, тик аларга акыл сатарга кыймый, шуна да ике арада бәргәләнә: картлык көннәрендә кызлары белән яшисе; һич көтмәгәндә—ә бәлки киресенчәдер—ата-ана йорты бусагасын атлаган улын да читкә тибәрәсе килми иде.

Әтиләре исән булсамы! Аһ, ничек сонлап әйтәбез шул без бу шулкадәрле изге җөмләне! Беркемгә беркая, бигрәк тә үз-үзеннән качасы юк—сонга калып төшенәбез шул.

Төнгелеккә ни сәбәпледер гаражга куелмый калдырылган машина янында бик озак уйланып торды ул. Аны ачык террасадан күзәтеп торган Фәридә, өйдәгеләргә дә ишетелерлек итеп:

—Нәрсә, кадерле абыем, машинага сокланып туялмыйсынмы? Федя дөрес әйтә: искитмәле, туганыннан да сөйкемлерәк. Ә ир-ат йөрәге өчен—күп тонналы магнит кебек, үзенә тартып тора, әйдә, яшермә, рәхәтләнеп куан, болай да озак түзден...—дип, ашыга-төртелә тезеп китте.

«Волга» янында басып торганга карап, Гаяз машинага күз дә салмады—уйлары еракта, үзе турында иде. Шунадырмы, ул сенлесенең ни әйтергә

теләвен башта аңлап житкермәде, әмма күзе балкып торган бамперга төшкәч, кинәт айнып киткәндәй булды.

Сеңелләренең кичә әйтеп житкермәгәннәре чылбырга бикләнде. Ул аларның борчылу, ыгы-зыгыларын, ниһаять, аңлап алды: кызлар Гаязны әтиләренең мирасын бүлешергә кайткан, шул исәптән, машинаны да үзенә алыр дип уйлыйлар иде. Шуңа ачулары кабара: алар «Волга» инде «тү-тү» дип белеп, үз-үзләренә урын таба алмыйлар, бертуган абыйларын теләсә нәрсәдә гаепләргә әзер иделәр...

Анын башына килгән беренче уй: «Аллага шөкер, ярый әле бу хәлләрне әти үзе белми»,—булды. Бу фикер аны айнытып жибәрде, сеңелләренең этлекләренә үзләре кебек үк жавап кайтарырлык көч бирде. Төкерә ул машинага! Хәтта ике «Волга» да аңа бәхет китерә алмый: аны хәзер бөтенләй бүтән нәрсә борчый, ә алар моны аңларга теләми. Әтисе исән булсамы... Ул, һичшиксез, аңлар иде...

«Сезгә «Волга» тынычлык бирми, алайсам...» Анын башында бәйләнчек уйлар буталды, әмма килеп чыккан каршылыкны шунда ук чишәрлек юньле фикер тумады. Нишләргә? Ишегалдында юаныргамы, әллә анын артыннан калмый бүлмәдән бүлмәгә күзәтеп йөргән сеңелләре белән бер табын артына иртәнге ашка утырыргамы? Янәдән аларның астыртынлык салынган фикерләрен, үпкә-шелтәләрен тыңларга анын сабырлыгы житмәс, ул үзенең ычкынып китүеннән, тупас сүзләр әйтеп ташлавыннан курыкты. Һәм бу талаш-кычкырыш (бигрәк тә анын аңына барып житмәслек яшерен, акылга сыймаслык планнар корган сеңелкәшләренә кирәк икәнен төшенгән иде инде) әтисе теге дөньяга күчкәннән соң болай да шактый бетерешкән әнисен борчуга салачак. Юк, Гаяз моңа юл куймас. Анын аңлавынча, сеңелләре бүген китәргә жыенмыйлар иде, ахры. Кинәт Гаязның башында мәшәкатьләрне чишәрлек булмаса да, тегеләрдән көне буена аерылып тора алырлык фикер туды.

Тиз генә үз бүлмәсенә үтте, ашыга-кабалана юл сумкасына ниндидер кирәкле әйберләрен ташлады да кабат машина янына юнәлде.

«Оренбургка барып кайтыйм әле, бераз күңел ачыйм, шунда бер очтан нишләргә икәнен дә хәл итәрмен.» Ул, беркемне дә кисәтеп тормыйча, юлга кузгалды. »Машинага утырып кая югалды дип, баш ватсыннар әле»,—дип уйлады ул һәм бу интектергеч иртәдә беренче мәртәбә үзалдына елмаеп куйды...

Ташкентта анын белән бер подъездда бик аралашучан, гадел, кунакчыл судья яши иде. Үзенең бар буш вакытын ишегалдында үткәрә һәм анын тырышлыгы аркасында йорт каршылары яшеллеккә бай, һәрвакыт каралган булды. Ташкент өчен бу гажәп хәл булмаса да, башка йортлардан үзенчәлекле булып, аерылып торды. Йөзем куаклары күләгәсенә поскан өстәлләр янында вакыт-вакыт туйлар, бәйрәмнәр гөрләде. Һәр теләгән кеше ачык һавада пылау яисә башка тәгам әзерләргә ниятләсә, рәхим итсен—өч казан асылган учак әзер иде. Бу инде сиңа газ плитәсендә пешерелгән ризык кына түгел! Боларның барысы да—аларның йорт комитеты рәисе Закиржан әкәнең бетмәс-төкәнмәс көче, тырышлыгы нәтижәсе булды. Гаяз монда әзергә-бәзер күчеп килде, шуңа күрә баштарак бу ялт итеп торган ишегалдының уңайлыкларыннан файдаланырга кыенсынды. Көннәрдән бер көнне Закиржан әкә Гаязны балконда күреп, аны чәй янына чакырды. Менә шул көннән ул судья белән дуслашты. Ә бер якшәмбедә, һичкемне кисәтеп тормастан, вакытлыча корылган мичне сүтеп, янадан салды, казаннар санын дүрткә житкерде, аларны төрле төстәге кафель белән тышлады. Менә шуннан бирле аны Закиржан әкәнең уң кулы, ярдәмчесе дип саный башлаулары күнелен күтәреп жибәрде. Ишегалдында эш күп,

гомуми ихтыяжлардан чыгып, Гаязга судья белән бик еш аралашырга туры килде. Кайчакларда Закирҗан әкә эшеннән кәефе кырылып кайта. Шәрык кешеләренә хас юллы ефәк пижамасын киеп, гадәтенчә, кулына көрәк йә китмән, күбрәк бакчага су сибәр өчен шланг тотып, ишегалдына чыга. Баштарак ул ыгы-зыгы килә, нидер эшләгәндәй итә, ләкин ахыр чиктә бакчадагы урындыкларның берсенә барып утыра, йә булмаса үзенең яраткан айванына[1] юнәлә. Кулыннан китмәнен ычкындырмый йә шуңа таянып, бик озакка үзенең күнелсез уйларына чума. Әгәр өченче каттагы балконыннан күреп калса, картның йөрәге сау түгеллеген белгән Гаяз шунда ук бар эшләрен читкә куеп, аска йөгерә. Дөрес, ул аны авыр уйларыннан читкә юнәлдерә алмый, тик картка бушанырга кирәк, ә Исламов моны булдыра—тыңларга ярата иде. Судьяны чүп-чар, вак-төяк уңышсызлыклар борчымый, карт көнчыгыш халкына хас булганча зирәк, юк-барга исе китми, шуңа да аның борчуын Гаяз йөрәгенә якын ала.

—Беләсеңме, Гаяз кадерлем,—дип сөйләп китә судья, аңа дулкынланган йөзен борып,—мин бит башкалада тудым, үстем, монда белем алдым. Элек Ташкент хәзерге кебек зур түгел, халкы аз иде, шуңа күпләрне таный идем, алар да мине белгәннәрдер. Кайчандыр бу шәһәрдә иң яшь судьялардан идем. Үз гомеремдә бик җитди эшләр белән шөгыльләндем, хәзер генә, соңгы ун елда, гражданлык эшләрен алып барам. Беләсеңме, мине нәрсә шаккатыра: шушы елларда мирас бүлешү буенча эш проценты кискәк югары сикерде, варислар, ир һәм кыз туганнар, бертуганнар арасында очы-кырые күренмәгән дәгъвалашу бара. Нигә бүген сөмсерем шулкадәр коелган дип уйлыйсыз? Сездән яшермим: мин бүген үзем белгән, аралашкан, хөрмәт иткән кешенең мирасын бүлү эшен алып бардым. Искитәрлек кеше иде,—дип, аның фамилиясен атады судья, тик Гаяз бу кешене белми иде.

Фикереннән читкәрәк китеп, Закирҗан әкә истәлекләргә бирелде: кеше, вакыт һәм үзе турында, ничектер, бергә үреп сөйләде.

—Беләсеңме,—дип дәвам итте ул, бүгенге көнгә кайтып төшеп,—мин бит аның балаларын да белә идем, кайсыберләре хәтта күз алдымда үсте. Ничек шушы көнгә төштегез, бертуган апагыз белән палас бүлешә алмыйсыз, әтиегезнең алтын кул сәгате сезнең өчен истәлек әйберсе түгел, ә талаш чыганагы!—дим. Хәтта менә шундый вак-төякне дә кешеләрчә бүлешә алмыйлар бит, ә дәгъвалашу өй , машина, дача, зур акчалар өчен барганда ниләр генә кыланмыйлар!? Туган-тумача мирас бүлешкәндә, үзләрен дошманнардан да битәр тоталар. Судка кадәр аларны татулаштырырга тырышмадык дип уйлыйсызмы? Дуслары да, күршеләр, хезмәттәшләр, кардәшләр, мәхәллә дә алар өчен беркем түгел, шул исәптән судья да. Ничә мәртәбәләр мине, фактларга карамыйча, эшне тойгы-кичерешләргә бирелеп алып бара дигән булып кире кактылар. Һәрберсе үзен дөрес саный. Кайвакыт уйлап та куям: ярый әле мәрхүм—мондый мәкерле ыгы-зыгыны үзе күрми, нишләр иде икән ул моңа охшаш хәлне алдан сиземләсә? Керосин сибеп ут төртер иде микән машинасына, акчаларына, дачасына? Балаларын гомерлек дошман ясаган алка-йөзекләрен төеп, порошок итәр иде микән? Менә нәрсәләр уйга сала мине, кадерле күршекәем...

Вакыт-вакыт судья озаклап тынып тора, мөгаен, авырту йөрәген йөдәткән шул күренешләр кабат аның күз алдына килеп баскандыр. Карт бервакыт, әрнеп, кайбер шундый эшләрдән соң, марафончы кебек биш кило тирәсе авырлыгын югалтуын әйткән иде.

Соңгы тапкыр алар язын—Гаяз китәр алдыннан очраштылар. Бакчада эш муеннан: агачларны кисеп агартырга, виноградларны күтәртергә, койманы буярга кирәк. Эче пошкан Закирҗан әкә кабат Гаязга бушанды:

---

[1] Киң балкон

—Ярар инде, гади гаиләдән чыккан алай укымышлы, зирәк булмаганнар арасындагы ызгыш-талашны аңлап та була... Ләкин танылган, республикада гына түгел, бөтен Союзга билгеле шәхесләр бакыйлыкка күчкәч тә кайчак шул ук хәл күзәтелә. Варисларга кем генә, ничек кенә мөрәҗәгать итми, хәтта әти-әниегезнең изге исеменә, нәселегезгә тап төшермәгез дип тә карыйсың, ләкин комсызлыклары аркасында беркемнең сүзе колакларына керми, шулай итеп ата-аналарының мактаулы исемнәрен гайбәт, имеш-мимеш, уйдырма-ялганнар каплый, алар, кар йомарламы кебек тәгәрәп, тирә-юньгә тарала. Яңа гына хөрмәткә лаек адәмнең—балалары, туганнары тырышлыгы белән исеме юкка чыга, ә кызык яратучыларга мәзәге кала. Мөгаен, «Известия» гәҗитеннән укыгансыздыр,—үзенең таланты-сәләте белән бөтен дөньяны шаккатырган танылган балерина үлеп китте. Үз халкының, республикасының данын бөтен дөньяга тараткан шәхес. Тагын шул ук хәл, тик әз генә башкарачак: әнисе һәм туганнары—барысы да кияүне читкә кага. Берсе дә кызларының аның хатыны, балаларының әнисе икәнен, шуннан соң гына билгеле балерина булуын танырга теләми. Башта шәһәр, аннары республика аларны килештермәкче булды, ә хәзер инде бөтен ил мөхтәрәм гәҗит аша—татулашырга теләмәсәләр, хет шул талант иясенең исемен чат саен төрләндермәсеннәр иде,—дип тели. Ничек уйлыйсың, барып чыгармы?—дип сорады бу тормышта шактый акыл туплаган судья, ышаныр-ышанмас. Җавапка Гаяз иңбашларын гына җыерды.

... Юк, Актүбә—Оренбург шоссесына алып чыга торган авылара юлдан барганда, Закирҗан әкәсе тиктомалга гына исенә төшмәде. Кәефе киткән судья күбрәк бер үк нәрсәләр турында сөйли, бары тик вәзгыять кенә үзгәрә һәм даулашучы кешеләрнең исемнәре генә башка була.

Закирҗан әкәне тыңлаганда, Гаяз әллә яшь булганга, әллә тормыш тәҗрибәсе житенкерәмәгәнгәме, мондый хәлләр бары зур шәһәрләрдә генә, кешеләр бер-берсеннән читләшкәнгә, һәркем үзенчә көн күргәнгә шулай була, дип уйлый иде. Кечкенә авыллардан чыкканнар күп еллар ата йортына кайтмасалар да, туган якларын күздә тотып фикер йөртергә яраталар. Менә Гаяз да әңгәмә барышында уйлары белән Күллесенә тартыла һәм, билгеле, һич икеләнмичә, авылымда алай булмас, андагы кешеләр үк икенче дип саный иде.Үткәннәрдән хәтер безгә бары тик яхшыларын гына калдыра шул. Күлледә яшәүчеләрнең бүлешер нәрсәләре юк , дип уйлый иде. Әнә ул—вакытлар узу белән янтайган өйләре, кышның кар-бураннарыннан һәм күзге янгырлардан каралган, чүккән читәннәре белән аның үсмер чаклары үткән Күллесе! Күңелсез вакыйгалар турында житәрлек тыңласа да, башына үзем белән шуна охшаш хәл килеп чыгар дигән уй башына да кереп чыкмады.

Ә бәлкем, эчкәре урнашкан авылларда яшәгән кешеләрне әхлаклы санап ялгышкан бер ул гына түгелдер? Тик соңгы елларда Күлле шикелле авылларга багышлап күпме китаплар язылды. Аларда туган жир турында бик якты итеп: кешеләре әйбәт, суы татлы, кызлары исә—иң чибәрләре, егетләре алтын куллы, күңелләре чишмә суы кебек чиста дип сурәтләнде. Ул чакта яртысыннан артыгы Күлле кебек авыллардан килеп урнашкан шәһәрләрдә адәм актыклары каян килә соң? Аларны шәһәр бозган, дип санау дөрес микән... Заман шулай үзгәртәме, хәтта кеше күңеле инженерлары—язучылар да нәрсәнедер күреп-белеп бетерми һәм кешелек кавемен: «Бер- берегезне саклагыз!» дип кисәтергә өлгерми торгандыр.

Якшәмбе иртәсендә ярым буш юлдан барганда, шундый уйлар килде Гаязга. Спидометрның угы «140» тирәсендә бәргәләнсә дә, ул тизлекне сизмәде. Аның уйлары Күлледән Ташкентка, үткәннән киләчәккә сикерде һәм кабат бүгенге көнгә әйләнеп кайтты. Юк, туган жир, ата йорты—аның

күнелен кайтармады—карашы гына катгыйланды. Үткәнен искә алу, кинодагы, китаптагы кебек,уйдырма сыман тоелды. Тормыш итү—теләсә кайсы проблеманы эченә алган китаптан йөз тапкыр катлаулырак ул. Ярар, зур өметләр баглаган ял итү тәтемәде, туган жир дә көч-куәт өстәмәде—менә тагын китапча килеп чыкты—ләкин яхшыдан башка яманлык була алмый. Инде, шәт, аңлагансыңдыр: синең урының анда, Ташкентта, хәзер беркем ярдәм итә алмый, нишләргә икәнен дә күрсәтеп бирмәячәк—без үз юлыбызны үзебез сайлыйбыз. Тормыш шулай да объектив булырга мөмкинлек бирә—шуны аңлар өчен булса да кайту һәм хәтта нәрсәдәндер күнел бизү дә кирәк икән.

Алда төзелеш материалына бай урманлы якларга гына хас булганча, күптәннән каралмаган күпер күренде һәм Исламов тизлекне киметергә мәжбүр булды. Пыяласы бераз төшерелгән тәрәзәдән, ургылып, саф елга исе бәреп керде һәм ул ис Гаязга балачагы үткән Илекне хәтерләтте. Ул ашыкмый гына күпер аша чыкты да, ирексездән, туктап калды.

Каршыда, күз күремен тутырып, яшел ярлары боргаланып-бормаланып киткән елга иртәнге тынлыкта жәйрәп ята иде. Су борылышларда челтерәп ала, елга култыкларында кара-кучкылланып, сай сулы сазлыкларда яшь кыякларны кыштырдатып, әкрен генә ага да ага; урыны-урыны белән аның өстеннән, томанга охшап, күренер-күренмәс юка пар күтәрелә; ә текә, биек ярлар бер-берсе белән күрешкән жирләрдә энжедәй ялтыраган су тасмасын йөз яшьлек карама агачлары каралҗым чатырлары белән каплап алган. Куе таллык белән уратылган тәбәнәк ярлары исә язын су баскан болыннарга алып чыга. Бу тугайлар, елга ярларының борылышларын кабатлап, каядыр еракка китеп югала—ни тырышсаң да, аның азагын күрә алмыйсың. Болыннарны күптән түгел беренче катка чапканнар, анда-монда нәни генә печән чүмәләләре калыккан, ә үлән исә, елганың якында һәм юмарт икәнен дәлилләп, икенче катка күтәрелеп килә.

Бер жан иясе юк. Тынлык, бары тик, Күлледәге шикелле, монда да ерактагы поездларның тавышы ишетелеп ала һәм уянып килгән елга өстеннән шуышкан ул аваз күнелдә куанычлы, эчкерсез истәлекләрне яңарта.

Җәелеп яткан болыннарга карап, Гаяз бала чагындагы төн кунуларны исенә төшерде, учакларны, тышаулап жибәрелгән атлар, уенчак колыннарны күргәндәй, нәселле чабыш атларының пошкыруларын һәм түземсез бияләрнең кешнәүләрен ишеткәндәй булды.Тик күрше казакъ һәм татар авыллары өчен уртак бу болынга ( тагын бер болынлык бүләк итәргә елга артык кечкенә һәм хәлсез иде) килгән малайларны ачык кына күз алдына китерә алмады. Юк, тыныч төн куналарны транзистор-магнитофонлы малайлар буыны белән бәйли алмады. Мәгәр шуны белә: атлар үрчетелмәсә дә, һәр яз-көзен татар авылларында уза торган сабантуйларда, казакъ авылларында оештырылган уныш бәйрәмнәрендә ат чабышлары булмый калмый, аларга һәр тарафтан, хәтта шәһәрләрдән дә киләләр...

Ярышучылар, билгеле, төнге куну мәктәбен үткән яшь егетләр—аларның да иң чаялары! Жир йөзеннән соңгы атлар юкка чыкканчы, үсмер чакның гажәеп дулкынландыргыч мизгелләре булып истә калачак төн саклаулар да, шулай ук кыю, житез егетләр дә булачак әле. Бары тик—вакыты башка да, төнге кунулар бүтән.

Озак басып торды ул. Күз алдындагы бер күренешне икенчесе алмаштырды: ул әле үткәнгә, әле киләчәккә күз салды, елга буенда—иркендә уйлавы да рәхәт, жинел иде. Ул кинәт кенә яңа күтәрелеп килгән үләндә атлы чапкыч эзләрен шәйләп алды, ә аннары болынга төшү урынын күрде. Аның ары таба бару теләге сүнде. Кая бара? Нигә?

Биек ярга елышкан карамалар артында казаклар авылы күренде. Нык кына ачыкканын абайлаган Гаяз: «Бүген якшәмбе—базар көн, өлгерәм әле»,—дип уйлады да, машинасын кабызып, яр буйлап сузылган, кайсыдыр бер җирдән авылга борылырга тиешле юл буйлап кузгалды. Бу казаклар авылы шактый зур, Гаязның анда баргалаганы булды— әтисе аны үзе белән базарга ала иде; ә бервакыт Нури абый анда иске тегермәннәренең ватылган инглиз двигателен рәтләгәндә, станицаның кунак йортында икесе генә атна буе тордылар. Ул вакытта Гаяз шуңа төшенә алмады: ни өчен андагы җирле халыкны казаклар дигәннәр икән—соң алар да, Күлледәге күршеләре кебек, русча сөйләшәләр, тышкы яктан да аерма юк төсле, хәер, карты-яше лакланган козыреклы кызыл кырпулы фуражкадан булуын әйтсәң генә инде. Тагын шунысы истә калган: монда Күлледәге кебек җимерек йортлар юк, тоташтан төзек ак өйләр һәм чия бакчалары. Иске тегермәнне төзекләндереп кайткannan соң, әтисенең кемгәдер—мөгаен, казакларның тормыш-көнкүрешләре белән кызыксынганнардыр инде—әйткәннәре хәтеренә төште: «Казакларда тәртип каты: урманны сакла, елганы сакла, болыннарны сакла—менә шуңа тормышлары да нык».

Теге чакта кечерәк булганга, ул болай да бар һәм булачак елга, урман, болын, басу-кырларны ни өчен сакларга кирәк икәнен аңлап җиткермәгән. «Кешенең ни катнашы бар монда?»—дип уйлаган...

Ун минуттан ул станицада иде инде, тик моның утыз ел элек алар булган авыл белән бернинди уртаклыгы калмаган: хәзер ул Күллегә охшап калган; вакыт—аяусыз шул, үзеңә генә хаслык, шәхсилекне юкка чыгарып, һәрберебезне тормышта тигезли дә куя... Элмә такталардан аңлашылганча, авыл хәзер район үзәге икән.

Райүзәкнең әллә кайчаннан асфальт күрмәгән, тузан очып торган җимерек юлыннан, беркемнән сораштырып тормыйча, хәтеренә таянып, Исламов туп-туры базарга юнәлде. Бары тик инде әкренләп тарала башлаган базар гына Гаязга балачагында булган казак авылын хәтерләтте. Койма буенда олаулар, җинел арбалар тора, араларында хәтта пар ат җигелгән өсте ябулы йөк арбасы да бар—анда чиелдик чучка балалары саталар иде. Гаяз машинасын төрле төстәге «Жигули»лар белән рәттән куйды да кибетләр янына китте. Тик никадәр кенә ашыкса да, кайчандыр атлар бәйләп куелган, кимерелеп, чәйнәлеп беткән баганалар янында адымнарын әкренәйтми түзә алмады. Тагын кайда һәм кайчан атлар туктау урынын күрергә була? Хәзерге балалар автомобиль һәм велосипед кую өчен махсус урыннар барлыгын белсәләр дә, элек атлар өчен дә булганын күз алдына да китерә алмыйлардыр.

Баганага берничә ат бәйләп куелган. Алар нәрсәдәндер өркеп, кырын-кырын карыйлар, тынычсызланып, нечкә аяклары белән таптаналар. Атларның икесендә купшы—күренеп тора: бик күптән эшләнгән—биек ияр, бар да кара көмештән дирбияләр, хәтта югары тарттырылган өзәңгеләр дә көмештән.

«Андый атлар бары тик чын казакларда гына, тик алар бик аз калды инде»,—дип уйлады Гаяз. Аның уен раслагандай, чандыр, нык беләкле бер карт соры ат янына килде. Ат, хуҗасын танып, бии-бии, аңа иреннәре белән сузылды.

—Йә-йә, җанашым, тынычлан,—диде күзе яктырып киткән карт. Тавышына караганда, ул инде шактый өлкән яшьтә иде.

Урыны-урыны белән яныпмы, әллә атышуданмы тишкәләнгән якасыз кыска җиләннән, яшь чагыннан сакланып калган көяз хром итекләрдән һәм текә генә кыңгыр салынган яңа фуражкадан карт әле бик җилле күренде. Картның карчыганыкы кебек үткен күзе кинәт атлар янында

торган Гаязны тотып алды, бу эләктереп ала торган караштa хуҗасының яраткан аты өчен куркуы чагыла, әйтерсең якында гына ат карагы-чегәнне сизеп алган; яшь һәм гайрәтле елларында ул аларны хаталанмый тойган, таныган, күрәсең..

Карт ялгышмады, Гаяз нәкъ менә аның юртагына сокланып тора иде. Бераздан, күнеле кайткандай:

—Ә-ә, жәяүле татар,—диде, йөз-битеннән шомлануын куып.Үртәгән һәм шелтәләгәндәй дәвам итте,—карап, сокланып кал, сездә мондый чибәркәйләр юк инде, хәзер татарлар элеккегеләр түгел...—Һәм, бераз тынып торганнан соң, монсу гына тәмамлап куйды:—Әй, казакларны да әйтмә инде...

Аты, хуҗасының тавышында сагыш сизеп, бу көтелмәгән әңгәмәне туктатырга теләгәндәй, картка таба атлады. Карт, иркәләп, аның башын күкрәгенә кысты һәм, сөеклесенең йомшак танавына сыенып, инде Гаязны искәрмәгән дә шикелле сөйләнүен дәвам итте: «Терек...әйдә, Терек». Картның ат муенын сыйпаган кулында казак камчысы селкенә иде. Үз гомерендә беренче тапкыр Исламов фотоаппараты булмавына һәм фотога төшерә белмәвенә үкенде.

Ул базардагы азык-төлек кибетеннән Куба ромыннан бушаган тартма сорап алды. Шау-шу, этеш-төртеш, шаяру-көлү, кычкырып сөйләшкән тавышлар Гаязны уятып, кыздырып җибәрде һәм ул башкалар кебек үк, җыен юк-бар такылдап, тиз арада кирәк нәрсәләрен җыеп та чыкты. Катык-сөт рәтендә бер банка әчегән сөт һәм казакның данлыклы сырын алды, шуннан ук ун йомырка да эләктерде. Помидор һәм кыярның беренче уңышы сатуга чыккан, әмма бәяләре нык тешләгәнгәме, сатып алучылар күренми, шуна күрә аның сатулашуын бик теләп кабул иттеләр. Базардан чыгу юлында әле җылысы сүрелергә өлгермәгән кабарып пешкән бер бөтен түгәрәк ипи дә тартмага салып куелды. Авыллардагы икмәк пешерү йортларына механикалаштыру-автоматлаштыру килеп җитмәгәнгә, ипиләре өйдә пешкәннән әллә ни аерылмый иде. Күпер янына җиткәндә, базарда яхшы балык һәм уылдык, чын кырпы очратып булмасмы, дигән яшерен өмет аның күңелен җылыткан иде. Теге вакытта әтисе белән тегермән рәтләргә баргач, аның хәтерендә бер күренеш уелып калды. Соңыннан ул турыда бик еш теленә алса да, аңа бик үк ышанып җитмәделәр, ахрысы.

Нури абый дигательне төзекләндереп бетереп, сынау өчен тегермәнне эшләтеп караганнан соң, тегермәнче—авыл җирлегендә төшеп калганнардан түгел— сый хәстәрләде. Мондый очракларда тегермән, авыл кешесен сөендереп, озак һәм ышанычлы эшләсен дип, сарык суялар икән. Тәкәне Нури абый үзе чалды, үзе эшкәртте. Табынга тагын ниндидер мөхтәрәм картлар һәм рәсми рәвештә куелмаса да, казаклар өстеннән яшертен генә хакимлек иткән староста да дәшелгән иде. Менә шунда Гаяз тәүге мәртәбә уылдык тәмләп карады, аны тирән эчле юкә савытлардан зур агач кашыклар белән алып ашадылар.Тагы ал төстә, майлары агып торган, искиткеч тәмле балыктан (зур калын кисәкләргә бүленгән булгач, аны малай башта ит дип уйлаган иде) авыз иттеләр. Бар да аның әтисен мактадылар һәм останың сәламәтлеге өчен стаканнарын күтәрделәр. Шунда, өстәл артында ук, аның белән исәп-хисап ясадылар. Ә тегермән каршында аларны Күлледән алып килгән пар ат җигелгән олау көтеп тора иде. Әтисе белән чыгуга, тегермәнче аяклары бәйләнгән тәкә алып килде.

—Ә менә бу сиңа, оста, миннән,—диде дә арбадагы яңа чабылган печән өстенә китереп салды.

Староста йөкченең колагына нидер пышылдады да аның янәшәсенә утырды һәм, серле генә елмаеп, кузгалырга кушты. Авыл башына чыккач, ат туктады, һәм

староста барысын да күзгә әллә ни ташланып тормаган бер подвалга чакырды. «Озын тәбәнәк идән астына калын-калын бүрәнәләрдән ике өрлек куелган, карангы булганга, староста белән йөкче тиз-тиз генә ике зур керосин лампасына ут элделәр. Боз күренмәсә дә, эчтә бик суык иде; туфрак астындагы сулар якыннан гына үтәләр, күрәсең. Элеккеләр хәзергеләр кебек озаклап укымасалар да, кайда һәм ничек төзергә кирәклекнең рәтен белгәннәр, ичмасам. Лампалар, караңгылыкны тирә-якка куып, әкрен генә яктылык сирпеделәр, һәм Гаяз, тимер ыргакка эләктерелеп, башлары түбән каратып эленгән алагаем зур—үзе буе булыр, бәлкем, зуррактыр да әле—дистәләгән балык күреп алды. Староста, иснәгәндәй, һәрберсе янынннан әйләнеп, орынып чыкты. Үзенең игътибарын җәлеп итәрдәен табып, итек балтырыннан озын пычак тартып чыгарды һәм тиз, җинел хәрәкәтләр белән, калын итеп, шактый дәү өч кисәк кисте дә сүзсез генә әтисенә сузды. Аннары ян дивар буеннан барып, лампаны киң итеп агачтан ясалган шүрлеккә куйды. Киштәләр ике рәт булып карангыга таба сузылганнар, аларда футбол тубы зурлыгындагы дәү кара шарлар ята. Йөкче аның кулына әллә кечерәк чиләк, әллә нәни генә мичкә бирдеме, староста шул ук пычагы белән бер шарны урталай кисеп җибәрде дә куллары белән савыт авызына тотты, аны мөлдерәмә тутырып, исе китеп карап торган Гаязга бирде.

—Монысы, оста, җәмгыятьтән, казаклар исеменнән,—дип, староста әтисе алдында баш иде...

Гаяз күпме генә як-ягына каранмасын—базарда ни ачыктан-ачык, ни яшертен балык һәм уылдык сатучыларны күрмәде. Бу якларда күп иде бит алар—теге чакларда үз күзләре белән күргән иде. Менә хәзер сонга калып булса да әтисенең сүзләренә төшенде: елганы саклыйлар...

Аның каравы, уылдык эзләп йөргәндә, ул чегәннәргә тап булды—юк-юк, ат каракларына түгел, хәзерге казак атлары, ай-һай, аларны кызыксындырыр микән? Болар башка, боларының кулы кулга йокмый: ерак штат—«Монтана»дан дип ялган тамга куеп, бик житез генә кулдан бәйләнгән свитер һәм пуловерлар белән сату итәләр.

Гаязның алган бар ашамлыгы пөхтә итеп тартмага салынган, булдыклы ипи сатучы исә тартманы, тиз һәм оста итеп, сүс бау белән бәйләп тә бирде. Ашыкмый-кабаланмый, сатып алган әйберләреннән һәм кайнап торган казаклар базарыннан канәгать калып, ул кабат атлар бәйли торган урынга килеп чыкты. Анда ялгызы гына башын иеп басып торган карт алмачуар ат яныннан үтеп, тукталышка юнәлде. Ерактан ук машинасын тыгыз итеп ураткан кешеләр төркемен күреп алды.

«Кузгалып киткәндә, кемдер минекен нык кына эләктергән, ахры». Әмма бу уй Гаязның кәефен китәрмәде. «Әгәр куып киткән булсалар—куаныр гына идем»,—дип уйлады да көлеп куйды. Станицада булу аңа унай тәэсир итте: күнел төшенкелегеннән арынды. Ул көч-хәл белән машинасы янына үтте дә капот өстенә тартмасын куеп, ачкычларын чыгарды.

—Синме хуҗасы?—дип сорады әсәрләнгән бер казак һәм, Гаязның кулыннан эләктереп, өтерсез-ноктасыз такылдарга тотынды,—мин беренче, мин беренче килдем, мин беренче сатып алучы...

Аны бүлдермәделәр, әмма зур гына гәүдәле ике ир-ат такылдыкны сүзсез генә кысрыклап, Гаязның игътибарын үзләренә җәлеп итәргә тырыштылар. Әмма теге дә, каерып алмаслык итеп, татар ир-атының терсәгенә ябышкан иде.

—Нәрсәне сатып алучы?—Каушап калган Гаяз, терсәген ычкындырырга маташты, теге нык ир-атлар да—мондагылар түгел, ахры—илтифатлы гына аңа ярдәмгә килделәр.

—Ай-һай, җор кеше син, туган,—терсәкне һаман да җибәрмичә,

ярсулы көлемсерәде теге дулкынланган казак.—«Волга»ны, менә шушы ак чибәркәйне, кадерлем.

—Ә кем әйтте сезгә сатыла дип?—Чит-ятларның ярдәменнән башка да терсәген бушата алган Исламов, ниһаять, һушына килде.

—Син нәрсә, саташкан? Машинасын базарның нәкъ күренә торган жиренә куйган да хәзер сатылмыймы? Хәйләкәр син, туган. Бәясен күтәрәсенме,—диде ачуы чыккан казак. Тирә-юньдәге халык гөжләргә тотынды..

Гаяз яңа гына аңышты: ерактан машина кую урынына охшаган бу жир автомобиль базары икән. Башында «ат базары, печән базары, кош-корт базары, инде менә килеп автобазар—һәр дәвернен үз жыры гына түгел, үз базары да икән» дигән уй чагылып үтте.

—Гафу итегез, мин читтән килгән кеше, үтеп барышлый гына. Белмәдем. Машина сатылмый,—диде хафага төшкән Гаяз. Төркем теләр-теләмәс кенә тарала башлады.

Гаяз багажникны ачкач, аның ике ягыннан теге таза ике ир-ат та иелде.

—Афәрин, жыен килде-киттене куып жибәрә алдың. Машинанны без алабыз, бик шәп, ошады. Читкә чыгару өчен эшләнгән, күрәсен.

—Чит ил өчен түгел, махсус атап эшләнгән,—дип бүлдерде аларны Гаяз, багажнигы‹ яба-яба.

—Бигрәк тә шәп, әллә каян күренеп тора—үзенә бер,—дип дәвам иттеләр куанган «тазалар».—Вакланып тормыйбыз, машинан жанга ятышлы, утыз меңгә ризамы?

—Әйтеп торам бит—машина сатылмый,—дип жавап бирде арыган Гаяз һәм алгы ишекне ачты.

«Волга» әкрен генә урыныннан кузгалды... Яртылаш ачык тәрәзәгә үҗәт сатып алучыларның берсе башын тыкты.

—Утыз бишне бирәм, кадерлем, соңгы—кызыл бәя,—дип ялынды, рульгә ябышып.

—Сатылмый,—диде дә Гаяз кызу гына китеп барды. Тирә-юньдәгеләр якякка сибелеп калдылар. Авылның басу киртәсен чыккач кына, ул тизлеген киметте һәм күпергә таба борылды. Ул көнне монда, елга янәшәсендәге болында үткәрергә булды.

Башыннан һаман да базар хәлләре чыкмады: Монтана штатының кайсы илдә икәнен күз алдына да китермәгән чегәннәр, «Терек» кушаматлы атның хуҗасы карт казак, аның озын һәм, күренеп тора, гади генә үтелмәгән гомер юлы; автомобиль базарында сатулашу...

—Утыз биш мең...

Ишетелерлек итеп әйтелгән цифр (гәрчә акча, ай-яй-яй, нихәтле!) Гаязда бернинди хис уятмады, башка бер кеше аның кадәрлене гомере буена эшли алырмы икән—китапханәче, шәфкать туташы, мәсәлән, шул исәптән, мөгаен, гади инженер да. Әгәр теләге булса, артык вөждан газаплары кичерми генә шул суммага ия була ала иде. Әле генә берничә мең хуҗасы булу мөмкинлеге—моның өчен бары кире борылырга гына кирәк—аңарда бернинди үкенү, икеләнү тудырмады, бик күпләрдә көнләшү китереп чыгарган бу зиннәтле машинага Нури Исламовның бердәнбер улы һәм нәселен дәвам итүче булса да, үзенең хакы юклыгына ышанган иде инде.

Ул чапкыч эзе буенча болынга керде, үзе һәм машинасы өчен унайлы урын караштыра-эзләштерә яр буйлатып шактый озак барды; матур урыннар күп очрады, шуна күрә сайлап алу кыен булды. Озакламый ул бер алан күреп алды. Бу алан печән чабучыларның ял итү урыны булса кирәк, жирләрдән дә матуррак урын табып булмас диг, ул шунда тукталасы итте. Кырыйлары

кирпеч ватыклары белән әйләндереп алынган нәни генә чишмә-кизләү дә үзенә тартып тора. Гаяз үз гомерендә бик күп җирләрне гизсә дә, кизләүне бары тик туган якларында гына очратты. Ерак түгел, иске учак урыны күренә, аннан бер генә тапкыр файдаланмаганнар—монысына да сөенде. Тирә-яктагы куаклар арасыннан өчаяк, корымга каткан казан табып алды, хәтта авылдан алып килгән утын запасы да бар иде. Гаяз утынга кагылмаска булды, ул беркая да ашыкмый, аны беркайда да көтеп тормыйлар—вакыты җитәрлек, шуна коры-сарыны яр буендагы таллыктан эзләргә булды.

Елгадан болынга таба, су исе, юеш яр исен ияртеп, сизелер-сизелмәс кенә дымлы йомшак җил исә; ә чәчкәле болын, яңа куелган кибәннәрдән мул булып үлән исе, җәй эссесе аңкый; Гаяз тукталган кизләү янында елга һәм болыннан агылган исләр бергә кушылып кабатланмас хуш ис тудыралар—башны әйләндереп, җанны исертәләр—аның моннан беркая да кузгаласы килмәде. Кояш инде югары күтәрелгән, көннең яртысы узып бара, әмма монда, болында, елга янында, эсселек сизелми: сокландыра, хыялга чумдыра, тынлыкка тарта торган рәхәт, йомшак, җылы. Ә менә гәрчә кияү—сенелләре, туган йорты турындагы уйларны төрлечә куып караса да, тынычлану дигәне белән берни барып чыкмады. Кинәт кенә хәтерендә Федорның сүзләре яңарып китте: «эшлекләләр» дигән иде ул Фәридә һәм Халияр хакында, кичә машинада сырага барган чакта. Юк, Федорның көнләшкәне сизелмәде, ләкин аңлатып та тормады, бәлки аның янында артыгын чәчелмәгәндер. Уйлар шушы гади генә сүз тирәсендә бөтерелә башлады... Эшлекләләр—әтиләре машинасында булсалар, базарда нишләгән булырлар иде икән, ә? Барыннан да элек, бер «Волга»дан дүрт «Жигули»—һәр кыз туганга берәрдән—ясаган булырлар иде. Бигрәк тә эшлекле Фәридә райбашкарма комитетында утырганда, үзе үк машина алу исемлеген алып барганда... Беренчесендә булмаса, икенче, өченче мәртәбәсендә чиратка кысылып, башта үзенә, аннары башкаларына барыбер эләктерер иде.

Нишләп, мәсәлән, Халиярны—районның иң яхшы диск-жокее, сыра бары ачыла калса иң яхшы бармен диеп, исемлеккә кертмәскә? Үзенә—районда бердәнбер хатын-кыз юрист дип. Ышандырамы ? Тулысынча... Ә Федор белән Алексейга рәсмиләштерү тагын да ансатрак—эшче сыйныф, акчалары гына булсын! Монда инде Фәридә, юрист буларак, кирәкле сүзләрен табар иде: эшче—иң бөек исем, гегемон-житәкче, җир сөрүче, туйдыручы—болар читтә урнашкан авылларда иң үтемле сүзләр.

Чынлап та, нәкъ шулай итәр иде. Машина артыннан өйгә чират житә. Фәридә менә-менә бистәнең үзәк урамында—анда Күлленең бар башлыклары, зыялылары яши !—хөкүмәт йорты-коттедж алырга тора. Әниләрен үзенә ала, йә булмаса берәрсенә илтеп куя да—янәсе, өлкән яшьтәге ялгыз карчык берүзе шундый зур өйдә ничек яшәсен,—йортны артык бәягә ычкындыра. Башына килгән уйлардан Гаяз төкереп куйды да җил искән якка борылып кычкырды: «Барып чыкмас!» һәм Күлле ягына биштән төрелгән кәҗә тоягы күрсәтте.

Ни гаҗәп: бу ярсынып алу башка тулган авыр уйларны читкә куды. Гаяз, ниһаять,үзендә җинеллек тоеп, кечкенә генә учак тергезде, казанда йомырка пешереп алды. Берничәсен чиле-пешле, калганнарын каты итте һәм аппетит белән ашарга утырды. Аннан инде озаклап, күнеле булганчы су коенды—елганың исемен белергә теләсә дә, сорашырга якын-тирәдә берәү дә юк иде,—аннары Паланганы хәтерләткән ком калкулыкларында кызынды.

Кояш көнбатышка таба тәгәрәде, кибәннәрдән, озынайганнан-озыная барып, йөнтәс, сәер күләгәләр сузылды. Кайтырга иртәрәк иде, өстәвенә, бу оҗмахтан китәсе килмәде. Һәм Гаяз кибәнне чак кына таратып, машинадагы

япма булып хезмәт иткән одеялны астына җәйде дә чалкан ятты.

Кибән исе аңа иске өйләрендәге печәнлекне хәтерләтте, кышкы суыкбураннар балаларны шунда куып кертә иде. Җылы печәнлеккә посып, дөм-караңгыда бер-берсенә сихерчеләр, җен, шайтан, пәриләр, өрәкләр турында коточкыч вакыйгалар сөйли торганнар иде... Кичәге кичке табынмы, әллә бүгенге матавыклы көн тәэсиреннәнме, үзе дә сизмәстән, ул йокыга талды.

Төн уртасында кинәт уянып китте. Нәкъ аның баш өстендә, җәйге биек күк йөзендә, йолдызлар җемелдәшә; андый биек күкне, шуның кадәрле йолдызларны аның күптәннән күзәткәне юк иде. Ул, уйларына уралып, озак ятты; рәхәт, салкынлык сизелми, аның бәхетенә төн җылы. Төнге күк йөзе, җиргә атылган йолдызлар, балкып торган йолдызлыклар (кызганычка күрә, Зур Аю йолдызлыгыннан кала башкаларының исемен белми иде), елга, урман, болыннар кебек үк, аны үзенә тарталар, ул шаярып күз кыскан йолдызлардан күзен ала алмады, алар Гаязга тынычлык, йомшаклык һәм наз китерделәр. Шулчак бу көннәрдә аны борчыган сорауларга җавап табылды. Гаҗәпләнүдән ул хәтта сикереп торуын сизми дә калды, тирә-якта төн карасы икәнен дә онытты, үзендә гадәттән тыш көч һәм күңел күтәренкелеге тойды. Янәдән учак тергезде, казанны утыртты һәм, кайчандыр балачакта төнге кунулардагы йә балыкка баргандагы кебек, суга бөтнек салып кайнатты. Аның кабызган төнге учагы биек яр буенда әле дә җитәкләшеп йөргән гашыйкларга, ә бәлки галәмдәгеләргә дә күренгәндер. Ничек дип әйтәләр әле, башыңны күтәрсәң, сиңа космонавтлар карап торганы күренә, диләрме? Галәмгә сәлам юллагандай, ул учактагы күмерләрне кузгаткалады да меңләгән очкыннар, җирдән калыккан йолдызлар сыман, күккә чөелделәр. Әгәр чынлыкта да космонавтлар Гаязны күзәтеп торсалар, аннан көнләшерләр иде, мөгаен: төн, тынлык, шул сихри тынлыкны бозарга курыккандай, чикерткәләр дә сайравыннан туктап калган; бары тик ара-тирә елгада зур балыклар йокы аралаш чупырдап куя да сизгер бака куркуыннан, ул-бу булмагае дип, төнбоек чәчәгенең яфрагында җәйләп утырган җиреннән суга шап итеп егылып төшә; сокланып туймаслык учак һәм мәңгелек сергә ия ут...

Коры-сары бетте, учак сүнде, әмма кузгаласы, өйгә кайтасы килми иде. Ул елга буена юнәлде. Үзендәге һәм тирә-ягындагы тереклекне уятудан курыккандай, елга тын гына Уралга таба агып ята. Тик йокысыз шаян җилкәй генә, елганы санламыйча, кисәк кенә яр буендагы камышларны шаулатып уза да гүя елгадан, яклау эзләгән һәм ярдәм сорагандай, ботакларын суга кадәр салындырып черем иткән тирәкләрне сискәндереп үтә. Төнгә кызуы кайткан комлык ялан табаннарны иркәләде, тынычландырды, тагын мондый хозурлыкны икенче тапкыр төшендә күрсәң генә инде дигәндәй, алга дәште. Ул сайлыкка керде, озын көн буена җәйге кояшның эссесен сеңдергән су көндезгегә караганда җылырак иде. Җәһәт кенә чишенде дә, гүя тынлыкны бозарга теләмәгәндәй, әкрен генә, тавышсыз гына йөзеп китте...

Кибән янында калган машинадан печән исе, болын исе аңкый. Башларын иеп йокымсыраган чәчкәләр һәм анда-сандагы ялгызак, ятим кибәннәр ачык күренсен дип, еракны алдырта торган фарасын яктыртып, Гаяз әкрен генә юлга төште. Күперне чыгуга, радиоалгычны кабызды—машина салонына ургылып, эфирдагы тавышлар бәреп керде. Эзләнә торгач, үзе кебек төнлә йөрүчеләргә кирәкле көйне тапты. Юл таныш, каршыга килүчеләр юк , дип уйласа да, тизлекне әллә ни арттыра алмады. Гаязның гаҗәпләнүенә, химикатлар белән кирәгенчә һәм кирәгеннән артык агуланган, кирәккирәкмәс урыннан сукаланып теткәләнгән, шау-шулы тар һәм киң машина юллары, тимер юллар белән өзгәләнгән, Оренбург нефть промыселларыннан

тәүлекләр буена аңкыган бензин һәм төтен исен үзенә сеңдергән, арбалар белән бозгаланган, нефть һәм газ үткәргечләр, телефон, телеграфның җир асты чыбыклары белән кискәләнгән дала үлмәгән, ә актив тормыш белән яшәп ята икән ләбаса...

Сирәк-мирәк булса да, ул исемен белмәгән еланнар, тузбашлар, бакаларның зур гаскәре очрый, алар, юлны бүлеп, каядыр шуышалар, сикерәләр... Ул да булмый, ут яктысына сукыраеп, кайсы якка сикерергә белмичә, каршысында кушаяк бии. Ике тапкыр, сискәндереп, йонын койган ябык төлкеләр юл аша йөгереп чыкты. Ә бераздан аңа йөрешен акрынайтырга туры килде. Күрәсең, су эчәргә диптер, араларында әле ныгып җитмәгән яшь үрчемнәре булган куркак кыр кәҗәләре көтүе юлны аркылы кисеп үтте. Бу бичара хайваннарга, кызганычка күрә, аучылык итү канунннарын бозучыларның машина фаралары яктысы таныш иде, һәм Гаяз, аларны куркытмас өчен, кырыйга китеп, төнге далада адашмасыннар дип, утын сүндергән килеш, шактый озак туктап торды. Тимер юл кырыйлатып утыртылган урман полосаларында керпеләр еш очрады, кызык: төнлә нишләп йөри икән алар? Юлны аркылы чыккан җирдә өне янында торган бурсыкны да күрде, тик тегесе, куркып, җир астына кереп югалмады: симез артын әвеш-түеш китереп, караңгыга таба тыйтаклап китеп барды. Бодай басуларында йомраннар хакимлек итә—менә аларны агу-химикатлар алмый, рәхәтләнеп симерешеп, исәпсез-хисапсыз үрчеп яталар. Шунда ук, бодай кырының урманга якынрак җирендә, зур гәүдәле, карт, ялкау ябалакларның иренеп кенә нидер эзләүләре күзгә чалынып калды. Гаҗәп: әле иртән генә шушы ук юлдан килгәндә бернәрсә күрмәде, шәйләмәде, хәтта фараз да итмәгән иде, менә сиңа мә! Төн аңа кеше күзеннән посып калган көтелмәгән серле дөньясын ачты. Таң калдыргыч төн! Менә шушы көн, очраклы сәяхәт өчен генә булса да, төп йортка кайтырга була.

Яктыра төште, йолдызлар тоныклана, сүнә башладылар. Күк йөзенең гаять зур киңлеге балкып торган йолдызлыклардан сизелер-сизелмәс кенә арына, күкнең әле генә бәрхет-кара астарлыгы күз ачып йомганчы сорыланды, таңның беренче нурлары белән ачык, зәңгәр җәйге төскә керде.

Күллегә ул әтисе яткан иске зират ягыннан кайтты. Мөселман каберлекләре гади: анда котырып үскән яшеллек тә юк, купшы һәйкәлләр дә куелмаган, күп очракларда зират сакчысы да булмый. Каберлек сутлы балчыктан катырылган койма-дувал белән әйләндереп алынган, вакыт узуга, койма утырган, урыны-урыны белән озакка сузылган көзге яңгырлар һәм язгы ташкыннар белән юылган, ишелгән. Әнисенең ничектер әйткәне бар: сарык көтүче кайсыдыр бер казак яна койма өчен шактый зур суммада акча васыять иткән булган, әмма икенче ел инде балалары судтан-судка йөри икән. Янәсе, васыятьнамәне язган чакта әтиләре үз-үзен белештерми торган халәттә булган, тик туганнарыннан башка бер генә шаһит та, үз өстенә гөнаһ алып, моны расларга теләми, ди. Әтиләрне хөрмәт белән искә алырга кирәк!

Гаяз машинасын керү юлында калдырды. Инде тәмам яктырды, төтен сыман җинел, кардай ак болытлар иртәнге саф күк йөзендә кояшның беренче нурларыннан эреп югалган йолдызлар урынын алдылар. Чык төште, сулган соры әрем куаклары, ниһаять, зарыгып көтелгән тамчыларга тиенеп, башларын күтәрделәр, эссе кояштан көйгән үлән кыяклары аяк астында калып, җиргә сырыштылар. Шактый зур мәйдан биләгән зиратка ишек төбеннән үк җилпәзә төсле таралган сукмакларга тузан утырмаган иде.

Нури абыйның кабере, башкаларныкы кебек үк, тыйнак кына, тик колхоз тимерлегендә коелган чардуганы киңрәк һәм биегрәк, хикмәтлерәк булганга, калганнарныкына караганда үзгәрәк, ышанычлырак төсле. Чардуган

кара төстәге ялтыравыклы тимер буявы белән буялган. Федор үзенең укытучысы, остазы, каенатасы өчен чын күңеленнән тырышкан. Кабер өстендәге зур гөлчәчәкләр бәйләме шиңгән,—кайткан көнне Гаяз аларны үзләренең бакчаларыннан алып килгән иде,—шәфкатьсез дала кояшы аларны көйдергән. Ул капканы ачты да кипкән чәчкәләрне читкә алып куйды һәм шунда кабернең баш ягында нечкә генә, әле ныгырга өлгермәсә дә ишле булып сабакка киткән шайтан таягын күреп алды. Шуның ин нәзек, зәгыйфь сабагы күптән түгел—ә бәлки бүген генәдер—чәчәген ачкан. Җирнең соңгы бүләге—шыксыз, әмма яшәү өчен ашкынып торган шайтан таягының нәфис чәчәге, җай гына тирбәнгәләп, пышылдый төсле: тыныч йокла, Нури Исламов, тырыш эшче, җир сөрүче...

...Әкрен генә Күлле уянып килә, ишекләр ачылып-ябыла, май күрмәгән капкалар шыгырдап ала, коеларда чиләкләр шалтырый, йоклап калган хатыннар, сөт чиләкләрен тотып, сыерлары янына ашыга, кайбер чатларда инде көтү чыгаралар. Гаяз, тавышланмаска тырышып, иплəп кенә капканы ачты да ишегалдына керде, өйдәгеләрнең иртәнге татлы йокыларыннан бүлмәс өчен, машинаны гаражга куеп тормады. Әтиләре үлгәннән соң, алар сыерны бетерделәр—кем печәнен тапсын, карасын, саусын. Әнисе бик еш авырый, ә Фәридә үз гомерендә бер тапкыр кулына сөт чиләге тотып карамаган. Нәрсәгә? Сөт эзләп йөрисе юк—райбашкарма комитеты буфетыннан теләсә кайсы вакытта сатып алырга мөмкин.

Гаяз, сак кына басып, үз бүлмәсенә үтте. Гадәттәгечә, бакча як тәрәзә төбенә кадәр ачык, урын-җир пөхтә итеп түшәлгән, ә караваm янындагы тумбочкада сулы графин һәм, төбен өскә каратып, стакан куелган иде. Гаяз тиз-тиз генә чишенде дә ятакка чумды, өйдәге тынлык шундук аны йокыга тартты. Ул ничек тиз йоклап киткән булса, шулай тиз уянды да. Бүлмәдә уйнаган нур шәүләләренә карап, үзенең черем итеп кенә алуын чамалады. Агачлар арасында шукланып уйнап йөргән наян җилкәй бакча ягыннан аңа кайнап утырган самоварның төтен исен алып килде. Әнисе дөрес әйтәдер: яшь, тиктормас җилкәйләрнең оясы, чыннан да, аларның бакчаларында—агачлар арасында бугай.

Гаязның өч-дүрт сәгатьләп кенә вакыты калып бара, шуңа күрә иркәләнеп, уйланып ятарга мөмкинлеге чикле, тиз генә урыныннан сикереп торды. Әнисе, аны күргәч:

—Ә-ә, улым, хәерле иртә,—дип кенә әйтте, әйтерсең, улы белән берни булмаган, тәүлек буе кайдадыр югалып тормаган. Ире белән бергә яшәгән чорда тормыш аңа ир-атка кирәкмәгән сораулар бирмәскә өйрәтте, кирәк тапсалар—үзләре әйтерләр.

Ишегалдында машина күренмәде, күрәсең, Халияр аны гаражга кертеп куйган. Улы коену бүлмәсенә үткәнче, әнисе сорап өлгерде:

—Сиңа йомырка тәбәсеме, әллә коймакмы, улым?

—Тәбә дә, коймак та,—диде ул, елмая төшеп. Улының җавабы ананың күңеленә кереп оялаган яшерен борчуны юып төшергәндәй булды.

Гаяз, бакта су беткәнче, озаклап юынды, кичәге исемсез елганы, аның тирәли урнашкан колхозларның елга суын, һич җәлләүсез, җирләрен сугару өчен суыртуларын исенә төшерде. Кызганыч иде елга, әгәр кешенең ярдәмен тоймаса, бөтенләй югалыр иде: тирә-юньдәге чишмәләрне чистартып тормасалар, үзенә су җыя алмас иде. Әгәр дә шушындый елгалар кибә калса, мона кадәр тирә-яктагы казак һәм татар авылларын туйдырып килгән, кайчандыр бик көчле-куәтле саналып та, елдан-ел хәлсезләнә барган Урал-атакай да юкка чыгар иде.

Иртәнге аш вакытында әнисе, ашыгып, бутала-бутала, сорап калырга ашыкты:

—Гаяз улым, ял итәсе көннәрең аз калып бара, ә син үз эшләрең белән бөтенләй кызыксынмыйсың, сенелләрең борчыла, теге...ничек әйтергә дә белмим... Синең нәрсә уйлавыңны беләселәре килә.

—Син нәрсә турында, әни?

—Соң машина, өй турында. Синең белән бу темага беркайчан да сөйләшкәнебез булмады, вакыт та, сәбәп тә табылмады; үзең дә ни хатларыңда сорашмадың, ни хәзер кызыксынмыйсың. Мөгаен, сизенәсеңдер, йорт һәм машинаны әтиең сиңа васыять итте бит. Әтиең әйтте: «Улым нәселне дәвам итүче бердәнбер Исламов»,—диде; үзең беләсең, аның өчен ин мөһим нәрсә булды ул, ә кызлардан зарланырлык түгел, аларны бик яратты. Һәммәсен кияүгә бирде, төзеште, аякларына басарга ярдәм итте. Ә барыбер варис дип сине санады. Тик сеңелләрең сиңа машина да җитә дип хәл кылдылар. Мин тегеләй дә, болай да башлап карадым, әтиегез сүзенә каршы килеп булмый дидем, ә алар, әйтерсең лә чит-ятлар, өй күпме тора икән дип исәплиләр-чутлыйлар. Бөтенесен әтиеңнең яраткан кызы—Фәридәсе болгата. Мәскәүдә укыган чагында иркенгә өйрәнде—һәммәсен биреп тордык, менә хәзер шуны куа. Күрәм мин: Федор белән Алексей газапланалар, синең күзеңә туры карарга кыенсыналар. Хатыннарын тыймакчы булалар, болай яхшы түгел диләр. Әнә Фәридә, Халияр икесе бергә Гөлфия белән Әлфияне шулкадәр оста котырталар, кайда өйрәгәннәр диген, бик яшьләр бит әле.—Әнисе бите буйлап тәгәрәгән күз яшьләрен яшереп кенә яулык чите белән сөртеп алды.—Аллага шөкер, әле ярый әтиең бу хәлләрне күрми дип куанам, болай буласын ул уена да китермәде,—дип, авыр сулап куйды әнисе.

—Өйне сатмакчы булалар диген?—Әллә сорау бирде, әллә үзалдына сөйләнде Гаяз. Аштан күңеле кайтты.—Чит-ят кешеләр яшәсен, чит оныклар тусын диләрме,—дип дәвам итте ул, өстәл артыннан кузгалып.—Нәрсә, безнең өй Иванов йә Вәлиевларныкы, яисә тагын кемнәрнекедер булсынмы? Борын-борыннан йорт үз хуҗасының исемен йөрткән! Әти бит аны чит абзыйлар, зур табыш-файдалар өчен төземәгән.

—Син болар турында миңа түгел, сеңелләреңә сөйләсәң иде, бәлки исләренә килерләр, әтиең исемен җәлләрләр иде. Авылның һәр почмагында Исламовлар исемен төрләндерәчәкләр, картлык көнемдә мина шул хурлык кына җитми иде.

—Юк, барып чыкмас!—Гаяз әнисенең калтыраган җилкәсеннән кочты.—Өй, синең әйтүеңә караганда, минеке санала, шулай булгач, мин аны беркайчан да сатмаячакмын. Менә бу йорт—әтинең төп эш-шөгыле, мин аны яна гына аңладым, ул безнең барыбыз өчен—хәзерге һәм булачак Исламовлар өчен бу дөньяда сыенып урын булыр, дип фикер йөрткәндер дип уйлыйм.—Озак кына тынып торганнан соң, әнисенәме, әллә инде үзенәме төбәп, тикшерелергә тиеш түгеллеген анлаткан карар кабул иткәндәй ныклык белән:

—Бер көнлек, бер минутлык файда өчен генә яшәргә ярамый, күңелгә ошап җитмәсә дә, кемдер җаваплылыкны үз өстенә алырга тиештер бит. Ә сеңелкәшләргә килгәндә... Әнә машинаны алсыннар. Безнең ишегалдында машина аз булмады, әмма алар әтинең күңеленә ятмады. Бәлки алар шуннан соң басылырлар һәм аңларлар: мине монда ач күзлелек, нәфес кайтармады.

—Син әллә бөтенләйгә кайтырга уйладыңмы, улым?—дигән ышаныч белән сорады әнисе.

—Белмим әле, әни. Һәрхәлдә, әлегә кадәр бу турыда уйлаганым булмады.

—Ул чагында нәрсәгә сиңа өй, әнә машинаны ал. Син әле яшь, андый зур шәһәрдә сиңа машина кирәгер, хәзер бик кыйммәт тә йөри диләр. Бу

машинаны күреп, барысы да һуштан язарлар иде.

—Әни, син мине дөрес анламадың. Машина да, өй дә кирәк түгел миңа. Әмма өенең язмышын миңа хәл итәргә туры килә икән инде, аны үзебезнең гаиләбезгә калдырам. Әти өчен бит анда мин яшимме, әллә берәр оныгымы—анысы мөһим булмаган. Бу нигездә аның нәселе дәвам итәргә тиеш. Кайтырмынмы мин? Белмим.Тик безнең өйдә Исламовларның оныклары яшәргә тиеш. Әгәр Фәридә белән Халияр китәләр икән, зинһар өчен, әни, өйне ялгыз калдырма, үз яныңа берәр өйдәш керт: кызлармы, берәр укытучымы, йә булмаса практикага килгәннәрнеме. Син өйдә булганда, мин тыныч булырмын һәм тәрәзәләре бакчага караган бүлмәм һәрвакыт мине көтеп торуын белермен.

—Мин бөтенләй буталып беттем, улым, сиңа әтиеңнән бернәрсә дә калмаганмы, әллә кирәк түгелме? Машинадан баш тартасынмы? Хәтта саткан акчадан тиешле өлештән дә? Ничек аңларга сезне, балалар, берегезгә барысын да тоттыр—каршы килми, ә икенчегезгә берни кирәкми. Әй улым, йөрәгем сизә, тормышыңда нидер бар, нәрсәдер эчтән кимерә сине, шуңа күрә машина да, акча да сөендерми. Һай, әтиең исән булса!

«Әти, мөгаен, миңа иң мөһимен тапшырырга теләр иде: йорт өчен, нәселыру, синең өчен ,әни, сенелкәшләр, җир, киләчәк өчен җаваплылыкны, тик хәзергә менә минем көчем җитәрлек түгел икән...» Ул моны кычкырып әйтмәде, әмма ишеттерерлек итеп әйткәне аяктан егарлык иде:

—Әни, мин бүген китәм.

Әнисе чәйнеген кулыннан төшереп җибәрә язды.

—Ничек бүген, дүшәмбе көннеме? Сенелкәшләрең белән хушлашмыйча?—дип каушап калды ул, улын ничек кенә токтарларга белмичә.—Берәү дә дүшәмбе көнне юлга чыкмый, ул көн уңышлы булмый—шундый ырым бар,—дисә дә, үз сүзләренең ышандырырлык көчкә ия булуына ышанып җитмәде.

Тик Гаязы ул ягы белән әтисенә охшаган, әйттеме—бетте, кире чигенми. «Исламовлар бар да шундый»,—дип кабатларга ярата иде Нури абый, һәм менә шушы минутларда әнисе аны бик ачык тоемлады.

—Ә мин инглизләрчә китәм,—дип шаяртырга маташты Гаяз, әнисен борчулы уйлардан арындырырга теләп.

—Ничек инде инглизләрчә?—Аптырап калган әнисе кабатлап сорады.

—Саубуллашмыйча. Тотам да сиздерми генә китеп барам. Аларда шулай кабул ителгән...

—Аларда бәлки шулайдыр да, ә менә минемчә, бу—кешеләрчә түгел. Бүреләр генә шулай эшли,—дип үпкәләде әнисе.

—Беләсеңме, бары тик ирләр генә кичектерми башкарырга тиешле эшләр була, син мине аңларга тиеш, әни...

Әнисе җавап бирмәде, улының нияте белән килешеп, юлга хәстәрләү өчен, өйгә кереп китте, аңа шулай күп тапкырлар, еш кына көтмәгәндә, ирен юлга озатырга туры килә иде.

Гаяз да үз бүлмәсенә кереп, әйберләрен тутыра башлады.Чемоданны ишек төбенә куйгач, күзенә диванда яткан төргәк чалынды, аны әнисе өченчекөн биргән иде. Ә ул төргәк турында бөтенләй оныткан.

Сүс бау белән аркылы-торкылы бәйләнгән төргәк шактый күләмле һәм авыр күренә. «Бу өйдән миңа, бәхәссез, шушы тиештер,—дип уйлады ул, төргәкне юл сумкасына сала-сала.—Ни өчен әни бу хатларны, фотографияләрне миңа бирде икән, бәлки нәрсәдер әйтергә, нәрсәнедер искә төшерергә теләведер?.. Кинәт җавап рәвешендә башында бер уй чагылып үтте: «Озын-озак юлда яхшылап уйлап карарга булыр».

Юлга кузгалганчы, хәйран вакыты бар иде, һәм ул Күлләне урап

кайтырга, дөресрәге—аның белән саубуллашырга теләде. Тагын кайчан кайта ала? Бу сорауга Гаяз үзе дә җавап бирә алмады.

Шактый озак йөрде ул: су буена төште, бушап калган иске мәктәпне әйләнеп чыкты, Натальялар йорты яныннан узды, тик биек койма аша үрелеп карарга тәвәккәллеге җитмәде—сирень әле дә исән микән?

Өйгә әйләнеп кайтканда, ишегалдында янәдән өстәл әзерләнгән, тик көндәлек ашъяулык урынына яхшылап крахмалланган ап-ак эскәтер җәелгән иде. Әнисенең өстәлгә самовар куеп маташкан мәле.

—Әйдә, улым, юл уңаена чәй эчеп алыйк,—диде ул, сагышлы итеп. Гаяз әнисен җәлләп куйды.

Әңгәмә барып чыкмады, һәркем үзенекен уйлады.

—Вакыт,—дип, Гаяз өстәл артыннан торды.—Әле билет та аласым бар...—Һәм, әйбер-карасын алырга дип, өйгә кереп китте.

Станциягә кадәр ул туктый-туктый барды, читтән аның әйберләре бик авыр кебек күренгәндер, әмма сәбәп анда түгел: һәр тукталган саен, ул өйләренә борылып карады, авылдан ераклаша барса да, зәңгәр чыршы—әтисенең яратып үстергән агачы аермачык күренеп тора иде...

## II бүлек

Күлле янындагы тимер юлда төзәтү эшләре башланганга, поездлар чикләнгән тизлек белән барырга мәҗбүрләр. Гаяз әйберләрен буш купеның диванына ташлады да коридорга чыгып, бик озак ачык тәрәзә каршында басып торды. Поезд хушлашу минутларын юри озакка суза төсле: каршы килә торган составны светофор янында сабыр гына көтеп ала, аннары ашыкмый гына кузгала да йөрешен кызулатканнан-кызулата бара. Гаяз каршыннан басулар, юллар, агачлыклар, ерымнар, калкулыклар йөгереп узды... Монда, бу иксез-чиксез басуларда, әтисе белән шактый еллар ашлык урдылар, шуңа горизонткача сузылган икмәк кырларын яхшы хәтерли ул. Күзен дә алмый карап бара торгач, соңгы көннәрдә беренче тапкыр аның башына яңа уй-фикерләр килде.

Әгәр Күлледә калган булса, аның тормышы ничек корылган булыр иде икән? Ул бәхетле булыр идеме? Әгәр Гаяз ышанычлы терәк булып, өметләрен аклаган булса, әтисе озаграк яшәр идеме? Ә сеңелкәшләре? Алар аны, ул аларны яратыр идеме? Үзенең Күллесенә—туган җиренә ул ни бирер, нинди эзләр калдырыр иде? Башка яшьтәшләре кебек җан-фәрманга чит-ят җирләргә ашкынып һәм бөтенләйгә югалмавына көенер иде микән? Үзенең фамилиясен яңгыратыр идеме, әллә Нури Исламовның улы гына булып калыр идеме?

Менә никадәр сораулар казып чыгарды поездның әкренәюе һәм тәрәзәдән йөзеп үткән туган як, туган туфрак... Хәтерендә газап чиккән кем тарафыннандыр язылган юллар яңарды :

Нәрсә алып килде аңа ят ераклык?
Ни бирде йөрәккә меннәрчә чакрым?

Гаяз купесына керде, сумкасыннан спорт костюмы—юлда кию өчен пижаманың хәзерге заман варианты—чыгарды, күзенә кабат әнисе биргән төргәк чалынды. Бераз икеләнеп торганнан соң, аны сумкадан алып, өстәлгә куйды. Вагон, инәдән-җептән генә чыккан төсле, өр-яңа иде; бу аның, мөгаен, беренче мәртәбә юлга кузгалуы булгандыр. Ачык яшел тышлы диван һәм өстәл, аның янына җайлы кәнәфи куелган ике кешелек иркен купе, үзенә җәлеп итеп, тыныч сәфәр вәгъдә итә, тавышсыз гына кондиционер эшләп тора, тавыш көчәйткечтән әкрен генә көй агыла. «Бар уңайлыклар

да бар,—дип көлемсерәде Гаяз,—әз генә күнел дә күтәренке булса... «Жиләс купеда нихәтле унайлы тоелса да, аны кабат коридорга—тәрәзә янына тартты.

Актүбәне үттеләр, һәм ашлыгы урып алынган тигез казакъ далалары башланды. Кем өчендер алар—бертөрле, төссез картина. «Даланы күрә белү һәм анлау өчен, димәк, ярату өчен дә, анда туарга кирәк»,—дигән иде кайчандыр менә шулай юлда, поездда очраклы юлдаш—ниндидер карт казакъ.

Ул салкынча буш коридорда төштән сон эссе капкан даланы—бу сәгатьләрдә анда кеше калмый—күзәтеп бик озак басып торды: бар тереклек үзләрен челләдән коткарачак төнне көтеп тынып, катып калган. Ташкент турында, ялдан вакытыннан алда әйләнеп кайтуы турында, калган көннәрне ничек үткәрү һәм аны өендә нинди кичектергесез эшләр көтүе хакында уйланасы килде. Даша ничек икән, ул ана үзенен китәсен бөтенләй дә әйтмәгән иде бит. Шунда, тәрәзә янында басып торганда, Закиржан әкагә бүләк алмавын абайлады, һәм бу анын күнелен төшерде. Ләкин бу уйлар сүлпән, таркау иде. Гаяз уйларынын һаман теге өстәл өстендә яткан төргәккә килеп бәйләнүен анлап алды.

«Юлда бер шөгыль булыр»,—дип уйлады, сүз унаенда гына хәл иткәндәй, ләкин бу битарафлык күз буяу өчен генә, уйлар тагын да ныграк төргәк тирәсендә әйләнде, һәм ул купега керергә мәҗбүр булды.

Кулына алып, игътибар белән карагач, Гаяз төргәкнен инде бик күптән, адрес иясенә тиз генә барып житәсенә исәп тотмый төрелгәнен анлады. Бу аны беркадәр тынычландырды. Нигәдер, әнисе төргәкне Гаязнын бу кайтуында бәйләгәндер дә нидер әйтергә йә исенә төшерергә теләгәндер, дип белгән иде. Бавы бик иске, тузган, төеннәре чияләнгән—ансат кына чишәрмен димә. Кулына пычак алырга туры килде. Пычакнын үтмәсләнгән йөзе белән кисәк кенә сызып жибәрүгә, төргәк кулдан ычкынып китте дә ачык яшел тышлы диванга фотографияләр, открыткалар, язмалар, телеграммалар, хатлар сибелде.

Ул каушавыннан кайсына тотынырга белмичә торды.

«Мин шунын кадәрле яздым микәнни?» дигән уй чагылып узды башыннан. Хатлар арасында ана язылганнары да бар, хәтта берничәсе ачылмаган да. Конвертлар, төрле төстәге кәгазьләр, мөһер, төссезләнгән язу карасы—боларнын барысына да вакыт үзенен эзен салган, диванда чәчелеп яткан шушы кәгазьләрдә—анын яшьлеге, өметләре.

«Менә ул минем гомер юлым, яхшырак күрсәтү өчен купайтылмаган, ничек бар, шулай теркәп куелган,»-дип уйлады Гаяз. Хатлар һәм фотографияләрне системага салырга, йә булмаса хронологик тәртипкә китерергә тырышып маташмады. Инде үзеннен үткән гомеренне актара башлагансын икән, —әле барысы да алда, «утыз яшьтә беренче орден алырга»,—дип йөргән вакытларда тирәнрәк казыну комачаулык итмәс.

Бер хат, очып, читкәрәк барып төшкән, адреслы ягы аста калган. Беренче итеп Гаяз шуна үрелде.

«Исәнмесез, кадерле әти, әни һәм минем сөекле сенелкәшләрем...» Хат шулай башланган, бик тырышып, яхшы—ул чакларда әйткәнчә—шома ялтыравыклы кәгазьгә язылган.

«Чыгарылыш кичәсе, диплом тапшырулар турында мин жентекләп язган идем инде. Омскидан язган ул хатымны алгансыздыр дип ышанам. Ә бу хатымны эшкә билгеләнгән шәһәрдән жибәрәм. Инженер булып эшләячәкмен. Әти, ишетәсенме, ин-же-нер булып! Син бит шунын кадәрле Гаяз Исламовнын инженерлыкка укуын теләгән идең, шулай да, әти, мин һәрвакыт синең тәжрибә белән тупланган белемеңә, синең алтын кулларына

кызыктым һәм кызыгам. Шуны әйтәсем килә: институт тәмамласам да, барыбер алган белем белән эш арасында бик зур аерма күрәм. Мин моны практика үткәндә аңладым. Әллә практиканың барысын да соң чиккәчә гадиләштереп, ансатлаштырып, кешелек туплаган белемне читләтеп үтәсе килә, әллә гыйлем тормыштан аерылып үзе генә яшиме, әмма фән һәм житештерү арасында бердәмлекне сизмим. Бу миңа комачаулар дип куркам, чөнки мин ничек кирәк алай эшләргә җыенмыйм. Шунын кадәр укып, кызыл диплом алуым нәрсәгә кирәк соң ул чакта?

Әйе, сүз уңаенда, минем ул кызыл дипломым сездән башка, хәер, тагын Наталья бар икән әле, беркемдә дә ни соклану, ни гажәпләнү уятмады бугай. Киресенчә түгел микән әле? Кадрлар бүлегендәге хатын мине һәм курсташым Юра Силкинны эшкә алганда, дипломымны күреп төрттерми калмады: «Башлы, димәк». Баш инженер да, безнең белән әңгәмә корганда, ничектер миңа сәер итеп карап-карап алды да ахырдан әйтеп куйды: «Кемнең белеме ничек, алда күрербез». Хәзер мин сизенәм: сәбәп чыкса да, чыкмаса да миңа имтихан оештырачаклар, кечкенә генә ялгышлык, хата да күз уңыннан ычкынмас. Тик сез борчылмагыз, монда төзелеш өстендә төзелеш, өч трест, дистәләгән СМУ—минем кызыл дипломым белән дә эш табылыр, югалмам. Торыр урын бирделәр—аерым бүлмә: тулай торак үзе дә, бүлмәдәге җиһазлар да өр-яңа, хәтта радиоалгыч белән көй уйнаткыч та бар. Шулай да курсташым Силкинның эше уңышлырак булып чыкты. Безне бер трестка билгеләделәр.

Шулай итеп, Силкин турында: ул инде өйләнгән, искиткеч сөйкемле игезәкләре бар, шуңа күрә гаилә белән нишләргә, кайда торырга дип бик борчылды. Ә аңа шунда ук фатир бирделәр, хәтта сайлап алырга тәкъдим иттеләр: ике бүлмәле кирәкме, әллә өчлеме? Бик шатланды Юра, инде гаиләсен көтә. Гомумән алганда, «Зәркәнт төзелеше» тресты нык, таза: комбинат һәм шәһәрне берьюлы төзи, киләчәктә фатир белән проблема булмас дип уйлыйм. Күчеп килү өчен, юл акчалары, прорабның хезмәт хакын—йөз кырык сум—, тәүлекләп түләнә торган акчаларны бирделәр, шуңа күрә кесәм буш түгел. Әле прорабларга хезмәт хакыннан тыш төрле премияләр, өстәмәләр түлиләр дип сөйләшәләр, акча мулдан булачак. Кайбер кышкы киемнәр һәм костюм алам да сезгә җибәрә башлармын, өй салганда кирәге чыгар.

Алдагы хатымда эшем турында, шәһәр турында язармын.

Сау булыгыз, барыгызны да кочып, үбеп, сезнең улыгыз һәм абыегыз Гаяз.

Әйтергә оныткынмын, чын язу өстәле артында утырам. Уңайлы, матур, тоткалары бакырдан.»

«Күңелле вакытлар, язу өстәленә дә, казнаның ялтыратылган җиһазына да куанган, сокланган чаклар»,—дип уйлады Гаяз һәм елмаеп куйды.

Тәрәзәдән шуышып калган берүк картина, җайлы урын, өй ризыгы тутырылган букча, диван өсте тулы хатлар өеме, һәрберсе, тылсымлы вакыт машинасы шикелле, сине үткәненә кайтара ала—тик кулыңны гына суз...

Дала эңгер-меңгере калын пыялалар аша үтеп, купега керде дә почмакларга посты. Гаяз ут яндырды. Хатлар өеме астында зур гына фотографиянең почмагы күренеп калган. Исламов аны, мәктәптә чыгарылыш кичәсендә төшерелгән сурәт дип уйлап, кулына алды. Кемне күрергә теләде ул—үзенме, Натальяны, әллә күптән онытылган классташларынмы? Тик ялгышты, бу—ул рәсем булып чыкмады. Монысы—башка. Профессиональ кул белән эшләнгән бу фоторәсем үз вакытында шактый гәжитләрдә урын алган иде. Фотода— СССР чемпионатының «Б» классы буенча бишенче зона чемпионы »Металлург» футбол командасы. Кайчандыр шундый төркемнәргә

бүленеш тә бар иде. Уң яктагы аскы почмакка, кыйгачлап, ачык матур почерк белән : «Гаяз Исламовка—якын дустыбыз, «Металлург»ның беренче җанатарына—безнең җиңүебез, яшьлегебез истәлеге» дип язылган, һәм язмадан соң команда капитаны Джумбер Джешкарианиның юан кызыл карандаш белән сырлаган имзасы тора. Гаяз фоторәсемнең икенче ягын әйләндерде, анда—футболчыларның төрле төс белән чуарлаган култамгалары. Фотография, күтәп алынган ике очко «Металлург»ны кендәшеннән өстен чыгарып, уен тәмамланганнан соң төшерелгән. Чәч юлы пөхтә итеп ачылган, футболкасы җентекләп кыстырылган Джумбер, елмаеп, беренче рәткә чүгәләгән, аяклары янында торган кубокны кулы белән җинелчә генә әләктергән, ә янәшәсендә—бәхеттән балкыган командасы.

Еллар узу белән, безнең зәвыклар, мавыгулар, гадәтләр ничек үзгәрәләр! Әгәр берәрсе, кайчан да булса Гаяз Исламовның уеннан күңеле кайтып, футболга йөрми башлар, дип фараз иткән булса, көлкегә алган булырлар иде. Хәер, андый кеше табылмас та иде. Балалар тизәйткечен төнлә уятып сораганда да һич тотлыкмый әйтеп чыга алган шикелле, ул—төп состав турында уйлыйсы да юк—«А» төркеменең теләсә кайсы командасындагы бер уенда ике туп керткән уенчысын атап бирә иде. Кайвакытларда кышын (югыйсә,футбол турында сүз дә булырга мөмкин түгел) ана төн уртасында репортаж тапшыралар күк тоела. Караваты янында тумбочкадан «Спидола» транзисторын әләктереп,—ул вакытларда яңа гына күренә башлаган һәм бик сирәк очрый торган әйбер—көйләгечнең тоткасын әйләндерә башлый: трибунадагы шау-шуны, очып барган каты туп тавышын, судья сыбызгысының чырылдавын ачык ишеткән кебек була иде.

Сугыштан соңгы балачак елларында Гаяз берчакны кара тәлинкәле тавыш көчәйткечтән бик кызу сөйләүче Синявскийның өзек-төтек сүзләрен ишетеп калды һәм менә шул көннән бирле бу уенга тугрылыклы җанатарлар исемлегендә инде. Синявскийны аерым-аерым тыңламыйлар. Гаяз әле дә хәтерли, зур уен көннәрендә Күлленең өлкәнрәк малайлары теленнән Бобров, Хомич, Пайчадзе исемнәре төшми иде. Алар алдан ук сүз куешалар: репортажны кайда, кемнәрдә тыңларга. Кара тәлинкә урам якка чыгарып куела, компания шактый алдан өй эргәсенә тезелеп, уенның башланганын көтеп, фикер алыша тора. Кечерәкләр әүвәл читтәрәк чуалалар, чөнки зурракларның куып җибәрәселәрен беләләр, шуңа күрә репортаж башланганын, тагын да ышанычлырагы—команданың көчле һөҗүмгә күчкәнен көтеп торалар да төркемгә елышалар—ул чакта берәүнең дә берәүдә эше калмый. Җиде яшьлекләр тыңлап кына футболда нәрсә аңлаганнардыр инде, әмма комментаторның тавышына, рухи күтәренкелегенә сокланып, өлкәннәрнең, абруйлы егетләрнең самими игътибарына сихерләнеп, әгәр яраткан «Спартак»лары җиңелә калса, зурлардан муен тамырына әләгәсен белә торып, ике тайм буенча шым гына басып торалар.

Гаяз Глориягә дә футбол авыруы йоктырды. Глория күп нәрсәләр белән мавыга иде, шул исәптән футболга да мөкиббән кызда ул үзенә фикердәш тапты. Кыз аның белән бергә, йә булмаса «Металлург» белән Ташкентка—«Пахтакор» уеннарына барырга бик яратты, анда ул чакларда данлыклы Красницкий, Стадник, Абдураимовлар... Нинди көчле җанатар иде ул! Моны үз күзләрең белән күрергә, үз колакларың белән ишетергә кирәк! Юк-юк, ул сикереп тормады, тамагы карлыкканчы кычкырмады, сызгырмады—тик ун минуттан аның янындагылар электрланган кебек булалар иде. Андагы үзгәреш башкаларга да йога, аның үткер, тапкыр сүзләренә колак салалар иде. Сизгерлегенә исең китәрлек, уен барышындагы нервлы киеренкелекне бик тиз чамалап ала, шуңа күрә нәтиҗә чыгарганда сирәк ялгыша. Дуслары уйнаган «Металлург» командасының җиңүләренә

ихластан сөенә, әгәр үзләрендә йә Зәркәнттә җиңелә калсалар, бик нык көенә иде. Шундый уеннардан соң, юеш, пычранган һәм ачулы Джумбернын, чишенү бүлмәсендә Гаязны күргәч, ярсулы күзләре аз гына жылынып китә һәм ана: «Гия ( командада нигәдер аны грузинчага охшатып шулай атыйлар иде), зинһар, Глорияне тизрәк алып кит, шундый хурлыклы уеннан соң аның күзләренә карарга оят»,—ди торган иде.

Һәрбер җиңүне ничек горур, бәхетле кичерәләр иде, һәр уенчы алар утырган трибуна янынннан (анда аларның даими урыннары бар) үткәндә, гладиатор үз корбанын аяк астына китереп салган шикелле, Глориягә җиңеп алынган кыйммәтле әйберне тапшырган кебек куаналар, кыз да аларны буш калдырмый: үзенең сөйкемле елмаюын бүләк итә, алар белән бергә шатлана. Команда читтәге уеннардан җинелеп кайткан очракларда, Джумбер, Глориянең шелтәләрен тынлаганнан соң:

—Глория, без анда кем өчен җиңик, безнен талисман син бит. Ир-егеткә бүләк итәр кешесе булмаганда җиңү нигә...—дип шаярта иде.

Гаяз еракта калган теге аяз, якты көзге көнне ( язгы көнгә охшаса да таулардан инде кыш исе килә иде) бик яхшы хәтерли. Глория белән икесен көчләп диярлек фотога төшәргә кыстадылар, әмма кыз бирешмәде.

—Бу сезнең җиңү, егетләр,—диде ул, дулкынлануын һәм күз яшьләрен көч-хәл белән тыеп, аларның юеш, пычрак битләреннән үпте, үзе ак күлмәгенең Джумбернын җиңү өчен барын да биргән футболкасына охшап калуын сизмәде дә.

Гаязны Глория белән футбол, дөресрәге, Джумбер таныштырды, хәер, ничек әйтсәң дә дөрес булыр иде.

Кеше хәтере гаҗәеп искитмәле: кайбер нәрсәләрне без төс-буяулары, шау-шу, тавыш, исе белән хәтерлибез, һәм, бераз вакыт узып, үткәннәргә күз салсаң—шаккатасың: син боларын теге вакытта бөтенләй искәрмәгәнсең икән бит.

Зәркәнт... Шәһәрнең исемендә Гаязга гына аңлаешлы ниндидер көй бар шикелле. Һәр кешенең күңеленә якын шәһәре була: исемен генә исеңә төшергәндә дә сискәндереп җибәрә һәм эчендә нәрсәдер шарт итеп өзелгән күк тоела, күз ачып йомган ара да үтми, рәхәт итеп баш әйләнә башлый. Шәһәр төрлечә булырга мөмкин: зурмы яки кечкенәме, искеме йә яңамы, данлыклы, танылганмы яисә тавыш-тынсыз тыныч кынамы—эш анда түгел, ул синең үзеннеке, йөрәгеннең бер кисәге булырга тиеш. Синең соңгы көннәрең, йөрәгеннең ахырдан истәлекләрдән өзгәләнмәвен теләсәң, нәкъ менә шул шәһәрдә узарга тиеш. Монда синен яшьлегенне, уңышларыңны хәтерләгән хет бер тере җан иясе булырга, сиңа беркөнне очрап: «Ай-яй, син бөркет идең, ә синең йөргән кызың... Хәзер андыйлар юк»,—диярга мөмкин.

Кемдер, бәлки, ышаныр-ышанмас елмаер—Зәркәнт? Менә сиңа зәвык! Ул шәһәргә торак алмаштыру белешмәләрендә дә югары бәя куелмый бит? Хәер, ник аңлатып, акланып маташырга? Гади генә итеп әйткәндә, анда яшәсә дә, бу аның шәһәре түгел. Мондый кешеләр җәл, чөнки алар җирсез-йортсыз кешеләргә тиң. Азиянең эссе каплаган күгенә йөк күтәрү манаралары тераләгән, Зәркәнтнең ул вакытта көн-төн төзелгән мәле, кичтән булмаган әйбернең иртәнгә калкып чыккан чагы.

Гаяз килгәндә, шәһәрдә беркадәр урыннар билгеләнгән иде инде. Үзәктә, табигый калкулыкта, төп урамнан аз гына читтәрәк кечерәк кенә бакчасы һәм фонтаны белән мәһабәт «Космос» кинотеатры утыра. Бу урын шәһәр кешеләре арасында киң танылды, кала үсеп, башка шундый үзенчәлекле җирләр күренгәнче, озак еллар күрешү урыны булып торды. Шулай да Зәркәнтнең иң зур мактанычы—стадион иде. Спорт мәйданчыгы өчен

үзәккә якын гына урнашкан паркта унайлы урын бирелгән.

Ун мең кешегә исәпләп, уйлап проектлаштырылган, күз явын алырлык уңышлы төзелгән бу стадион үзенең кышкы спорт заллары, йөзү спорты сарае белән бик күпләрне үзенә тартып тора. Металлургларның үзбәк шәһәрендәге (каланы әле төзисе дә төзисе) шушы зур булмаган стадионы үзәк матбугатта еш телгә алынды. Эш менә нәрсәдә: ил күләмендә бу—узыш юллары булган өченче стадион, һәм иртә яздан Зәркәнткә иң атаклы узышчылар—күпчелеге Уфадан—җыйнала. Һәр якшәмбедә ярышлар: кайсы гына исемгә күз салма, йә күп тапкырлар дөнья чемпионы, күп тапкырлар Европа чемпионы, күп тапкырлар СССР чемпионы, һәр фамилия алдында һәрбер спортчы өчен изге булган өч хәреф тора: а.с.м.—атказанган спорт мастеры. Андый белдерүләр белән җанатарларны һәм зур башкалаларны сирәк узындыралар. Дөньяга танылган Габдрахман Кадыйровның кызыл шарфы Зәркәнт җилләрендә бер яз гына җилфердәмәгәндер.Соңгы, хәлиткеч узышта Игорь Плеханов, Борис Самородов, Габдрахман Кадыйров һәм ярышларның лидерлары белән финалга чыккан кайсыдыр дүртенче спортчы очрашкач, стадионда ниләр булганын күз алдына китерүе дә кыен. Әмма иң осталар бер басмадан артыкка юл куймыйлар, башкача бүленеш шаккатыргыч хәл санала иде. Дүртенчегә күбрәк инде берничә мәртәбә китеп, янәдән узышу юлына кире кайткан өлкәнәеп баручы танылган Фәрит Шәйнуров, йә әле бик яшь, артык чая, мотоциклын атны үрә катырган кебек күтәргән Чика—Зәркәнттә Юрий Чекрановны яратып шулай атыйлар иде—чыга. Гадәттә җиңүче булып Борис Самородов кала.

Зифа буйлы, яшь кызлар төсле оялчан Габдрахман Кадыйров, үзенең мәшһүр шарфын сүтә-сүтә, җанатарлары каршында гаепле елмаеп аклана-килеп чыкмады. Алай да икенче урыннан төшкәне булмады, әле анысын да еш кына фотофиниш аша тәгаенлиләр иде.

«Сабыр итегез, кышын мин сезне унайсыз хәлгә куймам»,—дип өметләндерде кумир һәм кызларның кульяулыкларын читкә этәрде. Көек исен хуш исле яулык белән генә бетереп булмый. «Куышкан» вакытларында спидвейда, боз өстендәге узышларда ана тиңнәр табылмады, ул беркемгә баш бирми җиде тапкыр дөнья чемпионы, унике тапкыр СССР чемпионы булды һәм спидвей короленең кызыл шарфын Европа башкалаларының боз мәйданнарында бик озак искә алдылар әле.

Сонрак Глория Гаязга болай дигән иде: «Яна төзелгән Яшьләр сарае фойесында зур диварны «Мотоциклетта узышучылар» дигән мозаик панно бизәвен телим, тик узышучыларның йөзләре абстракт түгел, ә тормыштагыча: беренче юлдагы борылышка омтылучы Самородов—Кадыйров—Плеханов, уртада, әлбәттә, үзенең онытылмас кызыл шарфын җилфердәтеп Габрахман ясалсын иде.»

Яшь шәһәрнең кумирлары спортчылар булуына гаҗәпләнерлекмени? Нәрсә ул узышучылар! Алар мираж шикелле, күннән тегелгән комбинезоннары һәм танылган фирмаларның акылга сыймаслык бизәкләр белән чуарланган шлемнарыннан купшыланып, җилдәй җитез үтеп китәләр—йөзләрен дә күреп өлгермисең,—һәм көннәрдән бер көнне, вакытларын җанатарларына караганда күбрәк бүлгән бәһасез машиналарын төяп, үзләреннән соң стадионда аерым бер тәмле ис һәм төтен калдырып, китеп тә баралар. Чын кумирлар алар—футболчылар!..

Глория... Гаяз аның фотосын эзләргә тотынмакчы иде, шунда ук кире уйлады. Нигә, әгәр теләсә, ул болай да аны күз алдына китереп бастыра ала. Уйларының Глориягә күчүе белән, купеда язгы Зәркәнт җилләре исеп киткән кебек тоелды, җилләр анда бөтенләй үзгә, чөнки Зәркәнт өч яктан таулар белән уратылган, бары тик Ахангаран һәм Ташкентка гына

кин, иркен дала чыга. Тауларда бадам һәм чикләвек агачлары ал төскә кереп чәчәккә күмелеп утыралар, зур мәйданны биләгән карт алмагачлар кар астында калган кебек ап-акка төренгәннәр, бадам һәм алмагачлардан аңкыган чәчәк исләренә, тоташ яшәреп килгән таулар исе бергә кушылып, болай да яшь, кайнар башларны тагын да иләсләндереп җибәрә.

Әйе, алар танышканда яз иде. Гаяз инде өлкән прораб. Ул бик ачык хәтерли—шимбә, эш көн иде; әле биш көнлек эш атнасына күчү турында сүзләр генә бара. Идарә начальнигы—стажлы төзүче—шимбәләрен алай шелтәләр бирми, орышмый-тиргәми, моның өчен көн саен һәркем мәҗбүри катнашырга тиешле планеркалар бар. Киңәшмәләр тәмамланганда гына, киереп ачылган тәрәзәләргә төбәлгән мастер һәм прорабларга карап, канәгатьсезлеген (чыраеннан аның ясалма икәне күренеп тора) белдереп ала: «Күрәм, күрәм, яз җиттеме, барыгызның уенда бер нәрсә—футбол да, ничек әле, ие, спидвей дигәннәре. Барысы да шулар белән шашкан. Ярар, бетте, сез дә йөгерегез».

Һәм кырык минутлап алдан җибәрә. Сызымчылар шундук, кечкенә малайлар төсле, ишеккә ябырылалар, күз ачып йомганчы, берсе өстенә берсе өелеп тоткарлык ясыйлар, ә кайбер түземсезләре ачык тәрәзә аша сикерә.

Яшьләр яна аякка басып килә торган шәһәрдә, иң төп корылма буларак, стадион төзү идеясен үзләренең кырыс начальниклары күтәреп чыгуын күз алдына да китермиләр. Футболны да ул үз кул астында эшләүче кызу канлы ир-егетләрдән ким яратмый, әмма күпме генә әйләнмә-тулганма—барыбер вакыт җиткереп булмый иде. Кургаш-цинк комбинаты кебек шундый әһәмиятле дәүләт корылмасы төзүне теләсә кемгә ышанып тапшырмыйлар. Начальник ачык тәрәзә янына килде һәм егетләренең маршрут автобусларын да көтми шәһәр ягына бара торган машиналарны аулауларын карап торды. «Әле аларда андый азарт, кызыксыну барында, комбинатны без, һичшиксез, төзиячәкбез»,—диде бушап калган кабинет хуҗасы. Ә бу эш еллар буена сузылачак: башта беренче чиратны төзисе, аннары икенчесен, өченчесен...Теләсә кем уникe сәгатьлек эш көненә түзә, һәр көн объект, анда эшләүчеләр өчен җаваплылыкны күтәрә алмый. Әйе, яшьлек еллары хәтерләрендә төзелеш мәйданчыгы белән генә калырга тиеш түгел—ул моны да аңлый иде.

Гаяз үзенең ничек итеп чит-ят СМУ машинасында тулай торакка килүен хәтерли: машина туктар-туктамас сикереп төшеп, күңеле менә бүген аның тормышында нindидер мөһим, гадәттән тыш вакыйга булырын сизгән кебек, баскыч басмаларын өч атлыйсын бер сикереп, үзе яшәячәк өченче катка очып менгән иде. Яшь вакытта бик гади генә бит ул: коендың, чиста күлмәк, үтүкләнгән костюм киеп көзгегә күз ташладың—нинди тыгыз үткән көннең ару-талулары, аның яше һәм белгечлегенә караганда шактый күп мәшәкать-бурычлар юып алгандай була. Һәр чорның үз үзенчәлекләре: үз стиле, жаргоны, кумирлары, модасы дигәндәй, әгәр Гаяздан яшьлегенә хас берәр үзенчәлекне әйт әле дисәләр, ул уйлап та тормыйча, болай дияр иде: пөхтәлек, төгәллек, тагын да камилрәк булырга омтылу.

Яшь шәһәрдә Тбилиси, Мәскәү, Ташкент футболчыларының яңа мода алып килүчеләр дигән даны чыккан... Ә команда үзенең капитанына—футболга җаны-тәне белән бирелгән, иң яхшы уенчы, әйтеп бетергесез пөхтә, төгәл,тумыштан грузин халкының күркәмлегенә, зәвыгына ия булган кешесенә төбәлгән. Хәзер хәтта халыкара матчларда да сакал-мыегы җиткән, гетры—оеклары салынып төшкән, бөгәрләнеп беткән күлмәкле футболчыны күрү берәүне дә гаҗәпләндерми, чөнки гадәти күренеш; ә менә Джумберныкылар гадәти матчларга да нәни генә пычрак чәчрәгән бутсыдан чыкмады.

Көй уйнаткычны кабызып, киенә башлагач, Гаяз исенә төшерде: бүген кызлар төп корпусның түшәмнәрен штукатурладылар. Шундый авыр эштән соң, бер уйласаң, барысында да «ничек кенә тулай торакка кайтып житәргә дә урынга аварга...» дигән теләк кенәдер кебек. Юк шул, яшьлек барыбер үзенекен итә: көн азагы житкәндә, кызлар үзләре чыгарган шаян жырга (кушымтасы «О, шимбә! О шимбә!—дип тәмамлана иде) бии-бии эшләделәр.

Тәрәзә артында инде шимбә киче: парктан көй агыла, урам лампалары кабынды, тулай торак әкрен генә бушап калды. Гаяз да ашыкты, аның яратып ял итә торган урыннары бар иде инде, өстәвенә, мото куучылар килгән, иртәгә белдерүләр зур узыш вәгъдә итә, һәм бу күренекле кунакларны кайда очратып буласын ул яхшы белә иде.

Алтмышынчы еллар башында яшьләрнең буш вакытын оештыруга зур игътибар бирелә башлады, ә инде Зәркәнт кебек яшь шәһәр тормышына бу һич кенә дә кагылмыйча кала алмый. Яшьләр сарайлары, клублары, спорт сарайлары, бәхет сарайлары, театр-студияләр, яшьләр театрлары, вокал-инструменталь ансамбльләр, яшьләр кафесы—болар бар да хәзер гадәти, көндәлек нәрсәләр, ә бит боларга нигез шул вакытларда салынды. Үзенең яшь архитектор, төзүчеләре булган Зәркәнт тә, комсомолларның якшәмбе өмәләрендә эшләп алган акчаларына җәмәгать тәртибендә җәйге яшьләр кафесы төзеде, читтән килгәннәрне аның архитектурасы, интерьеры сокландырды, таң калдырды. Менә шул Яшьләр кафесы—«Энже бөртеге»нә якынлашкач, Гаяз уен коралларын көйләгән авазлар ишетте. Күз чагылдыргыч утлар белән яктыртылган гажәп зур куышлык ерактан ук бәйрәм, уен-көлке вәгъдә итә. Буяулар һәм төс—«Энже бөртеге»нең архитектурасын хәл иткәндә катнашкан күп компонентлардан бер-икесе генә. Кафе башта архитектор тарафыннан киң масса өчен —шәһәрдә тулай торак өстендә тулай торак бит,—һәм жәйге—чөнки Зәркәнттә тугыз ай буе менә дигән һава торышы—дип уйланылган. Нәрсәгә кешеләрне тимер-бетон читлекләргә, пыяла аквариумнарга куып кертергә, саф һава иснәсеннәр, ял итсеннәр, биесеннәр. «Энже бөртеге»нең гаять зур куышлыгы кафенең мәрмәр-гранит валчыкларыннан коеп ясалган һәм көзгедәй шомартылган утыру мәйданының өчтән берен дә капламый. Бу мәйдан төрле калынлыктагы яссы бакыр кисәкләре ( суынырга өлгермәгән массага батырылган һәм шомартканнан соң өслегендә үткен алтын эз калган) белән бүлемнәргә бүлгәләнгән. Һәрбер бүлем билгеле бер төснең кыйпылчыклары белән тулган һәм уртасында шул ук алтын сызыклардан торган гажәеп чәчәге бар. Явым-төшемле һавада, сирәк-мирәк йә язгы коеп яуган яңгырларда түбәнең капланган өлешенә эләгә алмаган ял итүчеләр үзләрен читкә кагылган дип уйламасыннар өчен, һәр бүлемдә аерым бер урында күз күрмәгән илләрдән кайтартылган шикелле сәер агач «үсеп утыра» һәм аның әкәмәт зур яфраклары калган өстәлләрне дә «саклый».

Гаяз саран гына яктыртылган ишек төбендә туктап калды да өстәлләргә күз салды. Бүген монда аның бик күп танышлары жыелган: СМУ дан егетләр, үз участогы кызлары; хәтта Силкинга кадәр игезәкләрен карап торырга кеше тапсалар, хатыны белән бер-ике сәгатькә килеп чыгарга ышандырды. Кинәт аңа кемдер эндәште:

—Гия, безнең янга кил.—Теге сәер агач астындагы өстәлдән аңа «Металлург»ның кырый һөҗүмчеләре Джумбер, Тамаз Антидзе һәм Роберт Гогелия сәламләп кул болгадылар.

Гаяз, елмаеп, кулын күтәреп сәлам бирде. Якынлаша төшкәч, ул Тамаз каршында Гаязга аркасы белән утырган бер кызны шәйләп алды. Кызның озын муены үтә нәфис, яклаучысыз сыман тоела, шуңа күрә авыр, күз

явын алырлык чәчләре махсус баш артына тыгыз итеп төенләнгән кебек хис калдыра.

—Сез танышмы?—дип сорады Джумбер, Гаязның кызыксынучан карашын тотып.—Алайса,таныш булыгыз, Глория: Гия—безнен дус, шул ук вакытта начальник, мондый хәл тормышта сирәк була.

—Глория.—Кыз баса төште һәм, бераз гына чытлыкланып, тар өстәл аша кулын сузды, ә Гаяз, иелеп, аның нечкә беләзегеннән үпте.

...Теге вакытта Күлледә Наталья белән очрашканда да яз иде. Мөгаен, шул вакытта Наталья, күп еллардан соң ниләр буласын сизенгәндер, бәлки менә шушы кечне һәм карадан киенгән кызны күз алдына китереп, бите буйлап тәгәрәгән яшь тамчыларын яшертен генә сыпырып төшергәндер дә Гаязга истәлеккә сирень чәчкәләре бүләк иткәндер...

—Алайса, сез тренер буласыз, үзегезнекеләрнен буш вакытларын ничек үткәрүләрен карарга кердегезме? Әйтеп бирәм: Тамазнын инде бишенче сигареты, менә төпчекләре көл савытында.

—Кара син аны, нинди чибәр, өстәвенә акыллы дип тә әйтәләр, ә үзе гап-гади бер әләкче булып чыкты,—дип бүлдерде аны Тамаз, көлемсерәп, һәм тартмасыннан тагын бер сигарет алды.

—Мин тренер түгел, Глория.

—Джумбер, тагын шаяртуыңмы? Син бит Гияне сезнен начальник диден.

—Нәкъ шулай, кадерлем, безнең баш начальник. Безне туйдыручы...—һәм Джумбер белән Тамаз икесе берьюлы Гаязны кочаклап алдылар.

Үзен инде өчәүләп шаярталар дип уйлап, югалып калган кызны үпкәләтмәс өчен, Гаяз ашыгып аңлатырга кереште:

—Әйе, ниндидер мәгънәдә мин аларның начальниклары. Гәрчә аларны бик еш күрмәсәм дә: менә кичләрен «Энже бөртеге»ндә йә «Космос»та һәм, билгеле инде, уен кырында очрата алам. Бу һөҗүмчеләргә ай саен хезмәт хакын түләү буенча нарядны мин ябам, менә шушы өч бөркет минем участок эшчеләре булып санала. Джумбер бу айда—алтынчы разрядлы балта остасы, ул—капитан, лидер. Тамаз белән Роберт берәр ранг түбәнрәк—бишенче разрядлы, тупны әзрәк кертәләр.—Һәм калганнар кәефенә яраклашып, Глорияне шаяртуын дәвам итте:—Әгәр дә мәгәр, бүген алар үзләрен тиешле дәрәҗәдә тотмасалар, өстәл артындагы берданбер кызга тиешле игътибар бирмәсәләр, мин, һичшиксез, аларның разрядларын түбән төшерәм. Кесәгә сугу—иң тәэсирле сугу, минем начальнигым шулай уйлый.

—Глория, мин сезнең күзләрегездә яшь күрәм... Курыкмагыз, Гия бик мәрхәмәтле һәм бик тә футбол ярата, андый адымга бармас...

Джумберның шаяртуыннан өстәл янындагылар дәррәү көлеп җибәрделәр.

Аз сүзле Роберт, Джумберның аркасына ышыкланып, официантка ниндидер ишарәләр ясады, һәм тегесе озакламый зур савыт белән куе кызыл төче чия китереп куйды.

—Сез төзүче, алайса?—дип сорады кыз, нигәдер куанып.

—Әйе, өлкән прораб.

—Ә без сезнең белән өлешчә коллегалар, мин бит архитектор. Тик мин төзүчеләр белән һаман көрәшәм—тыныч кына берни барып чыкмый. Алар миңа утыз яшендә инфаркт эләктерәчәксең диләр...—Кинәт ул, Тамаз белән урынын алыштырып, Гаяз янәшәсенә утырды һәм хыялга бирелеп дәвам итте:—Әгәр мин шәһәребез өчен гадәти булмаган берәр нәрсә иҗат итсәм, ә сез төзесәгез—ничек шәп булыр иде. Миңа калса, сез мине инфарктка җиткермәс идегез, сез мине аңлар идегез,—дип, сүзен бөтенләй башкача тәмамлады.

Гаяз кызның күзләрендә сагыш күрде. Анын башында «сәер кыз» диган уй чагылып үтте.

—Глория, сине күптәннән хөрмәт итүчеләр алдында андый сүзләр сөйләү—вөҗдансызлык. Ә кинәт Гия борынын күтәреп куйса?

Өстәл янында күнел ачу дәвам итте. Алардан ерак түгел, күрше бүлемдә, берничә өстәл алып, узышчылар утыра, алар янында танылган спортчыларны озатып йөрүче техник персонал да бар, ахры, һәрхәлдә, шуларга охшаган.

—Миңа Кадыйровны күрсәтегез әле,—дип үтенде кинәт Глория.

—Әнә кара, китлар аерым—оркестр белән янәшәдәге өстәл артында утыралар,—диде әлегә кадәр дәшми утырган Роберт.

Зур өстәл янында җиделәп кеше. Өлкәнрәкләре костюм, галстуктан, ә яшьрәкләре исә джинсы чалбар, күзгә бәрелеп торган эмблемалы пуловерлар, бизәксез күлмәкләр кигәннәр һәм, әйтерсең, безнең артыгын ашыкмас моданы унбишләп елга узып киткәннәр. Әллә каян сизелеп тора: болар дөнья күргән халык. Үзләренең дәрәҗәләрен яхшы беләләр, тыныч кына утыралар. Оркестр уйнап җибәрде. Тамаз, мондагылардан гафу сорап, күрше өстәлдәге кызны биергә чакырды.

—Минем Кадыйров белән танцевать итәсем килә. Атаклы кешеләр белән аралашу уңыш китерә, диләр. Ә мин хорафатларга ышанам. Минем дә күренекле кеше буласым килә!—Глория каядыр еракка төбәлеп, житди генә сүзен тәмамлады. Күрәсең, анын уйлары монда түгел иде.

—Әгәр дә биисең килә икән—чакыр.—Джумбер анын тавышынын үзгәрүенә игътибар итеп тормыйча, тыныч кына үзенең кинәшен бирде.

—Әгәр кире какса?—Глориянең табигый куркынган тавышы Гаязны аптырашта калдырды.

—Синамы?—дип гаҗәпләнде Джумбер һәм, елмаеп:—Синең үтенечне үтәмәгән берәр егетне күрер идем мин!—дип куйды. Минут та узмады:

—Нәрсә булса, шул булыр!—диде кыз, чытлыкланып, аңарда каушау һәм икеләнүнең эзе дә калмады.

—Карале, Гия, алар бииләр, сөйләшәләр, әйтерсең, әллә кайчангы дуслар. Глория Габдрахманнан озынрак дип кем әйтә? Таң калырлык үз-үзен тотышына. Кара аны, Гия, гашыйк булып куйма, андый кыз ир-егетләр өчен бәхет тә, һәлакәт тә...

Кич утыруны алар узышчылар белән бергәләп дәвам иттеләр, һәм ахырга кадәр кызлардан Глория берүзе булды. Барысы бергә кунакларны кунакханәгә кадәр озата бардылар, ә узышчылар исә юл буе Глориядән иртәгә булачак ярышта кем өчен җан атасын белергә теләделәр. Кызый, болай да оялчан Кадыйровны, үзенең җавабы белән тагын да кызартып:

—Билгеле инде, Зәркәнттәге бар халык кебек, Габдрахман өчен,—диде. Кунакханә ишек төбендә теләр-теләмәс кенә саубуллаштылар,—узышчыларны авыр көн көтә иде. Джумбер Гаяздан:

—Гия, Глорияне озатып куйчы, зинһар,—дип үтенде.—Мин бүген тренер урынында, соңга калырга ярамый, шуның өстенә иртә таңнан күнегүләр ясарга кирәк. Йоклап калмасаң, син дә сугыл.

Җае килгәндә, Гаяз алар белән бергә шөгыльләнә, ике яклы уеннарда да катнаша иде.

Кешесез тын урамнан атлаганда, Глория сорап куйды:

—Гия, сиңа «Энҗе бөртеге» ошыймы? Архитектурасын, бизәлешен күз алдында тотуым.

—Искиткеч кафе. Миңа шактый җирләрдә булырга туры килде. Мәсәлән, мин укыган Омскида яшьләр өчен андый гаҗәеп матур, һәркем керә алырлык урыннар юк иде.

—Алай булгач, нигә мине тәбрик итмәдең?—диде, үпкәләгән сыман.

—Нәрсә белән?—Гаяз каушап китте.

—Бер ай элек син бу кафены ачканда булмадыңмыни?

—Ул турыда белсәм дә, туры килмәде шул. Икенче сменада идем.

—Ә, минә ничек икән,—диде кыз битараф кына.—Архитекторы кем, ишетмәдеңме?

—Колак чите белән генә. Фамилиясе әрмәннеке бугай.

—Караян?

—Әйе, әйе, җитди, яңгыравыклы фамилия, мөгаен, танылган архитектордыр.

—Алайса, үзем белән таныштырырга рөхсәт итегез—Глория Караян.—Кыз барган җиреннән туктап, шаярып башын иде дә егеткә кулын сузды.

—Син шул архитекторның кызымы? Зинһар, әтиеңне тәбрик ит! Сокланырлык хезмәт.

—Гия, әгәр тагын бер мәртәбә мыскыл итсәң, мин китәм... Хәйран калудан Гаязның аяклары атламас хәлгә килде...—Син... Синме кафеның архитекторы? Шундый...

—Дәвам ит, дәвам ит... Нинди соң? Борын асты кипмәгән дип әйтәсең киләме? Әх, бу төзүче халкы...—ләкин аның тавышында гаепләү сизелмәде, киресенчә, Гаязны аптырашта калдыруына куана иде.—Тагын бер мәгълүмат өстим: Караян, бәлки, әрмән фамилиясен хәтерләтәдер, тик миндә әрмән каны акмый... Минем ата-бабаларым—Европада билгеле архитекторлар, Россиягә бер ярым гасыр элек чакырылган булганнар, һәм минә берничә буыннан соң миндә аларның геннары кабатланган.

Гаяз әле дә үз хәленә кайта алмый иде.

—Ничек булдыра алдың, Глория?

—Сиңа, чыннан да, кызыкмы?—Кыз аны култыклап алды.—Алайса, тыңла...

Мин биредә ярты ел диплом алды практикасында булдым. Архитектор буларак, шәһәр миңа ошады, чөнки монда бар да нульдән башланган һәм үзеңне күрсәтү өчен менә дигән мөмкинлек бар. Мин инде үзем практика үткән «Градострой»ны карап куйган идем, шунда миңа, институтны тәмамлагач, Зәркәнткә кайтырга тәкъдим ясадылар. Шәһәр яшь, халкы да—яшьләр. Менә шул чакта башыма шушы фикер килде дә инде. Ул яшьләр соравын канәгатьләндерергә тиеш иде. Минем алга мондый бурыч куелды: инде ияләшкән һәм бетүгә йөз тоткан танцы мәйданчыгы һәм кунак кабул итү бүлмәсе—гәрчә анда мине бәйрәм тантанасы һәм биюләр арасында утырып ял итәргә йә әңгәмә корырга куелган өстәлләр генә кызыксындырды—шуларның икесенең уртасы булырдай берәр нәрсә уйлап табарга.

Шулай да төп идеяне миңа шәһәр үзе бүләк итте. Эссе климат, җиләк-җимеш искиткеч, газлы һәм минераль суга таләп зур. Син, мөгаен, игътибар иткәнсеңдер, «Энҗе бөртеге»ндә «Экспрессо» кофе өчен кыйммәтле аппаратлар белән җиһазланган кечкенә буфетлар юк, гомумән, үзбәкләргә ят булган кофе бөтенләй кулланылмый. Аның каравы, туңдырма һәм газлы сулар җитештерүче цехлар булдыруны күздә тоттым, шуңа кафе аларны читтән китертүгә мохтаҗ түгел. Бу очракта үземә архитектор вазифасы гына алмадым. Мин дә бит башкалар шикелле үк—кулланучы, үзем дә яшь булганга, яшьләрнең теләкләрен якларга тырыштым. Шуның өчен бу цехны булдыруны алдан ук максат итеп куйдым, сәүдәнең, үзең беләсең, урынга ия булу белән, иртәме-соңмы тиеннәр генә торган су һәм туңдырма ташу теләге бетә дә киштәләрне кыйммәтле коньяклар белән шыплап тутыра. Ә биредә цехлар җитештерә, телисеңме-юкмы сатарга туры килә. Мин боларын аңладым, тик әле кафеның нинди буласын күз алдыма китерә

алмадым. Махсус минем өчен әзерләп куелгандай урынны күргәч, мине чын-чынлап мавыгу биләп алды. Һәр кичне буш жиргә килеп, кафены күзалларга тырыштым, тик очына гына чыгып булмады... Ничек итеп кенә уйласам да, ул гаять зур һәм кыйммәткә төшә торган булып чыкты. Төзелешнең иң аз чыгымнар белән озак дигәндә ярты елда төзелергә тиешлеген искәрткәннәр иде. Гаяз, мин сине ялкытмадыммы?

Әмма аның игътибар белән тыңлавын күргәч, канатланып дәвам итте:

—Мин кафе салыначак урынга көн саен: таң атканда да, шәфәкъ батканда да, көндезен, эңгер-меңгердә дә килдем. Шулай итеп, беренчесеннән әһәмияте һич ким булмаган икенче фикер туды. Шәһәр үзе вазифам буенча карар кабул итәргә ярдәм итсә, буш урын исә хыялым тормышка ашар дигән ышаныч уятты. Һәм менә ни өчен?

Башта: «Кем соң әле мин?»—дип уйладым. Көлмә, Гаяз, шик-шөбһәләр еш кына миннән өстен чыкты. Проектымны кем күреп алыр? Кем аны хуплар? Кем аны төзелеш исемлегенә һәм кайсы елга кертер? Кистереп һәм ышанып, бер генә сорауга да жавап бирә алмый идем. Ләкин проектны ерып чыгу өчен еллар китәсен беләм. Үземне менә хәзер, кичекмәстән күрсәтәсем килә—миндә шундый ижади ашкыну туды. Һәм проектымны жәмәгать башлангычында—шәһәргә шәхси бүләк итеп эшләргә уйладым, ә аннан соң инде эшемне комсомолның шәһәр комитетына, яшьләр хөкеменә куеп, аның игътибарга лаек икәнлеген раслый алуыма шикләнмәдем.

Борылышка житкәч, төн карангысын яктыртып кабынган кызыл светофор янында Глория, кинәт шаяртуга борып:

—Менә мин шундый дан, шөһрәт яратучы инде,—диде.

—Шөһрәт ярату—әле начар дигән сүз түгел.—Гаяз аны тынычландырырга ашыкты. Ул бу минутларда үзенең ни теләвен: кызны тыңларгамы, әллә үзен күзәтергәме—аңларлык халәттә түгел иде.

—Жәмәгать тәртибендәге проект жәмәгатьчелек белән төзүне таләп итә. Финанслау ягы өчен әллә ни борчылмадым: акчаның нәрсәгә тотыласын белсәләр, яшьләрне якшәмбе өмәләренә тартырга була. Кафенең нинди буласын тәмам ачыклап бетергәндә, практикам тәмамланырга ике ай вакыт калган иде. Идеямне житәкчем белән уртаклаштым, ул мине аңлады, хуплады. Нәкъ менә шул вакытта ул, институтны тәмамлагач, Зәркәнткә кайтырга тәкъдим итте дә инде. Берүземә бирелгән аерым бүлмәмдә бикләнеп, иртә таңнан, кайчагында кара төнгә кадәр утырдым. Рациональ булуым мине тагын коткарды. Проектны алты айдан кимрәк вакытта эшләп бетерергә көчем житмәслеген аңлагач, киткәнче, шәһәр комитетына сугылырга уйладым. Башта проектның эскизын, макетын, рәсемнәр эшләдем : бик зур табаклы кәгазьдә гомуми күренеше, аерым куышлыкның үзен, гомумән, отышлы детальләрен—бөтенесен дә төсле итеп ясадым.

—Шуның кадәр бирелгәнлекне күр әле!—дип сокланды Гаяз.

Кыз аның аңлавы өчен рәхмәтен белдергәндәй елмайды.

—Нәкъ шулай булды да... Китәремә бер атна калгач, баш архитектор комсомолның шәһәр комитеты секретаре белән очрашу оештырды. Ә ул һөнәре буенча төзүче булып чыкты, ана үземнең идеяләремне йоктыра алдым. Секретарь миннән бары тик бер нәрсәне—шәһәр активы алдында да шулай ышандырырлык итеп чыгыш ясый алырмынмы икәнен генә сорады. Идеяләремне теләсә кайда якларга әзер икәнемне белдердем. «Градострой»дагы яшь коллегаларым мина стендлар оештырырга булыштылар, моның буенча аларның тәжрибәләре житәрлек иде. Ләкин мина күрсәтмәлелек кенә аз, ышандырырга кирәклеген белә идем. Үзем өчен машинка язуы белән ун битлек чыгыш әзерләдем, анда кафемнын һәрбер детале ничек бар, шулай куелмаган, ә минем тарафтан нәкъ

менә Зәркәнт өчен, Урта Азия зонасы өчен махсус уйланылган икәнен анлатырга тырыштым. Мисал өчен, идәннәр. Нигә мәрмәр-гранит кыйпылчыкларыннан коелган? Чөнки бу материалга Үзбәкстанда кытлык юк, шомартып ялтыратылган идәннәр гигиеник таләпләргә җавап бирә, ә иң мөһиме: алар салкынча булалар. Әгәр ачылырга ярты сәгатьләр кала шлангтан су йөгертеп алсаң, аларнын төсләре жетеләнә, жиләслек арта, кич буена салкынча була, бу—бик әһәмиятле, чөнки Зәркәнттә кичләрен дә җылылык утыз градустан арта. Гомумән, залны проектым белән генә түгел, үземне ышанычлы тотуым белән дә алдырдым... Миңа сорау арты сораулар яудырдылар—залда төзүчеләр утыра иде,—сораудан сораугa кыюлана гына бардым, чөнки аларга җавапларны күптән белә идем инде. Төзелешне финанслау өчен, хәтта ничә якшәмбе өмәсе үткәрергә кирәк икәнен дә исәпләгән идем. Дөрес, активка эскизларым да, макет та ошады. Бу очрашуга футболчылар да килгән иде, менә шунда мин Джумбер белән таныштым. Чынлык һәм вакытның аз куелуы залны дулкынландырды. Шул ук активта төзелеш буенча штаб та сайлап куелды. Яшь архитекторлар һәм проектлаучылар эшне ахырынача җиткерергә булдылар, нульдән башларга туры киләчәк иде: эшче сызымнар, булачак чыгымнар һәм керемнәр, исәп-хисап эшләре...

Өемә мин канатланып, бәхетем ташып кайтып киттем. Ел буе миңа Ленинградка төзелеш штабыннан шалтыратып тордылар: эшлекле сөйләшүләр, киңәшүләр... Кышкы каникулда шәһәр комитеты үз хисабына Зәркәнткә чакыртып алды, һәм мин сызымнар визирладым, планны урынга яраклаштырдым. Ә институтны тәгәлләгәч, хәтта бизәкләү эшләрендә автор күзәтүе алып бардым. Менә нинди эш иде ул! Синекеннән ансат түгел, әйеме? Гаяз таң калудан сүзсез торды. Менә нинди кыз! Нинди нык куллы ! Ул Глорияне өр-яңадан күргәндәй булды: чибәр, куркәм һәм гаҗәеп нәфис.

Гаязның кыз белән аерылышасы килмәде, аны тагы да тынлыйсы килде, эше турында сөйләгәндә, үзе белән дә таныштыра иде бит.

—«Энҗе бөртеге» синен диплом эшең булдымы?

—Иң кызыгы шунда: юк. Мин Ленинградта анын турында телгә дә алмадым. Шушы көннәрдә Ташкенттан төсле фотографияләр буенча белгеч килергә тиеш, ул кафены төшерәчәк, һәм мин рәсемнәрне институтка җибәрәчәкмен. Һичшиксез, моны эшләячәкмен. Анда чыгарылышларның эшләрен күрсәтә торган заллар бар. Ә диплом эшемне кирәксез, актуаль түгел дип таптылар, көчкә-көчкә генә яклаттылар.

—Шунын хәтле ни майтардың соң син?—дип кызыксынды Исламов.

—Ярар, монысын кыскарак тотам. Кара аны, бу турыда башка берәүгә дә сөйләгәнем булмады. Беләсенме, мин беренче тапкыр Үзбәкстанга ничек килеп эләктем? Институтның волейбол командасы белән Ташкентка студентлар очрашуына киттем. Безгә, билгеле инде, Бохара белән Сәмәркандны да күрсәттеләр. Шул вакытта мин Үзбәкстанны ошатып калдым, алай гына түгел—гашыйк булдым, шуңа практика үтү өчен Зәркәнткә җибәрүләрен сорадым. Ә син ничек уйлыйсын, мине, булачак архитекторны, Үзбәкстанда нәрсә хәйран калдырды? Гүр-Әмир, Бибиханым, Күкелдаш мәдрәсәсе йә Ташкенттагы иске базармы? Ә менә юк шул. Барыннан да бигрәк минем андагы көлчәгә исем китте. Әйе, әйе, гап-гади көлчәгә. Гомеремдә аннан да тәмле әйберне ашаганым юк иде. Кайнар, алланып торган йөзе сипкелләр белән тулганмыни—кунжут орлыклары сибелгән. Кабарып пешкән, ап-ак, ә исеннән—тынын кысыла.Син шәрык базарында иң анкыган ис нәрсәнеке икәнен беләсенме? Ашка сала торган үләннәр һәм тәмләткечләр, яшелләкләр, җиләк-җимеш исе? Юк, белмәден, мин тикшереп чыктым—көлчәләр рәтендәге ис. Теләсә кайсы базарда

беркемнән сорашмыйча мин көлчәләр сата торган рәтләрне таба алам. Шуның кадәр гаҗәпләндем, аларны ничек пешергәннәрен сорамый кала алмадым. Кызыксынуым шул дәрәҗәдә булгангамы, кунакка чакырдылар. Мин анда беренче мәртәбә тандыр күрдем.

Көлчә, тандыр, Ташкент, институтны тәмамларга ике елым калганда, миңа диплом эшемнең темасын ачыкларга булыштылар.Ул вакытларда әле вакытым иксез-чиксез, берничә вариант уйладым, тик шулар арасындагы иң яхшысын да буш хыял диеп бракка чыгардылар. Проект турындагы нәтиҗәләре бигрәк көлке тоелды: «Совет кешесенен үсеп килүче тормыш ихтыяҗларына җавап бирми». Әллә тагы мин французлар өчен тырышкан?

Диплом эше турында искә төшерү Глорияне нык дулкынландырды, Гаяз аның үпкәсе әле дә бетеп житмәгәнен сизде.

—Беләсеңме, Гия, архитектор буларак, минем йомшак ягым нәрсәдә? Син аны берничек тә чамалый алмыйсың. Мин һәрвакыт төзегән корылмаларымның бар кеше өчен яраклы булуын телим. Менә «Энже бөртеге»—һәркем йөри торган урын. Социаль караш эшемә шулкадәр тәэсир итәдер дип һич уйлаганым юк иде. Мин беркайчан да, мәсәлән, орган залы төзүгә җанымны бирә алмас идем. Юк, орган музыкасын аңлыйм, яратам. Әти-әниләрем белән Риганың диңгез буенда ял иткәндә, Собор йортында бер генә концертны да калдырмадым. Бу теманың уңыш китерәсен дә беләм. Орган концертларына йөрүче публика архитекторның эшен яхшы яктан бәһаләр, һәм исемем дә тизрәк танылыр иде. Әйе, мин дан яратам. Минем танылasым, атаклы буласым килә, әмма аерым бер публиканың гына бәяләве—минем өчен түгел. Кафены бизәп бетергәндә, беләсеңме, нәрсәне аңладым: монда килүчеләрнең берсе дә бу кем эше дип сорамас, мөгаен. Бу ачышым кәефемне әз генә дә төшермәде. Мин башканы теләдем: монда җан ял итсен, күңел шатлансын, кеше үзен һәртөрле богаулардан азат итеп тойсын.

—Глория,—Гаяз аны түземсезләнеп бүлдерде,—син бит мона ирешкәнсең. Бу—бүләк түгелмени?

Ул, килешеп, башын селкеде һәм, үткәннәргә кайтып, тынып калды. Гаяз, сөйләшүне дәвам итәргә чакыргандай, аның терсәгенә кагылды. Глория кабат җанланып китте.

—Теге вакытта Ташкентта көлчәгә исем киткән иде. Бәясе—ун тиен, ә бер чәйнек чәй өчен теләсә кайсы үзбәк чәйханәсендә өч тиен алалар. Үзбәкстанда, якында чәйханәләр булганда, капкалап алырга унбиш тиен җитә. Менә шуннан чыгып, миндә һәр җирлектә кечкенә генә икмәк пешерү йорты-кибет төзү идеясе туды. Уемда аларны студентларның тулай торакларында, стадионнарда, зур кинотеатрларда, вокзалларда, аэропортларда һәм хәтта кеше яши торган урыннарда аерым бер сәгатьләрдә яңа пешкән кабартма-көлчәләр, ләвәшләр, хачапури, чебурекимы—анысы мөһим түгел—күрә идем. Шунда гына капкаларга теләгәннәргә чәй, яна гына мичтән чыккан ипи—унбиш-егерме тиенгә төшәр иде. Үзеннән-үзе икмәккә сакчыл караш тәрбияләү кебек тә килеп чыга. Шушы унбиш тиен харап итте дә инде... Мине чак кына вакчыллыкта, безнең кешеләрнең ихтыяҗы, мөмкинлекләребезнең арта баруын аңламауда гаепләмәделәр. Бигрәк тә диплом эшләре комиссиясен ахырдан чәй янына вологод маен һәм кара уылдык өстәргә мөмкин дигән чыгырдан чыгарды. Мин бит үзебезнең куәтле икмәк пешерү тармагын читкә какмадым—оппонентларым шуның өчен гаепләргә маташтылар,—бары тик кешеләрнең, артыгын мәшәкатьләнмичә генә, кайнар икмәк алуларын теләдем. Бәлкем, Даша апакай, йә булмаса Кондрат агайның шәхси икмәк пешерү йорты-кибет

кебекләр икмәк пешерү тармагын үзенә яңача карарга һәм безнең икмәккә карашыбыз алардан да тора иканлеген төшендерерләр иде. Яклау вакытында менә шундый уңышсызлыкка тарыдым мин. Әмма ата-бабаларым минем өчен кызармаслар иде, кыю тордым һәм бер генә минутка да үземнең фикеремнән кайтмадым, бары тик сәгатем сукмагандыр әле дип кенә уйладым.

Гаяз шактыйдан үзләренең нииндидер ишек төбендә торганнарын сизмәде дә.

—Ә без мин яшәгән кварталны инде алты тапкыр әйләндек,—дип көлеп җибәрде Глория.—Мин менә монда, икенче катта яшим,—ул якындагы өйгә күрсәтте.—Үземә чакыра алмыйм, бик соң инде. Сау бул. Синең белән танышуыма шатмын, Гия.

Ашыгыч кына саубуллашып, ул караңгы подъездга кереп югалды, ә Гаяз икенче кат тәрәзәсендә ут янып сүнгәнче йорт каршында басып торды.

Зәркәнтнең кешесе калмаган йокылы урамнары буйлап өенә таба атлаганда, ул кабат-кабат бүгенге искиткеч кич һәм көтелмәгән танышу турында уйланды. Башын күтәреп караса, кабат кафе янына килеп чыкканын аңлады. Ялтырап торган идәннәргә тоныкяктылык сирпеп җемелдәгән утларның күбесен сүндергәннәр. Бер мизгелгә генә бернича сәгать элек булган музыка, көлү тавышлары ишетелеп киткәндәй тоелды. «Энҗе бөртеге»нә хәзер икенче төрле күз белән карый-карый, Гаяз эчкә үтте. Кызыл төстәге бию түгәрәгендәге алтын сызыклардан торган нииндидер әкәмәт чәчәкне хәтерләткән бизәк бик сәер, серле тоелды. Гаяз тагын шуны да искәрде: һәр дүрт түгәрәктәге бизәкләр төрледән-төрле иде. Башваткыч чишәргә әзерләнгәндәй, игътибар белән рәк күз салса, чәчәк сызыкларында бик оста итеп «Г» һәм «К» хәрефләреннән дүрт вариант укмаштырып язылганын күрде. Глория бу турыда аңа берни әйтмәсә дә, ул хәрефләрдән кызның култамгасын укыды: «Глория Караян»...

...Тепловозның куәтле уты яктысында поезд, дала караңгылыгын ерып, алга ыргылды. Утлары белән ялт-йолт итеп кечкенә тукталышлар, разъездлар, бәләкәй станцияләр утырып калды, тиз йөрешле поезд алар яныннан выжылдап кына узып китте. Анда яшәүчеләр, мөгаен, менә бу икенче дөнья, кара, утларын җемелдәтеп, мондагы иркен, рәхәт һавага ят ис сеңдереп, китеп тә бардылар дип уйлыйлардыр. Әле, мөгаен, салкынча вагоннарда тирән эчтәлектәге әңгәмәләр корып утырган бәхетле кешеләр, юлларыннан кайтуларын ышанычлы дуслары, сөйгәннәре һәм бик мөһим эшләре, гомумән, төсле матур фильмнарда гына очрый торган тормыш көтә дип беләләрдер.Зур юлга үтәргә рөхсәт биреп торган кизүдә торучыларның эссе кояшта көйгән, дала җилләрендә яргаланган йөзләре фотодагы кебек катып калган, алардан берни аңлап булмый. Менә, ичмасам, кизүләр беркемгә, бернигә кызыкмыйлар: дөресрәге, поездларга, юлчыларның төрлесенә күнеккәннәр—шуңа көнләшмиләр; иге-чиге күренмәгән илебезнең теләсә кайсы почмагына бару мөмкинлеге биргән еллык буш билетларыннан да бик сирәк файдаланалар. Аларны тормыш ыгы-зыгысы күмеп киткән: бия аксаклаган, усал тилгән бәбкәне эләктергән, тагын разъездларга он китермәделәр, түбәдән су үтә, инде өченче кыш мич төтенле, кайчаннан бирле улыннан хат юк, шәһәр тәмен татыган малай бу кечкенә тукталышка, ай-һай, кайтыр микән... Башка берәүләрнең тормышы турында уйланган булып, Гаяз коридорда ялгызы бик озак басып торды...

Диван өстенә тәртипсез таралып яткан кәгазьләр арасында кызларча пөхтә итеп, ал тасма белән бәйләп куелган бер төргәк хат аерылып тора. Ул шунда ук сизенде: бу аның Натальяга язган хатлары. Анык кына хәтерләми: кыз үзе Гаязга кире бирдеме, әллә иртәме-соңмы барыбер егетнең кулына

әләгер дип, Күллегә—өйләренә җибәрдеме? Саны буенча ул аларның бары тик Зәркәнттән язылган хатлар гына икәнен чамалады. Омскидан җибәрелгәннәре әллә югалган, әллә үзендә саклана. Бу хатларда анын гомеренең бер өлеше, аларның мәхәббәте, һәр юлыннан хисләр дулкыны бәрелеп тора.

Юк-юк, менә хәзер бернинди көч тә бу төргәктәге бер генә хатны да укып чыгарга мәҗбүр итә алмас иде. Ни турыда язганын белгәнгә, хәтерләгәнгә түгел.

...Бәхетле очрашу көннәренең берсендә, ничектер, Глория аңа Жан Кокто турында сөйләгән иде... Бернинди сәбәпсез, сылтаусыз ул көннәрдә кыз аны укый иде. Менә нәрсә килеп чыккан: шагыйрь үлеменнән соң биографлар искитәрлек наз тулы дүрт мәхәббәт хаты табып алганнар—әллә үзләре килеп чыкканмы, хәер, эш анда түгел,—ин мөһиме: бу хатлар бер үк көнне язылган... дүрт хатын-кызга. Һәм аларның берсе генә дә хаттан баш тартмаган, әле тагын, житмәсә, текст күчергеч кәгазь аша чыгарылгандай бертөсле булса да, һәркайсы хат аңа гына адресланган һәм шагыйрьнең аңа булган хисләре, мәхәббәте тулысынча чагылдырылган, дип саный икән.

Гаяз да Глориягә гашыйк, тик ул Жан Кокто түгел шул.

Менә хәзер сорасаң да, ни өчен ул вакытта һәрдаим Глория турында уйлап та, тагын ярты еллап Натальяга ягымлы-назлы хатлар язуын аңлата алмас иде. Бәлки, аның сүзләре генә аңа адреслангандыр, ә хисләре—Глориягәдер? Сонлап булса да, үзенең хыянәткә тартым кыюсызлыгыннан, куркаклыгыннан оялды. Натальяга башкага гашыйк булуы һәм өйләнергә җыенуы турында хәбәр иткән бердәнбер хаты да—ул шушы ук төргәктә ятадыр, бәлки—аны коткара алмый иде. Гәрчә ул чакта Глория белән икесенең хәлләре мөшкел иде: бернинди перспектива юк, тоташы белән билгесезлек, әмма кызый аның тормышына нык үтеп керде—бөтенләйгә.

Бер генә мизгелгә аңарда, Натальяның җавап хаты да төргәктә булырга тиеш, дигән уй кабынып алды, тик ул үзенең кызыксынуын шунда ук сүндерде. Хат нәрсә турында—төшенү кыен түгел, нинди сүзләр сайлаган—хәзер инде әһәмияте юк. Ярсулы гаепләү сүзләре, күралмау, ялвару, түбәнсетү? Теләсә кайсысы кызлар өметенең челпәрәмә килүен, кайгысын белдерә, тагын бер кат аны түбәнсетеп, кызыксынып торырга кирәк микән? Ул купесына керде дә төргәкне кулына алды.

Чыннан да, иң өстәге ачылмаган хат Натальядан иде. Нинди карарга килергә белмичә икеләнеп, уйланып торганнан соң, ул кинәт бер тында вагон тәрәзәсен төшереп, хатларны тимер юл кырыенда куе үлән белән капланган сөзәк җиргә ыргытты. Озакка сузылган көзге яңгырлар буш сүзләрне юып төшерсен, җилләр ялганны кисәкләргә өзгәләп, тынсыз-өнсез далага сипсен, мәрхәмәтсез Азия кояшы үтәлмәгән ант һәм вәгъдәләрне көйдерсен, яндырсын. Ә инде егерме еллар элек язылып, карасының төсен югалткан, саргаеп беткән бу хатлар кемнеңдер кулына килеп керсәләр, шул кеше билгесез адәм—Гаяз Исламовны тирән нәфрәт, яман сүзләр белән телгә алсын...

...Уйлар тынычлыкта калдырмаганга, йоклап китеп булмый... Гаяз инде бу төргәкне алып китүенә үкенә дә башлады бугай, әмма икенче яктан, кәгазьләр аны дулкынландырып, үзенә җәлеп итәләр. Аларда үзенең тормышыннан, дусларыннан, Глориядән кала тагын нидер—теге чакта язмышында аңлап бетермәгән нәрсәдер яшеренгән. Яныннан үтеп киттеме, күреп җиткермәдеме?

Ашыгып, берникадәр шапшак итеп язылган чираттагы хат болай башлана:

«Исәнмесез, минем кадерлеләрем!

Мин хәзер—участок начальнигы. Ел ярым эчендә бу үсеш, әлбәттә. Тик безнең шәһәр, төзелеш шартларында гына—закончалыклы рәвештә үсү. Сез миннән эшем турында тулырак язуымны сорыйсыз. Җентекләп язарга вакыт юк, эшнең асылын аңлатыр өчен шуны гына әйтәсем килә: прораблар илле биштә лаеклы ялга китә, аңа унбиш ел стаж җитә. Ташламалары шахтерларныкы йә мартен мич каршында торучыларныкы кебек—бер сүз белән әйткәндә, зарарлы цех.

Дусларым еш кына бер-берсен, шаяртышып, инфаркт белән куркыталар. Йөрәк авыруларыннан үлүчеләрнең иң югары күрсәткече—прорабларда булып чыга икән, һәм алар еш кына йөрәк өянәгеннән китәләр икән... Хезмәттәшләрем әйтүенчә, артистлар арасында да сәхнәдә үлүчеләр бар, ләкин алай еш түгел. Мондый карага төрелгән шаяртуым өчен кичерегез. Минем иптәшләрем әле яшь, гайрәтле, безгә инфарктлар турында уйларга бик иртә, һәм вакыт та юк. Их, өч көн тирәсе тоташ йокласаң иде ул! Менә нәрсә, әти, тагын бер чагыштыру, шуннан сиңа минем эшем тәмам аңлашылыр. Бу бик тә урып-җыюга охшаш, һәр көн, һәр сәгать исәптә. Шундый ук киеренкелек, шундый ук таләпләр, шул ук караңгы чырайлы җитәкчеләр, бар да бер очтан талкыйлар: әйдә, әйдә, кыса төш. Төп аермасы шунда: әйбәт барганда урып-җыю ике-өч атнада төгәлләнә, авыр шартларда дүрт-биш атнага сузыла, һәм бетте! Алда—уныш бәйрәме, сабан туе һәм озын кыш айлары... Безнеке кебек төзелеш—аеруча әһәмиятле ел, тоташ урып-җыюга тиң. Берне тапшырабыз—әйдә икенчесен, анысы булдымы—өченчесенә тотын. Гомер буена шулай, дип ышандыралар мине иртә пеләшләнгән өлкәннәр.

Прораб буларак, мин эшчеләр белән, идарә яки трест җитәкчеләре минем белән сөйләшкән тавыш һәм телдә аралашсаммы, алар мине шунда ук судка бирерләр иде. Эшнең башы шунда: безнең башлык кайларда гына булмаган, ниләр генә күрмәгән, бер сүз белән әйткәндә—үз эшенең остасы, әмма аты-юлы белән сүгенә, шуңардан кизү-йогышлы чир шикелле, әйләнә-тирәдәгеләренә йога; берәүләре үзләре теләп үстереп җибәрсә, икенчеләре ияреп, өченчеләре исә ялагайланып охшарга тырышалар, әмма барысы да күңелне биздерәләр.»

Гаяз хатны читкә куеп, әллә үкенечтән, әллә әрнүдән көлемсерәп куйды. Ул үзен участок начальнигы итеп билгеләп куюларын хәтерли, бик яхшы хәтерли, әтисенә бу турыда язарга теләп тә язмый калдыруы да исендә. Үзе өчен яна социаль тип ачуын да хәбәр итмәде. Юк, ул вакытта андый төгәл тәгъбирне белми иде әле. Соңрак аңлады—социаль тип. Ул чакта гади генә тип иде Юра Силкин. Гаяз үзенең вазифасына ихлас күңелдән куанды—бу ана үсү өчен мөмкинлекләр ача, әмма шул сөенечле минутында Юра Силкинның карашын тотып алды. Бу караштан үзеннән астыртын мыскыллап көлүне ... һәм кызгануны, хәленә керүне укыды. Силкинны һөнәри үсеш барыннан азрак кызыксындырды. Өстәвенә, ул Гаяз өчен бөтенләй көтелмәгән адым ясады.

«Күз алдына китерәм, эченнән генә ничек көлгәндер ул миннән! Менә хәзер ышанам: ул моны анлап, барлык вариантларны исәпләп эшләгән»,—дип фикер йөртте Гаяз. Прораблыкта Силкин төп-төгәл ай ярым йөрде, ягъни бер материаль хисап эшләп тапшырырга өлгерде (ә ул егерме битлек, меңләгән исемнәр), үз объекты эшчеләренә наряд япты, заказ бирүченең (прораб эшчәнлегенең бу этабы югары сәнгать, дипломатия сорый) форма ике дигәненә кул куйды һәм, күрәсең, прораблык тормышының үзе уйлаганча барып чыкмавын аңлады. Шуннан ул җитәкчелек янына килеп зарланырга тотынды: минем, янәсе, ике бала, хатын эшләми, буш фатир, прорабның йөз кырык сумына гаиләнең очын очка ялгап булмый,

имеш. Шуңа күрә бригадир, ягъни эшче булырга рөхсәт итегез. Төзелеш бик зур, юньле, акыллы бригадирларны көндез чыра яндырып та эзләп таба алмыйсың, егет тә җәл кебек, яна корылманы башларга торалар иде—Силкинга бригада тупларга куштылар.

Озакламый Силкин үзгәрде: вакчылланды, сынын туры катырып, ак күлмәктән генә йөри башлады. Эш вакыты анык билгеләнгән: тугыздан алтыга кадәр, алты йөздән ким чыкмый. Зур коллективларда эштән бушатылган бригадирлар булырга тиеш, ул мастер һәм прорабдар белән бер үк эшне башкара, тик бернинди юридик һәм материаль җаваплылыгы юк.

Бригадир буларак, ул үзен бик тиз танытты, җитәкчелек куанып туялмады; аның бригадасына эләгү өчен институтка кергәндәге шикелле конкурстан үтәсе бар, ягъни нечкә иләктән илиләр—Силкин теләсә кемне үзенә алмады. Унайлы очрактан файдаланып, ул бөтен төзелешне тунап, үз тирәсенә бар осталарны җыеп алды. Кешеләр беләләр: Силкинда акча сугып була. Силкин Гаяз участогына күчерүләрен дә сорап карады, әмма ул кире какты, чөнки зур акчаның кайдан килгәнен аңлаган иде: Силкин бар төшемле эшне үзенә эләктерә. Инженер икәне сизелә: сызымнарга күз салып, булачак керем-чыгымнарны алдан исәпләп куя.

Иң гаҗәпләндергәне: Силкин бик активлашты, җыелышларда чыгыш ясый, сүз аралаш «без, эшчеләр...», «хезмәт иясләре...» диярге дә онытмый. Озакламый президиумга да үрмәләде, һәм әллә кем булып, масаеп, кирәкле кеше икәнлеген күрсәтеп утыра башлады. Эш мәйданында ак күлмәктән бригадирга бик охшамаса да, президиумнарда—суйган да каплаган алдынгы эшче. Ничек булдыра алды ул шулай?

Әйе, Гаяз өчен ачышлар вакыты булды ул.

Ул кабаттан күзләрен укылып бетмәгән хатның саргайган битләренә күчерде.

«Әни, ә хәзер синең сорауларына җавап бирәм. Шәп кенә каралдым—үзбәккә охшап калдым. Эшчеләремнең күбесе шушындагылар, һәм алар белән бик тиз уртак тел таптым, әле үзбәкчә сөйләшергә дә өйрәндем. Ашау яхшы, мондагы ашханәләрдән зарлану—гөнаһ булыр иде, яшелчә, җиләк-җимеш күп. Үзбәк кухнясына өстенлек бирәм: пылау, шурпа, шашлык, манты. Ә мондагы көлчәләр, әни! Башкалардагы кебек минем участокта да хатын-кызлар күп, һәм һәрвакыт шуларның ике-өче декретка китәр алдыннан җиңелчә эштә йөриләр. Түзеп булмаслык эссе, мин аларны бик җәллим, эшчеләр әйтмешли, команда пунктында—прораб вагончыгында тотарга тырышам. Ә алар кайдандыр ике чиләк сыешлы иске самовар табып алганнар, һәм ул көне буе шунда пыш-пыш килеп утыра. Хәзер бөтен төзелешкә шул самоварым белән минем дан китте. Еш кына прораб-туганкайлар бер чәйнек чәйгә кергәлиләр, самоварым аркасында мин аларның барысы белән дә диярлек танышып чыктым.

Яшел чәй генә эчәм, баштарак тәмсез тоела иде, тора-бара күнектем, хәзер ошый һәм иң мөһиме—сусынны баса. Еш кына кафега танцыга йөрим.»

Карашы, әйтерсең лә, төртелеп калды. «Кафега танцыга» дигән сүзләр җанын нindидер җылылык, назлылык белән тутырдылар.

Эшләре—ике сменалы, аерым очракларда—өч тә була. Эшчеләрнеке аңлашыла: аларның сигез сәгатьлек эш көне, калып эшләсәләр—бары тик профсоюз рөхсәте һәм һәр сәгате икеләтелгән түләү белән. Аның участогында ничә смена булса да, барысы өчен дә ул һәм аның ике прорабы җавап бирә. Авария буламы, эштә брак килеп чыгамы яисә бәхетсезлек очрагымы—тәүлекнең теләсә кайсы вакытында: төн уртасымы, таң

алдымы—алардан сорыйлар. Ничек булдыра алалар, шулай бөтерелделәр. Прораб вагончыгының яртысын йокы бүлмәсе итеп ясадылар, анда һәрвакыт җыеп куелган җәелмә ятак тора; урын-җирне исә тулай торак коменданты атнага бер алыштыра. Бер ул гына түгел, башкалар да шулай. Эш катлаулы, күз-колак булу кирәк... Киеренкелек, нервылар...

Эшеннән тулай торакка Гаяз кичке сигезләрдә кайта, өс-башын алмаштыра да—«Энже бөртеге»нә китә. Кафега җәяүләп ун минутлык юл. Сәгать тугызларда ул инде анда була: дуслары белән кичке аш ашый, бии, аннары нәкъ уникенче яртыда аны дежур машина кереп ала һәм—туп-туры объектка. Кайчакларда шулхәтле китәсе килми, дуслары белән утырасы килә, тик...быргы чакыра, караватт көтә. Бу ятак аларның бетмәс-төкәнмәс гәп темаларына әйләнде. Бер кызның хәтта, кайчан да булса төнлә объектка килеп чыгып, ни өчен әкияттәге Көллекәй кебек, нәкъ төн уртасында китеп югалуыңны тикшерәчәкмен, дип янаганы да булды. Биюләр, дуслары белән аралашулар эш йөген тартырга көч бирделәр.

Хатның ахыргы юлларыннан никадәрле шатлык бөркелеп тора!

«Минем бизәк төшерүчеләрем «О, шимбә!» дигән шаян җыр чыгарганнар һәм аны җомгадан җырлый башлыйлар, мин дә яшертен генә шуны көйләп йөрим, җитәкчедән башлап, бар хезмәттәшләрем дә җырлыйдыр дигән шигем дә бар,—шимбәләрен икенче сменалар юк.

Хушыгыз. Үбәм, сезнең улыгыз һәм абыегыз Гаяз».

...Бу төндә ул таң беленгәндә генә йоклап китте, һәм күпме елларга беренче тапкыр төшендә үзенең туен күрде. Төсле слайдлардагы кебек, үз тормышын җентекләп карап чыкты. Бары төш кенә—табигатьнең иң тылсымлы, бәһасыз бүләге—үзенне, эшләгән эшләреңне читтән торып күзәтергә мөмкинлек бирә; тик, ни кызганыч: бу үткәнгә карау, аны берничек тә үзгәртеп булмый инде.

Глория яңа гына Әдрән дингез буе курорты Дубровниктан кайтып төште, анда яшь архитекторларның халыкара конкурсы үткәрелде. Аның яңа өйләнешкән парларның туй сәяхәте өчен дингез буендагы кунакханә проекты Югославиядә Гран-при алган, ә конкурсны оештыручылар аңа тагын бер —конкурсның иң сокландыргыч катнашучысына дигән приз тапшырганнар.

Бер итальян фирмасы шунда ук проектны сатып алу турында Глория белән килешү дә төзегән. Кыю, чая итальяннарның, мондый гадәти булмаган кунакханә төзергә нинди уйлар этәрде ? дигән соравына ул:

—Бернинди дә сере юк, синьорлар, минем туй сәяхәтемнең шундый кунакханәдә дингез буенда тәмамлануын телим,—дип җавап биргән.

—Сезнең исемегез ничек?—дип сораган аннан фирма вәкиле.

—Глория.

—Глория?—дип кабатлап сораган да шатланып кычкырып җибәргән,—Глория! Уйлап та торасы юк—кунакханә өчен моннан да матур исем булмас. Сезне ышандырырга батырчылык итәм, синьорина, без Италиядә һәм Франциядә шундый дистәләгән кунакханәләр төзиячәкбез, фирма проектта бер генә сызыкны да үзгәртмәүне гарантияли.

Фотоаппаратлар ялт-йолт килгән, һәм итальяннар шунда ук төсле фотографияләрне сузып, култамга сораганнар.

Фирма вәкиле фотографияне сузгач, Глория:

—Кунакханәне минем исемем белән атавыгыз өчен мин сезгә бик рәхмәтлемен, тик берәр урынында монограммам булса ярыймы?—Тиз генә фотографиянең икенче ягына фломастеры белән «Энже бөртеге»ндә шифрланган бер монорамманы чыгарып та куйган.

Эшлекле итальян шунда ук:

—Бәлки, синьорина, вывесканы да тәкъдим итәрсез?—дип сораган. Кайсыдыр илтифатлы гына итеп кызга альбом һәм фломастерлар сузган. Глория уйлап та тормый, латинга хас булмаганча хәрефләрне керештереп, исемен язган. Ә сул ягына үзенең монограммасын куйган.

—Ә фоны?—дигән итальян, ашыга-ашыга. Һөнәри әңгәмә киткән...

—Алтын йөгертелгән чия кызыл, монограмма—ак белән кара, яшьләрне көтеп торучы яхшылык һәм яманлык символлары—теләсә кайсы хәрефне сайларга була. Бар да минут эчендә башкарылган, тойгыларын тыя алмаган итальян гаҗәпләнүдән һәм шатлыгыннан сызгырып куйган.

Шул төндә тулай торакка Гаяз исеменә, мөгаен, Зәркәнт өчен бик сирәк хәлдер, халыкара телеграмма китерделәр. Анда берничә генә сүз язылган: «Гия, сөеклем, мин җиндем!»

Танышуларына өч ел узса да, кызның аңа беркайчан да алай әйткәне булмады. Гаяз Глорияне Ташкент аэропортында каршы алды, һәм андый бәхетле чагын кабат беркайчан да күрергә туры килмәде. Унышны дуслары белән кафеда билгеләп үттеләр. Бушап калган урамнар буйлап озата кайтканда, Гаяз инде күптәннән җыенып та әйтергә кыюлыгы җитмәгән тәкъдимне ясарга булды.

—Глория, чык миңа кияүгә.

Әйтерсең лә, аның өчен бу—көтелмәгән хәл, ул туктап калды, кайчандыр кафеда Габдрахман Кадыйровны танцыга чакыргандагы шикелле каушады. Озак кына җавап бирмәде, әллә тәкъдимне үлчәп карады, әллә инде, гадәтенчә, үзенең проектлары белән онытылды. Әмма юк, ул бернәрсәне дә үлчәмәде дә, архитектура да уенда түгел иде. Ул чынлап та югалып калды. Эш белән күмелеп, бар вакытын һәм көчен шуңа биргәнгә, Глория хатын, әни, өйдә хуҗабикә булу турында бик аз уйлый иде.

—Гия, сөеклем,—диде ул монсу гына. Гаяз аның күзләрендә яшь күрде.—Мин кирәк микән соң сиңа? Кара әле миңа яхшы итеп, нинди хуҗабикә инде мин? Архитектура белән җенләнгән дуамал, холыксыз тәкәббер бер кеше. Бөтен йөрәгем белән бәхетле итәргә тырышсам да, син бит минем белән җәфа чигәчәксең. Бәхетле гаилә булырыбызга бик икеләнәм. Мин нәрсә генә сөйләсәм дә хәзерге вакытта бик бәхетле, чөнки моңарчы миңа беркемнең дә тәкъдим ясаганы булмады, күрәсең, башкалар синнән акыллырак булган... Кызның каушавы үтте, ул янәдән төртмә телгә әйләнде.

Гаяз аяк астындагы җирлекне югалтуын сизенде. Бу нәрсә—кире кагумы?

—Син миңа җавап бирмәдең,—диде ул, калтырап киткән тавыш белән.

—Нәрсә булса, шул булыр!—Мизгел эчендә ул үзгәрде, күнелләләнде.—Инде үзең теләп һәлакәт сорыйсың икән, менә сиңа минем шартым: әгәр бер атнадан кире уйламыйча тәкъдимеңне кабатлыйсың икән, мин сиңа кияүгә чыгам. Гия, котылу өчен сиңа мөмкинлек бирергә тиеш ич инде мин.

Прораб вагончыгына тагын бер җәелмә ятак өстәлде. Шимбә дә җинел түгел. Глория кайтканнан соң, аларның бер мәртәбә очраша алганнары юк. Шимбә планерка озакка сузыласын сизенеп, Гаяз Джумберга шалтыратты. Капитанга үзенең уй-ниятләрен сиздерми генә, кафеда зур өстәлгә заказ бирүен үтенде.

«Энҗе бөртеге»нә Гаяз бераз соңарып килде. Чәчәкләр белән бераз матавык килеп чыкты: кичке базарда ак розалар табылмады, таныш бакчачының өенә барырга туры килде, сабакларын озын калдырып, розаларны куаклардан тыгыз, нәфис бөреләре белән бергә кисеп алдылар.

Ул кафега кергәндә, кичә инде башланган иде. Аларның күнегелгән бүлемендә чытыр ак эскәтер ябылган зур банкет өстәле артында аның дуслары күңел ача. Күзе белән өстәлне айкап чыккач, Гаяз Джумберга карап, рәхмәтле елмайды. Алар еш кына үзләренең компанияләре белән кечкенә генә шатлык һәм уңышларын билгеләп үтәләр иде, шуңа күрә бу мәҗлес берәүне дә гаҗәпләндермәде, тик өстәл бүген бәйрәмчә, баерак. Глория Джумбер янәшәсендә утыра, бары тик аның матур ак күлмәге йөзенең сизелер-сизелмәс кенә нервлы аклыгын чагылдыра, Гаяз моны кергәч тә күреп алды. Ул кыз янына килеп, чәчәкләрен сузды. Аларны кабул итеп, кыз рәхмәт йөзеннән башкаларга сиздерми генә аның кулын кысты һәм шау-шу эчендә: «Рәхмәт, сөеклем»,—дип пышылдады.

—Глория, нәрсә, тагын бер проектмы?—дип сорады Тамаз.

Аңа каршы:

—Син үзең шулай ешрак голлар кертсәң иде,—дип, Джумбер өстәл янындагыларны бер көлдереп алды.

—Мин аңларга теләр идем, нинди хөрмәттән без шулай матур утырабыз? Гия, әллә сине идарә начальнигы иттеләрме? Әллә безне Зәркәнттә хезмәт хакы буенча рекорд куйган Силкин бригадасына кертә алдыңмы?—Джумберның бүген нәрсә өчен шулай тырышканын беләсе килде.

—Картаясың, капитан, син түгелме соң: иң кирәге—сабырлык, түземлелек, дигән кеше. Капкага болай гына юләр дә кертә ала, ә менә кайчан һәм кая кирәк—бары тик оста гына булдыра. Минем үземнең дә әйтәсем килеп, телем кычытып тора.—Гаяз торып басты да җыелганнарга күз йөртеп чыкты, аннары җитдиләнеп дәвам итте:—Дусларым, мин Глориягә тәкъдим ясадым, һәм бүген сезгә өйләнешүебез турында җиткерәсебез килә.

Өстәл янында шундый шау-шу күтәрелде ки, хәтта бер мәлгә оркестр да туктап торырга мәҗбүр булды. Роберт, уен кырындагы кебек, яшен тизлегендә урыныннан купты да кемдер: «Шампан шәрабе китерегез!»—дип кычкырганчы, шешәләр тотып килеп тә җитте. Бер өстәлдән икенчесенә: «Гия өйләнә, Глория кияүгә чыга...»—дигән хәбәр таралды. Өстәлнең каршы ягында Джумбер һәм Тамаз янында утырган Глорияне Гаяз белән янәшә утыртырга теләгәннәр иде, кая ул, Тамаз үҗәтләнде:

—Уйламагыз да, Глорияне үз янымнан җибәрмим. Беләбез без Гия ханны, башка беркайчан да бу гүзәл кыз янына утырырга рөхсәт бирмәячәк. Гомумән, ул безгә калым йә йолым түләсен, иң яхшы архитекторыбыз белән аны без таныштырдык бит. Глория, әйт әле!

Глория аны тынычландырды:

—Менә шуңа күрә без Гаяз белән болай хәл иттек: сез загста шаһитларыбыз, ә туйда кияү егетләре булырсыз.

—Әгәр алай икән—бирелəм, менә урынымны да Гияга бирәм.—Дуслар урыннарын алмаштылар.

Танышлар, күргән-белгәннәр килеп, Гаяз белән Глорияне тәбрикләделәр, туйның кайчан булачагы белән кызыксындылар. Тамаз, бу сорауны эләктереп алып, җавап бирде:

—Кичке гәҗитләрне карап барыгыз, ашыгыч чыгарылыш булырга мөмкин...

Тәбрик итүчеләр кимеп, өстәл янында әзрәк тынлык урнашкач, Джумбер, Гаязга карап:

—Ә шулай да кайчан?—дип сорады.

Гаяз иңбашларын сикертте.

Шулчак аз сүзле Роберт әйтеп куйды:

—Икенче шимбәгә—нәкъ вакыты дип уйлыйм. Беренчедән, чигерергә бернинди сәбәп юк, икенчедән, чәршәмбедә беренче өйләнештә соңгы

уен, һәм без ике атнага ялга тукталабыз. Шулай итеп, безнең, синең дусларыңның, буш вакыты була, һәм тренерга карап тормый, рәхәтләнеп туй итәчәкбез. Үземне төп хуҗа дип билгелим,—мин дә гомеремдә бер тапкыр булса да югары вазифада йөрим әле,—ник дигәндә, көз көне сеңлемне кияүгә бирдем, бу өлкәдә тәҗрибәм бар. Джумбер, Тамаз, раслагыз әле.

Дуслары, килешеп, башларын селкеделәр.

—Кайда үткәрү турында сорау тумас дип уйлыйм,—әлбәттә, «Энҗе бөртеге»ндә,—дип дәвам итте Роберт.

—Усал телләр Глория махсус үзе өчен төзеде, диячәкләр,—дип бүлдерде Тамаз.

Тик Глория кире какты:

—Юк, Тамаз, кафены мин Гаяз белән очрашу өчен иҗат иттем.

—Сезгә, яңа өйләнешүчеләр, үтенеч бер генә: сишәмбегә кунакларның тулы исемлеге булсын...—диде Роберт.

—Роберт, кадерлем, синнән бер нәрсәне генә сорыйм, миннән алда өйләнә күрмә, минем туемда да баш булуыңны телим.—Тамаз иптәшен кочаклап алды.

Андый ыгы-зыгылы атна Глория белән Гаяз тормышында башка кабатланмады. Сишәмбе көнне Глориянең эшенә кафе идеясен яклаган комсомолның шәһәр комитеты секретаре шалтыратты. Башта аны, алда биографиясен үзгәртәчәк фактны комсомолдан яшергәне өчен, җинелчә генә кыздырып алды, аннары комсомол-яшьләр туе булачагын һәм моның инде расланганын, тикшерелергә тиеш түгеллеген житкерде. Глория аны сүзеннән кире кайтарырга тырышты, шәһәр комитетының туйлардан башка да эшләре житәрлектер, диде. Ләкин секретарь үз сүзендә нык торды: син,—диде,—комсомолның шәһәр комитеты әгъзасы, кияү—бәя бирүләре буенча яхшы прораб, алдынгы участокны житәкли,—кыскасы, комсомол туе өчен алардан да яхшы парны табып булмаячак икән.

Чәршәмбе көнге уеннардан соң кафеда утырганда, Роберт Глория белән Гаязга болай диде:

—Башта беренче туй бүләге итеп бүгенге җиңүебезне кабул итегез. Хәзер тыныч күңел белән туй итә алабыз. Финиш безнеке, беренче әйләнеш нәтиҗәләре буенча без зонада—лидерлар. Ә хәзер мин сүзне урынбасарыма—«Энҗе бөртеге» директоры, дустыбыз Бәхтиярга бирәм. Һәм шаярулы кул чабулар астында үз урынына утырды.

—Дусларым, Шәрыкта болай диләр: күпме генә хәлвә дип сөйләмә, аннан гына авызга хәлвә тәме кермәс. Шуңа күрә мин күп сөйләмим, бары сезне, барысы да тиешле югарылыкта булыр, дип ышандырам. Бу безнең кафе коллективы өчен дә—имтихан, бездә туй—беренче мәртәбә. Архитектор Глория шәһәребезгә бүләк ясаган икән, шәһәр рәхмәтсез кала алмый, безнең якларда андый гадәт юк.

...Туйдан соң ике көн үткәч, Глориянең өенә җыелдылар, Гаяз да шунда килде. Музыка тыңладылар, күңелле, шау-гөрле туйны искә алдылар.

Шулвакыт Джумбер тәкъдим ясады:

—Ә сезгә туй сәяхәтенә китәргәме әллә, берьюлы эсседән дә качарсыз?

Тамаз кысылмый калмады:

—Итальяннар әле кунакханәне төзеп бетерә алмаганнардыр, дип уйлыйм. Глория бит аларны, кайту белән Гияны бәхетле итәм, дип искәртмәде.

—Тиккә генә мин сиңа акыллы киңәшләр бирмим, Тамаз, мин—алтынчы разрядлы балта остасы-штукатур, ә синеке бишенче генә. Дөрес әйтәмме, Гия?..Менә шулай...Безнең уеннар башланганчы ике атналык буш ара бар, мин бер ун көнгә Гаграга—диңгезгә очмакчы булам. Анда минем туган

тиешле абыем нәкъ дингез буенда ике катлы аерым йортта яши. Барыбызга бергә шунда китәргәме әллә, дим?

Шулай итеп алар Глория белән дингезгә барып чыктылар, ике еллык ялларын шунда үткәрделәр. Бу аларның бергә яшәгәндәге иң бәхетле көннәре булды.

Студент елларында Джумбер ялларын Гаграда уздырган, шәһәрне генә түгел, өлкәдәге барлык шәһәрчекләр-курортларны белә, алар белән булганда, күбесен күрсәтергә һәм гагралы дуслары белән таныштырырга өлгерде. Пицунданы, Джумбер киткәннән соң, очраклы рәвештә ачтылар. Ул елларда Гагра белән янәшә Пицунда борынында зур төзелеш җәелә башлап, хәзерге дөнья курорты нигезеннән күтәрелеп кенә килә иде әле.

Глория төзелешнең колачын ошатты, дөрес, уналты катлы корпусларның проектлары аны куандырмады. Аның фикеренчә, бигрәк гади-гадәти һәм бертөсле күренәләр; аның каравы урынын искиткеч дип тапты. Бар территория аша дингез җиле үтә, борынгыдан килгән нарат урманы корпусларга килеп терәлгән. Саф һавада йөрү өчен сукмаклар, аллеялар, юл чатларындагы, мәйданнардагы сынлы сәнгать әсәрләре, ресторан һәм кафелар аны хәйран калдырдылар. Глория бик тиз арада архитекторлар белән танышып алды—аларның күбесе Тбилисидан иде,—һәм алар еш кына Гаградагы кичләрне бергә үткәрә башладылар. Инде гадәти булмаган ачык төсле ялтыравык белән капланган гипсокерамик әкияти аждаһалар, сигезаяклар, сугыш чукмары әтәчләр, тәкәббер тавислар, йокы баскан ябалаклар, тылсымлы тирмәләр, ак өйләр, саклялар (Кавказдагы тау халыкларының торагы)—Гаградан Пицундага кадәрге автобус тукталышлары—ул вакытларда бик данлыклы Зураб Каргаретели эшләре, беренче мәртәбә очрашканнан соң ук, Глория белән икесе арасында дуслык мөнәсәбәтләре урнашты.

Каргаретели кинәт ниндидер идея белән кабынып китә, андый чакларда аны өстәл янында тотам димә, хәтта иртәнгә кадәр дә сабырлыгы җитми иде. Шунда ук машинасы да табыла, һәм төнлә иҗатчыны, үзенең фикерләрен тикшереп карау өчен, Пицундага илтә. Глория Каргаретели турында: «Хыялый, шашкан,»—ди, һәм, әлбәттә, иҗатчы шундый булырга тиеш, дип саный.

Зәркәнткә алар Тбилиси аша кайттылар. Грузиядә, Тбилисида икесенең дә беренче булулары, һәм бу искиткеч як, аның кешеләренә карата йөрәкләрендә тирән мәхәббәт хисләре алып киттеләр...

...Ул бик иртә уянды, йоклавы да ике-өч сәгатьтән артмагандыр,—яшь чагында Зәркәнттә барлыкка килгән гадәте әле дә дәвам итә. Күршедәге купе ишекләре әле ачылмаганга, проводник Гаязны күргәч шатланды,—сүз алышырга кеше табылды. Тик Гаяз аның белән һава торышы, расписание, алдагы тукталыш турында берничә җөмлә алышты да, бер чәйнек алып, купесына кереп югалды.

Иртәнгә һава җилләткеч сүндерелгән, ул тәрәзәне төшерде. Чүлгә якынлашканнары сизелә, иртә әле яңа гына башланса да, Күлледәге кебек сафлык юк. Карашы тагын диванда тоткарланды, шәт, хат һәм фотографияләрне җыярга, тутырырга кирәктер, тик ниндидер яңа уй аның игътибарын гел читкә юнәлтә.

Үзе дә белми: менә хәзер нигәдер: «Гия, Ташкентта тагын өч көнгә тоткарланам. Проектны ектылар—көрәшәчәкмен»,—дигән телеграмма исенә төште. Андый эчтәлектәге хәбәрләрне Глориядән бер генә һәм Ташкенттан гына алмады, аның яшь бала караган төсле, борчулы, йокысыз төннәрдә тудырган, үстергән проектларының һәрберсе Гаязга таныш иде. Монысында сүз Яшьләр йорты турында бара, Глория аны туйдан соң өч ел

узгач тапшырган иде. Бу проектны төзү аңа авыр бирелде, берничәсе юкка чыгарылды, һәрберсе дөнья кадәр көчне, иксез-чиксез вакытны алды. Ике тапкыр Тбилисига очты, эшен Каргаретели һәм аның дус архитекторларына күрсәтте. Грузиядән канатланып, куен дәфтәрен төрле язмалар, кинәшләр, тәкъдимнәр белән чуарлап кайтты. Менә табылды, ахрысы, дия иде. Атна да үтми, тәмамланып килә торган эш тагын бракка чыгарыла, кинәшләре искергән, күп чәйнәлгән, кирәксез дип, куен дәфтәрләре чүп чиләгенә оча...

Глория шуны аңлап алды: Зәркәнт үзен күрсәтергә мөмкинлек бирү белән бергә, аны һәр иҗатчыга кирәк булган һөнәри мохиттән, тирәлектән аера икән бит. Илнең архитектур уй-фикерләр үзәге саналган урыннарыннан ерак яшәсә дә, ул аларның «цехлар»ында ниндидер җитди үзгәрешләр булып ятуын сиземли, тоя иде. Ул моны, көтмәгәндә кин яңгыраш алып, ниндидер бер калыпка әйләнгән проектлардан аңлап алды. Архитектурадагы бу яңа карашлар, язгы тау ташкыны сыман, бик тиз көч-куәт алып, Глория һич көтмәгәндә килеп керделәр. Ул «талантсыз, сәләтсез, тартмалар, стандарт» ишеләрдән башка ачулы сүзләрне таба алмады. Эшеннән Гаяз кебек үк бик соң кайта, еш кына тавышы карлыккан була,—шулай шул: архитекторлар көрәшсез генә бирелмиләр.

—Гия, сөеклем,—диде ул, дулкынланып.—Мин ничек итеп яңа торак массивның проектын раслый алыйм, түшәмнәрне ике ярым метрга кадәр түбәнәйтергә кушалар! Һәм бу безнең Зәркәнттә бит! Болай да суларга һава җитми, җәй буе кырык градус эсселек тора. Өстәлдәге аш савыты урынына люстраны файдаланырга мөмкин, тик безнең Урта Азиядә, күп балалы, зур гаиләле җирдә, санузел белән ваннаны берләштерү бөтенләй башка сыймый. Соң, ванна гаиләдә кер юу урыны да булып тора ич?!

Глория кызып китеп, кичке аш турында да онытты.

—Ә менә сез, төзүчеләр, ни әйтәсез? Архитекторлар акылдан язган дипме? Үз акылыгыздамы, дисезме? Акыллы да, аннан ни файда соң? Проектка рөхсәт бирмим мин, башка кеше бик теләп башкарсын.

Гаяз ул вакытта Глориянең тормышында күп нәрсәне үзгәрткән «архитектур чамасызлык»дигән атаманы исендә калдырды.

Аның хатыны үзе өчен берничә төп кагыйдә булдырды һәм аларны Урта Азиядәге эшләре өчен мөһим дип санады. Ул бер генә проектны да яшел зонасыз күз алдына китерми—теге һәр проектта була торган «Зеленстрой»ның күз буяу өчен генә ясалган чәчәк түтәлләре, утыртылган үсемлекләрен түгел, ә Азиядә корылмаларны төп җимерүчеләр булган тузан һәм чилләдән саклый һәм тирәсендә кирәкле микроклимат тудыра торган зур бакчалы архитектураны күз уңында тота иде. Үзенең архитектурасын судан: фонтаннардан, арыклардан, каналлардан, тере бакалы савытлардан, эчәргә яраклы су фонтаннарыннан башка фикерли дә алмый, монда ул һәрвакыт суны хөрмәтләгән шәрык архитектурасы традицияләренә таяна. Су мәсьәләсен бөтенләйгә хәл итү өчен,—ул Үзбәкстанда гомере буе эшләргә җыена иде,—Глория архивларда казынды; Хива, Сәмәрканд, Бохара кебек даны таралган шәһәрләрне генә түгел, аз танылган Китаб, Коканд кебекләрне дә йөреп чыкты, өлкәннәрен күреп сөйләште. Аннары үзенчәлекле, үзенә бер төрле формалы, шуның өстенә эстетик вазифаны күздә тоткан хауза—хәзерге бассейннар кебек бернәрсә—иҗат итте.

Аның фонтанлы һәм хаузалы паркларында арыганнар, кызыксынучаннар, ял итүчеләр һәм, билгеле инде, гашыйклар өчен ял итү урыннары да каралган. Урындыклар, зур эскәмияләр, айваннар, бер кешелек, ике... компания өчен, бетмәс-төкәнмәс хыял-фантазия һәм кыюлык белән иҗат ителгән бу әйберләр формалары, материаллары белән генә түгел, Глория

тарафыннан гаҗәеп уйлап урнаштырылуы белән дә сокландыралар. Гүя алар гөмбәләр кебек җир астыннан үсеп чыкканнар, урыннары нәкъ шунда кебек, бик табигый күренәләр. Шәрык халкының фонтаннарга мәхәббәтен аңлап һәм кичләрен алар янына кеше җыелганын күреп, ул фонтан тирәли су тамчылары чәчрәми торган аралыкта, беркемгә дә комачауламый ял итәр өчен өзек-өзек эскәмияләр куярга уйлады. Гашыйклар өчен куелган чатыр-беседкалары белән дә шаккатырды. Алар шәрык әкиятләре битләреннән туры җиргә төшкәннәрмени: җиңел, челтәрле-бизәкле, язларын виноград агачлары, үрмәле үсемлекләр белән чорналган, роза чәчкәләре...

Глория, бездә, кызганычка күрә, паркларны камилләштерү буенча архитекторлар аз, кайчан да булса житди заказ ала калса—корылмалар янына чып-чын сквер утыртасы—кемгә мөрәҗәгать итәргә, бергәләп эшләргә кемне чакырырга белмәссең, дип зарланды. Бу турыда ул еш кабатлады. Шәһәр төзелгәнче, башта читендә парк утыртырга кирәк, ул тыныч кына күтәрелеп килгәндә, шәһәр аның янына килеп житәчәк. Үзе өчен, барыбер кирәк булачак дигән ышаныч белән, парк мәдәниятен дә өйрәнде. Ташкентка, Ботаника бакчасына, Шредер институтына еш йөрде һәм Урта Азиянең агачлары, куаклары, чәчәкләре турында шактый мәгълүмат туплады. Һәрхәлдә, ул сайлаган агачлар бина тирәсендә матур күренеш-пейзаж тудырыр өчен ничә ел кирәген төгәл белә иде.

Тик Глория нык игътибар биргән агачлар һәм су, шулай да, әйтик, бинаның үзен чолгап алу өчен генә хезмәт итәләр. Эшендә чагылып-чагылып киткән яшьлегенә, хатын-кыз романтикасына карамастан, Глориядә барыннан да элек ирләргә хас акылга муафыйклык, ирләрчә исәп-хисаплы булу тоемлана иде. Гаяз хәтерли, бервакыт Деградa өстәл артында утырганда, Зураб Каргаретели болай дигән иде: «Миңа авторы куелмаган проектка күз ташлау да житә, ул ирләр хезмәтеме, хатын-кызныкымы—бервакытта да ялгышмыйча әйтәм». Зурабның дуслары—алар да архитекторлар—ул вакытта көлештеләр дә андый тоемлауның бер аңа гына бирелмәгәнен әйттеләр.Үзенең хезмәтләрен архитектур конкурсларга җибәргән Глория ничә мәртәбәләр: «Хөрмәтле иптәш Караян...» («Дорогой товарищ Караян...») дигән сүзләр белән башланган җаваплар алганы бар. Ә бит бу конкурсларның жюриенда шулай ук үзләрен бернинди авырлыксыз ирләр эшен хатын-кызныкыннан җиңел аерабыз дигән кешеләр утыргандыр.

Глориядәге ирләрчә фикерләү алымын башта ук, аларның беренче танышу кичендә «Энҗе бөртеге» турында сөйләгәндә үк сизеп алды, һәм соңрак та моңа бер генә инанмады: өйләнешкәннән соң, ул инде хатынының кызыксынулары белән яшәде, архитектура турында теләсә кайсы дипломлы белгечне урынына утырта ала иде, чөнки Глориягә тагын бер сәләт—мәсьәләнең асылын ачып бирә алырлык педагоглык таланты да бирелгән. Әмма Глория, бернигә карамастан, чын хатын-кыз булып кала белде. Гаяз шуны аңлады: аның архитектурасында, һичшиксез, бер генә талантлы ир-атка да бирелмәгән нәрсәләр катнашырга тиеш иде—аның бергә берләшкән хатын-кыз табигыйлеге, сокландыргыч тәэсирлелеге, зәвыгы һәм холык-фигыле чагылыш табарга тиеш. Ул, ярсып, эшенә тулысынча бирелде, хәтта вакыт-вакыт ире, гаиләсе, өе турында да онытты. Бу акыллылык, киләчәк буын алдында җаваплылык хисе, минутлык табыш-файдалар артыннан кумау—аңа төп кагыйдәләрне эшләргә мөмкинлек бирделәр, теләсә кайсы очракларда ул шуларга таянды. Аның ышануынча, Урта Азиядә шәхси проект буенча төзелә торган биналар, шәһәрнең йөзен күрсәтә торган корылмалар өчен, эссегә һәм тузанга азрак бирешә торган материалларны гына яраклы дип табалар: югары сыйфатлы ачык төстәге кирпеч, таш—шомартылган булуы мәслихәт, һәм металл...кызыл бакырның,

цинкның, кургашның, алюминийның юка табаклары, аларның эретмәләре... Бу материалларның һәркайсы үзенчә яраклы, тик Глория аларны берләштерү яхшырак дип саный. Эш барышында ул болытларга утырып йөзмәде, проектка көндез чыра яндырып та эзләп табылмаганнарны тутырмады—Урта Азиядә яхшы кирпечтән башкалары җитәрлек иде. Безнең архитектура өчен гадәти булмаган төсле металлны—Глория анда киләчәкне күрә—ул эшләп чыгарылган Зәркәнттә яшәгәнгә күрә генә кулланырга булды. Кайчакларда үкенечле итеп: «Архитектурага ун ел соңга калдым»,—дип әйтеп куя. Яшьләр йортын проектлаштырганда, Глория төзелештә блок, бетон, күчерелмә калып-тышча, яңа тышлау материаллары, пыяла кулланып эшләү вакыты җиткәнен, әлбәттә, белә иде. Серияләп төзү, йортлар салу комбинатлары чоры икәнен белә иде һәм еш кына кулына карандашын тотып, карар күзгә арзан материалларның бик кыска аралыкта гына файда китерүен, еллар үткән саен, төзекләндерүгә әллә ничә мәртәбә күбрәк чыгым китәчәген, дистә елларга исәпләп чыгарылган төзү материаллары күпкә отышлы икәнен исәпләп тә күрсәтте. «Саран ике тапкыр түләр, дип архитектура турында әйтелгән»,—ди ул, үзенең хаклы икәнлегенә ышандырып.

Мәкаләләренең берсендә, шуның кадәрле эссе һәм кояшлы Урта Азия өчен ул бөтенләй зарарлы дип, Глория пыяла турындагы фикерен ачык һәм кискен итеп әйтеп бирде. Беренче шатлык-куанычлар узуга, барлык проблемалары белән җылыту мәсьәләсе алга килеп басачак: аның фикеренчә, пыяла биналарны җылыту—урамга ягу белән бер. Ә аквариумдагы кеше,—ди ул,—архитекторның ирексезләвенә дучар ителә. Бу мәкаләсе басылгач, аның белән күңелсезлекләр башланды: архитекторлар берлеге Глорияне киң колачлы төзелеш куйган заман таләпләрен аңламый, архитектураның киләчәге булган яңа төр материалларны дөрес бәяләми, дип гаепләп чыкты. Гаяз Глориянең җавап язганын да хәтерли, ул нибары бер җөмләдән тора иде: «Архитектор алдында һәрвакыт бер бурыч торды һәм торачак: матур, яхшы сыйфатлы, гасырлар буена чыдарлык итеп төзү». Әмма Гаяз хатны тартмага салырга барган җиреннән—кире уйлады, җибәрмәде, чөнки чамалый иде: яшьләрнең кыюлыгын, дорфалыгын кичермиләр.

... Менә хәзер, күп еллар узгач, коридорда тәрәзә янында басып торганда, Глориянең үз карашын яклап көрәшүен күз алдына китерде, аның күпчелек очракта дөрес булуын таный, гәрчә ул вакытта да аның карашлары һәм идеяләренең дөреслегендә шикләнмәде.

Ул, җир тетрәгәннән соң, Ташкентта төзелгән бик күп биналарны исенә төшерде. Кайсыдыр ун ел эчендә бетон һәм тышлау материаллары яндылар, искерделәр—аларга инде берничек тә ярдәм итеп булмый иде. Күп катлы йортларның заманча һәм арзанлы тоелган чынаяк кирпеч, кафельләре кубып төшә, ә хәзер башка сыймаслык биеклектәге бер плитканы алыштыру йөзләрчә сумнарга төшә, хәл ителмәслек технологик мәсьәлә булып тоела.

Гаяз шулай ук Глориянең Яшьләр йорты турында янып эшләгәнен хәтерли, ул аңа туйлар узуга тотынган иде. Өч ел буена тырышты хатыны, өйләрендә булган бер генә очрашу да проект турында әңгәмәдән башка тәмамланмады. Тамаз шаярткан да иде әле, Глория архитектура турында шулкадәр мавыктыргыч сөйләп, футбол җанатарларын да үзенә каратып бетерер, дигән иде. Ә Глория сагышлы гына: «Миңа сезгә биргән кебек стадион бирсәләрме, халыкка чыга алсаммы, балам күк күргән һәрбер проектымны яклый белер идем!» Кайчакларда аңа берәрсе читләтеп: «Менә синең, үз канаты астына алучың, укытучың булса иде»,—дип куя. Моңа каршы Глория: «Минем химаячым киң катлау халык булсын иде»,—дип җавап кайтара иде. Ул һәрвакыт, м:'нем тыңлаучыларым аз дип өзгәләнде.

Бәлки, үзенең беренче уңышлы проектын һәм аны иҗатының төплелегенә ышандыруын оныта алмагандыр?

Яшьләр йортына вакланып шомартылган таш кисәкләре, югары сортлы ачык төстәге кирпеч һәм Зәркәнтнең барлык төсле металлын диярлек «тутырды», шулай да кызыл бакырны күбрәк кулланды, чөнки бакыр—Шәрык металлы, дип саный иде. Глория бу вакытка Үзбәкстанны әйләнеп чыкты һәм җәен «тир»гә батмаган бер генә заманча бина да күрмәдем дип раслады, ул чакларда көнкүреш кондиционерлары турында сүз дә юк иде әле. Аны бигрәк тә биналарда җиләслек булдыру мәсьәләсе борчыды. Болай дип шаярта иде: «Мәсәлән, концерт залларын кабул иткәндә, зурмы ул, кечкенәме, комиссия теләсә нәрсәгә: идәннәргә, түшәмгә, баскычларга игътибар итәргә мөмкин, тик иң әһәмиятлесе булырга тиешле ишетелеш-яңгыраш читтә кала. Шуңа «яңгырап торган» заллар бармак белән генә санарлык, ышанмаган кеше артистлардан сорасын. «Тагын шуңа игътибар итте: хәзерге заманча архитектурада тулы элемент—түбә югалган. Шул нәрсә Глорияне яңа идеягә этәрде. Башта ул түбәне гади генә—кояш нурларын көзгедәге кебек чагылдыра торган цинк калайлардан эшләргә уйлады. Тик Яшьләр сараен романтик бина итеп күзаллады, тышкы кыяфәте белән үк яшьләрне җәлеп итүен теләде, шуңа гадәти түбәне кире какты. Ә идеяне аңа Гаяз бирде: нигә кафесын түбәдә ясамаска?

Мәйданны урынлы куллану төп кагыйдәләренең берсе булса да: «Чынлап та, нигә шулай итмәскә?»—дигән уй килде аның башына. Кафены тиз сызгалады, иң әһәмиятлесе—түбә-чатыр уйлап тапты, ул кафены гына түгел, бар корылманы каплап торачак иде. Кафе шәрыкка тартым булачак, хром белән капланган цинк түбә-чатыр милли үзбәк нәкышы—ганч белән бизәлгән бик күп баганаларга таяначак. Глория бу элементны үзе яратып өлгергән Сәмәркәнд мәчетеннән алуын яшермәде. Аның уйлавынча, түбә шунда ук ике проблеманы хәл итәчәк: кояшның иң эссе, туры нурларын кире кайтара һәм бинаны җилләтә торган даими аэродинамик һава ташкынын булдыра. Кафенең исеме дә менә шуннан туды—«Йомшак җил»—эссе якларда анысы да ярап куя. Глория моның белән генә тукталып калмады: әлеге дә баягы Гаяз тәкъдиме белән, заман нормативларына таянып, диварларның калынлыгын арттырды һәм, җәйләрен бинаны салкынча тоту максатында, салкын су әйләнеп йөрсен өчен, торбалар урнаштырды. Бизәлеш, баскычлар Глориягә җиңел бирелде: фантазиягә бай иде ул. Гаяз, аның күңелмәгәндә туган чишелешләрен әкренләп кенә язып барды, бу язмаларның бер тапкыр гына кирәге чыкмагандыр. Гаяз шуны аңлады: архитектурада да фикер шигъри юлларга охшаган икән, вакытында язып куймасаң—кабат искә төшерермен димә.

Иркен холлның зур диварын «Мото куучылар» дигән мозаик панно бизәргә тиеш иде. Глория узыш юлларына хирыслыгын һич оныта алмады. Тизлеккә мөкиббән Зураб Каргаретели панноны үзе ясарга вәгъдә бирде. Гаязга проект тулысы белән ошады: кафе да, түбәсе дә, концерт залы да, барыннан да бигрәк холл: анда ваткаланган ташларга икенче каттан, шыбырдап, шарлавык агып тора, хауз кырыенда фонтан сиптерә, үтә күренмәле шахталардан бина буйлап, кунакларны холлдан «Йомшак җил»гә тавышсыз гына лифтлар ташып торачак.

«Вакытында туарга» дигән гыйбарәгә Гаяз элек игътибар бирми иде, бәлки, еш кына тиктомалдан искә алынганга һәм романтик чорларга кагылганга шулай булгандыр, чөнки ул чакларда мушкетер булырга яисә Чапаев белән янәшә ат өстендә чабарга телисең, ә кызлар исә сарайларда үтә торган баллар, үзләре өчен дуэльләрдә көч сынашулары, иртә беләнгә алар өчен мәхәббәт газаплары кичерүчеләрнең кәрзин-кәрзин чәчкәләр

җибәрүләре турында хыялланалар... Ә бит бу тәгъбир, барыннан да элек, кемнендер фаҗигале язмышы аркасында тугандыр. Гаяз үз заманыннан артта калганнарны наданнар—алар күпчелек, моңа әллә ни кайгырмыйлар—дип саный, ә вакытны узып китүче кешеләр—азчылык, аларының язмышлары йә бөек була, йә фаҗигале тәмамлана, әгәр дә беркем аларны аңламаса, яклап чыкмаса, хәтта вакыт та кайчакларда андыйларның хаклылыгын раслый алмый.

Гаяз гәрчә институтта укып, төгәл биш ел Себернең мәдәният үзәге дип саналган Омскида яшәсә дә, үзен әллә ни мәдәниятле кеше дип мактана алмый. Шулай ук аның күп кенә иптәшләре, курсташлары, кулларын йөрәгенә куеп, үзләрен мәдәниятле дип атарлар иде микән? Болай, тышкы билгеләр турында нәрсәдер укыдылар, нидер күрделәр, галстук бәйләргә өйрәнделәр һәм бар белгәннәре таушалып беткән «Яхшы тон кагыйдәләре» дигән китаптан, ул да күбесенчә салоннарда үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен пропагандалый, алар укыганда ук җиргә сеңгәндәй юкка чыктылар, һәм мондый укулар кешене, тәрбияле дип данын чыгарудан битәр, киресенчә, бик җинел генә уңайсыз хәлдә калдыруы ихтимал... Ә бит алар югары белемле кешеләр! Билгеле, аның буынының мәдәният өлкәсендә нәрсәнедер алып бетерә алмавының сәбәпләре күп төрле—объективлары да, субъективлары да бар: студентларның өчтән икесе стипендия хисабына гына яшәделәр, аларда, ничек кенә булса да институтны ташламаска, дигән уй иде, ләкин хәзер бу аклану өчен сәбәп түгел. Бәлки, алар ул вакытта бик модалы булган «физиклар—лириклар» формуласы артына качканнардыр? Техник фәннәрне үзләштерүчеләр—нәрсәгә ул безгә шигърият, сынлы сәнгать, музыка, скульптура дигәннәрдер? Җәл, ул чакта мондый фикернең шактый зыянлы булуы турында уйлап бетермәгәннәр. Иң беренчесе—аны Гаяз хәзер генә аңлады—акыл, рух дигәннәре институт һәм тулай торакларның диварларында да булмаган икән бит. Әлбәттә, анда башка студентлар да укыды, алар үзләрен «элита» дип санап, Гаяз кебекләрне «колхозчылар» дип ирештерә иделәр. Тик болар үзләрен фидакарьләр итеп күрсәтеп мәшәкатьләнмәделәр, аерым, үзләренә охшашлар белән аралашып яшәделәр. Әйләнә-тирә, мохит—мәдәният таратучы, ул теләсә кайсы акыллы трактаттан әһәмиятлерәк. Ул моңа Зәркәнттә, уйламаганда Джумбер компаниясенә эләккәч төшенде. Тбилисидан килгән югары белемле—Джумбер белән Роберт музыкаль мәктәп тә тәмамлаганнар, егетләрдән башка тагын табиблар, музыкантлар, педагоглар—гомумән, яңа каланың яшь зыялылары шактый иде. Тик ул аларга караганда, Глориядән күбрәк мәгълүмат алды, әйтерсең, тормыш үзе кыз янәшәсендә аңа шәхес буларак баерга мөмкинлек тудырды.

Яшьләрнең өй китапханәсендә үз чорында тумаган кешеләр турында китаплар бар иде. Бу чор һәм эпохалар буенча эш итүне аңлатмый, таланты көч җыйган, программалы эшләр, идеяләр белән килгән кешегә ун еллар да җитә ала. Ун еллыкны көтү һәм көрәшү һәркемгә бирелмәгән, кеше чигенмәскә, ә сынарга мөмкин.

Глориянең Яшьләр сарае проекты расланмады: айсбергка таба барган караб кебек, ул әле яңарак кына чыккан «архитектурада чаманы белмәү» дигән карарга «килеп бәрелде». Һәрвакыттагыча, тулаем алганда, гадел һәм үз вакытында башланган эштә арттырып җибәрү, артык гадиләштерүләр башланды. Аны сайлап алулары, Глориянең аңлавынча, очраклы хәл, кемнең дә булса үзенә карата явыз ниятен күрмәде—язмыш, бары тик язмыш шаяруы. Дөрес, аның проектында, яңа карардан чыгып фикер йөрткәндә, чамадан тышлары җитәрлек иде.

Кыю, искитәрлек, матур? Болар барысы да комиссиягә рөхсәт ителмәслек

купшылык, зиннәтлелек булып тоелды. Ә залны җиләсләндерү нияте? Дворяннарча иркәлек дип тамга сугылды һәм кабул ителмәде. Лифтлар, шарлавыклар, эчке хаузалар, фонтаннар? Яшьләр сараендамы? Әле барлык картада да урын алмаган Зәркәнттә? Барысы да, хәтта фикер дә алышып тормыйча, шунда ук кире кагылды. Ни гаҗәп: «Мото куучылар» турында бәхәс барыннан озак барды... Металлурглар шәһәренең Яшьләр сараенда узышчылар? Глория: «Тизлек, узышу—яшьлек, вакыт, чор символлары ул»,-дип аңлатырга тырышты. Комиссия җитәкчеләреннән берсе, кин күңеллеләнеп: «Панно—иң мөһиме түгел, аны үзгәртергә була,—диде һәм, үзенең карашынча, бәяләп бетергесез идеясен бирде,—диварның буеннан-буена ялкын сипкән бакыр фонында, кулына кисәвен тоттырып, шат күңелле металлург рәсемен ясарга да куярга». Куанычыннан һәм уйлап таба алуыннан, үзе дә Зәркәнт бакыры сыман балкыды. Глория тыелып кала алмады, кискен генә: «Бу сезне ванна янында кулыгызга чебен үтергеч тоттырып рәсемләү белән бер, чөнки бакырны Зәркәнттә химик ысул белән гальваник ванналарда табалар, ә ул ванналар өйнеке белән бик охшаш, бераз зуррак һәм агрессив тирәлеккә каршы тору өчен винипласт белән тышланган, димәк, бакырны табуда бернинди геройлык юк, дөрес, тагын бер аерма—зөбәрҗәт төсендәге матур измә—агулы». Бу каршы чыгыш белән ябырылу комиссия рәисенең, кемнең диген әле—күп хезмәтләр күрсәтеп дан казанган скульпторны, кәйлә яки чүкеч тоткан ир-атларны, кулларында ишкәк йә сөт чиләге булган хатын-кызларны сурәтләгән—заказ бирүче ничек тели, бары бүгенге тормыш кына «чагылдырылсын»—бик күп композицияләр авторының хәтерен калдырды.

Әгәр Глория үзен башкачарак тоткан булса, бәлки, проектның «януы» аның өчен ул хәтле авыр да булмас иде. Күңеленнән яңа карар куйган максат һәм бурычларны бик яхшы аңлады, иң беренче чиратта архитекторларның тырышлыклары, көче нәрсәгә юнәлтелергә тиешлеген дә төшенде. Күпләр, бик күпләр әле гомуми тулай торакларда, ә Урта Азиядә саман, балчык белән сыланган өйләрдә яшиләр. Бу проблеманы тиз хәл итәргә кирәклеген дә белә, тик шундый гади, әйтергә кирәк, чыдамлыкны, ныклыкны, матурлык, уңайлылыкны билгели торган элементлар салынган проектлардан баш тартулары берничек тә аңына барып җитә алмады.

Бу карашка ул проектны яклау барышында да ышандырырга тырышты, әмма, күрәсең, идеясе уңышсызлыкка дучар булды дип уйлап, турысын ярырга тотынды һәм аның кызуы, ярсуы бөтен чикләрне узып китте. Аннары шәхесләргә күчеп, комиссия рәисен талантсызлыкта, булдыксызлыкта гаепләүгә күчте, үзенең проектының вакыты киләсенә тулысынча ышануын әйтеп, усал һәм килешмәүчән тон белән тәмамлады. Бу чыгышы Глориягә бик кыйммәткә төште: аны архитектураның юнәлеш бирүче карарының бар пунктлары буенча «үтергеч» гөнаһларында гаепләделәр.

Туйдан соңгы дүртенче ел алар өчен бөтенләй уңышсыз булды. Иртә язда, футбол сезоны башланып китүгә, компаниянең җаны—шаян, мәзәкчән күңелле һәм юмарт Тамаз җитди җәрәхәт алды. Өч ай буе Ташкентның травмотология институтында сынган җирен дәвалатты һәм аннан инвалид булып чыкты. Ябыгып, суырылып калган Тамазга каравы җәл иде, кулында —табиблар ана гомере буе кирәк булачак дип ышанырга мәҗбүр иткән таяк. «Энҗе бөртеге»ндә уздырылган озату кичәсе, һәркем булдыра алган кадәрле шат күңелле булырга тырышса да, күбрәк искә алу мәҗлесенә охшап калды, табында һичкем җинә алмаслык сагыш урнашты. Тамазны озатканда, нинди дус компанияләренең әкренләп тарала, шуның белән бергә яшьлекләренең дә артта кала баруын тойдылар. Алар гомерләренең яңа этабына керделәр, анда зарыгып көтүләр дә, өметләр дә аз, иң яхшы дуслар югала бара;

кемнендер төн уртасында шаяртып чылтыратуы да сөенеч китерми, инде артка борылып карана башлыйсын: кичә нәрсә эшләнеп бетмәде дисен, үтәлмәсә дә бернинди авырту, сагыш сизмисен. Әнә шундый кәеф белән уратылган Тамаз, бу шәһәрдә анын яшьлеге бергә үткән купләрне сонгы тапкыр күрүен анласа да шаяртып маташты:

—Начардан башка яхшы була алмый, егетләр. Өйдә сөенерләр инде, менә, ниһаять, футболны ташлады диярләр, мин бит юрист, бөтен көчемне Фемидага бирермен... Ин башта бюрократлардан пенсиямне судлашырга туры килер, мин эчеп-исереп түгел, уннарча мен кешенен күз алдында гарип калдым: шулай итеп, ярты еллык практика белән тәэмин ителәм, дип санагыз. Мин сездән шуны сорыйм, дусларым, йөзләрегездәге кайгы-хәсрәтне алып ташлагыз, минем белән бик үк күнелле булмаган хәл килеп чыкса да, футболга яшьлегемнен ин матур елларын багышлавыма һич үкенмим. Футбол—минем мавыгуым, рухи күтәренкелегем. Глория, синен өчен архитектура ни-нәрсә булса, футбол да минем өчен шулай...

Иртән Тамаз кайтып китте, һәм компания шуннан сон беркайчан да элеккечә тулы составта җыела алмады. Әкрен генә, берәмләп, йә парлы-парлы өстәл янындагы очрашулардан төшеп кала бардылар һәм әйтерсен лә чонгылга туры килделәр—сәер генә юкка чыктылар, бу кеп-кечкенә шәһәрдә бит...

Шул ук елда гигант комбинатнын сонгы—өченче чиратын тапшырдылар, һәм һәрвакыттагыча эшләтә башлау алдыннан көне-төне кайтып кермәделәр. Гаяз элеккечә, тик хәзер икеләтә арттырылган, хуҗалык исәбенә күчерелгән участок белән җитәкчелек итә, эшләре күләме ягыннан Зәркәнтнен кайбер төзелеш-монтаж идарәләрен узып та китә иде. Шунын кадәр стажы һәм тәҗрибәсе белән инде ана күптән күпсанлы СМУларнын берсен җитәкләргә була, тик җитәкчеләргә яхшырак күренә: бер сызыкка югары хезмәткәргә караганда, шундый җаваплы объектта участок начальнигы мөһимрәк һәм кирәгрәктер. «Көт,—диделәр ана,—үзенә язылган беркая да китмәс». Ә ул ашыкмады, үзен тиешле урынында итеп тойды, менә дигән ирләр эше белән шөгыльләнүен анлый иде.

Комбинатны практик файдалануга тапшыру—дәүләт күләмендәге вакыйга, һәм бу датага төзүчеләр генә түгел, бөтен шәһәр әзерләнде. Монтажчылар төзелешне бер елга алдан тәмамлады, шуна аларны күп күләмдәге премияләр көтә. Гәрчә Гаязга да андый акчалар комачауламас иде,—хатыны Яшьләр сарае проектын тапшырганнан сон , тагын ике еллык ялларын алып, Глориянен дуслары—грузин архитекторлары чакыруы буенча Гаграга барырга җыеналар.

Күп кенә төзүчеләрне орден һәм медальләр белән бүләклиләр икән, кемнедер Хезмәт Героена тәкъдим итәләр кебек имеш-мимешләр таралды. Вакыты якынлашкан саен, бүләк эләгәселәрнен фамилияләре ешрак янгырады. Телдәге исемлектә Исламов та искә алынды.

Беркөнне идарәнен кадрлар буенча инженеры—янасы, теге дипломын алып карагач: «Акыллы, алайса», дигәне түгел—сер итеп кенә Гаязга документлар әзерләнүе турында пышылдады. Глориягә ул берсе турында да: кадрлар буенча инженернын сүзләрен дә, үзенен дә бүләк аласы бик килүен дә әйтмәде. Гәрчә анын башыннан Күлледә яшәгәндә үсмер чактагы—үзенен беренче хезмәт орденын утызда эшләп алу хыялы башыннан чыкмады. Орден Гаязга әтисе алдында ин нигезле исәп-хисабы булыр иде. Документларны шәһәр комитетына биргәннән сон, сер калмады, инде барысы да бүләккә аларнын идарәсеннән бизәүчеләр бригадиры—үзенен туган кышлагыннан дистәләгән кызларга төзелеш юлын күрсәткән Зөлфия Батырова һәм Исламов тәкъдим ителгәнен беләләр иде инде. Икесе дә—комбинатнын беренче чиратыннан ук төзелештә.

Шулай да Исламовның документларын кире бордылар. Юк, лаек булмаганга, орденга хакы юклыкка түгел—гади генә итеп, эшче кандидатурасы кирәк, диделәр. Күрәсең, башка идарә һәм трестларда җитәкчеләрне бүләкләүгә куйганда тырышыбрак җибәргәннәрме—артыгын шаярганнар. Ә бәлки, очраклы хәл генәдер. Ашыгыч рәвештә танылган бригадир, шәһәр советы депутаты Силкинга документлар тутырдылар.

Ничәдер еллардан соң курсташларның язмышлары менә шулай сәер итеп кабаттан килеп кушылды. Югары орден—Хезмәт Кызыл Байрагы ордены Юрий Силкинга эләкте. Гаязның үпкәсе бик озакка сузылды. Силкин «чәчәк атты». Бакчасы булган ике катлы коттеджга күченде, ике еллап инде шәхси «Волга»сында йөри һәм республиканың эшче делегациясе составында берничә мәртәбә чит илләрдә булды.

Уңышсызлыгы, Гаяз шулай санады, үзе артыннан хатыныныкын да ияртте. Глория Гаязның сөйләүләре аша аның әтисенең һәм абыйларының үлеменнән хәбәрдар иде, иренең шулай ук нәселне, фамилияне дәвам итүче бердәнбер ир заты итеп санавын да белә, аның өчен бала, малай, кечкенә Исламовның нәрсә аңлатуын да төшенә. Иренең бала турындагы хыялын никадәр уртаклашса да, эше бар нәрсәгә киртә булып тора. Ул һаман: «Әз генә сабыр ит, менә Яшьләр сараен тәмамлыйм да эштән туктап торам: үрнәк хатын, хуҗабикә, әни булам»,—дип сүз бирә. Проектны якларга киткәндә, ул иренә үзенең балага узуын әйтте. Менә ни өчен, телеграмманы алгач, Гаяз бик борчылып, Ташкентка ашкынды. Иренең игътибары Глориянең күңелен нечкәртеп җибәрде, ул яшь аралаш елмаеп: «Исәр, икенче ай гына бит әле, минем дулкынлануларым нәни Исламовка һич тә зыян китерми»,—диде. Алар уллары буласына икесе дә шикләнмәделәр.

Ташкенттан буш кул белән кайттылар. Хатыны үзенең җиңелүе белән килешкән кебек. Гаяз аны тынычландырды: «Менә ике атнадан, комбинатны файдалануга тапшыруга, Гаграга китәрбез. Ял итәрбез, аннан күз күрер тагын».

Көтмәгәндә, кайтуына ике көн дигәндә, Глория ял алды һәм Мәскәүгә китәсен, комбинатның өченче чиратын тапшыру тантанасына кайтып җитәсен әйтте. Гаяз ни тырышмасын—аны туктата алмады. Глория, ахырына кадәр көрәшәсем килә, диде. Зур кунаклар килүен көтеп, тантананы ике тапкыр кичектерделәр. Глория кайтмады, сирәк кенә шалтыраткалады, хәбәрләр куанырлык түгел иде. Гаяз объектны дәүләт комиссиясенә тапшыргач, ни теләсә дә хатыны янына бара алмады. Глория Зәркәнткә, телеграмма биреп тормый-нитми, ай ярымнан кайтып төште, ябыккан, борчулы. Кыяфәтеннән күренеп тора: юлы уңмаган, бусагадан атлауга, ул иренең муенына сарылды һәм үксеп елап җибәрде. Озак үкседе—Мәскәүдә үзенә бушанырга юл куймаган горур Глория хисләренә ирек бирде. Гаяз, кулларына күтәреп, аны диванга илтеп салды. Иренең беләгендә яткан килеш, тәмам хәлсезләнеп калган Глория йокымсырады. Төн уртасында кинәт уянып китте, әйтерсең күзен дә йомарга өлгермәгән, төшенкелеккә бирелгән кыяфәттә:

—Гия, мин Мәскәүдә синең улыңны үтердем...—диде.

Гаяз төзәтә алмаслык нәрсәдер булганын сизенгән иде, көч-хәлгә кыргый тавыш белән кычкырып җибәрүдән тыелып калды һәм үзендә, әрнүдән, ачынудан тыны кысылып, янәдән бәргәләнеп үксергә тотынган авыру хатынын тынычландырырлык көч таба алды. Шул чакта нишләргә белмәгән, арыган-талчыккан Глориягә ачы үпкә-шелтә сүзләре әйтми калырга көч таба алуы өчен, язмышына гомере буе рәхмәтле булды. Хатыны өч көн урыныннан тормады, өйдән чыкмады. Гаяз ял алып, аның янында булды.

Глориясе әзрәк үз хәленә кайтуга, дингезгә китәргә җыендылар. Гаграда фатирны Джумберның агасы Дато Джешкарианиның кунакчыл йортыннанерактарак—шәһәрнең икенче ягында сайладылар, мондый төшенке күңел белән үзләренә карата яхшы мөнәсәбәттә булган кешеләрнең кәефләрен җибәрәселәре килмәде. Халык күп җыелган урыннарда да күренмәскә тырыштылар. Көннәрен комлыкта үткәрделәр, әмма кайчандыр бу урыннарда үзләрен бик бәхетле һәм рәхәт хис иткәннәре турында телгә алырга да курыктылар; әйләнә-тирәне мондагылардан ким белмәсәләр дә, беркая да бармадылар, хәтта авызларыннан Пицунда дигән сүз дә чыкмады. Кичләрен бер үк ресторанга йөрделәр, анда аларның фатир хуҗасы официантка булып эшләгәнгә, террасаның почмагындарак торган өстәлдә кечке сменада һәркөнне «Заказ бирелгән» дигән язу тора, бу—аларның урыны иде.

Сәер: элегрәк уен-көлке белән вакыт үткәне сизелми дә иде, хәзер дә кичләр, өстәл яны шау-гөр килмәсә дә, бик тиз кимиләр, тик икенче террасадан ишетелгән музыка да аларны урыннарыннан кузгата алмады. Икесенең дә эчләрендә нидер өзелгән төсле, алар хәлсезләнеп калган карт белән карчык шикелле, бер-берсенә таяныч булырга тырыштылар. Сөйләшер теманы да үзләренең тормышыннан читтәрәкне сайладылар. Ул җәйдә, һәр кич, террасада, шәфәкъка сокланып, әдәбият турында гәп кордылар, хәер, күбрәк Глория сөйләде, ә Гаяз, теге вакытта «Энҗе бөртеге»ндә беренче очрашкандагы кебек, әкренләп булса да тормышка кайтучы чибәр, гүзәл хатынынннан күзен дә ала алмыйча тыңлап утырды.

Өйләренә сентябрьдә, Зәркәнттә һәркемне йөдәтеп бетергән эсселек кимегән һәм озакка сузыла торган җылы көз ае кергәч, Үзбәкстанда табигатьнең иң гаҗәеп чорында кайтып төштеләр. Шау-шусыз, берәүне дә кисәтеп тормыйча, хәбәрсез-нисез. Кайту хөрмәтенә, элеккеге кебек, өйгә яки кафега кунаклар да дәшеп тормадылар. Футбол командасының читтә уйнаганын беләләр иде.

Төнлә телефон шалтыравыннан уянып киттеләр. Шалтыратучы—Павлодардан Джумбер иде.

Алар моңа шулхәтле куандылар, йокыга китә алмый шул турыда сөйләшеп яттылар. Югыйсә шалтырату шатлык алып килмәде—киресенчә... Джумбер Робертны «Пахтакор»га алулары турында хәбәр итте, аларның уң кырый һөҗүмчеләре җәрәхәт алган икән, тренерлар советы «Металлург» футболчысына туктаган.

Команда Павлодардан төштән соң кайтып төште, һәм Робертның Зәркәнттә бер генә булса да буш киче табылды, иртәгесен ул «Пахтакор» командасы составында Тбилисиның «Динамо»сы белән булачак уенга очарга тиеш иде. Джумбер аннан саубуллашу кичәсе үткәрүен сорады. Компания тагын бер әйдәманын югалтырга җыена. Роберт өчен бу күтәрелү саналса да, табында шатлык сизелмәде. Барысы да, беренче чиратта Роберт үзе, моның бик соңлап чакыру икәнен аңлыйлар. Бердәнбер сөенеч шул: өч көннән соң ул туган җире Тбилиси кырына аяк басачак.

Робертның туган шәһәрендәге уены аның үз гомерендә иң яхшы уены булды. Исламовларда телевизордан матчны карап утырган Джумбер күз яшьләрен яшермәде. Таныш түгел командада «Пахтакор» өчен беренче уенында кеше ышанмаслык, мөмкин булмастайны эшләде—бар нәрсә унай килеп торды. Тәҗрибәле иптәшләре яна килгән һөҗүмченең уены барганлыгын шәйләп, бар пасларны аңа—инде ике тапкыр туп кертергә өлгергән Робертка юлладылар. Бер мизгелгә генә стадионның трибуналарын күрсәтеп алганда, дуслары Тамазның йөзе чагылып киткәндәй булды, ә алар аны Роберт Тбилисида уйный дип кисәтергә дә өлгермәделәр. Гаяз

Робертның хәлен бик яхшы аңлады: бер яктан, ул үзенең иң әйбәт уенын күрсәтә алды, әмма икенче яктан,—аңа бит үзенекеләргә каршы уйнарга туры килде. Исламов тагын шуны уйлады: бер Робертка гына түгел, тагын бик күпләгән грузин егетләренә үз командаларында урын табылмады—бу республика талантлы футболчыларга бик бай иде шул. Шуңа күрә аларга бәхетләрен башка командаларда эзләргә туры килде. Дустының уенын Джумбер болай дип шәрехләде:

—Һәркайсыбыз, өйдә—Грузиядә уйнау тәтемәгәннәр, соңгы көчкәчә, нәкъ шулай уйнарга тиешбез... яки кырда үлеп калырга.—Бу кичтә алар белән саубуллашканда иртә чал кергән капитан:

—Тирә-юньдә күпме кеше, ә миңа шәһәрдә өчебез генә калган шикелле,—диде.

Кайгы-хәсрәтләр Глория белән Гаязны якынайтты, аларның уртак тормышлары җайга салына башлады, гәрчә өйләнешүләренең бишенче елында бу сүзләр сәер яңгыраса да—дөресе шулай. Артта күз иярмәс тизлек белән ераклашкан еллар икесе өчен дә эш белән тум-тулы иде. Глория, әгәр нинди дә булса идея туса, төннәрен дә сикереп торып кульман янына килеп баса, ә Гаязның объектында җәелмә ятак һәрвакыт әзер тора—өченчесеме, дүртенчесеме инде, әллә бик нәфис итеп чыгаралар, әллә йончыган прораблар тыныч кына йоклый белмиләрме шунда. Эш, эш, эш... Әгәр буш вакыт килеп чыкса, дуслары белән аралашырга, кунаклар чакырырга, Ташкентка барып чыгу мөмкинлеген кулдан ычкындырмаска тырыштылар. Гаяз, студент вакытындагы кебек үк, һич нәзберек түгел, өйдә төшке ашлар, уңайлылык таләп иткәне булмады, ул Глорияне аңлый, аның белән горурлана, эшенә зур хөрмәт белән карый, һәм яшертен генә улы да әнисе кебек архитектор булыр дип хыяллана иде.

Глорияне архитектурасына суынды дип әйтү дөрес булмас, ул бары тик, башкалар кебек үк, эшеннән вакытында кайта башлады. Фатирдан кульман һәм эскизлар төшерелгән дистәләгән ватман битләре юкка чыкты, һәм, ниһаять, моңарчы проект институтының мастерскоен хәтерләткән бүлмә чын бүлмәгә охшап калды. Ә бервакыт өйдә чүлмәктә утырган гаҗәеп гөлләр барлыкка килде. Эштән соң Глория базарга сугыла, һәм ире кайтуга, кухнядан тәмле исләр тарала. Гаяз хатынының шундый искиткеч тәмле әзерли белүенә бик гаҗәпсенде. Глория эшен өенә башка алып кайтмады.

Гаязның да эшендә нидәрдер үзгәрде. Комбинатны инде тапшырсалар да, объектта эшчеләр бар иде әле, тагын ярты еллап алар эшләнеп бетмәгәннәрне карап чыгачаклар—бу бик сәер, әмма законлаштырылган нормативны хәтта Гаяз—инженер булса да, аңлап җиткермәде. Аның алдынгы коллектив тупланган һәм үз хисабына эшләүче участогын кая илтеп тыгарлар: көнкүреш химиясе заводы төзелешенәме, әллә үзләре төзегән комбинат базасындагы сульфат кислотасы цехынамы—анык кына билгеле түгел иде. Төзүчеләр объектларның барысын да алдан тапшырганга, тегесенең дә, монысының да проект документлары әзер түгел иде. Исламов өчен тагын аңлашылмаслык хәл: кәгазьләр эшне тоткарлый иде. Гаяз да вакытында кайтып, өй эшләре белән шөгыльләнә башлады. Ниһаять, балкон тәрәзәләрен куйды, идәннәрен җәйде. Еллар буе чигерелеп килгән бу эшләрнең атна эчендә тәмамлануына икесенең дә исләре-акыллары китте. Кызып китеп, үз куллары белән фатирларына ремонт ясарга булдылар, Глориянең күзләрендә кабат очкыннар кабынды.

Гаяз яңа гына утызын тутырса да, комбинат төзелешендә көченең соңгы тамчысына кадәр сыгылганын сизде, башка эшләр чамасы юк, шуңа күп кенә хезмәттәшләре шикелле, тынычрак объект алырга булды—тик бу

турыда әлегә Глориягә әйтмәде. Соңгы вакытларда алар Ташкентта еш булдылар, хәтта тукталу өчен бер карчыкны да таптылар. Бу язда яна орган залына йөрергә һәвәсләнеп киттеләр, шуның өстенә «Пахтакор»ның бер генә уенын калдырмадылар—Роберт өчен җанаттылар.

—Сезнең трибунада икәнегезне күргәч, мин үземне ышанычлырак сизәм,—ди иде тегесе уеннардан соң.

Ул җәйдә аларның компаниясе тәмам таркалды. «Металлург» составы бик зур янарыш кичерде, икенче төрле әйткәндә, буыннар алмашынды, элеккеге чемпионнардан икәве генә калды—алыштыргысыз капитан һәм капкачы. Тренер да бүтән, ул үзе белән ярты команда ияртеп килде. Джумберның тренер белән дә, яналар белән дә мөнәсәбәтләре барып чыкмады—футболга карашлары төрлечә иде. Зәркәнт кырында беренче тапкыр чәчләре таралмаган тузган башлы, сызырылып төшкән гетрлы, төймәләре ычкынган күлмәкле футболчылар күренде, житмәсә, һәрберсенең муенында, талисман дигән булып, ниндидер вак-төяк чайкала иде. Джумберның тизлеге бераз кимесә дә, уенына тел-теш тидерерлек түгел әле. Футбол хикмәтләрен энәсеннән җебенә кадәр белә, тактик сиземләве үткен, ә иң мөһиме—үзенең канатлары Тамаз белән Робертны югалтуга карамастан, капкага күп кертә, тик яна һөҗүмчеләр аны пас белән әллә ни узындырмадылар, моның артында яшьләр генә түгел, ә тренерның да кулы уйнаганын ул сизенгән иде инде. Футболда кайбер нәрсәләрне чамалаган Глория белән Гаязга да нәрсәдер шикле тоелды. Өйләрендә уйналган чираттагы уенда, мәш килеп икенче тайм барганда, нәкъ кирәк чагында Джумбер гол керткәннән соң, тренер футбол кырына якын килеп, ишарәләр белән Джешкарианины алыштырырга теләвен белдерде. Джумбер башта аңлап җиткермәде—ничек, аны алыштырыргамы? Вакыйга Глория белән Гаяз утырган сектор янында барганга, алар капитанның ап-ак булуын күреп тордылар. Секунд та үтмәде, ул кыр читенә йөгереп килеп, тренерның түшеннән эләктереп, карлыккан тавыш белән:

—Тотынып кына кара, тотынып кына кара!..—дип хырылдады һәм, әйләнеп тә карамыйча, түгәрәкнең уртасына йөгерде.

Исламовлар һәм запастагылардан башкалар ни булганын аңышмый да калдылар бугай.

—Менә, дуслар, футбол белән саубуллашу чираты мина да килеп җитте,—диде капитан, уеннар беткәч.

Бүтәннәр өчен озатканда һәм каршылаганда купшы кичәләр үткәрергә яраткан Джумбер кафеда оештырылачак саубуллашу кичәсеннән баш тартты. Аның китүен Гаязларның яна гына ремонт ясалып беткән фатирларында өчесе генә, таң беленгәнчегә кадәр, билгеләп үттеләр. Джумбер киткәннән соң, Исламовлар өчен Зәркәнт тоныкланып калган кебек тоелды, алар моңа бик озак ияләшә алмадылар. Джумбер, әйтерсең, Зәркәнттә футболның тиздән бетәчәген сизенгән. Күзгә кергәч, «Б» классын кыскарттылар, һәм шуннан соң чын футбол башка беркайчан да күренмәде. Язларын узышчылар да килмәс булдылар, ләкин аңа аңлатма биреп була: узыш юлларын хәзер бар җирдә дә төзиләр, шуңа күрә бөтен илне үтеп, штаттан тыш шәһәрчеккә килүнең мәгънәсе калмаган иде...

Айлар үтте, аларның бер җайга салынган гаилә тормышларында вакытның узуы сизелмәде дә... Гаяз Глориянең тынычланып калуына куана һәм эчтән генә: «Бәхетебез тагын да тулы булсын өчен малай да булса»,—дип уйлана иде. Гәрчә хатынының бу турыда уйлануын сизсә дә, Глориягә бала хакында беркайчан да әйткәне булмады. Аның табибларга ешлавын да белә иде. Вакыт бара, тик шатлыклы кыенсыну белән әйтеләсе сүзне ул һаман да ишетмәде...

Бервакыт төнлә белән иңбашына сыенып яткан Глориянең тавышсыз гына үксүеннән кинәт уянып китте. Уяу икәнен сиздермәскә тырышты, бәлки, берәр төш күргәндер, дип уйлады. Әмма бу хәл икенче кат кабатлангач, тынычландырырга маташканда, хатыны белән чын-чынлап истерика башланды. Үз-үзен тота алмас дәрәҗәгә җитеп, кайгыдан саргаеп, акылдан язган кебек кычкырына башлады:

—Мин балабызны үтердем, нигә син мине яныңнан куып җибәрмисең? Мин синең тормышыңны җимердем! Синең бервакытта да улың булмаячак, Исламов! Мин бит беләм: син көннәр-төннәр буе шул турыда хыялланасың. Куып җибәр мине! Куып җибәр!

Хатынының шашкан күзләреннән үбә-үбә, Гаяз ничек кирәк алай аны тынычландырырга тотынды, һәм кайчандыр аңа улы турында, Исламовлар нәселе алдында үзен бурычлы хис итүе хакында сөйләве өчен бик нык үкенде. Глориянең җанында тынычлык урнашсын өчен, туачак ун улыннан баш тартырга да әзер, сизә: хатыны харап була, ә ул ничек ярдәм итәргә дә белми.

Бу вакыйгадан соң, Гаяз хатынына игътибарын тагын да арттырды, төнге сменалардан катгый рәвештә баш тартты, аны авыр уйлары белән ялгызын гына калдырырга курыкты. Әй, шул чакта Гаяз өчен җир йөзендә аннан да кадерлерәк берни юк икәнен Глориянең дә аңлавын бик теләгән иде ул! Кайчакларда бар нәрсә уңышлы гына килеп чыга да Глория берәр-икешәр ай куанып, тәэсирләргә бирелеп йөри, киемнәр сатып ала, һәм алар, һәр шимбә диярлек, Ташкентка баралар. Ял алгач, туристлар белән Болгариядә сәяхәт иттеләр, Глория диңгез буендагы кунакханәләргә сокланып туя алмады. Монда ул яңадан күп итеп рәсемнәр ясый башлады, башына яңадан-яңа идеяләр килде. Гаяз Глориянең кабат архитектурага омтылышын күреп, сөенеченнән нишләргә белмәде, кабат гаилә уңайлыкларын корбан итәргә, фатирны проект мастерскоена әйләндерергә бик теләп риза, тик ул гына төннәрен, үзен гаепле санап, күз яшьләре түкмәсен. Болгариядә яңа гына дискотекалар барлыкка килгән чак, рестораннарда беренче класслы оркестрлар уйный, һәм Глория, теге вакытта «Энҗе бөртеге»ндәге кебек, һәр кичне бик рәхәтләнеп биеде. Варнадан Одессага пароходта кайтканда, өске палубадагы танцы залында ял итүчеләрдән берәү, хатыны нинди гамьсез, шат күңелле дип, Гаяздан көнләшкән дә иде әле. Гаяз эченнән генә: «Аллага шөкер, һушына килде, ахры»,—дип сөенде.

Болгариядән кайтып, берәр атна үткәч, Гаяз, чәчәкләр тотып, өенә кайтса, өстәлдә язу ята иде.

«Гия, сөеклем, мине эзләмә. Безнең бергә яшәвебездән берни барып чыкмас. Барысын да яңабаштан башларга тырыш. Синең бер гаебең дә юк, барысы өчен дә мин сиңа рәхмәтле. Булдыра алсаң, кичер һәм мәңгегә хуш.

Үбәм, Глория.»

Сүзләренең коточкыч мәгънәсе тиз генә аңына барып ирешмәде, язуны кат-кат укыды, әгәр таныш кул белән язылмаган булса, кемдер рәхимсез рәвештә шаярткан, дип уйлар иде. Өйдә берни үзгәрмәгән, бөтен җир чип-чиста, җыештырылган, чүлмәкләрдәге гөлләргә су сибелгән... Гаяз кием шкафының ишекләрен каерып ачты—аның киемнәре янында Глориянең ике искергән күлмәге һәм плащы эленеп тора. Чемодан һәм аның яраткан юл сумкасы урынында юк иде. Ул акча һәм документлар саклана торган кечкенә тартмага ташланды—Глориянең паспорты юк. Башында: «Хет, акча алырга иде» дигән уй чагылып узды. Гаяз тахтага барып ауды да, кечкенә чагындагы кебек үкереп елап җибәрде...

Бер ай үтте, икенчесе... Гаяз беркемгә дә Глориянең киткәнен әйтергә

теләмәде, хәер, кемгә әйтсен, соңгы вакытта ул берәү белән дә диярлек аралашмады. Үзе дә булган хәлгә ахырына кадәр ышанып бетмәде, ана хатынының эшендә ниндидер уңышсызлык булган, барысы да озакламый үтәр, тынычланыр да өйгә әйләнеп кайтыр кебек тоелды. Бетмәс-төкәнмәс уйларыннан һәм йокысыз төннәрдән каралып чыккан Гаяз эшеннән һәркөнне, Глория өйдәдер дип, очып диярлек кайта. Әгәр тоткарланасын белсә, ишектә хат калдыра: «Глория, мин фәлән сәгатьтә кайтам». Беркөнне баскычтан менеп килгәндә, ул үзенең язуын урынында күрмәде, шатлыгыннан тыны кысылды. Тиккә генә куанган булып чыкты—язуны, мөгаен, шаяртырга теләп, малайлар алган булгандыр. Төннәрен ул, шалтыраталар дип, шатлыгыннан сикереп торды, ялгышуына төшенгәч, иртәнгә кадәр йокыга китә алмый, борсаланып ятты.

Беренче айларда Гаяз Глорияне эзләп маташмады, аны оятка калдырудан курыктымы шунда, әллә әйләнеп кайтуына ышанычы зур иде микән? Инде өченче айга киткәч, ышаныч югалды, һәм ул, бизгәк тоткандай калтыранып, үзенә билгеле булган адреслар буенча эзләргә кереште, тик берсеннән дә тынычландырырлык хәбәрләр килмәде. Кичләрен ул өеннән дә чыгарга курыкты: әгәр Глория кайтса йә хәбәр итүләрен сораган кешеләр шалтыратса? Бары тик бер елдан соң гына Норильскидан телеграмма алды, ул бернечә генә сүздән тора иде: «Газаплама үзеңне, мине эзләмә».

Атна узуга, Гаяз Норильскида иде инде, шәһәрне аркылыга-буйга айкап чыкты, милицияне аякка бастырды, тик Глориянең эзенә төшә алмады. Бәлки, ул берәрсенә дөньяның икенче читеннән хәбәр салырга кушкандыр? Нәкъ шулай булгандыр, печән чүмәләсендәге инә түгел—кеше кадәр кеше бит, Норильск та ул заманнарда әллә ни зур шәһәрләрдән саналмады.

Ике ел үтеп китте. Глориянең соңга калып тотынган мавыгуы—чүлмәктәге чәчкәләре шинделәр. Кайчандыр шатлык тулы уен-көлкеле мәҗлесләрнең шаһите булган бәхеттән ташыган йорт, әйтерсең, телдән язды...

Эшендә кирәклеген тою һәм канына үтеп кергән җаваплылык хисе генә Гаязны тотып тора. Беркем аны күтәрү турында сүз катмый, бар да—егет башын югалтты, диләр. Шунысы яхшы: яна объект—көнкүреш химиясе заводы комбинат төзелеше кебек артык киеренкелек таләп итмәде, шуның өстенә Гаяз инде—начальство шулай әйтергә ярата—шомарган төзүче. Эшендә аңа начарлык теләүчеләр юк, ә дуслары аның бәхетсезлеген белеп (шәһәр кечкенә, яшереп калдырып булмый, Глория үзе дә Зәркәнттә билгеле кеше, шуның өстенә төзелешкә турыдан-туры бәйләнеше бар), төрлечә ярдәм итәргә тырыштылар.

Участогында коллективы бердәм, инде сигез ел бергә эшлиләр. Тик көннәрдән бер көнне хәл кискен үзгәрде—идарә җитәкчесе итеп Силкинны куйдылар. Бу очраклы гына килеп чыкмады. Соңгы елларда төзүчеләрнең министрлыкта зур түрәләр катнашында уза торган аеруча әһәмиятле киңәшмәләренә, планеркаларга бригадирлар, алдынгы эшчеләр дә чакырыла иде. Аларның идарәсеннән эшчеләр исеменнән еш кына Силкин катнашты. Теләсә нинди эссе көн булсын, андый киңәшмәләргә ул һәрвакыт күкрәгенә орден тагылган махсус эш курткасыннан килә иде. Шунысын да әйтергә кирәк, Силкин үз идарәсенең мәнфәгатьләрен лаеклы рәвештә яклаучы вәкил булды, җитәкчеләрен шелтәдән бер генә тапкыр йолып калмады. Башка эшләрдәге кебек, төзүчеләрнең дә үз этикалары яшәп килә: ачыктан-ачык хезмәттәшләреңне батырырга, аларны һөҗүм астына куярга ярамый, чөнки төзелеш тулысынча бер-беренә, бер идарәнең икенчесенә бәйле булуы ул. Идарә җитәкчесе йә баш инженер үзенең күрше коллегасына нәрсәнедер этикага туры килердәй әйтеп җиткерә алмаса, бу эшне, эчкерсез кыяфәт чыгарып, Силкин башкара иде. Министр урынбасары яисә икенче

бер түрә, Силкинга мөрәҗәгать итеп: «Халык нәрсә дип әйтә»,—дип сорау бирсә—күршеләренең тез буыннары калтырый башлый. Силкин күрер күзгә гади инженер кебек кенә тоелса да, еллар аның өчен эзсез үтмәгән, күрәсең. Ул һәрвакыт эшлекле, төпле чыгышлар ясады; әлбәттә, күбрәк чит бакчага таш ата, шуның белән идарәсенә янаган хәвеф-хәтәрне читкә бора, шул арада үзләренең җитәкчеләре, тын алып, бар көчләрен күршеләреннән күләме һәм вакыты ягыннан файдалы эш фронты таләп итүгә юнәлтә—аның данлыклы бригадасының табыш алуы менә шунда яшеренгән. Төзелештә башка андый бригадир булмаганга, аны берничә мәртәбә, кызыктырып, башка идарәләргә чакырып карадылар, әмма Силкин үз идарәсенә ныклап ябышкан, күрәсең, яхшыдан әйбәтне эзләмиләр дигән фикердә тора. Билгеле, Силкин барысына да үзе өлгерә алмый, кайбер кайнар киңәшмәләр алдыннан җитәкчелек аны җентекләп әзерли: күрсәтмәләр бирә, бар бүлекләр дә аның өчен исәп-хисап эшли, шуна күрә ул чыгышларын тулы коралланган хәлдә ясап, кергәндә бик нык торды, аның моңа сизгерлеге җитәрлек иде. Көчлерәк ышандыру максатында,—акылга сыярлык чиктә үтәнкыйтькә дә юл куела,—күбесенчә, минутларга, граммнарга карата сакчыл караш булдырырга кирәк, миллионнар шулардан җыела кебек таныш җөмләләр кулланырга тырышты.

Шундый вакытларда Исламовның: «Тынычлыкта калдырыгыз әле шул минутлар, граммнарны, иң яхшысы—үзегез миллионнарны саклагыз»,—дип әйтәсе килә. Бик еш һәм эшлекле чыгышлар ясап, Силкин гел югары түрәләрнең күз уңында булды. Министр урынбасары идарәнең кайбер җитәкчеләре белән баш кагып исәнләшә, ә Юрий Ивановичка һичшиксез кулын суза, әле эше һәм сәламәтлеге турында сорашырга да онытмый. Министр урынбасарының үзе башлап кул бирүен күргән җитәкчеләр аны кулларына гына күтәреп йөртмиләр.

Озак еллар эшләсә дә, Гаяз ялагайлыкка, түрәләргә баш июләргә һич өйрәнә алмады, югыйсә, беренче карашка каты күңелле, кырыс кешеләр җитди эш белән шөгыльләнәләр сыман. Аяк чалуларга да күнегә алмады. Ә кем-кем—ул «куркыныч астына кую» дигәнне бик яхшы аңлый, төзелештәге һәр һөҗүм нокаутка җибәрә.

Ничектер берчак шулай килеп чыкты: бер бик зур киңәшмәдә тиргәш, кычкырыш вакытында министр урынбасары бер идарә җитәкчесенә: «Үзегезне иртәгесе көннән бу хезмәт вазифагыздан азат, дип санагыз»,—диде һәм, тезелеп киткән өстәлләр буенча күз йөртеп, СМУ җитәкчесенә эшне кабул итеп алырга кушты. Күршеләре озак елларга сузылган түбәнсетү, этлекнең уен булмавына шунда гына төшенделәр.

Министр урынбасарының бригадирга карата яхшы мөнәсәбәтен белгәнгә, сүз куешкандай, барысы бергә шау килделәр:

—Юрий Иванович Силкинга...

—Юрий Иванович, сез нәрсә, институтны җиңеп чыгарга өлгердегезме?—дип сорау бирде министр урынбасары.

Силкинга, аңына килеп, авыз ачарга да ирек бирмичә, тагын шул ук күршеләре дәррәү җавап бирделәр:

—Әлбәттә, җинде, Сергей Петрович, ул барысына да житешә.

—Бик яхшы, практикларның югары белем алуларын без бәялибез.—Министр урынбасары, соңгы елларда Силкин читтән торып институт тәмамлаган , дип санады.—Мин каршы түгел, менә дигән бригадир, шәһәр советы депутаты, орден иясе. Идарә җитәкчеләре хуплап тора икән, эшне кабул итеп алыгыз, Юрий Иванович. Андый үзара әйбәт мөнәсәбәтләр эш өчен бары тик файдага гына.

Ярты сәгать эчендә өч кешенең язмышы хәл ителде, жилләре читләтеп

булса да дүртенчегә—Гаязга килеп кагылды.

Өч ай тирәсе, урынына үзләшкәнче, Силкин Исламовны юк-барга йолыкмады. Әйтергә кирәк, Силкин вазифасыннан канәгать иде, инженерлыкка омтылмады шикелле, ә түрәлеккә—монысы инде башка мәсьәлә, язмышының алай борыласын ул күз алдына да китермәде, дипломының да кирәге шуның кадәр генә дип санады. Инде бригадирлык та туйдыра, ялкыта башлаган иде, кемнәр өчендер еллар буена сузылган проблемаларны ул утыз яшенә хәл итте, дәрәҗә-дан ятратуын эчтә яшереп тотарга мәҗбүр иткән матди омтылыш та юк,—яшь шәһәр Силкинга карата бик юмарт булды, хәтта үзенең депутаты итеп тә сайлады. Утызга кадәр үзләренең тормыш мәшәкатьләре белән мәшгуль булганда, кем генә хакимлек, аның үз ихтыярына буйсындыручы көче, кемнең власть белән идарә итүе, кемнең аңа буйсынуы турында уйлар икән? Силкинны үз бригадасы өстеннән чиксез хакимлеге генә канәгатьләндерә алмый иде инде, күләме ул түгел. Эшче битлегенә капланып, ул бик күп утты, тик тернәкләнгәч, көч җыеп, үз урынын тапканнан соң, үзенең практик акылы белән исәпләп чыгарды: юк, үзенең күтәрелә алуын чикләгән, эшчеләр өчен бригадирлык—иң соңгы дәрәҗә, дип санаган. Кинәт кенә менә сиңа бригадир башы белән идарә җитәкчесе, ул елларда ни хыялланган инженерларның да төшенә кермәгәндер бу хәл. Бу исәптән, теләсә кайсы биеклекне яуларга була: идарә җитәкчесе, ә анда, белмәссең, бәлки, кайчан да булса, министр үзе аталарча урынын аңа калдырыр? Ә ни өчен юк? Силкинның тавышы яңгырап тора, нервлары һәм сәламәтлеге тәртиптә, әнә кайбер прораб яшьтәшләре көнгә икешәр тартма тәмәке тартып, дарусыз йоклап китә алмыйлар, берәр нәрсә булса, йөрәкләренә тотыналар. Белеме менә дигән, көндезгедә укып, җитди институт тәмамлады. Идарәсеннән дә унды: нинди мираска ия булган җитәкчесен бернинди икеләнүләрсез, күз ачып йомганчы идарәче итеп куюларыннан да аңлашыла. Баш инженер да, бүлек мөдирләре дә СМУга нигез салынган көннән монда, үз эшләрен бик яхшы беләләр. Хет ятып йокла, ә эшең барачак. Әмма Силкин йоклап ятмаска булды. Үзенә бирелгән мөмкинлекне кулыннан ычкындырырга теләмәде, җитмәсә, хатыны да, Зәркәнтне тарсынып, зур шәһәр турында хыяллана башлады. Вакыты да уң килеп тора: комбинат төзегәндәге кызулык узган—ул вакытта теләсә кайсы көнне муенынны сындырырга була,—хәзер алда, яңа эшкә кереп китү өчен, айларга сузылган артык киеренке булмаган тормыш. Иляләшеп, эшләр әйбәт кенә барганда, Силкин иң зур һәм җаваплы участокны аның курсташы—институтта укуының әллә кем булмавына, прораблыкның кыен эшеннән качып, зур акча артыннан куууына һәм озак еллар бер идарәдә эшләп, бик күп астыртын эшләренә шаһит булган Исламов җитәкләвен күрде... һәм аңлады: Исламовның җитәкчесе, өйрәтеп торучысы булса да—ул аның өчен авторитет түгел, ә Силкинның бик тә абруй казанасы килә! Ә болай, Исламов катнашында уза торган планеркаларда, берәр яшь прорабны кыздырганда, сезне институтта нәрсәгә генә өйрәттеләр, дип әйтә алмаячак, чөнки үзе укыганда белеме белән әллә ни ялтырый алмады, һәм бу турыда Зәркәнттә бердәнбер кеше—аның кул астындагы Гаяз Исламов кына белә иде.

Глорияне югалтканнан соң, әле һаман үз хәленә кайтып җитмәгән Гаяз Силкинның үз участогын ник шулай өзлексез күзәтүен баштарак сизми йөрде. Беренче мәлдә бәйләнүләренә дә әллә ни игътибар бирмәде, яңа җитәкче, нәкъ менә аңардан башлап, яшьрәкләр алдында үзенең абруен нығыта, дип уйлады. Ярты еллап узгач кына, Исламов Силкинның бугазына кылчык шикелле кадалуына төшенде. Идарәдә эшләр яхшырак барган саен, Гаязга карата тагын да начаррак мөнәсәбәттә булды. Силкинның нинди

адәм икәнен данлыклы бригадир вакытыннан ук белгән дуслары Гаязга: «Төкерсәнә бу идарәгә, ул сиңа барыбер эшләргә ирек бирмәс»,—дип киңәш иттеләр.

Әгәр янында Глориясе, җанында тынычлык булса, Силкинга бирешеп тормас иде ул. Хәер, күз алдында шулай җебеп төшмәгән булса, теге—Силкинга бәхет китергән планеркада Исламов фамилиясе дә яңгырарга бик мөмкин иде бит. Менә шунда, өч тапкыр депутат, орден иясе булуына карамастан, Силкинның бәхетле көннәренә нокта куелган булыр иде. Исламовның кешеләргә, бигрәк тә күрше участокларда эшләүчеләргә карата үз фикере булыр иде. Моннан соң алты йөз сумнар Силкинның төшенә дә кермәслек итәр иде. Тегесе чынлап та аңлап, чибәр хатыны ташлап киткәннән соң нык бирешкән Гаязның каршы торырга көче беткәнлеген чамалап, үз дигәненә ирешү максатында шулай каныгадыр...

Кайчакларда Гаязның башына, эшем тыгыз, буш вакытым булмавы аркасында сизми калдыммы икән, яшәештә нәрсәдер үзгәрә, дигән уйлар килгәләде. Аның фикеренчә, шуның белән затлылык шкаласы да бозыла: каяндыр яңа каһарманнар калкып чыга, алар сокланудан битәр икеләнү, аптыраш уяталар. Ул әлегә кадәр шуны аңлый алмый: ничек инде, акылың сау була торып та, нииндидер вакытлыча чыгарылган фәрманга иярәп, Глориянең шундый проектын бракка чыгарырга мөмкин? Төзелештәгеләр үз артында «Бөек Силкин»дип йөрткән кешенең карьерасы да Исламовка аңлашылмады. Әмма үзенең элеккеге курсташыннан беркайчан да көнләшмәде, андый көнчелек белән кая хәтле тәгәрәп буласына төшенә иде. Әтисе биргән сабаклар әле дә исендә.

Ул ни Силкин белән көрәшергә, ни икенче идарәгә күчәргә теләмәде—кайсыдыр мизгелдә, бу шәһәрдә яшәүнең никадәр авыр һәм тынчу икәнен, бар нәрсәнең Глорияне хәтерләткәнен, кайчандыр аның белән бергә булган фатирда яшәүнең көннән-көн газаплырак була баруын тойды. Элеккечә үк искәрмәгәндә шалтыраган тавышка сискәнеп китә, нииндидер шатлыклы хәбәрне ишетми калмыйм дип, кичләрен өеннән бик сирәк чыга. Тик Глориядән бер хәбәр дә юк иде. Гаяз нәрсәдер эшләргә кирәген аңлый, әмма Глория белән бергә аның көчен дә, ирегeн дә тартып алдылар сыман.

Гаяз Силкинның чираттагы өйрәтү, башка тукуларыннан соң, элеккеге вакытлардагы кебек эшендә тоткарланып, соңлатып кына кайтырга чыкты да «Энҗе бөртеге» тукталышында төшеп калды. Яшь төзүчеләр сөйләшкәндә кафены еш искә алсалар да, дүрт еллап инде анда аяк басканы юк иде.

Элеккеге официанткаларны яңалары алмаштырган—аны елмаеп каршылаучы булмады, хәер, чалара башлаган чәчле ир-атта «Энҗе бөртеге»нә даими йөргән, кайчандыр чибәр хатыны белән һәр кичен шау-шулы грузин компаниясендә үткәргән Гаяз Исламовны тану кыен иде.

Беренче минутлардан ук Гаяз вакыт дигән нәрсәнең кафены да аямавын күрде. Кафе, Глория ниятләгәнчә, элек бәйрәмнәр үткәрү урыны булды. Официантлар эшкә көнозын ял итеп, көч туплап, кичке алтыга киләләр. Залны тәртипкә китергәч, шланглардан сиптереп, идәннәрнең тузанын алалар—бөтен җир ялт итеп кала, аннары һәр өстәлгә чәчәкләр куеп чыгалар да кичке сәгать җидедә кунакчыл кафе киң итеп ишекләрен ача. Хәзер исә бу «нокта» иртәдән үк ачыла, официантлар да заводтагы кебек бер тәүлек эшләп, ике тәүлек ял итүгә күчкәннәр, кичкә таба алар Зәркәнт чилләсендә согы сыгылган лимонга охшап калалар. Күп чакларда бу вакытка көнлек план инде үтәлгән була, эш көненнән соң махсус ял итәргә, вакытларын күңелле итеп уздырырга дип килгән кичке клиентлар алар өчен кирәксез, артык булып чыга. «Энҗе бөртеге» инде төзекләндерү эшләрен күрергә дә өлгергән: җете кызыл төстәге нәфис раковина пычрак төсендәге соргылт

буяу белән буялып, кара кучкылланып, тоныкланып калган; электр энергиясенә чыгымны киметү кампаниясе барган вакытлар, мөгаен, шунын нәтиҗәседер—архитектура бизәге булып торган яктыртылыш юкка чыккан. Тундырма белән газлы сулар да күренми, алар урынын бик кыю рәвештә кыйбатлы коктейльләр, коньяклар алган.

Гадәттә алар компаниясе җыела торган өстәл буш булып чыкты һәм Гаяз күнегелгән урынына барып урнашуга, як-ягына каранып алды. Йөрүчеләр әүвәлгечә күп, күрәсен, кафенын даны һаман да югары иде. Гаяз кинәт бер нәрсәне күреп алды, мөгаен, ул нәрсә Глорияне бик сөендерер иде, ә бәлки үзе дә, вакытлар үтү белән, шулай буласын күз алдына китергән булгандыр: Глориянең иң яраткан архитектура материалы кызыл һәм сары бакыр—ул аны беренче проектында куллана алды—ниндидер яна гомер кичерә: күзләрне рәхәтләндерә иде. Шәрык бизәкләренен милли элементларын кертеп авыр, кызыл бакырдан коелган койманы урыны-урыны белән яшькелт куңык чуарлаган, әйтерсен, аны вакыт тузаны каплаган. Койма—сәер, әмма күнелне кайтармый, шулай да бик нык күзгә ташлана, ә бит элегрәк Гаяз Шәрыкны, заманны, вакытны бергә туплаган бу искиткеч коелмага, челтәрләргә игътибар иткәне дә булмаган икән. Бакыр да үзгәреш кичергән: көн саен йөзләгән кеше кулы орынган бар баганалары, мәрмәр өстәлләрнен каймалары, ишекләрдәге авыр, әллә нинди хикмәтле тоткалар шомарып, ялтырап беткәннәр. Оркестр күтәренке, шат күнелле көйләр уйный, куәтле тавыш көчәйткеч аша музыка, колакларны тондырып, «Энҗе бөртеге» биләгән зур иркен мәйданнын теләсә кайсы почмагына барып бәрелә. Монысы да—Глория музыканын электрон күтәрелешен алдан ук чамалаган сыман килеп чыккан. Оркестрга төрле яклап заказлар ява, Гаязга «Безнең якын дустыбыз Әхмәт хөрмәтенә башкарыла...» дип, бөтен залга мөрәҗәгать итүләр ят иде. Кайсыдыр Әхмәт бу кичтә рәхәтләнеп күнел ачты. Шундыйлар тарафыннан финансланган оркестр бер генә минутка да тынып тормады, дүрт бүлемнен дүртесендә дә кызып-кызып биеделәр.

Биючеләр төркеме вакытлыча сирәгәя төшкәч, күренде: бөтен килеш калган куәтле яктырткычларнын якты нурлары бии торган түгәрәктәге чәчәкләрне айкап ала, андагы чәчкәләр ялтырап , шомарып беткәнгә, тирә-якта ут яктысында алтындай балкыш тирбәлә.

Озакламый анын өстәле янына яшьләрне китереп утырттылар. Берсенең туган көне икән, алдан әзерлексез-нисез генә бәйрәм итәргә уйлаганнар. Туган көнен үткәрүче кызны Гаязнын кайдадыр, төзелештә ахры, очратканы бар шикелле. Кунакчыллык, аралашучанлык—үзбәк халкына хас сыйфатларнын берсе булганлыктан, күп тә үтми, бүгенге бәйрәм сәбәпчесенең сәламәтлеге хөрмәтенә Гаязга да чәркә күтәрергә туры килде. Ниндидер Әхмәтнең чираттагы, аерата купшы заказы буенча көй яңгырауга, яшь парлар урыннарыннан куптылар, Гаяз каршында утыручы, матурлык өләшкәндә арттарак калган кызнын да биисе килгәне бөтен кыяфәтенә чыккан. Нишлисен, Гаязга аны чакырырга туры килде. Биегәндә, ул ирексездән аяк астына карап-карап алды, кыз, нидер сизенеп: «Берәр нәрсә югалттыгыз мәллә?»—дип сорап куйды.

—Сезгә бу чәчәкләр сәер тоелмыймы?—диде Гаяз.

—Ахрысы, анда ниндидер сер бар,—дип җавап бирде кыз, аңа карап.

—Ә сез игътибар беләнрәк карагыз...

—Чәчәкнең бу сызыклары «К» һәм «Г» хәрефләренен үрелеп кушылуын хәтерләтә бугай. Әйе, әйе, мин бу хәрефләрне бик ачык күрәм. Сезгә алар нәрсәнедер искә төшерәләрме?—дип сорады кыз, борчыла төшеп.

—Юк, юк, мин болай гына монограмманы карадым, мөгаен, остасы үзе турында истәлек калдыргандыр, тапталып бетәргә күп калмаган инде,—диде

Гаяз һәм аның кинәт кенә моннан китәсе, тизрәк өенә кайтасы килде.

Кафедан элекке юл буйлап кайтканда, эчтән генә шәһәр белән хушлашты. Ул китәргә дигән катгый карарга килде.

Берәр ай үтүгә, алмашу мөмкинлеге дә табылды. Шул рәвешле, ул Закиржан әкә белән бер ишегалдына туры килде.

## III бүлек

... Мәскәүдән чыккан тиз йөрешле поезд Ташкентка сонарып килеп төште. Килеп җитәрәк, юлчыларга җан керде, ыгы-зыгы башланды, алар тәрәзә янына бөялеп, кем каршы алыр дип, ишетелерлек итеп күрәзәлек иттеләр. Исламов кына тыныч иде, хәтта поездның сонга калуы да аның кәефен китәрмәде: Ташкентта аның беркеме дә юк, перронда каршы алучылар кулындагы букетларның берсе дә аның өчен түгел. Вагоннан да иң соңгы булып төште.

Эш көне әле тәмамланмаган, шуңа күрә ишегалдында беркем юк, бу аны шатландырды гына, аның берәү белән дә әңгәмә кору теләге юк иде. Тавышсыз, тиз генә үз фатирына юнәлде. Борынга күптәннән җилләтелмәгән торак исе—тынчу һава килеп сыланды. Тиз генә ишек-тәрәзәләрне төбенә кадәр ачып куйганнан соң, кондиционерны кабызды. Көтмәгәндә алмашу юлы белән кулына кергән фатир аңа бер күрүдән ошады, һәм ул аны, кайчандыр Даша әйткәнчә, үрнәк тәртиптә тотты. Кызга аңлатып торасы килмәде: чисталык һәм җайлылыкка һәвәслектән түгел, сәбәбе бик гади—ул түбән тәгәрәүдән, эчүчелеккә бирелүдән курыкты. Глория ташлап киткәннән соң, бар нәрсәгә кызыксынуын югалтты, өй эшләре белән мавыгу үзен коткарыр дигән җептәй нечкә уйга чытырдатып ябышты. Ә аннары, берәр елдан, бу аның өчен гадәткә әверелде. Гаязны фатирдагы тынчу һава белән бергә тагын бер нәрсә гаҗәпләндерде: ул киткәннән бирле Даша монда бер тапкыр да булмаган, ашау өстәлендә аның өчен калдырылган «Мин ялга киттем, ай ахырында кайтырмын» дигән язу инде саргаеп, өстен тузан капларга өлгергән. Димәк, ул аның кайда булуы турында белмәгән дә, кызыксынмаган да—бу Гаяз өчен көтелмәгән хәл иде. Дашада ачкыч бар, кайчан тели, шунда килеп йөрде, хәер, үзенең фатиры булса да, эченнән генә монысын да үзенеке дип саный иде бугай. Кайчакларда төнге сменадан кайтып кергәч, Гаяз Дашаның монда кунып калуын чамалый, ник дисәң, аш бүлмәсендә аны өсте сөлге белән томаланган, әле суынырга да өлгермәгән иртәнге аш көтә, суыткыч яңа гына сатып алынган азык-төлек белән тулы, һавасы җилләтелгән фатир чисталыктан көлеп тора. Кайсы көнне өстәлдә язу көтә: «Гаяз,зинһар, кичен өйдә булырга тырыш, мин билетлар алган идем», яки «Гаяз, безне кунакка дәштеләр»... Чираттагы ялга китәр алдыннан, якшәмбе көнне, Даша бәйрәм торты пешерде,—ул моңа бик оста, ашап туймаслык була,—тортның өстен «18» саны һәм кечкенә шәмнәр бизәп тора. Гаяз, кызыксынып, нәрсәне аңлатыр икән бу?—дип баш ватты, әмма бу цифр белән бер генә вакыйганы да бәйли алмады. Даша, күрәсең, ир-атның хәтерсезлегенә, дөресрәге, игътибарсызлыгына үзен алдан ук әзерләгән, чөнки ул Гаязның беренче никахы белән бәйле кичерешләрдән әле арынып җитмәгәнен чамалый, шуңа күрә икесен таныштырган көнне онытуына артыгын үпкәләмәде. Даша Исламовның тормышында аны чыгырдан чыгарырлык нидер булганын хатын-кызларга хас тоем белән сизенә; тик ни башка хатын-кызлар турында, ни аның беренче гаиләсе, ни Гаязны мондый хәлгә китергән сәбәпләр турында алар арасында беркайчан да сөйләшү булмады. Кайчандыр бу мәсьәләдә авызы нык пешкән Даша үзен ир-атны белә, таный дип саный һәм кайчан да булса унышка ирешәсенә ышанып, вакыйгаларны ашыктырмаска булды. Гаязның өйләнгән кеше

икәнен белә, хәтта кемгә икәнен дә—нindidер Глория Караянга. Бүлмәдә, диван өстендә, авыр бронзадан ясалган рамлы майлы буяу белән эшләнгән зур портрет эленеп тора. Ничектер, бик күптәнге осталар башкарган эшкә охшаган. Ләкин Даша монын башкару—иҗади алым гына икәненә төшенә, ә портретта исә анардан аз гына өлкәнрәк булыр—замандаш кызы сурәтләнгән. Бу кыз—Глория Караян булуы ихтимал, моны да тоемлады, тик портрет турында сорашырга кыймады, чөнки монда беренче тапкыр калуында ук, Гаяз бик кырыс кына беркайчан да үткәнендә казынмавын сорады, кирәк тапкач, вакыты җиткәч, үзе сөйләячәген әйтте. Ул чакта аның шундый шарт куюы Дашага ошады да әле: ана Гаязнын үткәннәре нәрсәгә, аны бары тик киләчәк—икесенең киләчәге генә кызыксындырды. Бу газаплары күпмегә сузылса да—вакыт үзе дәва диләр—Гаязнын бер савыгасына ышана иде. Аннары, башка хатын-кызлар кебек үк, үзенең мөмкинлекләренә, яшьлегенә, тормыш тәҗрибәсенә дә таянды. Исламов үзе дә ватылмас чикләвек кебек тоелмады: теләсә кайсы итәк артыннан чапмый—намуслы, илтифатлы: хатын-кызлар янында да, тормышта да. Ана килгән хат-хәбәрләр Дашаның күз алдында, телефоннан диспетчер кыздан гайре берәүнең дә шалтыратканы юк. Кыскасы, Исламов ана һәр яктан туры килә—бары тик күтәргә генә кала...

Вакыт бара, айлар бер-бер артлы уза тора. Алар инде бергә, тик Гаяз барыбер аны җанына, күнел түренә үткәзә алмады, күптәннән өмет ителгән анлашулар да килеп чыкмады. Фатирда ялгызы гына калганда, Даша портрет каршына килеп баса. Кызның гаҗәеп матурлыгы үзенә тартып тора, кайчакларда анын портретны алып, өйдән чыгарып атасы килә, тик соңгы мизгелдә генә нидер туктатып кала. Әгәр монда калса, шушы таныш булмаган серле хатын-кыз белән бергә яшәргә туры киләсен тоемлый, кайчан да булса серенә төшенми калмам, дип, үз-үзен юата.

Дашада зур кызыксыну уяткан бу автопортретны Глория студент елларында язды. Ничектер шулай туры килде, антиквар кибеткә сугылса—борынгы, әмма бик әйбәт сакланган матур рамга күзе төште, стипендия акчасы кесәсендә иде—сатты да алды. Рам үзе нинди стиль кирәклеген әйтеп тора—кызны автопортрет ясау уена этәрде. Соңыннан картина Глориянең үзенә дә ошады. Шушындый истәлекләр белән бәйле картинаны дивардан юк итәргә дигән уй белән Гаяз һич килешмәс, чөнки болай эшләү—үткән тормышына, Глориясенә хыянәт итү булыр иде.

Гәрчә тегендә, Күлледә, Даша турында еш кына исенә алса да, бүгенге бәйләнчек уйлар Гаяз өчен ят тоелды. Юл сумкасыннан спорт костюмын алып киде дә өй җыештырырга тотынды. Көй уйнаткычны кабызды, аннан агылган классик музыка—бу һәвәслеккә Глориядән өйрәнде—җанына тынычлык китерде. Хәзер башкалада яшәгәндә, анын фонотекасы даими баеп тора—Аллага шөкер, ажиотаж симфоник музыкага кагылмады. Баштарак анын мавыгуына көлемсерәп караган Даша да тора-бара күнекте, хәзер үзе дә җае чыкканда Гаязга пластинкалар бүләк итә, анын күнелен таба алуына куана иде.

Җыештырып бетергәч, Гаяз базарга сугылырга булды, бәхетенә, анысы якын гына, күрше кварталда гына урнашкан. Урта Азиядә яшәү аны күп нәрсәгә өйрәтте. Беренче чиратта—мөстәкыйльлеккә. Өйне, хуҗалыкны карау аңа бернинди авырлык тудырмады, хәтта рәхәт, тансык тоелды. Шуна күрә елллардамы, командировкалардамы башка җирләрдән килгән кайбер ир-атларның тормыш-көнкүреш мәсьәләләрендә югалып калуларын күрү аны хәйранга калдыра. Ә үзләре—ирләр, хатын-кызларны бик хөрмәтли торган өлкәләрдә яшиләр. Хөрмәт итүен итә,тик... «Кулыннан берни килмәгәч, нинди ярдәмче инде ул?»—дип эчтән генә көлеп куйды Исламов. Элеккеге

гадәт буенча, бик күпләр Урта Азия хатын-кызлары ирләре хакимлеге астында яшиләр дип уйлый, түбәнсетелеп диләрме... Әмма монда хатыны кунакка китәме, командировка яки ялгамы, ирләре беркайчан да югалып калмый. Өйләнеп кайтканда, бервакытта да өе ташландык хәлдә, балалары ач булмый. Шәрык ирләре кирәк әйберләрне сатып та ала белә, ашын да пешерә, өендә, ишегалдында, бакчасында тәртип тә урнаштыра, хатынын өстәл әзерләп көтеп тә тора. Менә шуннан килеп чыга инде, тормышта сөйләшә белү барыбер өстен чыга, сүзе белән түгел, эше белән алдырган ирне хәзер дә элеккечә хатынын кимсетә, ә булдыксыз лыгырдыкларны— ихтирам итә дип саныйлар. Бервакыт Әмир Хөсрәү Дәһләвинең : «Ярату турында сөйлә, жырла, тик бүләкләр бирергә онытма»,—дигән юлларына юлыккач, әй рәхәтләнеп, чын күңеленнән шатланган иде Гаяз. Шигъри юлның икенче яртысындагы: «бүләк бир» дигәндә, Исламов хатынына ярдәм итү турында да күз алдында тотылгандыр дип санады.

Кичке аштан соң, жыелган, әүвәлге тәртип урнаштырылган өендә Гаяз, чемодан һәм юл сумкасыннан әйберләрен бушатканда, янәдән кәгазь һәм фотографияләргә тап булды. Укып-нитеп тормастан, ул аларны төркемнәргә аерды: Омскидан, Зәркәнттән, Ташкенттан килгән хатлар. Ташкенттан нибары юка гына дүрт конверт жибәргән. Беренчесен аралап алып, укырга керешге.

«Исәнмесез, минем кадерлеләрем!

Сез, мөгаен, конверт тышындагы яна адресымны күреп, гажәпләнеп калгансыздыр. Әйе, минем тормышымда кискен үзгәрешләр булды, хәзер мин Ташкентта яшим. Зәркәнттән күчеп китүемнең сәбәпләре күп жыелды, шуңа күрә ваклыклары белән сезне ялкытып тормыйм, үз эшегез дә муеннан. Үземнең таза-сау икәнлегемне һәм үз теләгем буенча китүемне генә хәбәр итәм. Алмашкан фатирым бик жайлы, әйбәт районда, ишегаллары яшеллеккә чумып утыра. Әзрәк ияләшеп, эшкә урнашкач, кунакка чакырырмын. Ташкентта карар урыннар күп—башкала бит. Эш белән дә кыенлыклар килеп чыкмас дип уйлыйм, Ташкентта бик зур төзелешләр бара. Дөрес, бу бераз үзгәрәк, төзелеш гражданнарныкы—мин бит үземнең елларымны сәнәгать төзелешләренә багышладым—монда бөтенләй башка кинлек, темплар, коллективларда климаты да икенче, мине Зәркәнттән киткәндә дусларым кисәттеләр. Алар менә ничек чагыштырып күрсәттеләр: зур юлларда йөри торган йөк машинасы шоферы таксига эшкә күчә, бер уйласан, шул ук шофер, тик эшнең үзенчәлеге бөтенләй башка. Пәри башка, жен башка диләрме, ничек тә тырышырмын. Гомумән, тәжрибә туплап, монарчы күрелмәгән бик матур сарай төзисем килә, мин беләм: андый проектлар бар.

Бер яңа жырда шундый юллар бар: «Өр-яңадан башла, нульдән башла». Вакыт белән бер аяктан атларга тырышам һәм барысын да нульдән башлыйм.

Кочып, Гаяз».

Тәрәзә артында июль аенын энгер-менгере, Закиржан әкә тарафыннан мул итеп сугарылган бакча һәм ишегалдыннан сафлык һәм туфрак исе аңкый. Кичкә рәйханнан һәм кайсы ягы беләндер бөтнекне хәтерләткән чабыр үләненнән гажәеп хуш исләр тарала. Рәйхан шәрык кешесенен тормышында аерым бер урын били, шәһәрдә кечкенә генә ишегалларында да аны үстерергә тырышалар, аш тәмләткече буларак та, салатлар ясаганда да кулланалар, яңа өйләнешкән парларнын бүлмәләрен бизиләр. «Минем өчен рәйхан—туган жирем исе»,—дигән иде Закиржан әкә кайчандыр Гаязга.

Телефонның тыны-өне юк, беркемне көтми, беркая ашыкмый—Гаязнын уйлары, прокатка алып торылган һәм кабат-кабат каралган фильм шикелле,

тагын үткәннәргә кайтып төште, тик анда бернәрсәне дә үзгәртеп булмый иде инде...

... Ташкентта ул техникалар эшләп чыгара торган житештерү берләшмәсе каршындагы ремонт-төзелеш идарәсенә прораб булып эшкә урнашты. Моның ике сәбәбе бар иде. Беренчесе—эш урыны өе янәшәсендә генә, РСУга эшкә чакырып торучы белдерүне үзләренең автобус тукталышында укыган иде; икенчесе—аны ремонт-төзелеш дигән тезмә җәлеп итте. Беренче кисәге Гаязга бөтенләй аңлашылмады, әлек ул төзелеш һәм монтаж эшләре белән генә шөгыльләнде, ә төзекләндерү эше аның өчен сөрелмәгән басу кебек. Үзенең яңа тормышын башлап, «гражданлык төзелешенә күчәргә уйлаганмын икән инде, ремонт эшләрен белү дә зыян итмәс» дип уйлады. Житештерү берләшмәсенең Ташкентта ике биләмәсе бар, РСУ цехларны кушып салу, янадан торгызу, күбрәк көнкүреш һәм хезмәт биналарына ремонт ясау белән шөгыльләнә иде. Ремонт идарәсенең еллык эш күләме Гаязның элеккеге хуҗалык исәбенә эшләүче участогының айлык программасыннан да кимрәк. Аның—прорабның—кул астында ике бригада. Беренче атналарда ук Гаяз коллективның күптәннән бергә эшләүләрен һәм бригадирларның эшчеләрен каты тотуларын аңлап алды. Ирексездән хәтергә Силкин килде—бригадалар бик охшашлар, алтын куллы кешеләр, тик бригадирларына Юрий Ивановичка житәргә, ай-һай, бик ерак иде. Бәлки, масштабы ул түгелдер? «Вакыт күрсәтер»,—дип уйлады Исламов. Китәр алдыннан дуслары әйткән мәкальне кабат исенә төшерде: «Чит монастырьга үз уставың белән кермиләр», ул яңа коллективка күз салгалады, сизеп тора: үзен дә игътибар белән күзәтәләр—эшчеләр дә, хезмәттәшләре дә. Бигрәк тә хезмәттәшләре, чөнки берсендә дә Исламовныкы кадәр тәҗрибә юк: бакыр казылмаларын баета торган комбинат, сульфат кислотасы цехлары һәм тормыш-көнкүреш химиясе заводлары белән искиткеч зур комплекс—болар бар да аның җилкәсендә булды. Гомере буена горурланырлык. Гәрчә Исламов беркайчан, бер мәртәбә элекке эшләре турында теленә алмаса да, барысының да хәбәрдар икәнлеген тоя. Бәлки, Зәркәнт якында булганга беләләрдер, аннары үзе шикелле күпме инженерлар Ташкентка гел күченеп тора бит. Хезмәттәшләренең игътибары бер төрле түгел. Яшьрәкләре планеркаларда кызыксынып күзәтәләр, Исламовның кире кагылмаслык төпле, нигезле итеп әйтеп куюына сокландылар. Ә өлкәнрәкләре, үзләренең көндәлек тәҗрибәләреннән чыгып, ниндидер шикләнделәр шикелле, Гаяз андыйларның күзеннән болай дип укыды: «Шуның кадәрле тәҗрибәң була торып, безнең хәлсез РСУ чуртыма кирәкме сина? Бәлки, син безгә тәккә генә килмәгәнсеңдер, әллә кайчан кемдер сиңа күн кәнәфиле унайлы кабинет бирүне вәгъдә иткәндер?»

Идарә чагыштырмача тату көн күрә, план һәрдаим үтәлә, димәк, премияләр дә даими рәвештә килеп тора. Зур төзелешләрдәге шикелле ашык-пошык эшләүләр, ярсу-кызып китүләр бик сирәк була, бу, гадәттә «җылы»дип йөртелә торган урын булды, ахрысы. Бәйрәмнәрне, истәлекле даталарны хезмәттәшләр дус-тату үткәрәләр, күп еллык тәҗрибә, оешканлык күренеп тора; бу тантана һәм мәҗлесләргә Гаязны чын күңелдән чакырдылар.

Элеккеге эше белән чагыштырганда, Гаязның бик күп буш вакыты табылды. Эшнең барышын белү өчен, объектта иртән һәм кичен булу җитә. Эшчеләр артыннан ул хәтле тикшерү соралмый, бригадада моны ошатып та бетермиләр—ул аны шунда ук сизеп алды,—эш үзе дә даими инженер күзәтүен таләп итми. Беренче атналарда ул көне буе эш урынында булырга тырышты. Тик эшчеләр моңа ияләшмәгәннәр, һәрвакыт яннарында булуын бригадирлар да яратмады. Мөгаен, прораб ышанмый дип уйлаганнардыр. Хәер, озакламый ике бригадир да вак-төяк ярдәмнәргә мохтаж түгеллекләрен

сиздереп куйдылар. Гаяз конторда ешрак булырга тырышты, андагылар төзелештәгеләргә караганда да сагаеп калдылар.

Ничектер Исламовның янәшә йортта яшәвен белеп алган бригадирларның берсе:

—Гаяз Нуриевич, көне буе бу эссе кояш астында нишләп йөрисез? Тыныч кына өегезгә кайтыгыз, берәр нәрсә булып, сезнең кирәгегез чыкса, мин тиз генә килеп җитәрмен, йә телефоннан хәбәр итәрмен,—диде.

Гаяз бу тәкъдимгә берничек тә җавап кайтармады, әмма күңеленә салып куйды. Гаҗәп, ул шундый гадәти булмаган ысул белән җитәкчелек итсә дә, эшләр әйбәт кенә бара, планнар үтәлә, объектлар вакытында тапшырыла. Документларны алып бару бик күпкә гадирәк, саннарын әйтеп торасы да юк. Ярты еллап узгач, Гаяз үзенең Зәркәнттә участок җитәкчесе булып эшләгәненнән ким алмавын белде, әшен исә алдагысы белән ни күләме ягыннан, ни таләпләре буенча, ни вакыты, ни сыйфаты, ни белемнең кирәклеге ягыннан чагыштырырлык та түгел. Менә хәзер аңлады: ни өчен зур әһәмиятле төзелешләрдә прораблар озакка тоткарланмый, аларның авыр профессияләре өчен тыныч, җылы урыннар да бар икән, бернинди кайгы-борчусыз өендә кунып, шул ук акчаларны алырга була икән бит. Бу ачышы Гаязны сөендермәде, уйлары аның һаман да Зәркәнттә, дистәдән артык еллар бергә эшләгән кешеләр—тынычлыкны төшендә дә күрсәтми торган акыллы, төпле инженерлар белән. Аңарда хәтта үзенең иптәшләрен сата, авырлыклардан аларның җилкәләре артына кача шикелле тойгы барлыкка килде.

Вакыт бара. Глория турында бернинди хәбәр юк, аны кайвакыт сагыш биләп ала да ул тагын ярсып эзләргә тотына: таныш-белешләренә хатлар яза, телеграммалар җибәрә, шалтырата. Гаяз махсус «Архитектура» журналына язылды, һәрбер мәкаләне инә күзеннән үткәрде: аның исеме килеп чыкмасмы—тик бөтен тырышулары юкка чыга.

Бервакыт Ташкентта беренче ялы якынлашканда, төшенә диңгез, Гагра, Глория белән бәхетле көннәре керде... Көне буе күргән төше исеннән чыкмады, Зураб Каргарелинының чакыруы турында уйланды, тегесе аны катгый рәвештә Пицундага—тормышка ашкан проектларын карарга чакыра. Өстәвенә, нинди дер көтелмәгән яңалык вәгъдә итә. Батып баручы саламга ябышкандай, бәйләнчеккә әйләнгән шул фикер бар тынычлыгын алды. Ә бу сюрприз—Глория булса?!

Атна буе җәфаланганнан соң, ул диңгезгә барырга булды: бер очтан ял да итәр, ә иң мөһиме—аңарда өмет уянды... Бригадирлар, аның ялга җыенуын ишеткәч, китү көнен кичектерергә киңәш иттеләр, янәсе, ялның рәте-башы булмас: эшли башлаганына ел була, ә алар белән бер тапкыр да өстәл артында утырганы юк, һаман да конторда, җитәкчелек янында, янәсе, егетләр үпкәли. Теләсә кайсы җитештерүгә караганда, төзелештә инженер үзен эшчегә якын тота. Моны хәтта сугышчан хәл белән дә чагыштырып булыр иде: анда бит офицер сугыш елларының бар авырлыгын солдатлар белән бергә кичерә, бары тик җаваплылык аның җилкәсендә булуы белән генә аерыла. Гаяз бик шатланып ризалашты. Кире кагу дөрес булмас иде, чөнки чакырулары чын күңелдән.

Соңгы айларда аның белән коллектив арасында эшлекле, җылы мөнәсәбәтләр урнашты. Бервакыт идарәдә аның бригадаларын вакытлыча гына икенче участокка биреп торырга теләгәннәр иде—кая ул—бригадирлар да киреләренә каттылар: Гаяздан беркая да китмиләр, янәсе. Нишләсеннәр, әзер боерыкны үзгәртергә туры килде, чөнки беләләр: төзелештән бригадирлар үзләре генә китмиләр, ә бригадаларын да ияртәләр.

Берчакны шулай көтмәгәндә генә чит ил делегациясе килеп төшәсе

билгеле булгач, бер берләшмәдә ашыгыч рәвештә актлар залын ремонтларга кирәк булды. Эшне Исламовка тапшырдылар. Гаяз, аның ашыгыч һәм җаваплы булуы өстенә, түрәләрнең астыртынлыгын да сизенгәндәй булды, янәсе, менә синең нәрсәгә сәләтле булуын шунда күренә инде. Исламов йөзенә чыгармады. Көне-төне, хәтта шимбәләрен дә кертеп эшләсәләр эшләделәр—әмма объектны вакытында һәм бик яхшы итеп тапшырдылар. Кайда югалтасыңны, кайда табасыңны белеп булмый дияр: берләшмә җитәкчелеге участокны махсус приказ белән билгеләп, мактау кәгазьләре һәм зур күләмдә премияләр белән бүләкләде...

Саубуллашу мәҗлесен чәйханәдә оештырдылар. Ташкентта андый унайлы урыннар елга буйларында, паркларда җитәрлек иде. Чәйхәнәнең айваны яр буена чыгып, күпьяшәр чинарларның күләгәсенә чумып утыра. Шәрыкта һәр икенең берсе бик тәмле пешерә, бригадада исә барысы да беренче класслы кулинарлар булып чыкты. Мәҗлес бик күнелле узды, кара төнгәчә утырдылар. Бригадирлар Гаязны өенә кадәр озатып куябыз дип бәйләнделәр, җитәкчеләренең ничек яшәгәннәрен дә күрәселәре килә, янәсе. Киткәндә, ишегенең шыксызлыгына игътибар иттеләр. Элеккеге хуҗалары, күрәсең, йозакларын бер генә алмаштырмаган, кискәләп-тишкәләп бетергәннәр, катырак тартсаң—биге очып чыгарга тора.

—Менә сина прораб,—бригадирларның берсе шелтәләп, башын чайкады.—Гражданлык төзелешендә тәҗрибәгез юклыгы сизелеп тора, Гаяз Нуриевич. Ачкычыгызны калдырыгыз, ишегегезне алыштырырбыз, алайса, буш фатирга кайтып кермәгәегез.

Гаяз ишеген беренче мәртәбә күргәндәй карап торды, чыннан да, ничек эләгеп торган диярсең, аны-моны уйлап тормыйча запас ачкычын сузды.

Адлерга иртән очып килде. Әле бик иртә булуга карамастан, монда инде җанлылык хөкем сөрә. Кояшта каралган, ял иткән курортчылар теләр-теләмәс кенә Кара диңгез буен калдырырга җыеналар, ә яна килеп төшкәннәр алардан тәннәренең диңгез буе күрмәве белән генә түгел, ашыгу-кабаланулары, тизрәк ял итү урынына—диңгезгә ашкынулары белән дә аерылып торалар иде. Шул төркем Гаязны да Гаграга баручы беренче автобуска бөтереп алып керде.

Безнең көннәрдә шәһәрләр йөзләрен бик тиз арада танымаслык итеп үзгәртәләр, бары тик кечкенә, ял итә торган шәһәрчекләр генә, замана шаукымына бирешмичә, элекке нигез салынган үз кыяфәтләрен югалтмыйлар. Һәр яна чор үзенең сизелер-сизелмәс эз салуын исәпләмәгәндә, әлбәттә. Мәсәлән, духанны чәйханә дип, чәйханәне—закусочный (җинелчә капкалап чыгу урыны), анысын—кафе, кафены—бар, барны дискотека—һәм шулай тезелеп китә—дип алмаштыра, ана карап аның асылы шул ук кала.

Бәлки бу шәһәрчекләрнең бар матурлыгы да шундадыр, сезоннан сезонга бизәкләрен алмаштырмый, үзгәрми, үзенчәлекләрен кипарислар күләгәсендә, тау куышы-мәгарәләр тынлыгында, тар гына тау сукмакларында, чуерташлы, шау-шулы пляжларда саклап калалар... Әгәр сезгә—диңгез сезнең эзләрегезне күптән юган, сезнең бәхетле көлүегезнең кайтавазларын тауларга таратып ташлаган диләр икән—ышанмагыз,—кабат килегез дә карагыз: сез кичә, өченчекөн, күп еллар элек ничек калдырган булсагыз—бар да шул килеш саклана...

Гаязга да беренче карашка берни дә үзгәрмәгән сыман тоелды, шулай да бик күп яна кибетләр, башка төрле урыннар барлыкка килүен сизмичә калмады, тик алар бик тиз күренгән шикелле бик тиз юкка чыгарга да мөмкиннәр иде. Бу корылмалар ялтыравыклары белән аерылып, курорт шәһәрчекләргә ярашып торсалар да, Гаязның тәҗрибәле төзүче күзләре шунда ук аларның вакытлыча икәнен чамалап алды.

Джумбер белән беренче баруында ук Гаяз шәһәрне яхшылап белеп калды, аның борылмалы-сырылмалы урамнарында буталмыйча йөри ала, шуңа күрә үзенә ошаган—үзәк парктан ерак булмаган, кичләрен транспорт көтеп мәшәкатьләнми үз аякларың белән кайтып житәрлек арада урнашкан фатирны тиз эзләп тапты. Кич белән ял итәргә, диңгездә коенырга өлгергән Гаяз беренче мәртәбә Глория белән булган урыннардан урарга уйлады. Көзгегә күз ташлады, чал чәчләре артуын күрсә дә, әллә ни хафаланмады.

Телеграф янышнан узганда, ул үзеннән-үзе туктап калды. Әгәр Тбилисига телеграмма жибәрә калса, дуслары Джумбер, Тамаз, Роберт шунда ук килеп житәселәрен белә иде. Аларны шулкадәр күрәсе, теге чаклардагы кебек өстәл тирәли утырып, яшьлекләрен, Зәркәнтне, «Металлург»ны искә төшерәсе килде... Әмма алар белән үзе арасында үтеп чыга алмаслык упкын ятканын сизә: Глория турында нәрсә әйтер соң ул? Китте, югалды, тотып кала, саклый-яклый, эзләп таба алмадым дипме? Үзен акларлык сүзләр табылмады. Гаяз Глориянең алар өчен дә гади дус кына түгел, ә тормышларының, яшьлекләренең бер өлеше, талисманнары кебек булуын белә иде. Очрашу никадәрле генә куанычлы булса да, Глория язмышын белгәннән соң, ни дәрәҗәдә кайгылы-борчылуга әйләнәсен сизде ул. Телеграф янында тоткарланып тормыйча, алга таба атлады.

Гаҗәп: әмма аларның кичләрен Глория һәм грузин архитекторларының шау-шулы компанияләре белән бергәләп утырган җәйге кафеларның кайсылары юкка чыккан, калганнары исә йөзләрен, абруйларын югалтырга өлгергән; Гаяз һәр нәрсәнең үз чоры булуына тагын бер кат инанды. Бу кичтә, әгәр Глория диңгезгә ял итәргә килгән булса, аны яңа урыннан эзләргә кирәген аңлады.

Бер-бер артлы көннәр үтүе сизелми дә. Берничә тапкыр Глория белән беренче килгәндә тукталган өй яныннан узып китте. Капка янында Джумбернын инде буй тарткан энеләрен очратты, һәрберсен исемләп белсә дә, эндәшеп торуны кирәк тапмады. Берсендә элеккечә төз буйлы, теш арасына гадәттәгечә тәмәкесен кыстырган Дато абзыйның үзен дә күреп калды. Дато Вахтанговичның, машинага утырыр алдыннан карашы берничә генә секундка Гаязда тукталса да, ай-һай, кайчандыр бу өйдә үзенең ширбәт аен уздырган элеккеге Гия Исламовны таный алды микән? Шулай күрешми генә аерылыштылар. Икенче тапкыр соң гына өенә кайтып барганда, ул кабат шул якка борылды. Теге истәлекле көннәрдәге шикелле, якты сибелгән ишегалдында кунаклар шау-гөр килә, хәтта аңа Джумбернын тавышы да ишетелеп киткән кук тоелды. Икеләнеп тормыйча, ул капкага килде, әгәр тагын бер тапкыр дустының тавышын ишетә калса, керергә уйлады. Ачык калган капкадан өстәл артында утыручылар ачык күренә, Гаяз күз салды—әмма кунаклар арасында Джумбер юк иде.

Һава торышы көнләшерлек, диңгез тыныч, фатиры уңышлы туры килде; хуҗалары кунакчыл, көннәр генә бик тиз кими, алар белән бергә Гаязның өмете дә сүрелә барды. Кичләрнең берсендә, ресторанда утырганда, Гаяз, ялның иң кызган вакытында залда буш урыннарның күплегенә игътибар итте, официанттан сорашып, күпчелек ял итүчеләрнең кичләрен Пицундага китүен, анда өченче сезон инде менә дигән комплекс эшләп килүен белде.

«Пицундада, әлбәттә, Пицундада!» Дулкынланган Гаязның сүнеп барган өмете кабат яңарды. Иртәгесен, иртә таннан, Гаяз Пицундага китеп барды. Зураб Каргарателиның әкияти тукталышларын иркенләп карар өчен, махсус—автобуска утырып, юлга чыкты. Архитекторларның эшләрен күргәне бар иде инде, кайберләрен проектларыннан, рәсемнәреннән карады. Егерме дүрт тукталыш санады Гаяз, тик аларның берсе дә берсен

кабатламый: андагы фантазия күзне, йөрәкне иркәли. Юл кырыйларында котырып үскән субтропик үсемлекләр арасында, юлчыларны янгырлардан, жилләрдән ышыклап торган әкиятләрдән алынган тылсымлы персонажлар элек бер күргән кешеләрнең дә исләрен китәрә иде. Эшләр бик күп, шулкадәрле хезмәтне бер генә кеше башкарып чыкканы берәрсенен башына килде микән, тик Гаяз моны белә һәм жирдә шундый матур эз калдырачак кеше белән таныш булуына эченнән генә горурлык кичерә.

Пицунда белән очрашуга Гаяз әзер иде. Анын ише төзүче өчен бер тапкыр сызымда һәм проектта күрелгән әйбер чын булып күз алдына килә. Яр буендагы киң сукмактан бара-бара, ул Глорияне нәкъ менә иркенлек хәйран калдырганын исенә төшерде, чөнки төзүчеләр, бик күптәннән шаулап утырган нарат урманын саклап калып, шәһәрне һәм дингезне ана якынайтканнар. «Әгәр дингезгә килгән булса, мин аны бары тик монда, Пицундада гына очратачакмын»,—дигән нәтижәгә килде Гаяз, юл чатындагы бронзадан коелган скульптураны күзәтә-күзәтә. Кич үзенен хокукларын кабул итеп алуга, шат күнелле, бизәнгән-ясанган халык яр буена һәм урманнардагы сукмакларга тулды; һәр тарафтан музыка агыла.

Пицундада жәйге ресторан, кафе, бар, дискотека, варьетелар адым саен. Исламов кайсына сугылырга, Глорияне кайдан эзләргә белми аптырап калды. Кайберләренә ансат кына эләгеп тә булмый, су буе чират торырга кирәк. Проектларда һәр биек бинанын түбәсендә—иң өстә Пицунда, дингез бар киңлеге, борыннары белән бик яхшы күренә торган ачык кафелар планлаштырылганы исенә төште, һәм озак уйлап тормыйча, якындагы бинаның подъездына кереп китте. Тиз йөрешле лифт, күз ачып йомган арада, аны уналтынчы катка менгерде, монда да чират иде, кафега эләгергә теләүчеләрнең иге-чиге күренмәде. Кафе бик иркен, архитектур артык-портыклардан азат,—Глория булса, гадилектә матурлык дияр иде,—әмма ял итүчеләрне манзара, саф дингез һавасы тарта, шунын өстенә, башка урыннар әллә ни мактана алмаган бию мәйданнары да житәрлек иде. Буш өстәл эзләп, як-ягына каранганда, Гаяз монда Глориянең юклыгын һәм булуы мөмкин түгеллеген дә сизенде: ул анын зәвыгын бик яхшы белә иде. Бу уй аны бер яктан борчуга салса, икенче яктан сөендерде: ичмасам, эзләү кырыннан биек биналарның түбәләре төшеп кала.

Урын түбә кырыенда табылды. Гаяз битен дингездән килгән һавага куйды, залда ниләр булганы аны кызыксындырмады, берара торырга һәм чыгып китәргә дә уйлаган иде, тик кичке аш өчен кайдадыр тагын чират торырга туры киләчәген күз алдына китереп, калырга булды, житмәсә, шунда ук янына килеп баскан официант форель балыгы тәкъдим итте.

Иртәгесен дә аяз көн вәгъдә итеп, кояш әкрен генә дингезгә таба тәгәри. Сәйран кылу катерлары, кечкенә теплоходлар дингезгә китәләр дә Пицунда пристаньтаннарына әйләнеп кайталар. Сиздермәстән генә төн житте... Колхиданын ябышкак, дымлы, йолдызлы төне. Ерактa, жәелеп яткан су өстендә, кинәт бер рәткә берничә кат булып тезелгәндәй калкып чыккан зур, яңа ел чыршылары сыман, якты утлар кабынды. Ялтага таба өч палубалы дәү теплоходлар бара: төрек, грек, швед теплоходлары...

Жәй, дингез, сәяхәт, бәйрәмнәр...—кайчакларда Гаязга музыка чит караблардан һәм ерак палубалардан ишетелә сыман, тик ул шулай тоела гына—колак тондыргыч музыка анын артында ишетелә иде.

Һава сафланып китте, дингез ягыннан искән жил сизелерлек көчәйде, һәм ул туңып киткәндәй булды, гәрчә залда уен-көлке жанланып кына килсә дә, үзен унайсыз хис итеп, китәргә уйлады. Аста—яхшы итеп яктыртылган аллеяларда—ял итүчеләр йөренә, мөгаен, шушы биек корпусларда һәм кунакханәләрдә яшәүчеләрдер инде—беркая ашыгасылары юк. Бар жирдән,

үзенә чакыргандай, музыка тавышлары яңгырый, кайсыбер рестораннарның үтә күренмәле пыяла диварларыннан, төсле йомшак карандашлар белән ясалган рәсемнәр төсле, чекрәеп торган җәйге күлмәкләргә төренгән биючеләр күренә: кая бакма—бәйрәм. Тышкы яктан канәгать курортчыга охшаса да, Гаязның күңелендә буран дулый иде. Ашыкмыйча гына, көндез күреп бетерә алмаганнарны кичке ут яктысында караштыргалап, кайту ягына юнәлде. Чыгу юлында, шлагбаум янында, территориягә керү өчен шоферлардан рөхсәт кәгазе сорый торган җирдән сул якта кинәт музыка яңгырады. Барлык ял итә торган урыннар инде артта калды, дип, Гаяз ялгышкан икән: бу Пицунданың иң төп рестораны—«Алтын тире» иде; оркестрның, тәнәфестән соң икенче бүлеген башлап җибәрүе булды, күрәсең.

Моннан өч сәгатьләр чамасы элек үтеп киткәндә, ресторан, төнге саналганга, килүчеләр өчен ябык иде әле. Ресторан гадәти генә булса да, матур, купшы, өстәлләрнең бер өлеше сахрадагы шикелле агачлар астына урнаштырылган, ресторан үзе өстәлләренә хәтле салынып төшкән куе субтропик яшеллеккә күмелгән. Бакчадагы өстәлләрдә «керосин лампалары» тора, веранданың диварында жентекләп эшкәртелгән ак сарык тиреләре эленгән,—мөгаен, болары «Алтын тире»гә ишарәләүдер. Алар мода артыннан куучыларда, шиксез, көнләшү тудырып, нәкъ кайры тунга җитәрлек, дигән уйга этәрәдер. Әмма тиреләр ныклы күзәтү астында, аларны атаклы тиредән битәр саклыйлар, моның турында даими йөрүчеләр генә хәбәрдар иде. Ресторанның үз йөзе бар, сизелә: идеясен уйлаган, төзегәннәр—олыгайганнар инде.

Саран гына яктыртылган эстрадада, аннан башка да электрланган залны ярсытып, оркестр котыра. Кысан мәйданчыкта якын-тирә өстәлләр артында утыручылар бии, ә калганнарга алар биегәннән көнләшергә һәм үз чиратларын—җитәрме әле!—көтәргә генә кала. Гаяз өстәлләр янынннан буш урын эзләп барганда, кинәт бакчага таба киткән веранданың эчке ягыннан:

—Гия, безнең янга кил!—дигән тавыш ишетелде.

Гаяз, ялгыш ишеттем бугай , дип торганда, кабат тоныкм кына шәм янып утырган өстәл артыннан шатлыклы, ягымлы тавышлар таралды:

—Гия, монда кил!

Аяклары тынламас булып катып калды, секунд эчендә башыннан мең төрле фаразлар үтте: кемнәр булыр бу? Джумбер, Тамаз, Роберт, элеккеге дуслар-архитекторлар? Чакыручылар, һичшиксез, грузиннар, чөнки сүз алышкандай, бар да дәррәү, аның исемен үзләренең телләренә яраклаштырдылар. Ул әкрен генә, шау-шулы өстәлләрне урап, тавыш килгән якка бара башлады, ә уйлары күптән анда иде инде... әгәр дә?

—Гия, безнең ут тоныкмы, әллә син инде безне танымаслык булганчы шәпләп типтерденме?—дип сорады Тенгиз, елмаеп. Тенгиз—ул тукталган йорт хуҗасының улы.

Өстәл артында аның белән Тенгизларда беренче катның зур бүлмәсен алып торган өч кыз һәм егетнең дусты, күрше Заури утыра. Кичләрен өйгә кайтканда, Гаяз бу компанияне еш очрата, берсендә үзе дә алар белән төн уртасында гына аерылышты.

—Чынлап та, ут яктысы сүрәнрәк шул,—дигән булды арыган Гаяз.—Ә типтерү дигәннән, бүген нәкъ җитеп бетмәде, сезне очратуым яхшы булды әле. Берәр шешә «Киндзмараули» җибәргәндә шәп булыр иде...

Официант Тенгиз артында тора иде инде.

—Ишеттеңме безнең Гия дус әйткәнне? Утны көчәйтергә һәм вино...

Озак еллар буе нәрсә белән килешә, нәрсәгә күнә алмавы кинәт

Гаязның башына сукты... Монда, «Алтын тире»дә утырганда, мизгел эчендә барысын да аңлады, әйтерсең, ул яна гына наркоздан айныды: башында фәкать бер уй—Глориясен ул мәңгелеккә югалтты, күз алдында бердәнбер телеграммасындагы сүзләр биеште: «Мине эзләмә!»

Калган көннәрен, алар инде кимүгә бара, Гаяз күршеләре компаниясендә үткәрде, кабат монда килмәячәген сизенгәндәй, Гагра белән саубуллашты. Бер нәрсәгә инанды: үзенне чын-чынлап бәхетле тойган урыңга беркайчан да әйләнеп кайтма икән!

Эшенә чыкканчы, үзен тәртипкә китерергә уйлап, ул Ташкентка шимбә көндез кайтып төште. Ишегалларына кергәнче үк борынга тәмле булып пылау исе бәрелде. Иртәнге якта ир-атлар җыелышып, гәҗиттәге яңалыклар турында фикер алышкач, бергәләшеп пылау пешерергә булганнар икән. Күршеләре Гаязны шау-гөр килеп каршы алдылар. Гаяз исә, аларга дип вак-төяк бүләкләр һәм Урта Азиядә сирәк сорт саналган «Изабелла» виноградын алуына сөенде, менә бит, ничек урынлы чыкты. Күчтәнәчләрен айванда калдырып, юл тузаннарын юып төшерергә фатирына юнәлде. Баскычтан менеп килгәндә үк, күзенә берничә кат лакланган ишегенең ялык-йолык килүе чалынды, килеп житәрәк, каушавыннан аяклары атламас булды. Ишек шаккатырлык иде: чын имәннән, шыгырдамасын дип каяндыр юнәтеп (чөнки алар хәзер бик сирәк очрый), дүрт бакыр күгән беркетелгән, ишекне кисеп ямьсезләмәс өчен, дивардан бер-ике рәт кирпечне алырга туры килгән, аның каравы, ишек карап туйгысыз. Күзчек, бикләр—бар да пөхтә итеп уеп куелган, кайдан алганнардыр, лакланган имәнгә туры килеп торган авыр бронза тотка беркеткәннәр. Хәтта ишекнең янтыклары да имән тактадан эшләнгән һәм бүк агачыннан теленгән тар планка белән тоташ рамланган. Гаяз ашык-пошык килеп, ачкычларын тартып чыгарды. Җентекләп көйләнгән ишек артык тырышлык куймый җиңел генә ачылып китте. Әле күптән түгел генә монда кемнәрдер булуы сизелә—бүлмәнең һавасы саф. Күп фатирлардагы кебек, Гаязның да алгы бүлмәсе караңгы, шуңа күрә ул ут кабызды. Кабызды да беркавым шаккатып, үз өемә эләктем микән дигәндәй, урыныннан кузгалырга икеләнеп торды, күнегелгән әйберләрен күргәч кенә күңеленә тынычлык иңде.

Фатир танымаслык булган. Чемоданын ишек янында калдырып, Гаяз башта өен әйләнеп чыкты. Могжиза, башка берни түгел. Балкон һәм аш бүлмәсенең идәннәрендәге линолеум алыштырылган. Бәдрәф, юыну, аш бүлмәләрен түшәмгә кадәр аксыл-зәңгәр кафель белән каплаганнар. Шул тикле пөхтә башкарылган: чех йә югослав плиткаларыннан һич аерырлык түгел. Кытыршыланган кечкенә ваннаны яңага, зурракка алыштырганнар, урынын көйләү өчен, дивардан беркем, беркайчан файдаланмаган җиләтү торбаларын алырга туры килгән. Ванна һәм бәдрәф идәннәрен мәрмәр ватыкларыннан түшәгәннәр, могаен, чит төзелеш калдыкларын җыйганнардыр, чөнки үзләренең РСУсында ул материал юк иде. Алгы бүлмәне кирпечтән шулын кадәр тигез итеп эшләгәннәр ки, Гаяз, ирексездән, диварны кулы белән сыпырып карады. Түшәмнәрнең аклыгыннан күзләр камаша, хәзер кулланыла торган су кушылган эмульсиядән баш тартып, чын акбур белән агартканнар! Зал һәм йокы бүлмәләренең стеналарына ачык төстәге обойлар ябыштырганнар, өстен һәрьяклап яхшы күренеп торсын дип, караңгы кызыл төстәге бизәк белән чорнатып алганнар. Тапталып каралган, урыны-урыны белән купкан паркетлар алынып, машинка белән берничә кат җентекләп шомартып киредән урнаштырылган һәм ике кат—өч булмаса әле!—жиренә житкереп яхшы сыйфатлы лак белән капланган. Күз явын алырлык! Барыннан да бигрәк балкон зур үзгәреш кичергән, диварына имән төсенә охшатып, юыла торган обой ябыштырганнар, элекке

хуҗасыннан калган борысның аркылыга киселгән башларына куелган киштәләрне алып, яңаларын куйганнар һәм менә дигән тагын бер бүлмә барлыкка килгән. Эчке ишекләрне дә караганнар—шыгырдаулары беткән, җинел һәм тыгыз итеп ябылалар. Өйдә агачтан булган бар әйберне һәм балкондагы тәрәзә рамнарын ялтырап торган ак эмальгә буяганнар. Бер җирдә ремонт булган дип белмәссең—бар да тәртиптә, чиста, хәтта бүлмәләр җилләтелгән—бернинди буяу, лак исләре калмаган.

«Менә бу ремонт, ичмасам, менә бу хезмәт күрсәтү,—дип гаҗәпләнде Гаяз, бернинди гаеп-кыек таба алмагач.—Һәрвакыт һәм һәркемгә шулай булсын иде ул: ачкычыңны калдырасың да үзең ял итәргә китәсең, кайтасың да өр-яңа диярлек фатирыңа кереп утырасың. Андый хезмәт өчен нихәтле сорасалар да җәл булмас иде». Әле күпме шулай исенә килә алмый торыр иде—бакчадан Закирҗан әкәнең аны дәшкән тавышы ишетелде: «Пылау өлгерде».

Дүшәмбе көнне Гаяз күнегелгән гадәт буенча иртүк уянды. Ремонттан алган тәэсирләрне күмеп, башта икенче уй бөтерелә: »Ничек исәп-хисап ясарга?» Ялда булып кайтканнан соң, кесәдә җилләр уйный—мескен тиеннәр генә—хезмәт хакына чаклы барып егылырлык та акча юк, диңгездә вакытта ук, кайтуга, Закирҗан әкәдән йөз сум сорап торырга уйлаган иде дә, менә сиңа мә, нинди ремонт ясап ташлаганнар. Миннән күпме тиеш булачак икән?»—Гаяз эшне бәяләргә теләп, тагын бер мәртәбә әйләнеп чыкты.—Әллә ни кыйммәтле материаллар да түгел сыман, тик барысына да кытлык—табармын димә, линолеумга кадәр финнныкы бит.» Тегеләй дә исәпләп карады, болай да—мең тирәсе чыгарды, шуның өстенә материалларны табу, вакыт, сыйфатны да өстәсәң бер ярым тирәсенә тарта. Шуның кадәр дә түләмәсәң, гөнаһ булыр, бер ишек куюы гына да, эчке һәм тышкы якларын эшләүләрен дә кушып, дәүләт бәясе белән ике йөзләп тора. Ничек кенә әйләнмә-тулганма, эш иң югары дәрәҗәдә башкарылган, әйтерсең, алар Гаяз алдында мастерлыкка имтихан тапшырганнар. Менә хәзер дә, никадәр генә бәйләнергә тырышмасын, бернинди сәбәп таба алмады: җөе җөйгә китерелгән; кителгән, кугәргән урыннарны күрмәссең, хәтта обой өсләре дә шоп-шома, әз генә һава да кереп калмаган—җиренә җиткереп эшләгәннәр. Кинәт башына бер фикер килде, коткарса ул гына коткара—өлешләп түләргә! Һәм шул уй аның күңеленә тынычлык индерде.

Эшендә бар да тәртиптә, үз чираты белән бара: участогы артта калмаган, телгә алырлык шелтәләр күренми, китәр алдыннан билгеләнгән планны бригадалар әллә кайчан үтәгәннәр дә ике ай алдан яңа объектка күчкәннәр—андый срок һәм эш күләме РСУда бик сирәк күрелә торган хәл. Гаяз эшкә чыкканда, ай ахыры иде. Прораб өчен бик җаваплы вакыт: нарядларны ябарга, заказ бирүчедән үтәлгән эш күләмен раслатырга, матди исәп-хисап тапшырырга кирәк. Эшчеләр аны ачык чырай белән каршы алдылар, ялының ничек үтүе, диңгез, үзләре бер тапкыр да булмаган Пицунда турында сораштылар. Барыннан да бигрәк, аларны анда халыкның тормыш-көнкүреше, азык-төлеккә бәяләр, төзүчеләрнең күпме хезмәт хакы алулары кызыксындырды. Гаязның җавапларыннан шуны белделәр: халыкның тормышы кайда да бер, грузиннарда көзен мандариннарның бәяләре арзанрак дисәң генә инде; исәпли башласаң, Үзбәкстанның үз өстенлекләре дә аз түгел: ел әйләнә яшелчә, җиләк-җимеш. Хезмәт хакына килсәкме? Эшкә түләү кайда да бер, төзүчеләрнең эш хакы фонды бертөсле. Кайда яхшырак төзиләрме? Монысында Гаяз уйлап та тормады—бездә. Планлаштырылмаган тәнәфес тагын да сузыласын аңлап, бригадирлар әңгәмәне туктатырга кирәклеген сиздерделәр, янәсе, әйләнеп карарга да өлгермисең, җәйге көн хәзер үтеп китә, шулай ук прорабның да эше тавык

чүпләп бетермәслек—башыннан ашкан.

Гадәттә Гаяз нарядларны ябарга үзе белән берәр бригадирны ала иде. Бу юлы аның белән прораб бүлмәсенә Тарханов барырга булды. Ул бик тәҗрибәле, төзүче һөнәрләренең барысын да диярлек үзләштергән кеше. Нык, таза, каты тавышлы, хакимлек итәргә яратучан бу ир-ат үзенең бәясен яхшы белә. Гаяз аны ихтирам итә, исеме һәм әтисенең исеме белән генә дәшә. Тормышның ачысын-төчесен татыган бригадирга кешенеке кирәкми, үзенә тиешлене умырып алыр... Анарда ниндидер бер иске караш яшеренгән кебек, Гаяз шуны әлегә ачыклый алмады, әмма ул Тархановны намуслы кеше буларак белә, андыйларны, Аллам сакласын, алдап кара.

—Федот Карпович, ремонт өчен рәхмәт, фатирны шулай тиз арада үзгәртеп буладыр дип һич уйламаган идем. Картинка диярсең,—прораб бүлмәсенә җитәрәк, Гаяз рәхмәтен белдерде.

—Аллага шөкер, яраган, безнең эшебез күңелегезгә ошаган. Җаныбызны биреп эшләдек бит, Гаяз Нуриевич. Сез кешеләргә ачык күңелле, алар да миһербанлы кешегә карата шулай ук. Сезне көттек, дулкынландык, бүген хәтта наряд белән дә кызыксынучы булмады, сора инде, диләр, ошатты микән?

—Ничек кенә әле, бик ошады. Тик менә шунысын гына белмим, ничек исәп-хисап ясарга? Андый патшаларча ремонт турында хыялланмаган да идем. Мин монда исәпләп карадым, шактый килеп чыга, өлешләп түләсәм ярыймы?

—Нинди исәп-хисап?—Федот Карпович гаҗәпләнде, һәм Гаяз беренче тапкыр аның югалып калуын күрде. Бригадир тиз генә прораб вагончыгыннан чыгып, якын-тирәдә кеше юклыгына ышангач, елмая төшеп, кире әйләнеп керде.—Ничек инде түлим? Дөресен әйткәндә, сездән, Гаяз Нуриевич, охохо, күпме тиеш, безгә кешенеке кирәкми, без намусыбыз кушканча яшибез, шуңа күрә халык сезнең күңелегезне күрергә булды.

Хәзер инде, берни аңламыйча, Исламов аптырашта калды, хәтта агарынып китте һәм ипсез генә итеп урындыкка чүмәште. Тархановка җитәкченең йөрәгенә нидер булды кебек тоелды, бик курыкты.

—Ходаем, вак-төяккә борчылмагыз сез. Менә хәзер аермачык күрәм, сез безнең эшләрне ахырына кадәр аңлап җиткермәгәнсез икән. Ярар, яхшы. Намус белән дус яшәү—зур бәхет. Ә без монда шухыр-мухыр, бугаздан гөнаһка баттык, берүк кичер, Ходаем,—Федот Карпович кулын селтәде дә тагын бер мәртәбә күз карашы белән тышны айкап алды.—Шулай кадәр еллар кайда эшләдегез соң сез? Эшегезне, күреп торам, беләсез, инженер, әнә чәчегез дә чаларган, ә тормышта... ишегегезне дә алыштыра алмагансыз...

—Зәркәнттә эшләдем мин, Федот Карпович, тик башка төзелештә, монысына бөтенләй охшамаган. Сәнәгать төзелеше дип атала.

—Ә мин, Гаяз Нуриевич, гомерем буе шабашкада, нәрсәгәдер өйрәндем дә кебек, кулларымнан зарлансам гөнаһ булыр, тик шундый зур эшне күрергә туры килмәде. Безнең монда сәй җирнең үз законнары, шунысы гына тынычландыра: аларны мин уйлап чыгармадым. Төкерергә дә китеп барырга хәлемнән килми—күнегелгән, аннары бер ярдан икенчесенә ташланырга соңга да калынды, яшем дә андый батырлык күрсәтергә сәләтле түгел, шулай су унаена йөзәбез...—Тарханов авыр сулап куйды һәм дәвам итте:—Мин сезне үзебезнең сазлык законнары белән таныштырыйм әле... Үзем сөйләсәм әйбәтрәк булыр, югыйсә, кайчан да булса гауга, җәнҗалга килеп кабарсыз... Менә сез безнең эшкә өр-яңа күзлектән карыйсыз, бәлки, ни өчен үзегезне бу актовый зал белән әләктереп алмакчы булуларына төшенерсез.

...Ремонт-төзелеш идарәләре—бик кызыксынучан оешмалар: кайсына гына кагылма, һәркайсында бер үк хәл—башкарылган эшләрнең күләме арттырып күрсәтелә. Мисал өчен, сез хастаханә, мәктәп, почта директорымы, башкасымы—анысы мөһим түгел, агымдагы ремонт ясатырга телисез, ди. Бина йөзен югалткан, нинди дер бәйрәмгәме, йә булмаса юбилейгамы яңартасыгыз килә, кем әйтмешли, кунаклар килгәндә өеңне дә карыйсың. Ә эше, кулымны йөрәгемә куеп әйтәм, инә очы хәтле генә. Менә шуннан михнәт чигүләр китә инде. Шушындый вак нәрсәгә кем тотына, йә? Һәм сезгә сылый башлыйлар: монысын эшләсәк, тегесен яңартып җибәрсәк, без, бәлки, алынырбыз да. Ә сез нишли аласыз? Башкасына мөрәҗәгать итсәгез дә—шул ук хәл, бугазыңа пычак терәгән шикелле, икенче районга чыгарга бөтенләй рөхсәт ителми. Кыскасы, сезне, ремонт турында уйлана башлаганда ук, камап алалар. Ә сездән өстә үз хуҗаларыгыз эш барышы белән кызыксынып тора, хуҗалыкны алып бара белмәвегездә гаепли, акчаны да быелга гына күчерәләр, икенче елга элөгүе икеле. Башта тетеп ташлыйсыз, күзегезне яшьләндереп, акчаның санап кына бирелүе турында әйтәсез, аннары—нишлисең, күндердегез,—дисез дә килешү, исәп-хисап кәгазьләрен, документларны әзерләргә кушасыз. Менә шуннан соң, шомарып житкән агайлар утырган смета-килешү бүлегеннән сезгә бирәр инженер килә дә санаган-исәпләгән булып алдарга тотына: тегесен болай итәргә, монысын тегеләй: тузаннан, пычрактан арындырырга, шомартырга, өч тапкыр буярга, чарлак, идәннәрне карап чыгарга кирәк, ди, чынлыкта исә, унлап шиферны һәм өч идән тактасын алыштыралар. Хәзергеләр сүзгә ышана, интеллигентларның кайсысы түбәгә менеп шифер санап йөри, йә? Менә шулай итеп безнең смета төзүчебез закондагы бәяләр күрсәткече һәм житәкче күрсәтмәләре нигезендә түгәрәк кенә сумма ясап куя. Бу суммага эш хакы фонды да, билгеләнгән күләм өчен яхшырак, кыйбатлырак материаллар да керә, билгеле.

Заказчы мыгырданмасын өчен, иң беренче аның кабинетыннан тотыналар, материалны да, көчләрен дә жәлләмиләр—коеп кына куялар. Менә шуңа күрә купшы кабинетлар үрчегәннән-үрчи, кайбер ремонтлар шулар аркасында да тартыла-сузыла. Ремонтны сузган түрәгә—теге килешү кәгазьләренә кул куючыга да нәрсәдер тама: йә өенә ремонт ясыйлар, йә дачасына материаллар китереп ташлыйлар... Бар жирдә дә шулайдыр дип кисемләшә алмыйм, әмма мин эшләгән жирләрдә башымны кисәргә бирим, нәкъ шулай...—Федот Карпович тирән итеп сулыш алды.—Конторлар, оешмалар, хастаханәләр буенча йөргәндә—күрәм, бар жирдә бер үк төсле ремонт, безнең төзүче халкы әйтмешли, күз буяу.

Материалларга урын бик тиз табыла, кайбер эзләп тә табылмый торганнары складтан туп-туры ваклап сәүдә итү, төзелеш кибетләренә—кулларына да тими, күз ачып йомганчы алып бетерәләр. Бернинди ОБХСС та эзенә төшә алмый; материалларны, бер карасаң, көндез шәм кабызып эзләсәң дә таба алмыйсың, ә халык төзи, ремонт ясый. Еш кына башкача да эшлиләр: материалны прораблар үзләре эшкә жигә, хосусый фатирларга, бакча йортларына—хәзер андыйлардан буа буарлык—ремонт ясарга дип аерым наряд алалар, сыйфаты һәм вакыты гарантияләнгән, үзегез күрдегез. Эш үзеннән-үзе килеп чыга һәм ахмакны шартлар ашыктыра: материаллар житәрлек, эшче куллар бар. Заказ бирүчегә килешенгәннең биштән бер өлешен дә ясамыйлар, ә бу исә алдан ук югары хезмәт хакы гарантияләнгән дигән сүз. Нарядларда төзелеш нормалары һәм кагыйдәләренә туры китереп—кәгазьдә бернәрсәне дә төшереп калдырмыйлар—чарлакларны да әйбәтләп карап чыгалар, идән сайгакларын да куптарып, дүрттән өч өлешен яңартып кабат жәяләр, тузан-таплардан да арындыралар, бишәр кат лак

белән дә каплыйлар, кулдан эшләнгәнен дә исәпкә алалар, аерым хезмәт күрсәтүләр өчен коэффициентны да кушарга онытмыйлар, ремонттан соң бинаны —таләп ителгәнчә—җыештырып та куялар. Менә шунда инде аның сере, кадерле Гаяз Нуриевич...

Федот Карпович үзенең алыштыргысыз «Беломор»ын кабызды да, кеше-кара күренмиме дип, тагын бер кат тышка күз ташлады да сүзен ялгап китте:

—Безнең эшче халкын түрәләр менә шулай сатып ала да инде, нигә—теләсә нинди хәлләрдә дә югары хезмәт хакы тәэмин ителгән. Без дә юләрләр түгел, зур төзелешләр белән чагыштырабыз... Анда безнең уртача хезмәт хакын да ничек итеп эшләп алалар. Анда бит күләмне арттырып яза алмыйсың, бар да проект, смета буенча, катгый түләү бәяләре. Ун метр җирне штукатурлап, илле дип кертеп булмый, бездә күбрәк тә мөмкин әле: алагаем зур диварның ун урынына ямау салабыз да ышкыйбыз, янартабыз—бар, дивар тулаем эшләнмәгән дип исбат итеп кара. Ә йөз урынны ямасаң? Сез үзегез күрмисезмени, капиталь төзелешкә караганда ремонт вакытында эшнең күләме һәм эш хакы фонды чагыштырмача югары куелган бит? Ә без, карт зубрлар, моны бик яхшы беләбез, менә шулай итеп РСУ да безнең ишеләр сиздерми генә күпме җыела. Сез, мөгаен, Гаяз Нуриевич, нарядлар буенча күз йөрткәндә ярыйсы акча сугабыз дип уйлыйсыздыр, тик бу алай түгел. «Кайда гына эшләмәдем—бу идарәдә дә шул исәптән—кагыйдәләр беркү. Һәр ай ахырында прораб нарядларны япканда, мисал өчен, мина әйтә: Карпыч, көнгә унардан—сезнеке, калганнарын кайтарырсың. Янәсе, күләмне арттырып яздырту өчен заказ бирүчегә тәртәсе; контроль үлчәүләр белән шөгыльләнүче банк кешесенә, кайсыбер дефицитлар өчен складка, эш күләмен, эш хакы фондын оештырган конторда утыручы теге смета-килешү бүлеге әрсезләренә; тагын нарядларны үткәрүчегә, материалларны чыгымга язучыларга—кыскасы, син дигәндә аяк идәндә дигәннәрнең барысына да. Без дә канәгать, прораблар безне кыерсытмыйлар дип саныйбыз. Аның каравы, эшләр сыек торганда, безнең мәшәкать түгел,—көнгә ун сумнан ризалат, яки без икенче айда үзебезгә язылганны умырып алачакбыз, дисең. Мин бу мәсьәләдә бик кырыс—үземнекеләрне кыерсытырга юл куймыйм. Һәр ай саен без Коля белән һәр кешедән утызар, кайчагында иллешәр дә була—төрлечә килеп чыга—җыябыз да прорабка тапшырабыз, үзең санап кара, күпме чыга. Үз чиратында ул кемгә бирә, кем белән бүлешә—анысы безгә кагылмый. Кабахәтлек, билгеле, Гаяз Нуриевич, ләкин кая барасың—шулай яшибез.

Дөрес, кайчагында эш вакытында кешеләргә шәхси ремонтлар да ясыйбыз, прораб безне кыерсытмый, бер өлеше безгә дә тама, хезмәт хакы да бара. Менә шуна бездә булдыксыз һәм ялкаулар озакка тоткарланмый—эшли дә белергә кирәк бит, һәр кеше шәп башкарылган эшкә генә түли.

Менә сез безгә килдегез, Гаяз Нуриевич, безне куаламыйсыз, кирәге дә юк, чөнки без эшебезне беләбез, иске нарядларны, элеккеге хезмәт хакларын карадыгыз, берәүдән дә сорашып тормыйча, элеккесеннән киметмичә яба башладыгыз. Мин, билгеле, һәр айда билгеләнгәнчә җыям да Коля белән «китерегез» дигән сигналны көтәбез. Ә сигнал юк та юк, сумма инде шактый җыелды, шулай тиз арада шуның хәтле җыелуына аптырасам да—дәвам иттем, үзем, ай-яй шайтан, сак кеше туры килде, вакланып маташмый—барысын бергә чумырыргадыр исәбе, дип уйлыйм. Бригадаларда, билгеле, берниндн гу-гу, халык та бездә алай кызыксынучан түгел, чөнки үзебез сайлап тупладык. Шулай ел да узып китте, сезгә актлар залын ремонтлауны китереп тоттырганда, аның алдыннан безне, сездән алып, икенче участокка күчерергә теләгәннәр иде, хәтерлисездер, шунда

мин чамалап алдым: сез контор белән дә, житәкчеләр белән дә бер иярдә түгел икән. Кая инде сезгә алар белән бер компаниядә булу, сез бит аларга бернәрсә бирмисез, бернәрсә дә алмыйсыз. Дөресен әйтим: шактый озак сакландылар алар һәм, йә сез монда житәкчелеккә омтыласыз, йә тегеннән куып жибәрелгәнсез, дип уйладылар. Ә сез ялга китәргә жыенгач, барыбыз бергә жыелып утырганда, мин теге акчаны эләктердем. Коля белән сезне озатырга булып, өегезгә килгәч, ниһаять, аңлап алдык—бер сүз белән әйткәндә, сез безнең өчен моңарчы күрелмәгән прораб булып чыктыгыз. Иртән Коляша белән бик озак баш ваттык—акчаны нишләтергә соң? Халыкны жыйдык та сөйләп бирдек: алмады, сорамады—шуннан һәрберсенә тияр өлешен бүлдек тә бирдек. Акчаларын алсалар да, күрәм, берсе дә туздырырга ашыкмый. Миңа үпкәлиләр: син нәрсә, карт кәжә тәкәсе, ял итәргә дингезгә китте, ә син шул яхшы кешенең юлына дип кесәсенә өч-дүрт йөз дә салмагансың. Кыскасы, ул көнне эшнең рәте-башы булмады, ә кичен, жыелгач, тагын сезнең турыда сүз кузгалды, мөгаен, анда очкылык та тоткансыздыр әле... Шунда беребез—аңардан беркайчан да юньле-башлы фикер ишеткәнебез юк иде—кафельләр куючы Петька Морозов әйтә: «Егетләр, менә нәрсә, әйдәгез, өенә ремонт ясыйбыз»,—ди, намуслыга намус кушканча ягъни. Сезнең ишекне алыштырырга жыенганымны ул ишетеп калган иде. Һәм үкенечле өстәп куйды: «Сизеп торам, бездә озак тоткарланырга ирек бирмәсләр, хет РСУда бергә эшләвебезнең истәлеге булып калсын». Шулай килешендек. Аннары, Гаяз Нуриевич, эшләр майлаган кебек хутка китте, күнелле, жинел бара, егетләр чын йөрәктән тырыштылар, ә сез, исәпләшербез, имеш. Мәгъриче, менә, сездән тиеш, бу бурыч сезнең өстегездә кала.

Федот Карпович дулкынланудан башыннан истәлекле картузын—сугышка кадәр үк заказ биреп тектергән, дип әйтәләр—салып кулына тотты, тирләгән пеләшен шактый зур кульяулыгы белән сөртеп алды, мөгаен, үз гомерендә анын бу кадәрле озын сөйләгәне булмагандыр. Гаяз хәйран калып, югалып, озак утырды—хәле китте, тик өлкән яшьтәге кеше алдында унайсызланды, әйтерсең, моның барысы да анын аркасында килеп чыккан. Имәндә икән чикләвек: арттырып үтәүләр, эшләнеш, хезмәт житештерүчәнлеге, материалларны һәм эш хакы фондларын экономияләү, алдан гарантияләнгән өстәмә түләүләр—бер ялган икенчесен тудырган, бер жинаять икенчесенә этәргән.

—Алай өзгәләнмәгез, Гаяз Нуриевич, монда сезнең бер катнашыгыз да юк, системасы шундый, бер сез генә үзгәртә алмыйсыз. Менә сезнең белән бер генә ел эшләдек, жаныбыз чистаргандай булды. Безгә, эшчеләргә, нәрсәгә андый хәвефле эшләр, планнар, процентлар, безгә эш бир дә шул ук ун тәнкәнне түлә, тик гадел булсын—таулар актарырга әзербез. Өстән-өстән генә эшләргә күнел ята дип беләсезме әллә, бушка булмаса да? Һәрберсенә жавап табып кара: нигә эш вакытында, материаллар кайдан? Хужа безне тереләй тунаучылар дип саный, гәрчә без аңардан күпме каерганнарын белми дә калабыз. Фатирда һәр шалтыраган кыңгырау тавышына калтырап китәсең: кем килгән, нәрсәгә килгән—бер дә кызыгы юк. Подъездга кергәндә дә, караклар төсле як-ягына карангалап, тиз-тиз генә чумасың,—берәрсе күреп калмасын, янәсе, эш сәгатендә бу төзүчеләр нигә монда тулгана әле. Бу бер елда тирә-якка әйләнгәләп караудан да туктадык, биздек, ахры, монысы өчен дә рәхмәт, Гаяз Нуриевич.

Исламовның бөрешеп калганын күреп, Федот Карпович әйтте:

—Мин иртәгә төштән соң әйләнермен, нарядларны иртәгә дә эшли алабыз, вакыт бар әле, менә табель һәм кәгазьләрне сезгә калдырыйм, йә кирәкләре чыгар.

Әкрен генә прораб бүлмәсенен ишеген япты. Бу сөйләшүдән анын да кәефе төште, шуна, объектка кайткач, барысына да әләкте: измә тирәсендәге пычраклык өчен дә, тирә-яктагы ватык-җимерек тә читтә калмады, хәтта беркайчан күрелмәгән хәл—эш киеменә кадәр бәйләнде.

Тарханов киткәннән соң, Гаяз бик озак урыныннан купмады... Эшкә кулы бармады, уйлары һаман да Федот Карповичнын күтелмәгән тәүбәсе тирәсендә әйләнә, күрәсен, анын да шеше тулып ташыган иде. Билгеле, Исламов күптән балалык яшеннән чыккан, ләкин айда яшәми бит, төзелештә дә беренче көне түгел. Ул кайбер нәрсәләрдән хәбәрдар: кечерәк, йә булмаса зур астыртын башкарылган эшләр турында ишеткәне бар, әмма төгәл системага салынган күз буяу, караклык, арттырулар барлыгы... анын башына сыймаслык хәлләр. Бу турыда башка берәү сөйләгән булса, ул ышанмаган булыр иде, тик Федот Карпович алдамас, нигә кирәк ул ана?

Гаяз үткән елны хәтер иләге аша үткәргәндә, нинди дә репликаларга, әйтелеп бетмәгән җөмләләргә игътибар итте... Чынлап та, ул күренүгә, әнгәмәне шунда ук икенчегә борып җибәрүләрен сизенә иде. Ана айлык план житкергәндә, баш инженер алдан ук икешәр кат кисәтә килде, янәсе, анын объектында материалларга чыгымны кимету шактый булачак, Гаяз мона шаккатмасын, янәсе, кайбер әһәмиятле объектларда эшләр артык чыгым сорый. Болар да Исламовны шикләндерә алмады, чөнки төзелешләрдә мондый хәлләр булуын ул белә иде, бер-беренә ярдәм итмичә булмый. Хәзер генә төшенде: бу «эшлекләләр» анын «экономияләнгән» материаллары белән берәр ничек каба калсалар, жавапны ана тотарга туры киләчәк: чөнки «бу артык чыгым белән баручы хезмәттәшләренә биреләчәк ярдәмнәр» склдларда ятып калсалар да, анын объектына язылган. Бернинди артык чыгымнар турында сүз дә булырга тиеш түгел,—Гаяз моны әле анлады—аннан, яна килгән кешедән шикләнеп һәм куркып, алар зур калжаларны ычкындырырга теләмәгәннәр.

Исламов төшкә кадәр уйларына батып утырды, тик башына бернинди юньле-рәтле фикер килмәде. Ә Федот Карпович белән булган әнгәмәдән сон «камчы белән балта тутәсен ватып булмый» дигән мәкаль исеннән чыкмады.

Бер ай узып китте, икенчесе. Гаяз берни эшли алмады, үзе дә колакларына кадәр пычракка чумган кеше нәрсә эшли алсын? «Нинди хөрмәт белән фатирыгызга бушлай ремонт ясадылар, андый дефицит материалларны кайдан тапканнар? Кин күнелле, намуслы булуыгыз өченме? Алай булмый. Тәртипле кешеләр аз түгел, ә фатирларын ремонтлатырга еллар буе чират көтәләр, күз буяп маташма, Исламов»,—дисәләр, нәрсә дип жавап бирсен ул. Обойларны аерып төшерергәме, йә ишекне ватарга, йә булмаса, иске кытыршы ваннаны үз урынына кире куяргамы? Аннан да ахмаграк нәрсәне уйлап табып булмый. Күпме борылып карама—артка юл юк, башта ачык авыз булмаска кирәк иде. Ул көннән-көн ныграк газапланды. Бер генә нәрсә тынычландырды: Тарханов ремонтны үз теләге, бригада теләге белән ясаган. Ә махсус—контордагылар әйтүе буенча ясалган булса? Аны да пычрак эшләргә тартып, артка борылып карый алмасын дип эшләгән булсалар? Бу коточкыч уйдан ул нишләргә дә белмәде...

Тора-бара Гаязнын күнеле сизде: конторда ремонт турында берни белмиләр, андый уен тузын шунда ук әйләнешкә кертеп җибәрерләр иде. Ул берни эшләмәде, анын каравы, ана каршы бик актив хәрәкәт итә башладылар. Аны сынау вакыты узып бара, РСУ житәкчелегенә бар да ачык: бернинди житәкчелек постларына дәгъва кылмый, Исламовка ышерен йомыш, миссия тапшырылмаган, артында торучы «йонлач кулы» да юк. Ел дәвамында анын турында беркем сорашмады, беркем кызыксынмады,

өстән бер шалтырату булмады... Очраклы кеше, яхшы инженер, әмма «дөрес юнәлеш алмаган»,—үзе артында шундый бәя бирде аңа түрә. «Дөрес, йә бүтәннәр җырына кушыл, йә дүрт ягың кыйбла»,—дип ачыктан-ачык әле беркем дә әйтмәде. Тик аңа материаль исәп-хисапларны тапшыру көннән-көн кыенлашты, хезмәт хакы фонды булмауны сәбәп итеп нарядларын кисә башладылар. Материалларны да складтан иң соңыннан ул алды яисә бөтенләй бирмәделәр, өстәвенә транспорт белән бик еш кына матавык чыгып торды. Әгәр дә Тарханов белән Коляша булмасалар, әледән-әле складта да, идарәнең транспорт цехында да, конторның үзендә дә талашгауга чыгармасалар, участоктагы эшләр бөтенләй кәй булыр иде.

«Без сине якларбыз, тик син генә бирешмә!»—дип, Гаязның күнелен күтәрергә тырышты Федот Карпович. Аларның үзен уңайсыз хәлдә калдырмасларына Исламов ышана иде. Ә бригаданы аңа каршы куярга тырышу очраклары булмады түгел, булды; тик Тарханов кына җитәкчелек жаена барырга теләмәде. Шулай да читтән кесә калынайтырга күнеккән РСУ җитәкчелеге ярты елга, азрак күрсен, комачауламасын дип, Исламовны барыбер объекттан читләштерү жаен тапты. Берләшмә директорының шәһәр үзәгендәге яңа гына алынган биш бүлмәле фатирына ремонт ясарга кирәк булды, хәзер торакларны ничек тапшырулары беркемгә дә сер түгел. Директорның үлчәвенә килгәндә, барысын да өр-яңадан эшләп чыгарга кирәк иде, аны тик фатирның диварлары гына канәгатьләндерде, аларын да өлешчә үзгәртергә кушты. Гаяз үзенә йөкләмә биргән баш инженерга смета, материаллар, проект белән нишләргә, эшчеләргә ничек түләргә кебек сораулар белән мөрәҗәгать итте. Анысы башта көлде генә: нинди проект, нинди смета? «Менә сиңа адрес, иртәгә сәгать тугызда сине директор хатыны көтеп торачак, проектын да үзе аңлатачак». Ләкин соңыннан нәрсәнедер үлчәде, ахрысы: «Әлбәттә, син исәп эшләрен алып бар, аннары ремонт өчен сметасын, килешүен төзерсең, һәм директор касса аша ничек таләп ителә, шулай рәсмиләштерер. Ә материалларга килгәндә борчылма, үзебездә булмаганнарын берләшмәнең складларыннан табарсың, йә икенче җирдән алмаштырып алырбыз—берләшмәнең нәрсәгә дә булса алмашка һәрвакыт дефициты була. Синең бурычың—эшчеләр буш тормасын өчен, тәэмин итүчеләргә вакытында күрсәтмәләр бирү. Ә синең арттан күзәтү халык контроленнән арурак булыр»,—дип кисәтте аны баш инженер, күрәсең, директор хатынын бик яхшы белә иде.

Икенче көнне, күрсәтелгән адрес буенча килгәч, Исламов директор хатыны—Клара Васильевна белән очрашты, дөрес, тегесе бер сәгатькә якын соңлады. Ул бик тырыш, эшлекле ханым булып чыкты, соңрак Гаяз Клара Васильевнаның өлкәнең бер тармагына караган профсоз оешмасын җитәкләвен белде. Ул ишекне ачты һәм алар бергәләп фатирга керделәр. Йорт ведомствоныкы—республиканың төзелеш министрлыгы аны үзе өчен төзеткән, аларның берләшмә директоры ничек моннан фатир эләктергән диген—эшнең сыйфатына тел-теш тидерерлек түгел, проекты да, Гаяз карашынча, уңышсыз килеп чыкмаган.

—Үзләре өчен проект сайлап алырга да, тырышырга да ярый иде инде,—диде Клара Васильевна ишетелерлек итеп, ул министерствоны күздә тота иде. Алар бүлмәдән бүлмәгә керделәр, һәм һәркайсында хуҗабикә авыр итеп көрсенде, Гаяз аны аңлады. Фатирда ике юыну бүлмәсе, ике бәдрәф, ике лоджия бар—сөенеп туймассың, тик ханымның йөзендә елмаюның эзе дә күренмәде. Нәрсә дип куанырга, бар җир ташландык хәлдә, таушалган, әйтерсең монда бик озак вакытлар шапшак кешеләр яшәгән. Ә бит бу тугыз катлы йортны бер атна элек кенә «бишле» билгесенә тапшырдылар, бу турыда гәҗитләр дә—янәсе, шәһәр үзәгендә зур өч палубалы карабка

охшаган тагын бер бик матур йорт калкып чыкты,—дип шауладылар. Гәҗит битендә басылган фотографиядә, чыннан да, ул искиткеч күренде. Тик ретушьлап төзәтелгән фотография—бер нәрсә, ә ярыклар белән тулган йорт —бөтенләй икенче. Ирексездән Гаязга ялдан фатирына кайтып керүе, ишекне ачып җибәрүгә ахылдап куюы исенә төште, югыйсә, чынлыкта да яна өйгә күчүчеләргә торак нәкъ менә шулай, ишек ачучының беренче тавышы «ох» түгел, ә «ах!» булырлык итеп тапшырылырга тиеш тә бит.

Клара Васильевна үзен тиз кулга алды, күрәсең, вакыты тыгыз булгандыр.

—Зинһар, язып алыгыз,—диде ул Гаязга кискен генә.—Барлык ишек, тәрәзә, лоджия рамнарын алырга һәм имән яки бүкнеке белән алыштырырга, һич тә булмаганда, өйдә буяу эшләре булмасын өчен—миндә буяуга аллергия—лоджия рамнарын кызыл нараттан эшләргә мөмкин.

Бу җылыту өчен куелган калай гармушкалар шунда ук тама башлаячаклар, аларны кисеп алырга һәм гадәти чуеннан ясалганын куярга, билгеле инде, диварга уеп. Куышы тирәнрәк булсын. Газ плитәсен, югычны көньяк лоджияга чыгарырга, анда аш пешерү бүлмәсе булыр. Аш бүлмәсенең диварын алырга һәм иркен ашханә ясарга, стенаны такта белән тышлап аласы булыр. Залда, һичшиксез, камин торыр, мин түшәмне тишәр өчен махсус тугызынчы катны сайлап алдым. Әгәр монысы сезгә кыенлык тудырса, минем белгечем бар, рәшәткәләрен заводта телерләр.

Шуннан соң... Бар сантехниканы: ванна, унитаз, юынгычларны алырга, читтән китерелгәннәр белән алмаштырырга, финныкы яки шведныкы булса, яхшырак булыр. Әйе, онытып торам икән, бәдрәфкә, һичшиксез, кул югыч-тюльпан куярга, мин моны күптән түгел генә бик яхшы бер өйдә күрдем, хәзер модада шул, сез бу турыда белмәскә дә мөмкинсез, яшь кеше,—диде Клара Васильевна һәм, ашыгып, як-ягына каранды.—Паркетны кубарырга. Вьетнамныкына заказ бирегез, кызыл агачтан булсын, эшләгәндә бераз катырак диләр, әмма карап торуга искиткеч. Залга фин каеныннан җыелма паркет булса, шәп булыр иде, тик табуы җиңел түгел, шулай да сез заказ биреп карагыз, бәлки табарлар, мин дә үз каналларым буенча эзләтеп карармын, бездә тукучылар сараен бизи башладылар. Тәрәзә төпләре, батарея рәшәткәләрен имәннән, тик буяу тидермәскә, мин сезне кисәттем инде—миндә буяуга аллергия, бары тик лакларга. Барлык тәрәзәләргә, лоджияларныкына да кояштан саклагычны онытмагыз, пласстмассаны түгел—ул янып чыга,—дюральны, Италиянекен. Чак кына төшереп калдырмадым: юыну бүлмәсендә һәм бәдрәфләрдәге идәнгә төрле төстәге мәрмәр, тик артык калын итмәгез, суыккарак китәр. Ванналар, билгеле инде, керамикадан, бер квадратлы булса, әйбәт булыр, бассейн манерында, андый ванналар бик матур күренә һәм хәзергә алар бик аз кешедә. Бөтен яклап түшәмгә кадәр кафель, тагын шул, төсләр бер җирдә дә кабатланмасын, ваннаның берсен кара кафель һәм көзгеләр белән эшләргә, ирем кара төскә мөкиббән.

Менә болар сезгә башлап җибәрә торырга. Мин барлык кара эшләрне игътибарга алып бетердем бугай, соныннан чиста эшләргә—матурлауга, бизәүгә комачауламасыннар. Аның турында сөйләшү аерым булыр. Сез ничек саныйсыз?—Гаязга өстәрлек итмәде, Клара Васильевна нәрсә теләгәнен бик яхшы белә, этаплап фикер йөртә, чын төзүче диярсең. Эшләр катлауланып китсә, шунда ук тәүлекнең теләсә кайсы вакытында шалтыратуын үтенде. «Үтәлү вакытын ашыктырмыйм»,—диде ул, күрәсең, яхшы эшнең тиз генә очына чыгып булмавына төшенә иде.

Исламов шул ук көнне төштән соң фатирга Федот Карпович һәм Коляша белән әйләнеп килде, тегеләре исә куаныштылар: бригададагы ике кеше

төзелеш алып бара икән, Клара Васильевнага ошамаган әйберләрнең барысы да аларга тулаем яраклы, житмәсә бушка. Ә дүшәмбе көнне ниндидер үлчәүләр алыр өчен фатирга сугылса, Гаязның исе китте: кирәксезгә чыгарылган бар нәрсә бик сакланып, пөхтә итеп салдырып алынган иде. Кафельга кадәр куптарып алынган, чистартканнар, алып чыкканнар. Шәрә диварларда тәрәзәләрнең пыяласыз күзләре ярылып яталар; бар жирдә тәртип, чисталык. Исламов Тархановтан: «Ничек ике көндә башкарып чыктыгыз?»—дип сорагач, тегесе көлде дә җавап бирде: гаиләләре белән ябырылганнар, көне-төне эшләгәннәр, хуҗалары кире уйламасын дип курыкканнар. «Кызыксыну—бик зур көч»,—дип философларча тәмамлады Федот Карпович.

Һәр ай ахырында, әле берләшмә директорынын фатирында ремонт эшләре барганда, Гаяз нарядны төрле территорияләрдәге цехларда башкарылган эшләр хисабына ябып барды. Әз дә язмады, күп тә—гадәттәгечә. Берсендә, өченче ай беткәндә, ахрысы, инде эшнең шактые башкарылгач,—агач эшләре тәмамланды, жылыту системасы һәм катлаулы сантехника урнаштырылды,—гомумән, пычрактан арындык дигәндә, анын нарядын кистеләр. Бригадаңа артык яхшы түлисең, халыкны азындырасың, дип аңлаттылар. Иртән, объектка килеп, бу хәбәрне ирештергәч, бригада, билгеле, сукранырга тотынды, һәм Исламовка Клара Васильевнага шалтыратырга туры килде. Клара Васильевна ремонт барышын әзгә генә дә күзәтүсез калдырмады, Тарханов белән дә дуслашырга өлгерде, осталарның эшләрен карап, бәяләп торды, шуна күрә бик тиз арада чарасын күрде. Ә аннары ремонт ахырына кадәр бригадага күпме түләүләре белән кызыксынып торды, шуңадыр, мөгаен, идарә буенча иң югары хезмәт хакы аларда булып чыкты, эшчеләргә дә жан керде. Сәер, баштарак бу эш—Федот Карпович аны халтура, жинел табыш дип атый—Гаязның ачуын кабартса да, эченә ныграк кергән саен, жәлеп итә барды, чөнки бу анын өчен практика—гражданлык төзүчесенә житеп бетмәгән өйрәнү мәктәбе иде. Хәзер, ремонт беткәннән соң, ул курыкмыйча теләсә кайсы идарәгә төгәлләү эшләре буенча бара ала иде.

Фатирда ул көне буе була, чөнки сәгать саен проблемалар чыга тора, аларны урынында тиз генә хәл итәргә туры килә. Һәрбер тәмамланган эш этабын күрү генә дә ни тора! Төп тарту көче дә менә шунда иде. Даими рәвештә бригадасы янәшәсендә булуның файдасы искиткеч булды: монда бит үз эшләренең осталары эшли, шуңа Гаяз бер генә дәреслектән дә таба алмый торган бик күп серләргә төшенде. Әйтик, шул ук Петька Морозов—кафельчы—бассейнга охшаган, квадратлы тирән зәнгәрсу ваннаны шундый итеп эшләп куйды, Клара Васильевна сәгать буе чыга алмыйча, «ах»-«ух» килеп сокланып туя алмады. Хәтта житдилеген читкә куеп, Морозовка эшләр тәмамлангач, профсоюз хисабына жаны кая тели, шунда юллама вәгъдә итте. Һәм бригада берничә көннәр, оттырмас өчен, кайсын сорарга дип бәхәсләшеп бетте: Ялтагамы, әллә Сочигамы? Ә бригадир Коляша Байкалга бару ягында торды.

Бу айларда Гаязга нинди генә материаллар, нинди генә сантехника белән эш итәргә туры килмәде, мондый матурлыкны күргәне дә юк иде, анын ише нәрсәнең складларында булуын күз алдына да китерә алмады.

Клара Васильевна нихәтле генә куаламасын, темпны арттырып булмый: әле бер нәрсәдә тоткарлык килеп туды, әле икенчесендә. Озак вакытлар лоджиялардагы стеллажлар, стена куышындагы шкафлар өчен туры килә торган фурнитура табылмады, аннары күп санлы ишекләргә тоткалар һәм йозаклар, бикләр эзләделәр, һәм, ниһаять, бар да хәл ителде. Кайбер нәрсәләрне хәтта өр-яңадан эшләп чыгасы булды. Инде бар бүлмәләрне обойлап кына бетергәннәр иде, Клара Васильевна испанныкын—борынгы,

кулдан сугылган ефәккә охшатып ясалганнарын табып китерде. Ул бизәкләре! Төргәкләрнең башта берсен, аннары икенчеләрен таратып җибәргәч, бар да ахылдап куйдылар—нинди төсләр, нинди үзенчәлекләр, кәгазь генә димәссең. Тарханов, Клара Васильевнаның барысын да янадан эшләргә кирәклеген әйтергә кыенсынып торуын күреп, аны бу хәленнән коткарды:

—Нәрсә, хуҗабикә, эшлибез, андый обойлар гомердә бер генә эләгә, әле бар кешегә дә түгел.

Фатирда эш фронты тарая төште, һәм Гаяз әкренләп эшчеләрне объектка җибәрә башлады. Кемдер, мөгаен, менә, хуҗабикәнең көйсезлегеннән туяр да ремонтны ташлап качар, дип өметләнгәндер, тик Исламов белән Клара Васильевна арасында башта ук әйбәт мөгамәлә урнашты, эшләр дә, зарлану гөнаһ булыр, уңышлы барды. Ярты ел барган ремонт вакытында, Гаяз кайчан директор үзе кереп, купшы фатирын карап чыгар икән дип көтте, бәлки аның кара кафельлы ваннадан тыш башка теләкләре дә бардыр дип уйлады. Тик тегесе үзенең тугызынчы катына тәки бер тапкыр да күз салмады, анда инде сынар өчен каминны кабызып карадылар, биек йорттан күккә таба «авыл» төтене күтәрелде.

«Мөгаен, эше тыгыздыр»,—дигән фикергә килде Гаяз. Бу уен Тарханов белән бүлешкәч, Федот Карпович озак кына көлүеннән тыела алмады, аннары үз итеп Гаяз Нуриевичның җилкәсеннән кагып куйды:

—Син бездә барыбер бернигә дә өйрәнә алмадың, соң, нәрсәгә кеше тенкәсенә тиеп йөрсен ул? Эш барышы турында белә микән дип тә шикләнмә, бүтәнчә кайдан килсен шундый дефицит? Клара Васильевнамы? Ул бары ире кушканнарны гына үти. Нинди дә булса күңелсезлек чыга калса, җавап әзер—күрмәдем, ишетмәдем, аягымны да басканым юк, хәбәрдар түгелмен. Хатынына, РСУ җитәкчелегенә сылтый, аларны ялагайлыкта гаепли һәм начар дигәндә шелтә белән котыла, йә шәп итеп кыздырып, кичерүләре ихтимал. Ә монда килеп, күрсәтмәләр биреп йөри башласа—ахыры ничек бетә—билгесез, партбилетыннан колак кагуы да ихтимал. Шелтәне алып ташлап була, кадерле Гаяз Нуриевич, ә ремонт—гомерлек.

Тархановны ул аңлый, мөгаен, шулайдыр да, тик эченнән генә: «Нишләптер мин монда кирәкмәгәнне өйрәнәм һәм кирәкмәгәнгә иялəшәм»,—дип уйлап куйды.

Эшләрен тәмамлаганнан соң, ярты ел элек килешенгәнчә, Исламов баш инженерга ремонтка киткән исәп-хисап кәгазен тапшырды.

—Унсигез мең алты йөз сум!—дип кычкырып куйды баш инженер, иң ахырдагы саннарга күз салгач.—Син акылдан яздың мәллә! Кем мондый сумманы түләсен? Мә, ал, яңадан эшлә: алты йөз-җиде йөздән артмасын.

Менә шунда беренче тапкыр бик каты эләгештеләр! Исламов нәрсәнедер үзгәртүдән кырт кисеп баш тартты: «Әгәр сезгә шулай кирәк икән—үзегез эшләгез»,—диде дә сметаны өстәлдә калдырып чыгып китте.

Соңрак бу сумманы алты йөз житмеш сумга калдырып кабат эшләделәр, шушы юк диярлек акчаны директор кассага өчкә бүлеп түләде, өстәвенә: «Сез нәрсә, мине хәерчелеккә төшермәкче булдыгызмыни?»—дип, сукранып та йөрде әле. Моңа бер катнашы булмаса да, җитәкчелек Исламовка ләгънәт укыды: эттән алып эткә салды. Аллага шөкер, әле ярый, директор ремонттан зарланмады. Яңадан аның участогына материаллар бирүдә, транспорт белән тәэмин итүдә өзеклекләр башланды.

Беркөнне төштән соң Гаяз конторга керде, исәбе, ниһаять, баш инженер белән аңлашырга иде. Тегесе урынында юк, сәркатибе озакламый килеп җитәсен әйтте. Исламов көтәргә булды—ул зур сөйләшүгә әзерләнгән иде.

Көтмәгәндә идарә буйлап корт чаккандай йөгерешә башладылар: райкомнан шалтыратып, җитәкчелектән кемнең дә булса берәрсенең ашыгыч рәвештә беренче секретарь янына килеп җитүен сораганнар икән. Юри диярсең, ни җитәкче, ни баш инженер, ни партоешма секретаре—берсе дә эш урынында күренмәде. Сәркатип: «Барысы да объектта, конторда участок җитәкчесе Исламов кына бар»,—дип хәбәр итте. Ун минуттан, күрәсең, кем беләндер киңәшләшеп, кабат шалтыраттылар: «Участок җитәкчесе булса да ярый».

Һәр кешенең тормышы үзенчә төзелә: берәүләр югарыдагыларның кабинетларыннан чыкмыйлар, ә берәүләрнең анда башларын да тыгып караганнары булмый. Менә Исламовның да СМУ җитәкчесе кабинетыннан башкасында булганы юк, кирәксенми дә иде. Ә монда, менә сиңа мә, партиянең район комитетына чакырдылар. Гаязны кабинет купшы идән паласы, чит ил җиһазы, күренеп торган урындагы «ЗИЛ» суыткычы, чүлмәктәге фикус гөле, өстәлдәге рәсемнәр төшерелгән чәйнекләре белән гаҗәпкә калдырды. Ул райком секретареның эш урынын бөтенләй башкача күзаллый иде. Өйдә була торган халәт, гадәти кабинетларга хас булмаган иплелек ничектер Исламовны тайчандырып җибәрде.

Хуҗасы да кабинетына туры килә торган булып чыкты—йомшак күнелле, якты чырае балкып тора. Ул Исламовны чәй белән сыйлады. Тормыш-көнкүреш турында берничә гадәти сорау биреп, рәтле-башлы җавабын да тыңлап тормастан, кинәт кенә сорап куйды:

—Салар елгасы аша салынган күперне күргәнегез бармы?

Гаяз үзенең Ташкентка күчеп килүенә күптән түгел генә икәнен, бәлки күргәне бардыр, бәлки юк тадыр, тәгаен генә җавап бирә алмавын белдереп, эшнең нәрсәдә булуын сорады. Кабинет хуҗасы бер генә мизгелгә уйга калды.

—Хәер, күрдегезме, күрмәдегезме—анысы мөһим түгел. Ә күпер сезнең берләшмә каршында, күз салганыгыз бардыр дип ышанам.

—Әлбәттә, мин һәр көнне шуның астыннан эшкә йөрим.

—Һәм ул сезне канәгатьләндерәме?

—Аңламыйм. Әлбәттә, тулысынча. Күпер шикелле күпер, ышанычлы дип саныйм. Минем белүемчә, тимер юлчыларның күпер салучылары—илебездә иң яхшы төзүчеләр, безнең күперләргә заказлар дөньяның бөтен ягыннан килә, бу—гомумтанылган факт. Күпер салу традицияләре Россиядә гасырдан- гасырга көчлерәк дип санала,—дип, имтихан биргәндәге шикелле җавап тотты Гаяз.

—Мин ул турыда түгел,—дип, түземсезләнеп бүлдерде аны кабинет хуҗасы.—Мин әйткән Салар аша салынган күпер чиста, пөхтә, мәрмәрдән, саклагыч рәшәткәләр дә бик матурлар. Мин үземнең районымда да шундый күпер булуын телим, яхшырак ярый, әмма ким булмасын. Сезнең ярдәмегез белән, иптәш Исламов, без күрше районны уздырып җибәрербез дип ышанам,—ул бөтен йөзен тутырып елмайды, үзенең кабул иткән карарыннан бик канәгать калды бугай.

Гаяз шундый мәгънәсез хәлдә калды, хахылдап көлеп җибәрүдән үзен көч-хәл белән генә тыя алды: күперләрне бөтенләй чагыштырып булмый бит. Саларныкы—автотранспорт һәм җәяүлеләр өчен булса, монысы тимер юлныкы—ике юллы колея, интенсив йөреш белән. Тик җавабын җитди итеп кайтарды:

—Беләсезме, теләсә кайсы ясалма корылмаларныкы кебек, күпернең дә хуҗасы бар, әлеге очракта—аралашу юллары министрлыгы. Тәгаен, күпер проектка нигезләнеп салынгандыр, анда эстетик як та исәпкә алына. Хуҗасының рөхсәтеннән башка гаять зур күперне мәрмәр, гранит белән

эшләргә, плитәләрне бораулап тишепме яки башка төрле юл беләнме фермаларга корыч яки агач тирәкләрдән, очлары белән бере-берсенә нык беркетеп ясалган корылмаларга, порталларга, күпер баганаларына ныгытырга ярамый, алайса, мөһим нәрсә—күпернең күтәрү сәләтлелеге, аның куркынычсызлык гарантиясе бозыла. Шуна өстәп, МПСтан андый рөхсәтне ала калганда да—һич тә ышанырлык түгел—безнең аз егәрле төптөгәл таш фондына исәпләнгән РСУ оешмасы мәрмәр һәм башка төрле кыйммәтле материал фондлары белән эш итми. Аннары теләсә кайсы эш, андые турында әйтеп тә торасы юк, проект буенча эшләнә. Бу эшне махсуслашкан оешма гына башкара ала. Шул хәтле кыйбатлы эшне кем финансларга алыныр—бу мәсьәләне дә хәл итәргә кирәк. Шулай итеп, сезнең кәефегезне бозарга тиеш булам: якын арада безнең күршеләрдән уздырып җибәрү уе барып чыкмас дип уйлыйм.

Секретарьның йөзеннән елмаюын кул белән сыпырып алдылармыни! Бу әңгәмәдә катнашкан ике бүлек мөдире, хуҗаларының ачуын бүлешергә теләп, Исламовны карашлары белән яндырып, көл итәргә әзерләр иде.

—Кемнең нәрсәгә хуҗа икәнен аңларга сез бик яшь әле, иптәш Исламов. Китәргә мөмкин, сез азат. Һәм үзегезнең җитәкчегезгә тапшырыгыз, иртәгә нәкъ тугызга монда булсын!

Шулай итеп хушлаштылар.

Райкомнан соң Исламов РСУга барып тормады, җитәкчене дә кисәтмәде. Купшы кабинет хуҗасы аны болай гына, сүзе аста калмасын дип кенә әйткәндер дип карар кылды. Күпер белән булган вакыйга ачыктан ачыграк бит инде, чып-чын маниловщылык—хыялга бирелү генә. Тик барысы да яманрак булып чыкты. Төшкә таба объекттан аны идарә җитәкчесе чакыртып алды.

—Ну, эләгә сезгә, Гаяз Нуриевич. Җитәкчелек иртәдән авызыннан утлар чәчә,—дип кисәтте сәркатип.

—Утырыгыз,—диде җитәкчесе, Гаяз кабинетка узып, үзе артыннан ике катлы ишекне тыгыз итеп япкач. Шефның шелтәләре бик тавышлы була иде.

Түрә куллары белән башын кысып, шактый озак дәшмәде.

—Әгәр сез ике сәгатькә алданрак килгән булсагыз, белмим, мин сезне нишләткән булыр идем, Гаяз Нуриевич, инде үтте—тынычландым. Билгеле, мин аңлыйм, чит-ят күперне мәрмәр белән бизәү, җитмәсә безнең мөмкинлекләр белән—сез мондый саташуларны тыңларга күнекмәгән, ә мин бу кәнәфидә күрсәтмәләрнең андыйларын гына алмадым. Бер нәрсәне аңламыйм, кайдан килеп чыктыгыз сез, ә? Райком секретарен малай-шалай шикелле өйрәтеп утыр, башыма сыймый! Сез бит төзелештә күптәннән эшлисез, безнең һөнәри сөйләшебезне дә беләсез. Сез: «Ярар, башкарырбыз» дигән классик фразаны, йә булмаса икенче төрлесен—монысы да классик—«Эшләнер!»ләрне белмисезмени?

Чәй эчәргә, кешене күнел салып тыңларга иде дә: «Эшләрбез!»—дип, чакырганы өчен рәхмәт әйтеп, чыгып китәргә иде. Аларның башларына килгән бар нәрсәне үти башласаң, үзеңнекен эшләргә вакытың да калмас. Үзбәкләрнең андый очракларда ничек әйткәннәрен ишеткәнегез бардыр, мөгаен: «Ул вакытка кадәр йә ишәк үләр, йә арба ватылыр»,—диләр алар. Күпергә килгәндә дә: бер елны МПС рөхсәт бирми дип, икенче елны проект институты эзлибез дип сузсак, аннары райкомнан финанславын сорасак, шулай итеп бу идея үзеннән-үзе төшеп калыр иде—бернинди проблемаларсыз. Ә анда карыйсың,—секретарьның үзен йә күтәреп куялар, йә алып ташлыйлар. Имеш-мимешләр йөри, монысын алырга җыеналар

бугай. Тик бит әлегә ул хужа һәм миннән моны артыгы белән чыгартырга мөмкин.

Аннан соң бу унсигез мең сумлык смета,—түрә лимон йотарга мәҗбүр ителгән кеше сыман чыраен сытты.—Сез нәрсә, айдан төштегез мәллә? Без инде ремонтка алты йөз өстәгәнгә куана алмыйбыз. Югыйсә, аның үзе өчен бит, кирәк була калса дип. Юк, директор әлегә кадәр безне яман сүзләр белән искә ала...

Мөгаен, сезгә, Гаяз Нуриевич, җинел түгелдер—сез ул мәктәпне үтмәгәнсез. Безгә дә сезнең белән кыен, төрле телләрдә сөйләшәбез. Йә безнеңчә яшәргә өйрәнегез, йә дусларча аерылышабыз, бер-беребезне инфарктка кадәр җиткермик. Һәм соңгысы: без сезнең сәләтегезне, инженер буларак тәҗрибәгезне, турысын әйтик, коллективка, бигрәк тә эшчеләргә йогынтыгызны исәпкә алмасак, әңгәмәне икенче төрле, кыскарак тоткан булыр идек. Шулай булгач, зинһар, уйлагыз...

...Бу сөйләшүгә кадәр үк, райкомнан кайтып килгәндә, Гаяз, чыннан да, үзенең тиешсез урынга эләккәнен аңлаган иде инде. Тарханов белән Коляша бригадаларыннан яки башкасыннан ясак җыю турында сүз дә булырга мөмкин түгел. Тик хәтта шушы йөкләмәдән котылдырган очракта да, чит фатир, бакча йортлары ремонтлап, яшерен рәвештә фин сауналары салып, аларны эшчеләрнең ял бүлмәсе ремонтланды дип күрсәтү, ниндидер югарыда утырган түрәнең хатыны алдында үрә катып тору—юк, бу аның өчен түгел иде. Эшкә ашмаган боерыкларны үтәү дә. Бу очракта күпер—тулып ташыган сабырлык касәсеннән соңгы тамчы булды. Түрә янында булган бу сөйләшү дә, Гаязның аңлавынча, соңгы кисәтү иде. Юк, ул янадан өйрәнергә теләмәде.

Иртә белән эштән китүе турында гариза илтте. Эшчеләр белән аерылышу кызганыч, алар белән Клара Васильевнаның фатирын ремонтлаганда нык дуслашкан иде. Саубуллашканда Федот Карпович әйтте:

—Әгәр яхшы эш була калса, чакырыгыз, килербез, уңайсыз хәлгә куймабыз...

Эшеннән киткәч, Гаяз югалып калды. Ул шундый кешеләр төркеменә керә: андыйлар төп эшләрен менә дигән итеп беләләр, эш барышында акыл, характер, ихтыяр көче—табигатьтән нәрсә бирелгән—барысын да күрсәтә алалар, әгәр шул чиктән тышка атласалар, тормыш-көнкүреш ыгы-зыгысы, хәл-вакыйгалар алмашынуы алдында югалып калалар. Андый кешеләрнең хезмәт кенәгәләрендә бүләкләү турындагы язулардан тыш, кагыйдә буларак, бер, күп дигәндә ике язма була. Гәрчә төзүчеләр күчмә халык булса да, элегрәк гомерем буе Зәркәнттә генә эшләрмен, дип уйлаган иде. Ләкин ул сәнәгате ягыннан үскән һәм тагын дистәләрчә еллар киңәячәк шәһәргә килеп эләкте,—Гаяз бу төбәкнең перспектив үсеше белән таныш иде. Кара һәм төсле металлургия, химия белән берлектә, лак һәм башка көнкүреш химиясеннән башлап авыл хуҗалыгы өчен киң ассортиментта минераль ашламаларга кадәр, дистәләгән тармаклар барлыкка китерделәр. Һәрбер шундый җитештерү тирәсендә төзисе дә төзисе, Исламовка пенсиягә киткәнче эш җитәрлек булыр иде.

Ул әле бер идарәгә, әле икенчесенә сугылды—берсендә дә буш урын табылмады. Мастер булырга тәкъдим иттеләр, тик аның яшендә һәм аның тәҗрибәсе белән яңабаштан вак-төяк йомышка йөрүне, кабат бик аз хезмәт хакында утыруны Гаяз үзен түбәнсетү дип санады. Бер РСУда янганнан соң, мондый конторларны читләтеп үтте, төзелеш идарәләрен әйләнде. Трестларга кереп тә тормады, чөнки канцелярия эшен белми һәм чиновник тормышы аны кызыктырмады да: ул төзүче иде, прораб. Кемнедер масштаблар, сәнәгать комплексларының зурлыклары, миллионлаган күләмнәр куркыта

салса, Исламов, киресенчә, гражданлык төзелешенә юлыккач, андагы вактөяктән, бертөрлелектән югалып калган иде. Кайбер идарәләрдә—анын уйлавынча, иң яхшылардан саналучылар, шикләнеп, хезмәт кенәгәсендәге соңгы язмага күз төшерүгә кире кактылар. РСУ прорабларының даннары яхшылардан түгел иде, күрәсең.

Гаяз илдәге күпләгән эре төзелешләр турында хәбәрдар, башына шуларның берсенә китәргәме әллә дигән уй бер генә кереп чыкмады, анда ул үзен үз урынында дип хис итәр, ирләргә лаеклы эш белән шөгыльләнер иде. Әлеге дә баягы көнкүреш ыгы-зыгылары, күченүләр, тулай тораклар—гомумән, шундый мәшәкатьләр алдында куркып калу аны туктата, җаны исә хезмәткә тартыла, һәм ул үзенең элеккеге тынгысыз эшен сагына иде. Аны фатиры да тотып кала: ул инде малай-шалай түгел, илленче дистәне ваклады, ә торакны төзүчеләргә дә тиз генә бирмиләр. РСУдан киткәнгә ай тулды. Гаяз һаман да эш эзләүдә—әмма уңышсыз, кадрлар бүлегендә дә тизрәк урнашырга вакыт, алайса стаж өзелә, ди башладылар. Гаяз тормышта шомарганрак кеше булса, андый искә төшерүләргә исе дә китмәс иде—стаж өзелә, имеш, нинди бөек трагедия, имеш, пенсиягә хәтле о-хо-хо күпме, туйганчы эшләр әле. Әмма мондый искәртүләр аны аяктан егалар, әрле-бирле чабарга мәҗбүр итәләр. Хәтта ул бер идарәдә участок җитәкчесе булып урнашмакчы булып гариза да язды, иң соңгы мизгелдә генә объектлар белән танышу, эшчеләр белән сөйләшү өчен бер көн сорады... Идарә Ташкент югары уку йортларының берсендә яна уку корпуслары өстәп салу белән шөгыльләнә иде. Объект халык телендәгечә «койрыклы төзелеш» булып чыкты. Сметасы белән танышып, корпусларын карап чыкканнан соң, Гаяз шуны аңлады: болар акчаны ике-өч елга алдан алып куйганнар, һәм шуның кадәрле күләмдә ки—РСУдагы урлаулар моның янында бала-чага уены кебек кенә. Кем өчендер башны элмәккә тыгу—юләрлек булыр иде, җитмәсә, әлегә кадәр төзегәннәре дә капиталь төзекләндерү сорап тора.

Кәефе кырылган Гаяз гаризасын кире алды, һәм, такси чакыртып, өенә кайтып китте. Юл кыска түгел, сүз иярә сүз чыгып, таксист белән сөйләшеп киттеләр. Гаяз шоферның күкрәгендәге югары уку йорты значогын күреп бик гаҗәпләнде: аның буенча фикер йөртсәң, таксист йөртергә түгел, ә очарга тиешле кеше иде. Машина йөртүче аның соравына җавап бирде: дөрестән дә, авиация институтын тәмамлаган, тик факультеты очучылар әзерләми, ул очкычлар төзүче булып чыккан һәм авиация заводының бер эре цехында смена җитәкче булып урнашкан. Бер-ике сүз белән үзенең тарихын әйтеп бирде: шимбә, ял күрмәгән, әйбәтрәк эшченеке хәтле хезмәт хакы да эләкмәгән, әле җитмәсә, өенә сәгать уннан да иртә кайтып булмаган. Өйдә исә ике бала, үзең уйлап кара, ул аларны хәтта күрә дә алмаган. Эшкә киткәндә алар әле тормаган була, кайтканда—инде йоклыйлар. Гомумән, ул заводта эшләгән сигез елда гаиләдә көн дә ызгыш, көн дә талаш, эш аерылышуга барып җитә—йә хатыны һәм балалары, йә ыгы-зыгылы эше. Шул ук заводта йә слесарь, йә токарь булып урнашмакчы була, тик рөхсәт бирмиләр—эштән китәргә туры килә.

—Үкенмисеңме?—дип сорады Гаяз, кызыксынып.

—Нәрсәгә үкенергә,—диде такси йөртүче,—таксопаркта өчтән бере минем кебекләр, безне дипломлы колонна дип йөртәләр. Акча күпкә артык чыга. Сәгатьләп өйдә булам, хатын базар, авыр букчалар турында тәмам онытты, кайтышлый үзем кереп алам. Шәһәр күрәм, кешеләр белән танышам, дарусыз йоклый башладым. Артык эшләдең—күбрәк аласың. Сменаңны тапшырдыңмы—эшең бетте, бернәрсә турында кайгырасы, уйлыйсы юк. Заводтагыга караганда чистарак, әйбәтрәк киенәм. Нәрсәсен кызганырга?

Сигез елымны җилгә очырдым, хет күңел өчен булса да, киткәндә бер җылы сүз әйтүче табылмады.

Гаяз да үз проблемалары турында кузгатты, бигрәк тә ике көннән эшкә урнашу өчен бирелгән бер айлык срокның бетүе хакында борчылуын әйтте.

—Әгәр яна икән, кил безгә, аннан күз күрер, җаныңа яткан эшне көпчәкләр өстендә эзләү җиңелрәк булыр. Бәлкем, бездәге эш тә ошап куяр, дипломлы син генә түгел, бездә хәйран алар, ә күбесе—синең коллегаларың,—диде сүзгә һәвәс таксист, Исламовны тыңлап бетергәч.

Шулай итеп Гаяз Ташкенттагы таксопаркларның берсенә килеп юлыкты.

Югары белем алган кешене станок, руль, буфеттагы баганалар артында күрү хәзер, кызганыч, яңалык түгел, ул гадәти хәлгә әйләнеп бара. Менә мисал өчен, гәҗитләрдә шатланып, тәэсирле итеп фән кандидатлары һәм докторларыннан торган төзүчеләр бригадалары, янәсе, үзләренең ял вакытларында сыерлар йә бозаулар торагы салып бирергә килешү төзеделәр, дип язалар. Теләсә нәрсә дисеннәр, яхшы тормыштан түгел ул, сыерлар өчен торакны шулай да чын төзүчеләр салырга тиеш, ә дилетантлар түгел, өч-дүрт-биш атналык елларда гына андый торакларны төзеп тә булмый. Шуңа күрә югары белемлеләрдән төзелгән эшче коллективлар—яңа күренеш. Күпләр бу турыда белмидер: әмма алар бар, алар көн күрәләр.

Сергей Александрович—очкычлар төзүче инженерны шулай атыйлар—Гаязны, вәгъдә иткәнчә, колоннага алып керде. Яңа килүчеләргә ярдәм итү традициясе күптән кертелгән, аңа беренчеләрдән булып аяк баскан, соныннан профессиональ шофер булып киткән дипломлы белгечләр нигез салган булган. Колонна белән җитәкчелек итүче дә һөнәре буенча—юрист, ул да кайчандыр биш ел такси йөртүче булып эшләгән. Колоннаны махсус берәү дә дипломлы белгечләрдән туплап йөрмәгән, үзеннән-үзе шулай килеп чыккан: елдан-ел монда белемле кешеләр һәм читтән торып, йә кичке бүлекләрдә укучы яшьләр агылган. Таксилар паркында колонна алдынгылардан санала, планны һәрчак үтәп бара, гадәттән тыш хәлләргә юлыкканы юк, барлык күчмә бүләк һәм байракларны яулап ала, шуңадырмы, җитәкчелек аның оешуына бармак аша карый. Белемлелек цензы бу очракта эшкә киртә була алмый. Гаязга исә уңыш елмайды: эшкә чыкканның беренче көнендә үк колонна җир асты стажы булган элеккеге тау инженерын, илле бише тулып, лаеклы ялга озатты. Ул машинасының ачкычларын Гаязга тапшырды. Шулай итеп, аның яңа тормышы башланып китте.

Машинаны ул кече яшьтәк үк йөртергә өйрәнде, рәтләгәндә әтисенә һәрвакыт булыша торган иде, менә әти дәресләренең кирәге дә чыкты. Баштарак юлчылардан ояла, каушый иде, ләкин яңа дуслары: «Борчылма, күнегерсең,—дип ышандырдылар,—таксист эшендә иң мөһиме—сабырлык, тотнаклылык»,—диделәр.

Смена артыннан смена, көн артыннан көн—хәтта вакыт та тизрәк, ашыгыбрак йөгерә башлады сыман—хәзер аның тормышында барысы да тизлеккә корылган иде. Калейдоскоптагы кебек күз алдыннан табигать күренешләре, яңа төзелешләр, шәһәр кырыйлары шуышып үттеләр—таксист эше тәэсирләргә бай, хәтеренә элеп кенә өлгер. Гаяз эш барышында үзенең яңа коллективын күзәтте һәм аны хуплаганнарын сизде. Колоннадагы шоферлар арасында бик картлар һәм бик яшьләр юк, күбесе аның кормалы, һәрберсе алдагы эшендә күпне күргәнгә охшый. Бәлки шуңадыр, колоннада бер-берсенә бик сак карыйлар, хәтта яшьрәкләргә дә исеме һәм әтисенең исеме белән мөрәҗәгать итәләр. Шоферларның кайсыберләре элеккеге

эшләре белән дә араларын өзеп бетермәгәннәр. Гаяз ишетеп калды, парк житәкчеләреннән кайберләре андыйларга бензинга, запас частьларга, резинага үз фондларын юллап алуда ярдәм итү үтенече белән мөрәҗәгать итәләр, йә булмаса, автобазаны кышка ремонтлау өчен кирәкле төзелеш материаллары табуны сорыйлар. Колоннаның ремонт мастерскойлары да башкаларыннан аерылып тора. Шул ук Сергей Александрович—очкычлар ясаучы—тикмәгә генә сигез ел буе заводта конструктор, технолог һәм смена житәкчесе булып тир түкмәгән, шундый ярым-автомат җайланмалар уйлап тапкан, диагностик җиһазлар конструкциясен төзегән,—барлык төзек булмаган әйберләр санаулы минутта ремонтчыларга уч төбендә шикелле мәгълүм була! Ә үзара ярдәмләшү турында әйтәсе дә юк, мөгаен, шуңаргадыр, шоферлар бу колоннага килергә атлыгып торалар, тик монда теләсә кемне алмыйлар. Берничә ай эшләү дәверендә, Гаяз колонна яки парк житәкчесенең кемгәдер тавыш күтәргәннәрен ишетмәде, теләсә кайсы җитештерү коллективына хас булган әрләш-тиргәшләрне, ызгыш-талашларны күрмәде. Бервакыт бу турыда ул Сергей Александровичтан сорады. Тегесе—Гаяз уйлавынча—күптәннән чыгарылган һәм кат-кат кабатланган җөмләләр белән җавап бирде:

—Без монда килгәнгә кадәр туйганчы, бугаздан булганчы күрдек инде ул хәлләрне. Монда тыныч кына эшләргә телибез. Әгәр дә колоннада берәр кушбугаз килеп чыкса, беренче очракка кисәтәләр яки икенче колоннага күчерәләр. Коллективның законнары кырыс, әмма гадел: күпчелекнең теләк-ихтыяжлары саклана, һәм берниндн администрация андыйны яклау ягына басмый. Житәкчелек хакында... Колоннаны кичәге такси йөртүчеләр житәкли, шулай булгач нәрсәгә аларга бугаз киерергә? Без үзебез дә аңлы халык, эшебезне беләбез. Ә кемдер борын күтәрә башласа, тудырылган шартларны боза калса, андыйларны ул урыннарда озак тотмыйлар, аны алмаштырырлык кешеләр колоннада җитәрлек. Бу коллективның чынбарлыктагы көчен күрсәтә торган очрак була инде.—Һәм көлә төшеп, сүзен тәмамлады:—Кара, бер ун елданмы, син дә колонна житәкчесе булырсың.

Әгәр Гаяз үзен бирегә очраклы рәвештә һәм вакытлыча килеп эләктем дип санамаса, бар да яхшы булыр иде. Ул кайберәүләрнең бер-ике ел эшләгәннән соң кабат элекке урыннарына әйләнеп кайтулары турында белә иде, тик алар азчылык, күпчелек елга, дистәләгән елларга, лаеклы ялга кадәрле тоткарланып кала. «Ун елдан соң мин нинди төзүче булыйм инде,—дип уйлады ул.—Теге фән кандидатлары кебек сыер тораклары төзеп йөрсәм генә...»

Бервакыт ул хәзерге хезмәттәшләренең кайсысы нинди белгечлеккә ия булуы хакында ай буе исемлек төзеп маташты. Исемлек бик зур һәм чуар булып чыкты, һәм нәрсәсе гаҗәпкә калдырды: исемлектә бер генә табиб та, фармацевт та юк иде. Бу һөнәр ияләре Гаязның күз алдында үсте: кемнәр-кемнәр—алар ни зур хезмәт хакы, ни ансат кына белем алу белән мактана алмыйлар, эшләре турында әйтеп тә торасы юк. «Менә,—дип фикер йөртте Гаяз,—статистик идарәгә нәрсә белән шөгыльләнергә кирәк: кайсы югары уку йортларыннан чыккан белгечләр үз һөнәрләре буенча эшләмиләр, шунда ук кайсы белгечлекләрне үрчетмәскә кирәклеге, кайсы югары уку йорты эшләп бетерми, кайсысын бөтенләй ябарга—бар да ачыкланачак».

Үзенең хәзерге хәлен аңларга һәм бәяләргә теләп, Исламов хезмәттәшләренә игътибар беләнрәк карангалый башлады, бигрәк тә техник белемлеләре кызыксындырды,—аларны ул күбрәк төшенә һәм элекке эшләрен дә ачык итеп күз алдына китерә. Гаҗәпләндергәне шул булды: өч-дүрте генә Гаязга уртача, инициативасыз күренделәр, хәер, андыйлар теләсә кайсы мохиттә

дә, яшәештә дә нәкъ шундый ук булалар,—калганнары исә башкалардан аерылып тора иде. Үзен борчыган сорауларын хәзер бер парда эшли башлаган Сергей Александрович белән уртаклашты.

—Аптырарлык түгел,—Гаяздан яшьрәк булса да, аны беренче көннән үк үз канаты астына сыендырган элекке конструктор аңлатырга керешге,—урталар алар беркайдан һәм беркая качмыйлар, бигрәк тә безгә, үзең күрәсең, бездә шәп «сөрергә» кирәк. Урталарның ни проблемасы, ни сайлау мөмкинчелеге булмый, чөнки аларның белемнәре юк, белем булмадымы—нигез юк, инженер юк. Урыннарыннан көчләләр, югалып калмасына, үз ипиен һәрвакыт һәм һәркайда эшләп табарына ышанычы булганнар кузгала. Шулай итеп, кадерле Гаяз, син хаталанмагансың, монда күпчелекне катлаулы, инициативалы, юньле кешеләр тәшкил итә, кайсылары артыннан элеккеге эшләренә чакырып киләләр, ялыналар, кире кайтканнары да булгалый...

Бервакыт иртән Гаяз, пассажирлар булмау сәбәпле, Чиланзар буйлап әйләнергә уйлады. Кинәт аның машинасы каршына бер кыз ташланды.

—Зинһар өчен, «Хорәзм» ресторанына илтегезче, соңга калам. Бездәге иртәнге ашта бик мөһим чит ил делегациясе катнаша. Мөмкин булса, кызурак барыгызчы, мин яхшы түләрмен,—дип, кыз,ашыга-ашыга, янәшәсенә кереп утырды.

Машина кузгалып китүгә, юлчы тынычланды һәм, сумкасыннан көзге чыгарып, үзен игътибар белән «өйрәнә» башлады. Үзендә Гаязның карашын тойды һәм, чытлыкланып:

—Йә, ничек?—дип сорап куйды.

Гаяз аның кәефенә яраклашып җавап бирде:

—Тулы тәртип!—тагын да ышанычлырак булсын дигәндәй, баш бармагын күрсәтте.

—Рәхмәт!—Кыз, көлә-көлә, Гаязга төбәбрәк карады.

Ресторан янына барып туктагач, кыз аңа биш сум тоттырды да машинадан чыкты.

—Бер генә минут көтегезче,—диде каушап калган Гаяз,—мин сезгә калганын кайтарам.

—Анысы икенче вакытта. Сез мине коткардыгыз, рәхмәт. Ә инде бик тә кайтарасыгыз килсә... Мин монда метрдотель булып эшлим, исемем—Даша. Әгәр ул уегыз минем сменам ахырында кабатланса, тагын да шәбрәк булыр иде—берочтан өйгә дә кайтарып куярсыз.

Шоферның аңа сокланып каравын сизенеп, елмайды һәм күптәнге дусты сыман күреп, кулын болгады да сумкасын игътибарсыз гына селки-селки китеп барды. «Хорәзм» шәһәр үзәгенә—аҗаган кайнаган урында урнашкан, Гаяз аның янынннан узганда, берничә мәртәбә Дашаны исенә алды. Ул кыз кайсы ягы беләндер үзенә җәлеп итте.

Ике атналап үтте микән, көндәлек планы үтәлгәч, Гаяз өенә кайтып кырынды, чиста күлмәген киде дә, ресторан ябылыр алдыннан, «Хорәзм»гә килеп туктады.

Ресторан шәһәрдә һәркемгә билгеле. Анда ансат кына эләгеп булмасын Гаяз чамалый иде. Тик югалып калмады, ишек сакчысына: «Мин Дашаны алырга килдем»,—дип пышылдавына, аның алдында киң һәм кунакчыл ишекләр төбенә кадәр ачылды. Даша аны шунда ук күреп алды да, янына килеп:

—Исәнмесез! Сез нигә бик озак күренмәдегез? Мин инде таксопаркка шылтыратып, калган акча белән бергә такси йөртүчесен дә кайтарыгыз, димәкче идем. Ташкентта миңа унбер парк бар, диделәр, кызганыч, сезнең кайсысыннан икәнлегегез хәтердән чыккан. Аннан соң кинәт башыма сукты:

йә икенчене жибәрерләр дип курыктым, миңа башкасы кирәкми,—дип көлде дә култыклап алды.—Бездә кичке ашка калырсыз дип ышанам.

—Бик рәхәтләнеп.

Даша аны оркестрдан ерак түгел кечерәк кенә өстәл янына утыртты. Биш минут чамасы югалып торды, аннары официантны ияртеп килде. Анысы ризык тулы подносны эш өстәленә куйды да китеп барды, Даша өстәлне үзе тезде.

—Сезнең белән бик рәхәтләнеп бер компаниядә утырыр идем дә, үзегез аңлыйсыз—хезмәтне башкарасы бар. Ашыгыз тәмле булсын,—дип, берүзен калдырды.

Беренче мәртәбә кунакка чакыргач, аның өендәге китапларның күплегенә Дашаның исе китте, тагын да битәррәк пластинкаларга—тоташтан классик—хәйран калды.

—Сез сәер таксист икәнсез,—дигән иде ул, шаяртып, ләкин танышканда була торган гамьсезлек белән берни турында да сорашмады.

Даша белән мавыгу эш турындагы уйларын вакытлыча читкә этәрде. Кызның һәр сменасында диярлек ул аның эшенә керә, кайчакларда Даша үзенекен итә:

—Синең саулыгыңны кайгырту—минем бурычым,—дигәч, «Хорәзм»дә тәгам жыеп чыга.

Даша Гаяздан ун елга яшьрәк, энергиясе ташып тора, шат күңелле, шулай да тормыш—тоташ бәйрәм түгел, дип саный, тик булдыра алган кадәрле аны бизәргә тырыша иде. Хатын-кызларга хас сизгерлек белән ул Исламовның тормышында аны чыгырыннан чыгарган житди—фажига ук түгел микән әле?—нәрсәдер булганын тоемлый, шуңа күрә булдыра алган кадәр кайгыртырга тырыша. Кайдадыр укыганымы, әллә ишеткәнеме бар: «Хатын-кызларга көчле ир-атларның йомшак мизгелләре ошый». Бу аның хәзерге халәтенә туры килә дип санады. Гаяз аңа берни турында сөйләмәде һәм аннан сорашмавын үтенсә дә, кыз аның белән, һичшиксез, ниндидер мәхәббәт тарихы булгандыр дип ышана... Залдагы үтә чибәр кызның сәер портреты, Гайдн, Вивальди, китаплар... Юк, Гаяз аңа ошый иде...

Ярты еллап узгач, ничектер, Даша аның гардеробына тикшерү үткәрде, бу вакытта инде аның кулында фатир ачкычы бар, ул бу өйдә булырга ярата, аны хатын-кызларча тәртипле тотарга тырыша иде.

Үзе киенергә яратты, дефицитка үтеп керү юлы да бар: «Хорәзм»дә сәүдә базасы хезмәткәрләре еш була, үзәк кибетләрдә дә ул үз өендәгедәй иркенләп йөрде, чөнки аларда институтның сәүдә факультетын бергә тәмамлаган дус кызлары сату итә. Аның уйлавынча, Гаязга да заманчарак киенү комачауламас иде—киемнәре аз, алары да сайлап-нитеп тормый гына алынган, күрәсең, хужаларының уе кием-салымда булмаган. Тик элеккеге әйберләре арасында кайчандыр бик модалы саналган күлмәкләр, пиджаклар да очрый—боларында инде хатын-кыз кулы сизелә. Һәм Даша моны шунда ук башкалардан аерылып торган зәвыгы булган икенче берәү белән китереп бәйләде. Кинәт Дашаны шундый көнчелек биләп алды, аңарда Гаязны шаккатыру һәм сөендерү теләге уянды.

Исламовның язу өстәлендә акчалар ятканын белә иде Даша, аларны алды да базага китте. Озаклап аңлатып тормас өчен, база директорына үзенең кияүгә чыгарга жыенуын һәм кияven модалырак киендерергә теләвен белдерде...

Кичен шатлыгыннан канатланган кыз барысын да Гаязга кидереп карады, таман икәнлеген, Исламовка ошаганын күреп бер куанса, таксистның күз алдында үзгәреп калуын сизеп, кабат сөенде. Ә Гаяз уйлап-нитеп тормый гына: «Йә, нәрсәгә инде сиңа бу мәшәкатьләр?»—дигәч, Даша чүт елап

җибәрмәде, күзенә яшь тулды, һәм ул аны кочаклап, пышылдады:

—Гаяз, сөеклем, мин синең ин-ин, яхшыларның яхшысы булуыңны телим. Белсәң икән, хатын-кызга сөйгәне өчен нәрсәдер эшләүнең нинди зур ләззәт икәнен: аның өен җыештыру, күлмәкләрен юу, йә менә бүгенге кебек көтелмәгән бүләк ясау. Син канәгать бит? Ләкин мина калса, ир-ат акылының моны аңларга көче җитми,—диде һәм көлеп җибәрде.

Шушы көннән башлап, Даша аның һәрчак тиешле дәрәҗәдә киенеп йөрүен күзәтү астына алды... Менә ни өчен Күлледә вакытта Халияр белән Фәридәне аның киемнәре шулхәтле хәйран калдырган икән, алар әле аны «фирмач» дип тә кабул итәргә маташканнар иде.

Кыш ахырларында, Күллегә кайтырга өч айлап калгач, Гаяз таксистларның Чиланзардагы чәйханәсенә төшке ашка тукталды. Календарьда февраль ае торса да, көн матур, яз аендагыча җылы, кояшлы. Урамда шашлык кыздыралар, ангрен күмере белән куелган өч чиләк сыешлы самавырлар кайнап утыра. Таксистлар тыштагы үз-үзенә хезмәт күрсәтә торган өстәлләр артына урнаштылар, алданрак өлгергәннәр айванда утыралар. Кемнең планы тәртиптә, андыйларга чәйханәдә гадәттәгедән озаккарак тоткарлану мөмкинлеге туа. Монда һәр көнне билгеләүләр, хезмәт буенча күчерүләр турында яңалыклар ишетәсең. Гаязның эшләре ул көнне ах! итәрлек булмаганга, өстәвенә, үз колонна егетләре дә күренмәгәнгә, ул озак тоткарланмаска булды һәм айванда шашлык көтеп утырган шактый зур компаниягә барып сыенды. Аларның әңгәмәсендә таныш фамилияләр ишетеп, игътибарын арттырды. Гәп ул киткән берләшмәнең директоры хакында бара иде. Егетләр, кызып-кызып, директорның үз фатирына ун меңгә төшереп ремонт ясатуы, кассага бары тик мең тәңкә генә кертүе турында сөйлиләр иде, әңгәмәдән аңлашылганча, РСУның ул җитәкләгән берләшмәсендә бик зур күләмдә өстәп язулар, материаллар урлау фактлары ачылган, эшчеләр халык контроленә ай саен ришвәтләр җыеп алулары турында әйтеп биргәннәр. Шунда районда башка әһәмиятлерәк эшләр калмаган кебек, мәрмәрдән күпер салдырырга теләгән райком секретаренең да—дөрес, хәзер инде элеккеге—исеме дә калкып чыккан.

Гаяз бу яңалыкның җиле ана кагылып үтсә дә, үзен әз генә дә борчымавын сизде, әйтерсең, бу хәлләр аның белән, аның тормышында булган кебек тә тоелмады. Исламовның әлеге ачышы йөрәген кадап үтте: ул күптәннән инде чит-ят тормыш белән яши икән бит!

Ят тормыш... Шуңадыр, мөгаен, күңелендә тынычлык юк. Тыштан караганда тыныч, имин тормышы да, үзенең назлы, ягымлы, игътибарлы Дашасы да, бу уе башына кереп урнашкач, сөендерми башлады. Шушы уйларына уралып, ул ялга китте, анда, Күллесендә дә, үз-үзенә урын тапмады, һаман бер сорау йөдәтте: алга таба ничек яшәргә?

Ялга китәр алдыннан ул Ташкенттан ерак түгел сәнәгать шәһәре саналган Чирчикка барып чыккан иде. Командировкага килгән пассажирын кунакханә каршында төшереп калдыргач, буш көенчә кайту юлына борылды. Аның алдыннан да, артыннан да болай да тар юлны тутырып, панельләр ташучы көчле трейлерлар, озын-озын арматуралар төялгән тагылмалы «КамАЗ»лар, измә ташыган машиналар агыла, якында гына зур төзелеш барлыгы сизелә иде. Гаяз ирексездән бу бер-бер артлы тезелешкән машиналар төркеме артыннан каеруын сизми дә калды, шулай итеп тапшыруга хәзерләнгән зур «Капролактам» комбинаты төзелеш мәйданчыгына килеп керде. Билгеле, Гаязның бу төзелеш турында ишеткәне бар иде. Күзгә бәрелеп һәм башкаларга комачауламасын дип, машинасын читкәрәк туктатты да җәяүләп китте.

Төзелештә эшләтә башлау чоры иң киеренке вакыт саналса да, иң

мавыктыргычы да: тәмамлау алды, үз кулларың белән тудырган «бала»нны тулы матурлыгы белән күрү теләге кешеләргә өстәмә көч бирә. Гаяз моны хәтерли. Ул бер корпустан икенчесенә күчә, колагына җөмләләрнен өзек-төтеге эләгеп кала, һәм болар барысы да ана тансык. Исламов, консерваториянең класс бүлмәләре янычнан узып баручы музыкант кебек, хәтта ябык ишекләр аша да кайда һәм нинди җайланманың ялгышлык җибәрүен тоемлый, кайсы бүлмәдән чын көй агыла—шунда, үзе дә искәрмәстән, адымнарын акрынайта.

Җиһазларны технологик монтажлау барган корпусларнын берсе янында, монтажчылар яшь кенә прораб белән нәрсә турындадыр бәхәсләшәләр иде. Шактый ук таушалган зур табаклы сызымны, бер-берсенен кулыннан өзеп алырдай булып, тартышалар.

Гаяз үзен тотып кала алмады:

—Бәхәс нәрсә хакында?—дип сорау бирде.

Һәр ике як, күрәсен, аны берәр түрә дип уйладылар, бертавыштан үзенекен расларга тотынды. Гаяз сызымга күз ташлады, әзрәк фикерен туплап торды да әйтеп салды:

—Һәр икегез дә өлешчә дөрес, ләкин бәла менә нәрсәдә: сызымнын бу күчермәсендә, минем карашымча, нәкъ шушы урында монтажлау уемын күрсәтми калдырганнар. Ашыгыч рәвештә техбүлеккә шалтыратыгыз, төп нөсхәләрне күтәрсеннәр, тик бу ике кисемне төгәл житкерегез. Кызганыч, мондый хәлләр дә булгалый, сызымчы кызларнын карандаш белән сызылган ике ялгыш сызыгы тимер-бетон брагына әйләнә. Монтажчылар, рәхмәт тә әйтеп тормыйча, прораб вагончыгына йөгерделәр, анда телефон бар иде, ахрысы. Егерме минутлардан Гаяз кире әйләнеп килгәндә, яшь прораб анын каршына атылды.

—Рәхмәт сезгә. Бар да нәкъ шулай: сызымчы кызлар уемны төшереп калдырганнар, миңа хәзер кат ара түшәмне чокып тишәргә кирәк, көн югалды дигән сүз. Сез проект яклаучымы әллә? Шунда ук чамаладык.

—Юк. Мин сезнен коллегагыз—прораб. Борчылмагыз, бер комбинатны тапшырырсыз, икенчене,—тәжрибә тупларсыз, ышанычыгыз артыр, аннары инде проектлардагы хаталарны табарга өйрәнерсез. Ә проект институтынын бу брагы буенча дәгъва кәгазегезне төзегез. Һәркем үз эше өчен җавап бирергә тиеш...

Күлледәге кебек, поездда барганда да, Гаяз Ташкентта үткәргән елларын башыннан ахырына кадәр кабат уе аша үткәрде; никадәр генә тырышса да, әллә ни уныш хәтеренә килмәде—бары уйланулар өчен сәбәпләр генә туа торды. «Кечкенә станциядә утырып калды»... Гаязнын бүгенге тормышына бик туры килеп тора торган бу җөмләне кайдадыр ишеткәне бар иде.

Иртән ул таксопаркка шалтыратты—бүген ана төнгә чыгасы икән. Бу хәбәр Гаязны бик куандырды, чөнки ул төнге сменаларны бик ярата: яшеллеккә төренгән Ташкент төнге утлар яктысында кабатланмас матурлыкка чума. Әгәр ул рәссам булса, һичшиксез, төнге Ташкентны сурәтләми калмас иде: эсселек, анын карашынча, форма һәм төсне ала. Кызганыч, полотнода йокымсыраган яфракларнын сак кына лепердәшүләрен, төнлә арыкларнын шаулавын биреп булмый. Бәлки, шунадыр, борынгы шәрык шагыйрьләре бик еш төн юлдашы—айны яки бакчалардагы төн карасын сурәтләп биргәннәрдер?

Паркта Сергей Александрович юк иде инде, аз гына иртәрәк кергәндер, күрәсен, колоннадагы башка иптәшләре икенче сменаларда эшлиләр, ялдан килгәч була торган шау-шулы каршы алулар барып чыкмады. Андый каршылауга Гаяз әзер дә түгел, уйлары белән һаман да анда—ата йортында, Күлледә иде әле.

Өченче сменага чыгуы бик урынлы булды. Яңа иптәшләре алдында ул үзен нигәдер гаепле итеп тойды. Алар бит аны үзләренеке санадылар, тормыш юлы буйлап әле бергә-бергә бик озак барасы дип ышандылар. Бу юл җиңелләрдән булмаса да, күңеле икеләнде: аның юлымы соң ул? Ятлар арасында үз кеше? Үзенекеләр арасында ят? Бар, тикшереп кара, аның гаебе нәрсәдә, ул аны үзе дә аңлый алмый бит.

Районның таксопарк урнашкан саран гына яктыртылган караңгы урамнары буш, анда-санда яктылык төшкән тәрәзәләрдә шәүләләр күзгә чалынып кала, шәһәргә төн һәм тынлык хуҗа иде.

Кисәк кенә Гаязның Дашаны күрәсе, йә булмаса тавышын булса да ишетәсе килде һәм ул беренче очраган телефон будкасы янында туктады. Автомат эшләми иде, икенчесе дә ватык, һәм өченчесе дә... Озак уйлап тормастан, машинасын Чиланзарга борды.

Килеп җиткәнче, әле ерактан ук Исламов аның фатиры тәрәзәләрендә яктылык күреп алды, йокыга талган шундый зур йортта берләнбер ут гүя аны көтә иде. Шул уй куандырып җибәрде, һәм ул дүртенче катка очып диярлек менде.

Кыңгырау шалтырауга, тынып калган йортның баскычлары буйлап атлаган аяк тавышларын санап, көтеп торганнар диярсең, ишек шунда ук ачылып та китте.

—Син?—Даша гаҗәпләнде. Вакытның соң булуына карамастан, ул киенгән-ясанган, бик матур прическадан.

Гаяз нишләргә, нәрсә әйтергә белмичә каушап калды һәм уйлап-нитеп тормый, гадәттәгечә фатирга үтәргә теләде, тик Даша аның юлын кисте.

—Гаяз, гафу ит, ярамый! Мин кияүгә чыгам. Менә-менә, киявем килеп җитәргә тиеш. Мин ул шалтырата дип уйлаган идем. Гафу ит, Гаяз, шулай килеп чыкты, ләкин синең бит миңа тәкъдим ясаганың булмады, хәтта читләтеп тә әйтмәдең. Ә ул—хәрби, тәвәккәл, кыю, миңа шунда ук кулын һәм йөрәген тәкъдим итте. Хатын-кыз бик күп төрле кызыктыргыч нәрсәләргә каршы тора ала, тик кияүгә чыгарга ясалган тәкъдим алдында... Синең белән, мөгаен, миңа җиңел булмас иде. Син һаман тормышта нәрсәнедер аңларга, төшенергә тырышасың. Нәрсәгә? Гади генә яшә, гомер бик кыска бит...

Гаязның күзләре Дашага төбәлгән булса да, аның ашыга-ашыга тезгән сүзләре башына барып житми иде. Баскычтан төшеп, урамга чыкканнан соң, биш минутлап, катып калган хәлдә, машинасында утырып торды, бары подъезд төбендә тукталган таксига сораулы караш белән текәлгән озын, төз хәрбинең гайрәтле адымнары аны чынбарлыкка кайтарды. Кинәт үзенең яшь чакларындагы бер җырдан шаян юллар исенә төште:

> Әгәр башкага китсә кәләшең,
> Кем откандыр, анысы билгесез.

Йоклап яткан кварталны уятмаска тырышып, ул әкрен генә юлга чыкты. Борылышта ялгыз юлчы шәйләнсә дә, Гаяз тукталып тормады. Теге вакытта Гаграда, «Алтын тире»дәге шикелле, Ташкентта шушы еллар буе аны нәрсә интектергәне ап-ачык башына барып җитте. Әлеге эше нинди генә җайлы, яхшы түләүле булмасын, ул чын, зур эш белән шөгыльләнергә тиеш. Аның эше, урыны анда—зур төзелештә. Бары шунда гына ул фамилиясен, әтисенеке Күлледә яңгыраган шикелле, ишеттерә алачак.

Ниһаять, төшенде: моның өчен эшен яратучы, гадел кеше булу өстенә көрәшүче дә булырга кирәк икән. Гаделлек ул йодрык белән бергә булырга тиеш, башкача Силкиннарны, ул хурлыклы рәвештә китеп барган ремонт

конторларын, аның кебек хыялга чумып, кесәләрендә диплом йөртүчеләрдән тупланган таксопаркларны тузгытып, таратып буламы? Бары тик эш, көрәш белән таләпчәнлек күрсәтергә һәм нәтиҗәләргә ирешергә. Хәл ителде—аны төзелеш чакыра... Ә башкала, зур шәһәр?..

Синең җанына ята торган эш кайда—синең шәһәрең шунда! Барысы да ничек гади, аңлаешлы, тик шуңа төшенү өчен әтиеңә, туган йортына озын юл үтәргә кирәк булган икән.

Гаҗәеп серле төн, бәйрәм төне кебек, дөньяларын онытып йөрүчеләр, соңга калучылар күп—әмма яшел утын сүндерергә оныткан Гаяз аларнын яныннан выжылдап үтеп китте дә машинасын куарга тотынды, әйтерсең, шулай итеп Ташкент белән мәңгегә хушлаша. Инде ничәнче мәртәбәләр аның кабинасында диспетчерның тавышы яңгырады:

—Унҗиденче, унҗиденче, җавап бирегез, сез кайда?

Тик Гаяз дәшмәде.

Шәһәрне гизгәннән соң, Исламов Анхор ярларына таба каерды һәм, ишекләрен төбенә кадәр ачып, бетон ярларга килеп сыенган елга белән хозурланды. Кинәт, тынлыкны бозып, диспетчерның бөтен яр буен яңгыраткан тавышы ишетелде:

—Радиолаштырылган барлык таксилар игътибарына: 75-04 номерлы ТНС машинасы төн буе җавап бирми, йөртүчесе—Гаяз Исламов. Машинанын кайда икәнлеген белүчеләрнең ашыгыч рәвештә дүртенче таксопаркнын диспетчерына хәбәр итүегезне сорыйм... Игътибар, игътибар, машина югалды...

Үз уйларына күмелгән Гаяз башта сүз үзе турында барганлыкка төшенә алмады. Сорауны өченче тапкыр кабатлаганда гына, ашыгып трубканы күтәрде.

—Таня, бу—унҗиденче, Исламов. Рәхмәт, минем белән бар да тәртиптә, паркка кайтам.

Аны ниндидер җылы дулкын чорнап алды: аның турында уйлыйлар, борчылалар. Ул, машинасы белән борылып, олы юлга чыгуга, яшел дулкынга эләкте. Таксопаркка килеп кергәндә, эфирда янадан диспетчернын тавышы таралды, тик бу юлы шөбһәле түгел иде инде:

—Игътибар, игътибар, барчагызга да! Машина табылды... Исламов белән бар да тәртиптә! Бар да тәртиптә...

**Рөстәм ГАЛИУЛЛИН**

*тәрҗемәсе*



Гарифҗан
Мөхәммәтшин

# БЕЗНЕҢ ГОМЕР

## Хәтер барлау

**Шундый чаклар була—**
**Кайвакытта**
**Үз-үземне хәтта танымыйм,**
**Ә югыйсә Урбар авылының**
**Шул ук моңсу Гарифҗаны мин.**
**Шул ук җырчы Мещан урманының**
**Мең ялалы ап-ак каены,**
**Мең кармакка капмый уйнаклаган**
**Урбар елгасының җаене.**
**Миндә дә нәкъ меңнәрдәге гамьнәр,**
**Меңнәрдәге ачы хәсрәт,**
**Куанычым гына әзрәктер,**
**Шатлыкларым гына әзрәк..**
**Күзге кырау кунган кылганнар күк**
**Сирәк чәчем генә аграк,**
**Инде тоттым дигән хыял гына**
**Ераграк кешни,**
**Арырак.**
**Ә югыйсә шул ук Гарифҗан мин,**
**Шул ук исәр,**
**Шул ук хыялый,**
**Унсигездәге күк йөрәгемә**
**Ел да сандугачлар оялый.**
**Оялый да, таңда җырлар өчен**
**Җыр язарга куша,**
**Җыр сорый,**
**Язлар җитсә күңелем**
**Бер ашкыну белән**
**Тәүге чәчәк көтеп җирсүли.**

---

Гарифҗан МӨХӘММӘТШИН (1941)—*шагыйрь, публицист; «Килегез, дусларым», «Бәхет», «Робагыйлар бакчасы» һ.б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. «Татнефть» һәм Татарстан Язучылар берлегенең С.Сөләйманова исемендәге әдәби премия лауреаты. Балтачта яши.*

Унсигездәге кук сөя белә,
Унсигездәге кук алдалый,
Унсигездәге кук алдана да,
Үзенең алданганын аңламый...
Уйчанлыгы тагын мулрак аның,
Бераз моңсуырак күзләре,
Шул күзләрнең төпсез дәрьясында
Балачакның керсез эзләре.
Ул эзләрнең башы
Еррактагы ап-ак
Томаннарга кереп югала,
Югала да,
Бакыйлыкка күчкән дусларымның
Хатирәләренә урала.
Белмим,
Елак көзләр микән,
Әллә язлар микән
Мине шулай уйчан итүче?
Тик шомланма,
Мондый халем минем
Болай гына,
Ул моң—үтүче.
Килер бер көн—
Чиксез моңнарымны
Таң җилләре куып таратыр,
Күңелемдә барын оныттырып
Язгы таңдай балкып таң атыр.
Килер бер көн—
Барлык уйларымны
Төпләренә бикләп хәтернең
Син кайларда, таянычым, диеп
Мин елмаеп сиңа дәшермен.
Хәтер төпкелендә яшәр моңнар,
Күзләремдә иңрәр эзләре.
Юккамыни,
Нигә моңсу синең күзләрең, дип
Сорый идең бик еш элгәре...

Шундый чаклар була—
Хатирәләр мине кабат бер кат
Үткән елларыма кайтара,
Сизгерлеген барлап намусымның
Хәтер төпкелләрен актара.

## Хәтер көне

Мең биш йөз илле ике...
Мең биш йөз илле ике...
Сыкрый җан сулкылдап
Аныкы...
Синеке...
Минеке.
Бабайлар илем, дип
Сугышкан, җан аткан,
Казанда Иделгә
Ташкындай кан аккан.
Ишелгән әрнүдән
Колшәриф мәчете,
Мәетләр кимергән
Рәсәйнең ач эте.
Казанның таңнары
Кан кук ал бүген дә,
Тәреләр, тәреләр
Казанның күгендә...

И татар, юк синең
Илең дә, телең дә...
Килмешәк казына
Синең пакь көлеңдә.
Казына әрнетеп

Татарның ярасын—
Башыңны бер игәч
Кайларга барасың?!
Бер игәч башларны
Булмый шул күтәреп—
Октябрь,
Салкын җил
Үзәккә үтәрлек.

Октябрь,
Мең биш йөз
Илле ике, илле ике...

Турайганмы башлар—
Аныкы?
Синеке?
Минеке?

## Безнең гомер

Безнең яшәү бары каралама,
Язалмадык акка күчереп,
Хәлсезләндек, ахры, яши-яши
Хәтсез югалтулар кичереп.

Ихласы да булды, уены да—
Үзебезчә булды барысы да,
Туры юлда кайчак сөртенгәнбез
Ашыгудан, әллә ярсудан.

Башлаганы булган, ташлаганы,
Югалтканы... сөеп бетерми,
Уйламыйча нокта куйганбыз шул,
Кую кирәк чакта өтерне.

Изге эшләр азрак башкарылган,
Кыеклары күбрәк кылынган,
Заманы да килде—йөрмәдек шул
Чәчәк җыеп кына болыннан.

Без күрәсен башка кемнәр күрсен—
Язмышларга шулай язылган,
Сабырлыклар кайчак җитмәгәндер,
Түзәр чакта тузып азылган.

Ә гомер бер, күпме үкенсәң дә
Булмый аны кире кайтарып.
Безнең гомер бары каралама—
Шуны аңладым беткәч картаеп.

Язалмадык аны күчереп акка,
Анысына вакыт калмады...
Ә шулай да юкка яшәлмәгән,
Гомер үткәч шуны аңладым.

Бу дөньяда юкка яшәлмәгән—
Нидер калыр җирдә бездән дә,
Искә алыр кемдер без утырткан
Алмагачтан алма өзгәндә.

## Кешелек

### I

Үсеп килгән чакта хыялларга
Очам дигән өрпәк ак канат,
Әнә дошман, диеп, бармак төртеп
Тоттыралар кулга автомат.

Күңелләрдә язгы гөлләр кебек
Бөреләнгән чакта җыр, шигырь
Әйдә яуга, диеп, оран салып
Кидерәләр иңгә тар шинель.

Кеше,кеше, нигә әле шулай
Күңел дәрьяларың тар синең—
Бәгырь төпләреңдә аңламаслык
Мәкер, караңгылык бар синең.

### II

Кылыч ясый кеше, мылтык ясый,
Иген игә, гөлләр үстерә,
Көйли-көйли уллар үстерә ул,
Үсеп җиткәч яуда үтерә.

Бомба ясый бер сулышы белән
Бар дөньяны утка салырлык.

Кеше, кеше, синең акылыңа
Торып-торып хәйран калырлык.

Акыл җуеп гашыйк була белә,
Җырлар яза аңың алырлык,
Кешелекнең бәхете булсын дисәк
Кешеләргә бирсен сабырлык.

***

**Хәтерлимсең, мин елмайдым сиңа карап,**
**Үпкәләдең шулчак миңа бармак янап,**
**Ә аннары икәү бергә кочаклашып**
**Төн үткәрдек синең белән йолдыз санап.**

**Тик санына чыгалмадык без аларның**
**(Әллә рабем өстәп торды яңаларын!)...**
**Йолдыз санап үткән төннәр гомер буе**
**Дәвалады безнең йөрәк яраларын.**

***

**Мин бакчамда эшлим әле бүген—**
**Бер ялгызым кишер сирәклим,**
**Әллә нинди уйлар килә башка,**
**Уйлыйм үзем,**
**Аларны да инде**
**Сирәкләргә, ахры, кирәк дим.**

**Бере-берен куа уйлар башта**
**Берсе арты берсе караңгы:**
**Иле шундый,**
**Яшәеше рәтсез,**
**Кешеләрдә намус калмады...**

**Әллә нинди заманага язмыш**
**Язып куйган безнең картлыкны,**
**Әллә, мәйтәм, барысына төкереп**
**Гөнаһсыз чакларга кайтыйкмы?**

**Пакьләү өчен котсыз замананы**
**Бездә инде җегәр калмаган,**
**Үзем менә ялгыз кишер чүплим,**
**Ялгыз үз-үземә зарланам.**

**Ә югыйсә нигә зарланулар—**
**Үзебез төзегән тормыш икән бит,**
**Сирәклисе иде гөнаһларны,**
**Ә мин менә кишер сирәклим.**

**Редакциядән:**
*Каләмдәшебезне юбилее белән ихлас котлыйбыз, исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*



Фәнзаман
Баттал

## АЛЬТЕРНАТИВА

ХИКӘЯ

Йә, әйтегез әле, кеше театрга ни өчен йөри? Яңа спектакльләр карап, сәнгать белән таныш булып, милли рухны яңартып тору өчен дисезме? Пүчтәк! Анда, мәсәлән, карт кызлар, ирсез хатыннар, көне буе ясанып һәм үзләренә кияү табу өмете белән бара. Бай карчыклар үзе кебек үк карчыкларның гайбәтен җыеп, шуларны башкаларга сөйли-сөйли ләззәт чигү өчен теркелди ул тирәгә. Ә инде язучы, галим, эшмәкәр кебек ирләр, башка бик күп зыялылар кебек үк, бер-берсен күзәтеп, рухларын, сәламәтлеген барлап кайту өчен файдалана театрны. Алар өчен ошбу сәнгатьнең иң кирәкле мәлләре—антракт, фойе яки буфетлары. Шунда хәл белешәләр. Ә инде кайткач, нәтиҗә ясап сөенәләр: «Дә-ә-ә!.. Бәрәкәт Ясәви тау-шал-ган!.. Озакка тартмас, мөгаен. Бер көндәш кимер, ичмасам.» Яки: «Шәкүр Хыялыевтан цирроз тапканнар. Ут капкандай чабып, өтәләнеп җыйган миллиардларын эт койрыгына тагып кал-дыра-чак и-кән, һә-һә-һә!...»

Театр бинасының кабыргасына табуретка хәтле хәрефләр белән язылган яңа афишаны күреп кайткач, белем-гыйлем артыннан куа-куа утыз яшькә житеп, бер егетнең дә авына эләкми сакланган сазамык кыз Ямькилә дә әнә шул спектакльнең премьерасын карау ниятенә керде. Кем белә, үзенә дигән гомерлек яр да шунда йөридер, бәлкем. Кукрайган ялгыз кукы сыман күпме яшәргә була?! Кемнәрдәндер артып калган ир-егет табылмасмы, ичмасам?..

Алдан ук әйтеп китү кирәктер: исеменә җисеме дә туры килгән күркәм кыз булып үсте ул. Аның урамга чыгуы, кайсыдыр тарафка атлый башлавы була, урамда чуалган егетләр, ерактан ук күреп һәм сокланып:

—Ямь килә!—диешәләр иде. Әйе, исемен икегә бүлеп әйтәләр иде. Ләкин аның яме авылның бер генә егетенә дә тәтемәде—Казан тиклем Казанның иң мәшһүр университетына керде, тәмамлады, остазлары кыстагач, аспирантурада калды... Хәер, сөйләп бетермик, бары тик әле хәзер дә укасы коелмаганлыгын—яшьлек сыйфатларының саклануын әйтик тә, аның театр залына кереп утыруына игътибар итик.

---

Фәнзаман БАТТАЛ (1939)—*язучы; «Сакалыңа ут капса...», «Сигезенче оҗмах», «Безнең сурәт» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Әйе, утырды бу... Як-ягында бер йомышы да булмаган, беркемгә дә исе китмәгән кебек сәхнәгә текәлде, ләкин, залда ут сүнгәч, пәрдә ачылгач, күз кыры белән генә як-ягында утыручыларга карап алды. Уң ягында кулына блокнот белән каләм тоткан, күзлеген йә маңгаена күтәргәләп, йә төшергәләп утыручы нык кына бизәнгән карчык икән. Ә инде сул якта гәүдәсен төз тотарга маташкан тәкәббер кыяфәтле бер ир... Ирнең теге ягына исә пеләшеннән чебен таеп егылырлык бер карт кунаклаган. Димәк, кырык яшьләрдәге бу тәкәббер ир ялгыз килгән булырга тиеш.

Ә сәхнәдә балыкчылар төн куна торган куышка охшаган шалаш дигән нәрсә. Шул куыштан кулына китап тоткан бер егет чыгып баса да, уң кулын алга сузып, кешеләрнең бер-берсе белән тигез хокуклы, тигез мөлкәтле булырга тиешлеге хакында Ленин сүзләрен кычкыра. Әһә, кулындагы китабы да Ленин томы икән... Бераз карагач, күршедәге һавалы ир Ямькиләнең җилкәсенә кагылгандай тоелды.

—Йә, ошыймы тамаша?—дип сорады ул сүз уңае гына. Авыз читендә елмаюы да сизелде сыман.

—Әле хәзергә анлап ук бетермим,—диде Ямькилә.—Ә сезгә ничек тоела?

—Адекватно... Антогонизм куера инде... Радикализмга да тарта кебек шунда...

Бик затлы булып күренүче ирнең спектакльгә биргән бәясендәге сүзләрне аңышыр-аңышмас калган Ямькилә үзенең бик бәләкәйләнеп, бөрешеп куюын тойды. Әнә, ничек сөйләшә затлы кешеләр! Ә без, татар теленә хезмәт итәчәкбез дия-дия, егерме ел укып та авылча гәпләшүдән уза алмаганбыз... Тагын да бер-ике сүз алышмакчылар иде, әмма блокнотлы-каләмле карчык еландай ыслап куйды:

—Өегезгә кайткач сөйләшсәгез-з лә! Сез миңа резюме язарга комачаулыйсыз!

Әйе, театрны игътибар белән караучылар да сирәк-мирәк булгалый бит әле. Алары—сәнгать белгечләре дип аталучы затлар, ягъни теге яки бу спектакльне йә күкләргә күтәреп, йә тетмәсен тетеп матбугатта чыгаручылар. Бу көяз карчыкның да шуларның берсе икәнен аңлаганнардырмы яңа танышлар—анысын белгән юк, ләкин «соңнан сөйләшербез» дигәләштереп пышылдаштылар да шым булдылар. Ә инде спектакль бетеп, саф һавага чыккач, көлешеп алдылар.

—Теге карчык бик конфликтлы булып чыкты. Дебатлар, дискуссияләр вакытында да үзсүзледер,—диде ир киная беләнрәк.—Безне ирле-хатынлы дип уйлады, ахрысы. «Кайткач сөйләшерсез», имеш...

Бераз спектакль турында фикерләр әйтешкәч, Ямькилә, гүя юл эзләде:

—Әнә, тамашачылар тукталышта кайнаша инде. Сез кайсы якка кайтасыз? Миңа—бу якка...—дип куйды.

—Мин—кире якка. Ләкин Сезне өегезгә илтеп... яки илттереп куймасам, минем реномега тап төшүе бар...

—Машинагыз монда мыни?—дип, театр алдында торучы һәм бер-бер артлы кабынып китә баручы машиналарга ишарәләде Ямькилә.— Йөртә дә беләсез, алайса?

—Йөртә белсәм дә руль тотарга яратмыйм... Башымдагы кадерле фикерләр юлга сибелеп баргандай була. Машинам да монда, шоферым да бар.

—Килеп җиткән булса ярый ла бит...

—Аның киткәне дә юк.

—Көтеп утырган мыни өч сәгать буе?—дип гаҗәпләнде кыз.—Янына барыйк инде, алайса...

—Ә ни өчен? Үзе безнең аяк астына килеп туктар,—диде дә ир, кулын

күтәрә төшеп, имән бармагы белән машиналар торган якка сизелер-сизелмәс ишарә ясады. Ул арада затлы машина, мәрмәр баскычның аскы басмасына терәлердәй булып, килеп тә басты.

Машинада кайтканда анлашылды: депутат икән бу, машинасы да «служебный»...

—Шоферыгыз да Үзегез кебек мәһабәт гәүдәле икән,—дип елмайды Ямькилә бара торгач, шаяртырга теләп.—Бик пар килгәнсез. Туганнар түгелдер бит алай-болай?..

—Шулай зур гәүдәле булырга тиеш тә! Ул бит әле, критический ситуацияләр туа калса, тән сакчым һәм апологетым да булырга тиеш...

Машина Ямькилә яши торган биш катлы йорт төбенә килеп туктагач, Роберт Альбертович Октябрев (үзен шулай таныштырды депутат) тыныч һәм өзек-өзек кенә әйтә куйды:

—Әгәр яраса, килеп, сөйләшеп утырырга теләк бар. Визави беребезгә дә мишәйт итмәс дип уйлыйм... Йортыгызны күрдек, юлын шоферым онытмас... Телефон нумирыгызны да бирсәгез... Бүген вакыт юк. Дәүләт проблемалары хакында япа-ялгыз уйланасы бар. Ике көннән сессиягә җыелабыз. Кайчак кворум җитми—бармый ярамый.

Машина китүгә һәм фатирына кереп ялгыз калгач, матур хыялга чумды Ямькилә. Кайбер сүзләре чит тоелса да, күркәм кеше бу депутат. Гәүдәсе, кыяфәте дә шәп. Моның белән урам буйлап атлау да ни тора! Сайлана-сайлана утырып калдың инде, дип көенгән-сөенгән ахирәтләренең дә һушы китмәле...

Озак-озаклап хыялланырга да туры килмәде кызга—Роберт Альбертович ике-өч көннән килеп җитте. Ул биргән чәчәк бәйләмен озын муенлы вазага утырткач, кучтәнәч тортын өстәл уртасына куйгач, чәй кайнаган арада табын әзерли башлады.

—Да-а-а!.. Фатирыгызда комфорт сизелә!—дип куйды кунак.—Ләкин, барыбер, берүзегезгә бик күңелле түгелдер. Мин үзем дискомфорт сизә башладым инде ялгызлыктан.

—Иптәшем булгач, миңа бик моңаерга туры килми әле,—диде Ямькилә, тормышы түгәрәк кешедәй елмаеп.—Яшәп яткан булабыз... Моңайган чакларда җырлап та җибәрә...

—Как-так?! Мин бит сезнең иптәшегез юк дип уйладым! Үзегез дә шулай дигән идегез кебек!..

—Иптәш ба-ар,—диде Ямькилә, депутатның аптырашлы карашына күз сирпеп алгач.—Ир генә юк хәзергә.

—Кем, кая соң ул?..

—Әнә, түр башында утыра... Каяле, мин кухня белән ике арада йөргәндә сезнең дә күңелне күтәрә торсын...—диде дә кыз, кәнәфидә яткан пультны түр башындагы телевизорга төбәп алды һәм... менә хикмәт!—экранда бөтерелә-сикерә җырлаучы бер кыз пәйда булды.

Икәүләшеп көлешкәч, өстәп куйды Ямькилә:

—Безнең якта ирне иптәш дип йөртмиләр. Ир—ир инде ул! Әнә, кайберәүләр бабаларына да «дәү әти» дип дәшәләр. Культурно була, имеш... Һәр кешенең әтисе дә берәү генә була. Анысы—үзен бар иткән ата.

—Ә менә кияүгә чыксагыз?.. Иптәшегезнең... ә-ә... Ирегезнең ата-анасын «әти-әни» дип әйтергә туры киләчәк бит?

—Анысы бөтенләй бүтән нәрсә. Ир белән хатын бер җанга әйләнә. Ир ничек әйтсә, хатын да шулай сөйләшергә тиеш... Чөнки ул да калган гомерен ир атасының күзенә карап, бер гаиләдә яшәячәк.

—Һы-ы! Кредогыз ныклы!

—Кредога, безнеңчә әйтсәк, инануга кагылмый инде бу сүзләрем. Ул кадәресен һәр саф татар белә. Чөнки мантыйк шундый...

—Әйе, хәзер газеталар шулай яза шул, «мантыйк» диләр, «логика» димиләр... Әгәр дә менә... иргә чыксагыз, ирегез дә сезнең ата-анагызга «әти-әни» дияргә тиеш була бит...

—Булмый. Борынгыдан килгән йола буенча, хатынның ата-анасы «бабай-әби» була.

—Күнелле, кызык сезнең белән,—диде Роберт Альбертович, тәм-томнарны татып карап, чәй йотып куйгач.—Тагын да күңеллерәк булсын өчен...

Урыныннан кузгалып һәм ишек төбендәге утыргычта калдырган кейсыннан табынга шампан шәрабы белән коньяк китереп утырткач, өзелгән җөмләсенең калганын ялгады:—...болар да ярап куяр, бәлки...

—Әйе, ир затына алар да килешәдер,—дип балкыды Ямькилә.—Көн дә суытты. Җылытып та җибәрә диләр бит хәмерне... Машинасыз килгән булсагыз, әлбәттә. Руль тотасыгыз булмаса дип әйтүем инде...

—Аның өчен шофер бар бит. Бөтенләй үк исереп китсәм дә өйгә күтәреп кертәчәк.

—Бәй, без монда иркенләп утырганда, ул подъезд төбендә туңамыни?! Чатнама суыкта дип әйтүем...

—Нишләп туңсын? Мотор эшләп, җылытып тора. Оҗмах кебек! Күңелен музыка күтәрә.

—Чакырыргадыр, бәлки? Күңелсездер бит ана ...

—Борчылмагыз. Аның урыны шунда булырга тиеш. Урысча әйтсәк, каждый сверчок имеет свой шесток... Рюмкалар бардыр бит?

—Алары бар...—диде Ямькилә, сервантган бәллүр рюмкаларның берсен Роберт Альбертович алдына куйганда.—Шулай да... ишек төбендә эттәй булып... адәм баласының көтеп утыруы күңелгә ятмый.

Депутат исә, аның сүзен ишетмәгәндәй, кулларын җәйде:

—Бу ничек була инде? Бүтән рюмкаң юкмы әллә? Берүзем эчеп утырмамдыр бит?!

—Менә шушындый сорауларга җавап бирә алмаганга күрә дә карт кыз булып калдым инде мин,—диде Ямькилә, ихласлык белән көлә-көлә.—Тәмен дә белә алмадым мин рюмкалар, бокаллар белән эчә торган нәрсәләрнең. Чөнки аларның безнең өйгә кергәне булмады. Әткәй дә, әнкәй дә, туганнарым да эчми...

—Житешле тормышта яшәгәнсездер бит? Күңел ачмый гына булмагандыр... Кунакка да йөрешкәннәрдер...

—Еш булды андый чаклар. Әткәм-әнкәм дә укытучылар иде. Еш чакырдылар кунакка. Сыйланып кайтудан баш тартмадылар.

—Аеклар гына утыра торган мәҗлесләргә йөргәннәр, димәк?

—Аракылы мәҗлесләрдә дә булдылар. Эчкәннәре эчте, эчмәгәннәре ризык белән дә канәгать утыралар иде.

Кунак, йөзенә, карашына серлелек галәмәте өстәп, көлеп җибәрде:

—Ә шулай да сервантың матур бокаллар, фужер һәм рюмкалар белән тулы. Чехов әйтмешли, стенага элелгән мылтык атмый калмый инде ул...

— Атмый калучы мылтыклар да була. Ә минем сервантгагы нәрсәләр заманча булып күренергә теләү генә... һәр хатын-кыз кебек...

—Ник кирәк инде ул атмый да торган мылтык?

—Сувенир итеп элеләр аны кайбер кешеләр. Мәсәлән, минем әткәй белән бер карт профессор өендә булган бар. Профессорның стенасындагы бик матур борынгы мылтыкка карап торды да әткәй: «Бизәкләре дә гаҗәп моның! Алып, кулга тотып карыйсы килә», диде. «Кулын туйганчы кара», диде карт. «Атмасмы соң?» ди әткәй. «Бабамнан калган реликвия ул. Ана йөз илле ел буена, ягъни заводыннан сатып алынганнан бирле, бер генә мәртәбә дә патрон тыгылмаган. Курыкма, рәхәтләнеп кара», диде профе...

Болай да елмаюлар, көлешүләр белән барган сөйләшү Ямькиләнең сүзе бетмәс борын «шартлатты» Роберт Альбертовичны:

—Көлдереп үтерәсең... Бер генә мәртәбә дә патрон күрмәгән мылтык дисең инде, ә?! Уф-ф-ф!... Тыгылып үләм хәзер... Аркага сук... Ай, бик кызганыч булган ул мылтык... Бер генә патрон да тыкмаганнар мескенгә... Көпшәсе дә күгәреп беткәндер инде... Уф-ф...

Депутатның аркасын төйгән арада Ямькилә үзе дә бөгелә-сыгыла рәхәтләнеп көлде.

—Юк, күгәрмәгән... Көпшәсен кояшка борып карадым... Ялтырап тора...

Роберт Альбертович һушына килә-килә нәтиҗә ясап куйды:

—Һәйе!.. Металы яхшыдыр. Тагын мең ел торса да күгәрмәстер. Ләкин адәм балаларының гомере кыска шул. Йөз илле түгел, шуның яртысын да яши алмый китүчеләр хисапсыз. Әйдәле, тагын бер рюмка куй да, Ямькилә, кыланмый гына тотыйк әле бер... Бик күңелле синең белән сөйләшү.

—Гаеп итмә, мин рюмка тотмаган килеш тә күңелле сөйләшә беләм.

Шулчак депутатның тормыштагы роленә, үз асылына кайта башлавы сизелде кызга.

—Әйдә, консенсус өчен генә булса да, син дә йот инде.

Мөнәсәбәтләрне күңелле итеп дәвам итәргә өметләнгән Ямькилә, елмаюын сакларга тырышып, депутатлар авызыннан еш чыга торган сүзне дә кыстырып, шаярткан сыман ныклы сүзен әйтте:

—Арабызда компромисс та булсын әле, Роберт абый.

Аңлады, бик аңлады депутат кызның эчмәячәген. Бер рюмкага коньяк агызды да, аны йотып куйгач, кырт кына Ямькиләгә дәште:

—Бер бокал да куй әле, алайса.

Өстәлгә килеп утырган бокалга тутырып шампан салды, йотлыккандай эчте, сүзсез генә шоколад чәйнәде... Кунакның кәефе кырылганлыгын күреп һәм дә сүзне икенче тарафка юнәлтергә теләп, Ямькилә үзе сүз катты:

—Карале, Роберт абый, менә без спектакль карап кайттык теге көнне... Аның драмасын язган абзый да депутат бит әле, әйеме? Әйбәт кенә чыгышлар ясый ул сессияләрдә дә, радио белән телевизордан да... Кыюлыгын, ачыктан-ачык халыкчан сөйләвен ошатам мин аның...

—«Абый» дисең инде, ә? «Бабай» диген. Авызыңа йомшаграк булыр, җанкай. Мин бит синнән сигез яшькә зуррак,—дип елмаерга көчәнде Роберт Альбертович.—Әйе, сөйләүчеләр күп бездә. Әлеге драматург-депутат та ярсый-ярсый сөйли, колхозның отчет-сайлау җыелышында сөйләүче актив колхозчы кебек...

—Дөрес әйтәсең, ярсып та сөйли, кызып киткәнлеге дә, эчтән кайнаганлыгы да сизелеп тора. Ләкин ихлас сөйли бит ул! Халык өчен борчыла.

Кунакның авыз чите чалшаебрак куйды. Шул килбәтен югалтмыйча, ыңгырашкан аваз белән авызын ачты:

—Ну и што-о?.. Аның сөйләвеннән ни файда? Алар сөйли тора, сөйләгәннәре җилгә китә тора... Бар сөйләгәннәре таш стенага ыргытылган борчак шикелле аяк астына төшеп таптала. Карарны, законны без кабул итәбез бит, матуркаем! Без тавыш бирәбез! Аларның сүзе җинми бит анда!

Тагын да коньяк йотып, шампан чөмергәч, урыныннан торды депутат.

—Аңлашылды бугай, Ямькилә: безнең теләкләр дә, максатлар да бер-беренә ябышмый кебек. Корылмаган мылтык белән мылтык күрми күгәргән патрон кебек без... Китим әле мин... Кая, саубуллашу хакына бер кочаклыйм да үзеңне, китәм.

Кочаклавына Ямькилә каршы килмәде. Ләкин (менә гаҗәп!) Роберт Альбертовичның аяклары чыгу ягына түгел, түргә таба атлый башлады.

Эшнен кай якка барачагын тез аслары тахта читенә терәлгәч кенә шәйләп өлгерде кыз һәм, кунагын айнытырлык итеп, алга таба кискен адым ясады:

—Ша-яр-мыйк, Роберт абый!!

Кунак кызнын биленнән кулларын алды да, һәр сүзенә басым ясап, кистереп әйтте:

—Кугандай кайтарып җибәрәсең мине. Ләкин шуны бел, җанкисәк, син миңа тиң альтернатива таба алмаячаксың! Ахыр чиктә мин ялгыз калмам, ә син калачаксың! Яки берәр механизатор, үзең сынары фәкыйрь укытучы белән гомер үткәрәчәксең!...—Аннары, масайган һәр төрәнең «гомерлек эш коралы» булган имән бармагын Ямькиләнең күкрәгенә терәп диярлек өстәп куюны да кирәк тапты.—Но... Но!.. Тагын бер киләм әле мин синең янга. Уйлап бетер! Визавига әзер бул!

Әйе, аякларына тиз генә туфлиләрен элде, бүреген киеп, пәлтәсен җилкә аркылы сыртына ябып, чыкты да китте.

Машинага кереп утыргач, тешләрен кысып әйткән ике-өч сүзе генә ишетелде шоферына:

—Саф-ф кыз-з, имеш-ш! Кылана... Киттек!

... «Бер киләм әле» диюенә артык исе китмәде кызның. Килсән, кертермен, килмәсән дә дөнья җимерелмәс, дип уйлады эченнән. Чөнки аңлар кешегә аңларлык булды: Октябрев артык масая торган, анынчарак әйткәндә, дөньяга вакытлы престижга таянып кына, кешеләргә дә үз кәнәфие биеклегеннән торып кына бәя бирә торган адәм. Мондыйлар уртак ятакта да ир белән хатын арасындагы татулыкны—альянс, ризасызлыкны—конфликт, бәхәсне—дискуссия, хыялны—иллюзия, максатны—принцип дип сөйләшәләрдер. Әйтик, зөфаф төнендә, ирлек сәләтен күрсәтүгә үк:

—Йә, эффектлы партнермы мин?!—дип соравы бик мөмкин аның. Яки, яши-яши бер көн килеп, аның белән аерылышу ниятенә килсән:

—Сепаратистка син!—дип җикеренүе дә ихтимал.

Булыр-булыр... Әнә бит, адәмчә генә итеп, «син миңа тиңләшерлек алмаш таба алмассың» диясе урынга «альтернатива таба алмассың» дип чыгып китте. «Визавига әзерлән!» дидеме әле тагын? «Кара-каршы сөйләшеп аңлашуга әзерлән!» дию өчен туган теле җитми микәнни?

Мөгаен, нәселдән үк киләдер ул милләтнең рухи хәзинәләрен, изге дип саналган кануннарын өнәп бетермәү... Сөйләшеп утырганда Ямькилә, шаярткан кебегрәк итеп аннан:

—Фамилияң сәеррәк синең, Роберт әфәнде... Бабаңның исеме Октябрь булгандыр инде, әйеме?—дип сораган иде. Роберт Альбертович көлә-көлә сөйләп тә бирде.

—Юк... Бабай үзенә тапкан фамилия ул. Аның фамилиясе Шәрифуллин булган... Совет власте җиңгәч, коммунистлар партиясенә кергән. Партия билеты алыр алдыннан: «Минем фамилиямне дә алыштырыгыз. Миңа Шәриф тә, алла-улла-муллалар да кирәкми. Советский, ленинский фамилия бирегез миңа!» дигән. «Якты киләчәгебезнең башы октябрь ае бит инде», диешкәннәр дә, шул фамилияне бүләк итеп кайтарганнар аңа район үзәгеннән...

Әнә шулай итеп, Алланың кадерлесе дигән мәгънәдәге исем белән яшәп фани дөньядан киткән Шәрифулла Октябрьгә әйләнгән дә куйган. Ягъни, үзе үлгәч, җәсады каберенә иyләшеп беткәч... Әлбәттә инде, Октябрь исеменә Альберт, Роберт кебек исемнәрнең ялгана баруы беркемне дә гаҗәпләндермидер... Күнегә, бик тиз күнегә безнең татар... Яраклашуга да күнегә... Дөнья дигән куласа, әйләнде-тулганды да, безне чираттагы якты киләчәккә алып барачак чорга—модернизациягә китереп чыгарды. Шушы Роберт Альбертович үзе яки аның уллары Модернизаторов кебегрәк яна

фамилия сайламаслар микән, алай-болай?

... Әллә нинди ел булды бу... Җәй буе тәкатең калмаслык итеп кыздырды, бөтен Рәсәйне көйдерде. Хәзер инде кышы, шул кызуларын салкыннары белән каплау өчендер, бик яман булмакчы. Көннән-көн зәһәрләнә бара үзенең зәмһәрирләре белән. Тәрәзәдән төнге урамга карап торучы Ямькилә, ике кат пыяла артындагы термометрга да күз салып алгач, үзенчә нәтиҗә ясап куйды: этеңне дә урамда калдыра торган төн түгел бу... Әнә, машиналар үткәләп торсалар да, җәяүлеләр бөтенләй күренми. Нужасы гына куып чыгармаса, кем йөрсен бу салкында?!

Уйларыннан ишек кыңгыравы айнытты кызны. Күршеләрнең берәрседер, дип ачса... ике атна элек кенә кәефе кырылып киткән Роберт Альбертович килеп җиткән!

—Синең янга тагын килдем әле,—диде ул керә-керешкә, көлебрәк.—Куып чыгармасаң...

Ямькилә йөзендә дә көләчлек балкыды һәм ул әле бая гына зиһененнән йөгереп үткән уйларын теле белән «терелтте»:

—Дусларны түгел, дошманыңны, хәтта этеңне дә куып чыгара торган төн түгел бу, Роберт әфәнде! Рәхим ит!

Әйе, рәхим итте Октябрев. Теге кичтәге кебек үк матур алъяпкычлы шәраблар чыгарып утыртты өстәлгә. Бу юлы да ике рюмка куюын сорады. Ул теләгәнчә эшләде Ямькилә, барыбер сорамый калмас дип бокал да утыртты өстәлгә... Кунак, ике рюмканы да тутыргач, уйга чумгандай тынып калды да, карашын кызга текәде.

—Нишләптер үз итмисең син мине, Ямькилә... Кайсы төшем ошамый сиңа? Без бит инде яшь кыз белән әнкәсе дә үпмәгән егет түгел. Нужәли минем кебек ир белән яши алмассың икән? Өйләнешсәк дип әйтүем...

Кыз, гаҗәп сүз ишеткәндәй, күзләрен түгәрәкләндереп елмайды:

—Бәй, безнең ул темага кергәнебез дә булмады бит әле! Яңа сүз ишетәм...

—Ничек? Теге көнне юньләп кочакларга да юл куймадың, ятакта бергә ятып торырга да теләмәдең бит. Яратмыйсың, димәк...

Октябревның «сценариенда» яңалык булмаячагын аңлап өлгергән кыз, ачыклыгын, көләчлеген сакларга тырышып, сүз юнәлешенә куәт биргәндәй үзенекен әйтеп салды:

—Иманлы татарлар берчакта да ятактан башламаганнар өйләнешү, якынаю мәсьәләсен. Ата-ана хәер-фатихасыннан, никахтан, тора-бара ЗАГСтан башлауны гадел дип санаганнар. Яңа сүз түгел бу... Иллә дә мәгәр шулай булган, хәзер дә шулай, киләчәктә дә шулай дәвам ителәчәк...

—Һе-һей, җанкай!.. Бер гасырга артта калгансың син. Хәзерге тормыш бөтенләй икенче ул! Законнары да акыллырак, кырысрак...

—Теге... сессия вакытларында да сүгенә-сүгенә, бер-берсенең йөзенә төкерә-төкерә сугыша, буыша торган депутатлар чыгарган законнарны әйтәсеңме, Роберт абый? Шулар нинди акыллы законнар чыгардылар икән тагын?

—Әйтик, демократия шартларында. Килешү юлы белән. Ике яктан да тигез хокуклы килешү төзеп.

—Ул килешү договор дип аталамы инде ул?—дип сорады кыз гаҗәпләнеп, инде елмаюын да сакларга тырышмыйча.

—Договор түгел, контракт дип атала ул!

—Ә-ә-ә... Менә хәзер аң-ла-дым!—диде Ямькилә, хәйран калудан күзләре дә, авызы да ачык калган кыяфәттә.—Безнең авылда бер агай халыктан сыерлар, кәҗә-сарыклар җыя контракт буенча. Аннары, шулай ук, алдан төзелгән контракт буенча Казан сәүдәгәрләренә төяп җибәрә. Димәк, син

минем әткәй белән төзергә тиеш буласындыр инде ул контрактны?! Ни өчен дигәндә, мин аның тәрбияләп, ашатып-эчертеп үстергән малы, ягъни хайваны булам бит инде, синеңчә фикер йөртсәк. Кәҗә булам! Ә кәҗәнең контракт төзергә хокукы юк...

Инде «зәм-зәм суларыннан» бу юлы шактый кызган Октябрев әллә ихластан, әллә Ямькилә йөзендәге көтелмәгән үзгәрешләрне күреп, кытыклана-кытыклана көләргә, шул хәлендә өзек-өзек җөмләләр корыштырып аңлатырга кереште.

—Ник шаккатасың контракт фактына? Цивилизацияле шактый илләрдә күптән практикага кергән бит ул. Татар халкы гына түгел, хәтта Бөтенроссия аңлады үзенең бу мәсьәләдә артта калуын.

Ә инде көлүе басыла төшкәч, тирән генә сулыш алганнан соң, ягымлы тавыш белән сүзен дәвам итте:

—Ямькилә, инде менә өч сәгать үтте, һаман консенсуска килә алмыйбыз. Бәлки безгә төне буе сөйләшергә, анлашырга кирәктер... Әгәр дә монда калырга рөхсәт итсәң, хәтта...—Ул кесәсеннән телефон чыгарды.—...хәтта шоферымны да кайтарып җибәрер идем, шылтыратып...

Хикәябез затлылыгын югалтмаган, һәрчак сабырлыгын да сакларга күнеккән кыз турында барса да, нәкъ шушы урында халәтенең ничек үзгәрүен салмак кына тасвирлау җинел түгел... Ул, соңыннан үзе әйтмешли, котыргандай, өтәләнгәндәй сикереп торды, күзеннән чәчрәп чыккан яшьләрен сөртә-сөртә кычкырып җибәрде:

—Ничек?! Үзәккә үткеч шушы салкында ул хәзер дә сине саклап утырамыни? Бүген якшәмбе ... ял көне булгач, мин сине такси-мазар белән килгәнсеңдер дип уйлаган идем бит. Ул да контрактлы хайван мыни?!

—Соң... аңла, Ямькилә, ул бит мин кайда булсам шунда булырга тиеш!

—Соң, шулай булгач, ул хәзер дә синең янда—шушы җылы бүлмәдә булырга тиеш, һичьюгы кухняда утырырга тиеш адәм баласы!

Шушы сүзләреннән соң фатирның асты өскә килгәндәй булды: әүвәл, сикереп торып, әйберләрен җыештырып: «тәки шул шофер аркасында тавыш кубарасың, шушы минутта ук эшеннән дә куам, машинадан да селкеп төшерәм мин аны»,—дия-дия тиз генә Роберт Альбертович чыгып китте. Шулай да, ишекне терсәге белән төртеп ябар алдыннан:

—Синең янга бүтән эзем булмаячак!—дип әйтергә өлгерде тагын...

Аның артыннан ук, пәлтәсен кия-кия, Ямькилә үзе дә чыгып йөгерде. Баскычтан төшкән чакта бер генә уй кыздырды миен: «Чынлап та минем аркада кешене эштән куар микәнни бу?! Гаиләсе, балалары бардыр... Бу мәрхәмәтсез, эшсез заманда тилмереп яшәрләрме? Суытырга кирәк бу Робертны, суытырга!..»

Ләкин ул өлгерә алмады. Подъезд төбенә чыгып җитүенә барысы да бер мизгелдә хәл ителде... Машинаның шофер ягындагы ишеген ачуы, каты итеп сүгенүе һәм:

—Бүтән күземә күренмә, сине эштән кудым!—дигән җикерүе ишетелде Робертның, шоферын йолкып диярлек тартып чыгаруы, үзе руль артына утырып, китеп баруы күренде. Әнә, шоферы салкыннан томанланган, бер генә җан иясе дә күренмәгән тып-тын урамда, дәресрәге, шул урамның читендә басып калды... Аңа сүз катарга базмый торса да, кыз дәшмичә кала алмады:

—Нәрсә, китеп тә бардымыни?

Шофер борылды, үзенә таба килүче Ямькиләгә таба берничә адым атлады:

—Ә, сез икәнсез... Китте шул...—диде шофер сабыр гына.

—Димәк, эштән чыгарды сине?

—Анысы бәла түгел... Күптән китәргә уйлаган идем инде аның эшеннән. Тик вәгъдәсен үтәмәсме дип кенә түздем...

—Нинди вәгъдә?—дип сорауга ук, Ямькилә икенче сүзгә күчте:—Бик суык... Әйдә, син дә бераз җылынып чыгарсың, чәй эчеп алыйк...

Сүзсез генә баскычтан менделәр. Бары тик фатирга кергәч һәм як-ягына күз төшереп алгач кына шофер үзе сүз башлады:

—Өч ел буе биреп килгән вәгъдәсе шул иде аның... Социаль ипотекага кертмәкче иде... Минем яшьтәшләрнең балалары мәктәп юлында... Ә мин, инде ничә еллар, тулай торак караватында ауныйм...

Театрдан кайткан кичтә аның йөзен дә күрмәгән иде кыз. Чөнки артына, ягъни Ямькилә тарафына бер дә борылмады ул—юлына гына карап барды. Хәзер генә игътибар итте: кыз әтисе әрләп чыгарган алыптай сабый сыман икән бу... Әллә яшькелт-зәңгәр, әллә зәңгәр-яшькелт күзләре боек, уйчан, сөйләгән сүзләре дә үзе өчен генә кебек—салмак, сабыр. Хәер, бу хәлендә шулай булырга тиештер дә. Әле яңа гына эштән куылган кеше бит ул...

—Әйе, эш табулары кыен... Күпләр айлар буе эзли эшне,—дип кайгысына керде Ямькилә,—әле депутат абыең да сүзендә тормаган ипотека мәсьәләсендә...

—Бер дә кайгырмыйм мин эш җәһәтеннән,—диде егет, гәүдәсен турайта төшеп.—Кирәк икән, трактор йөртәм, катокка утырып, юл да салам. Шул ук урыныма кайтып, икенче депутатка да хезмәт күрсәтү мөмкинлегем бар.

—Алырлармы?

—Бер-икесе күптән чакырып тора. Ипотеканы да хәл итмәкчеләр. Аңа житә язарлык акчам да әзер инде.

—Тагын да алдамаслармы соң?

—Юк!—диде егет, көтелмәгән ныклык белән.—Мин аларның кайсысы кем икәнен беләм инде хәзер. Депутатлар арасында да адәмчә кешеләр житәрлек. Барысы да бер чыбыктан куылмаган.

Бераз тын гына утыргач, егет кузгала башлады:

—Кайтыйм инде мин. Соң бит...

Монарчы икеләнеп утырган Ямькилә әйтәсе сүзен әйтеп бетерергә булды.

—Шулай да... Карале, исемеңне дә белмим икән бит... Әйе, Давыт алайса... Шулай да, Давыт, эшкә урнашуың-урнашмавың хакында шалтырат әле миңа. Дөп-дөресен әйткәндә, синең эшсез калуыңда үземне гаепле итеп тоячакмын. Җаным тыныч булмас.

Давыт, нәрсә сөйли бу дигәндәй, туктап калды. Шулчак аңа Ямькилә Октябревнының ни өчен давыллап чыгып китүен, шоферына ни өчен ябырылуын сөйләп алды.

—Рәхмәт,—диде Давыт, яктырып китеп.—Мин аның сәбәбе башкачарак дип уйлаган идем. Үткән килүдә дә үртәлеп чыккан иде ул моннан...

—Берәр сүз әйттеме әллә минем хакта? Нәрсә диде?

Чыга-чыгышка серле генә елмайды да Давыт, кул селтәде:

—Ярый, ирләр сүзе ирләр арасында калсын инде. Ачуы бик килеп әйтсә дә, мин шуны аңладым: арзанлы кармакка капмый яшәгән балык кебегрәк кеше икәнсез.

—Нәр-сә-ә?

Ләкин кызның бу соравын ишетмәде дә кебек Давыт. Үзенә сузылган кулыннан визиткасын алып түш кесәсенә салды да ишек тоткасына тотынды. Ә инде чыгып киткәндә, ишек ачучы кызга сабыйларча янә бер кат елмаеп, кунак иткәне, җылытканы өчен рәхмәт әйтте. Мондый сүзләре дә колакка эленеп калды:

—Арада телефон бар бит. Бер булса да сөйләшми калмабыз әле, Аллаһ боерса...

***

Дөнья дигән куласаның ничек әйләнәчәген, нинди мәрәкәләр китереп чыгарачагын, кеше дигән җан ияләренең кайда батып, каян һәм нинди сурәттә калкып чыгачакларын, ничек яшәп нәрсәләр күрәчәкләрен, тормыш юлларының кайсы чатында адашачакларын бер кем дә алдан әйтә алмый... Дөньяның бердән-бер кендегедәй масайган кайбер патшаларны да асып куялар икән, кардәш түрәсе аркасында гына депутат булып җайланган, ләкин үзен сайланган депутатлардан да өстен куеп масайган Октябревка ни сан инде... Үзен сыендырган, депутат иткән түрә абзыйсын да урыныннан алып ташлаганнар, Октябревка да альтернатива тапканнар, ягъни затлы машинасына да, сессияләр залындагы урынына да яна хуҗа—яна депутат утыртканнар. Әнә, бүген җәйге чиләнен кайнар бер көнендә, пеләшләнеп баручы башындагы тирен сөртә-сөртә, әле кайчан гына шоферын машинадан йолкып чыгарып калдырган урында пәйда булды ул... Бераз әйләнеп-тулганып торгач, Ямькиләләр подъездына кереп китте. Менде. Кыңгырау төймәсенә басты. Ямькилә ишек ачты. Керде. Ә инде идән уртасына өелгән тартмаларга, зур-зур төенчекләргә, урыныннан купкан стенкаларга, кыскасы, асты-өскә килгән фатирга карап алгач, исәнләшергә дә оныткан хәлдә сорау бирде:

—Нинди хәл бу?..

—Яңа квартирга күченәбез,—дип җавап бирде бәхете балкыган Ямькилә.

—Күченәбез, диден... Кем белән?

Ямькилә көлеп җибәрде:

—Синең альтернативаң белән!

Шул сүзне генә көткән кебек, сөлге белән битләрен, күкрәген сөртә-сөртә, ванна бүлмәсеннән алыптай Давыт килеп чыкты. Трусик балакларын җилфердәтеп ике-өч адым атлады да, авызын җыра-җыра, биш бармагын җәеп Октябревка кул суздЫ:

—Сәлам, абзый! Әллә мине сагынып килдеңме? Әйдә, түрдән уз! Хәзер машина килеп җитә. Бәлки әле мебель дә төяшерсең...

Каушап калган, йөзе коелган Октябрев, аның кулын да алып тормастан, Ямькиләгә төбәлде:

—Шушымы инде ул миңа альтернатива булырдай кеше? Бу бит механизатор... Мин сине интеллигент дип уйлаган идем...

Йөзенә чыгарга маташкан ачуын басу өчен елмаерга тырышты Ямькилә:

—Мин бит депутат эзләмәгән идем, Роберт Альбертович. Ихлас күңелле, изге ниятле чын ир эзләгән идем. Таптым! Шуны миңа калдырып китүең өчен сиңа да зур рәхмәт,—диде.

Октябрев, нәрсәдер әйтергә теләгәндәй, калын иреннәрен мимылдаткалап алды да, сүз тапмагандай ярымачык калган ишеккә борылды.

—Ярый, абзый, грузчиклыкка да ярамагач, китсән дә сүзебез юк,—диде Давыт, бер аягы тупсадан атлаган Октябревка. Аннары, ишекне шыртлатып ябып куйгач һәм тагын да киң елмайган хәлдә Ямькиләгә әйтә куйды:

—Гали—үз юлында, Вәли үз эшендә, дигәндәй, киеним дә ишек алдына чыгыйм әле, хатын. Машина килер вакыт җитеп килә...



Әнвәр
Шәрипов

## КҮКРӘГЕМДӘ КӨН ДӘ БЕР ЯҢАРА...

### Әйләнәм дә кайтам Тукайга...

**Тигез генә бармый безнең тормыш,**
**Эш гел барып тормый уңайга...**
**Эш-гамәлләр авыр барган чакта,**
**Күңелемә азык кирәк чакта**
**Әйләнәм дә кайтам Тукайга.**

**Кулга алсам Тукай китапларын,**
**Күңелләрем китә яктырып.**
**Эзләп табам аның фикерләрен**
**Китап битләреннән актарып.**

**Көтмәгәндә авыр хәсрәт басса,**
**Күңел төшсә көнгә йә айга,—**
**Кайгыларны тизрәк басар өчен**
**Әйләнәм дә кайтам Тукайга.**

**Кайчагында уңыш та елмая,**
**Эшләр бара минем уңайга.**
**Шатлыкларны уртаклашыр өчен**
**Әйләнәм дә кайтам Тукайга.**

**Тукай—йолдыз, Тукай—идеал ул,**
**Минем өчен—кояш һәм аем!**
**Тормышыңны дөрес кичәр өчен**
**Булсын икән шагыйрь Тукаең!**

Әнвәр ШӘРИПОВ (1941)—*галим, шагыйрь; дистәләгән китап авторы. Чаллыда яши.*

## Яшьлегемдә, гүя, яшен сукты...

Яшьлегемдә, гүя, яшен сукты,—
Мин яр сөйдем...
Яшен утларында калып,
Ялкынында янып көйдем.
Яшьлегемдә, гүя, күк күкрәде,—
Мин яр сөйдем...
Дәһшәтле күкрәү алдында
Сүзем әйтә алмас булдым.
Яшьлегемдә таулар иңрәде,—
Мин яр сөйдем...
Мин үземне тау-таш актарырлык
Көчле батыр итеп тойдым.
Кинәт ялгыз калдым...
Ярым үзе белән
Алып китте бөтен дөньямны:
Эчәр суым, басар туфрагымны,
Күкрәк тутырып сулар һавамны...
Шул көннән соң ярты гасыр үтте,
Таба алмадым аңа тиңнәрне...
Күкрәгемдә көн дә бер яңара
Шул ук яшен,
Шул ук күкрәү,
Шул ук таулар иңрәве.

***

Минем йөрәк ничек ашалмасын,—
Тимер булып тимер ашала.
Үз өстеннән бик күп йөк уздырган
Тимер рельслар да таушала.

Күпме йөкләр узды бу йөрәктән,
Күпме шатлык, хәсрәт кичердем.
Тормыш миңа әле татлы шербәт,
Әле агулы су эчерде.

Шербәт суы миңа шифа булды,
Уңай булды,
Эшләсәм дә ул чак ни генә...
Ә борчулар—йөрәк җепселләрен
Тарттырдылар,
Җиткерделәр соңгы чигенә.

Кем белә бит,
Ул җепселләр беркөн
Тартылыр да, шартлап өзелер...
Шул чагында
Минем тирә-якка
Шул шартлаудан чыккан
Бары зыңлау чыңы сибелер...
Күпме вакыткадыр... моң калыр...

***

Җирдәгечә ярату гына түгел миндә...
Күкләрчә, галәмчә ярату да бар...

**Ак болытлар**
**Давылланып-котырынып киләләр дә,**
**Сине баштанаяк каплап китәләр...**
**Ә син,**
**Какшамас булып,**
**Аның эчендә каласың...**
**Бу—минем мәхәббәтем!..**

**Җирдәгечә ярату гына түгел миндә...**
**Диңгезләрчә, океаннарча ярату да бар...**
**Бөтен тирә-юньне, офыкны каплап,**
**Ажгырып-ажгырып киләләр дә дулкыннар,**
**Сине баштанаяк каплап китәләр...**
**Әйтерсең лә цунами...**
**Ә син,**
**Какшамас булып,**
**Аның эчендә басып каласың...**
**Бу—минем мәхәббәтем!..**
**Аңларсыңмы икән син аны?..**
**.......................................................................**
**...Бик авыр түгелме сиңа.**
**Минем хисләрдән?...**

## Бер әбигә хәер бирдем

**Бер әбигә хәер бирдем,**
**Күзләре моңлы иде.**
**Күзләре моңлы булса да,**
**Йөзләре нурлы иде.**

**Кинәт биргән хәер өчен**
**Башта ул аптырады.**
**Хәер акчасын алганда,**
**Куллары калтыранды.**

**Аннан әйтте ихлас белән,**
**Туры карап күземә:**
**«Мине шатландырган өчен,**
**Рәхмәт яусын үзеңә.**

**Аллаһ үзе кабул кылсын,**
**Савабын үзе бирсен!**
**Оҗмах ишекләрен ачсын,**
**Оҗмахка сине кертсен!»**

**Рәхәт булып китте шулчак**
**Ни өчендер җаныма:**
**Кем белә бит, ул әбигә**
**Ярдәмем тигәндер, бәлки,**
**Иң кирәкле чагында.**

**Аерылышкач, бәлки, аның**
**Күзенә яшь тулгандыр.**
**Уйлыйм, бәлки, ул чыннан да**
**Изге әби булгандыр...**

***

**Тыныч кына аккан елганың да**
**Уртасында була чоңгыллар.**
**Кешене син гади дип уйлама,—**
**Аның күңелендә**
**Әле без белмәгән,**
**Тыштан күренмәгән күпме чоңгыл бар.**

**Редакциядән:**
*Каләмдәшебезне юбилее белән ихлас котлыйбыз, исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*

## Печән базары

*Сатирик әсәрләр конкурсы*

Әхәт
Сафиуллин

# ТОРМЫШ ҖАЕ

ХИКӘЯ

Борынгыларның: «Җан биргәнгә җүн бирә».—дигән сүзләре дөрес икән. Бульнистә хирург булып эшләүче Мөстәкыймне генә күрегез! Эшли генә башлаган чагында җүне булу түгел, җаны да чыгам-чыгам дип кенә тора иде, хәзер әнә ничек түгәрәкләнде! Элек оялчан гына егет иде, хәзер исә авызыннан керә, кесәннән чыга!

Шулай бер мәртәбә бик каты эч авыртып эләктем мин ана. «Скурый» алып килде. Алып килде дә... кертеп ташладылар. Коридорга. Бер көн ятам шунда, ике көн. Ә эчнең авыртуына чыдар хәл юк! Актарыла прәме! Әйтерсең аны наркозсыз телгәлиләр. Башта кычкырып карадым, аннары акыра башладым. Ләкин ишетүче юк. Өченче көн дигәндә, Ходайның рәхмәте, яныма:

—Бик авыртамыни соң, улым? Нигә шул тамаша кычкырасың?—дип, идән юып йөрүче әби килеп туктады.

—Чыдар хәлем юк, әби җанашым!—мин әйтәм.

—Синең беркемең дә юкмыни соң?—ди әби.

—Өйдә хатыным белән ике балам бар,—мин әйтәм.

—Алайса нишләп хатының килеп хирурыг белән сөйләшми, үләсең бит, улым, шушында!—ди әби.

—Ни турында?

—Операци турында. Тизрәк операци ясасыннар!

—Соң, минем монда кергәнне беләләр ич монда. Нишләп кемдер килеп сөйләшергә тиеш тагын?!

—Карап торышка акыллы кешегә дә охшаган сыман үзең, ә тормыш җаең белмисең икән...—диде әби, миңа, мондый юләрне беренче күрүем, дигәндәй карап. Берәр туганың килеп сөйләшмичә, сиңа кем операция ясасын?!

—Нәрсә турында сөйләшергә тиеш соң ул, әби?

—«Нәрсә турында, нәрсә турында?..» Операци ясаган өчен акча бирү турында! Шунсыз үлгәнче ятачаксың шушы коридорда!

—Ни сөйлисең, әби?! Бездә дәвалау бушлай ич!

—Бир, улым, телефоныңны, үзем шалтыратам. Килсеннәр дә коткарсыннар сине үлемнән! Акча кызганып ятарлык түгел бит хәлең.—Телефон номерын әйттем дә, карчык, чүпрәк-чапрагын янымда калдырып, китеп барды.

—Өеңә шалтыраттым, улым. хатының хәзер энесен җибәрә. Болай булгач, яшисең, улым!—дип килеп җитте ул бераздан.

—Рәхмәт сиңа, әби!—мин әйтәм..

—Рәхмәтне ашап булмый аны, улым ... Син ни... хезмәтем өчен миңа да, йөз сум булса да, өлеш чыгарырсың инде...

—Бирәм, әби, бирәм! Терелим генә!

Ходайның рәхмәте, бераздан каениш килеп тә житте. Яныма хәтта өске киемен дә салмыйча килеп керде.

—Ничек керттеләр сине болай?!—дим.

—Сакта торучы егеткә унлыкны төрттем дә кереп киттем!—ди бу. Әйтергә кирәк, минем каениш терекөмеш кебек, суга салсаң, судан да коры чыга торган кеше!—Нишләп коридорда ятасың?

—Урыннары юктыр,—мин әйтәм.—Монда салмаслар иде...

—Үзең белән акча алмаган идеңмени соң?

—Мине эштән алып килделәр ич! Нинди акча?! Бездә медицина түләүсез бит!

—Дөрес, медицина түләүсез... Хөкүмәт табибларны бушлай эшләтә мәгънәсендә. Шуңа күрә алар хезмәт хакын сырхаулардан алырга мәҗбүр.

—Андый закон юк!—мин әйтәм.

—Аңа карасаң, бездә сырхау кеше коридорда ятарга тиеш, дигән закон да юк, ә ятасың бит менә! Ярар, сүз көрәштерүдән файда юк, сине моннан исән-сау алып чыгу чарасына керешергә кирәк,—дип, ул, җил-җил атлап, хирургны эзләп китте.

Озак та тормады, килә бу. Үзе генә дә түгел: бер табиб белән ике шәфкать туташын да иярткән!

—Исәнмесез, сырхау!—Карале, таныш та икән әле үзе!—дип елмайды табиб, мине беренче мәртәбә генә күрмәгәндәй, һәм теге ике кызга:—Хәзер үк палатага кертегез!—дип боерды.

«Таныш та икән», имеш! Күршедә генә яши, күрешкәләп, хәл белешкәләп йөрибез бит югыйсә!

Шәфкать туташларының ике кулымнан тотып палатага алып керүләре булды, арттан килүче табиб, ягъни күршебез Мөстәкыйм, мин яткан карават янына утырып, хәл-әхвәлемне сораша башлады. Үзе сораша, үзе анда баса, монда төртә. Ә мин ике көн эчендә яннымнан кырык тапкыр үтеп тә миңа кырын күзен дә төшермәгән, ә хәзер исә саулыгым турында кайгыртуы хәтта йөзенә чыккан бу ак халатлы Мөстәкыймгә гаҗәпләнеп, күзләремне челт-челт итеп карап ятам. Алдымда—Гиппократ антына тугрылыклы кеше!

Ул мине тикшереп-карап бетерде дә бик эшлекле кыяфәт белән: —Аппендицит. Инде шартлау хәлендә. Кичекмәстән операциягә!—диде һәм шәфкать туташларына дәште:—Хәзер үк әзерләгез!

Каениш күз кысып куйды. Шунда тирә-ягыма күз салсам, дүрт кешелек бүлмәдә бер сырхау гына ята.

—Башкаларны бүген чыгардыларммыни?—дип сорадым мин аннан.

—Инде бер атна үзем генә ятам! Сүз алышыр кеше дә юк!—диде ул.

Каениш сүзсез генә тагын күз кысып куйды. Ишеттеңме, янәсе!

Башка сөйләшеп торырга вакыт калмады, ике култыгымнан йомшак кына алып, шәфкать туташлары мине ванна бүлмәсенә алып киттеләр.

Аннары—операция, реанимация. Күзем ачсам, янымда бер кеше дә юк! Ә авыртуга түзәр хәл юк! Әллә, мин әйтәм, аппендицит урынына башка нәрсәне кисеп алдылармы икән? Бу уемнан куркыныч булып китте. Кычкыра торгач:

—Нигә акырасың? Ни кирәк?—дип, чәчләренә бигуди куйган чибәр генә бер шәфкать туташы килеп керде.

—Бигрәк авырта, сеңлем,—мин әйтәм,—шуны басар укол бирсәнче!

—Карале, кара, хатыныннан таләп итәмени! Син өеңдә түгел, абзый, ә ре-а-ни-ма-ци-я-дә. Ә монда кычкырырга ярамый. Юкса яраң озак төзәлер, моннан

тиз генә котыла алмассың,—диде чибәр кыз һәм озын нәфис бармаклары белән чәчләрен рәтли-рәтли чыгу юлына юнәлде. Артыннан:—Юк бездә андый дару. Тыныч кына ят! —дигән сүзләре генә ишетелеп калды.

—Юкка телегезне әрәм итмәгез! Әнә тегене дә алып чыгып китмиләр әле,—диде шунда берәү, нинди дер аппарат янындагы караватка таба ымлап.—Кичә үк җан тәслим кылган иде югыйсә...

Тәнемә салкын йөгерде. Шөкер, мин исән бит әле! Авыртуга гына түзәрмен! Шуннан соң, беркемне дә борчымадым, мине дә борчымадылар: ничек салдылар, шулай ята бирдем.

—Йә, хәлләр ничек?—дип сорады иртән күршем, аңа шәфкать туташы укол ясап чыгып киткәч.—Син төртмәденме әллә? Синең якка борылып та карамады...

—Нәрсәне?

—Нәрсәне, дип... акча инде, туган, акча. Савыгып чыгасың, килсә...

—Без хирургка...

—Анысы операция өчен бит аның. Ул үзенекен эшләде дә, аның эше бетте. Мондагылар башка бит.

—Димәк, монда да бирергә кирәк?!

—Яшисең килсә, кирәк, туган, кирәк! Төртсәң җаның тыныч. Әллә аларның авыртуны баса торган дарулары юк дип беләсеңме?

—Юк, диде ич.

—Бигрәк беркатлы кеше икән син! Соңгы вакытларда мондый җирдә бер дә ятарга туры килмәдеме әллә?

—Шөкер, туры килмәде. Ходай күрсәтмәсен дә...

—Шуңа белмисең син безнең хастаханәләрдәге хәлләрне. Хәзер монда һәр нәрсә өчен түләргә кирәк, туган!

—Бездә медицина бушлай дигән законны беркемнең дә юкка чыгарганы юк бит әле!—мин әйтәм.

—Дөрес әйтәсең: хәзерге мизгелдә син дә бушлай дәваланып ятасың—янына килеп карау чы да юк! Бушлай медицина дигәне менә шушы инде ул, туган.

—Алай булгач, нишләп реанимациядә тоталар, нигә палатага чыгармыйлар? Анда палата табибы карар иде...

—Тәртибе шулай: операция—реанимация—палата. Әллә анда чыккач дәвалый башлыйлар дип беләсеңме?! Өенә сау-сәламәт кайтасың килсә, анда да төртергә кирәк бит, туган...

Шунда аңымны җуйганмын. Табиб күршем чакыртып игә китерткән. Кесә телефоны бар икән, каенишкә чылтыратып алды. Ә ул килеп тә җитте, кием-ние белән реанимациягә килеп тә керде. Күзем шар булды!

—Ничек керттеләр сине монда?!—мин әйтәм.—Монда бит...

—Ишек төбендәге сакчы егет белән уч төбемә йөзлекләр салып күрештем,—дип елмайды ул.—Хәзер акчаң булса, Мәскәү Кремленә дә кереп була! Йә, нинди проблема туды?

Сөйләп бирдем. Ул бу юлы да җил-җил атлап тагын кемнедер эзләп китте. Бераздан карыйм, ак халатлы өч кешене ияртеп килә бу! Хәтта халатлылар аннан алданрак та йөгерәләр. Шушы минуттан башлап китте дәвалау, китте дәвалау: кайсы укол кадый, кайсы система куя. Тиз генә чакырып китергән теге чибәр туташ хәтта массаж ясый башлады.

Шөкер, хастаханәдән савыгып чыктым. Анысы да бер хәл, иң мөһиме—тормыш җаена төшендем мин анда!

❋

# Рүзәл Мөхәммәтшин

## Яңа тормыш

**Брат, авылда хәлләр әле,**
**искитмәле, түз генә!**
**Калхузыбызны җимереп,**
**«инвистыр» төзеделәр,**
**Һәрбер үзгәреш—яхшыга,**
**дөрес сүзләр бу, ышан:**
**Хәзер иркенрәк сулыйбыз—**
**дириктыр шулай куша.**
**Хәзер үзгә заман... Хәзер**
**тарантаста йөрмиләр,**
**Хәзер хезмәт хакын хәтта**
**майонезлап түлиләр,—**
**Эшлә генә! Бригадир—шат,**
**елдан-ел арта табыш,**
**Һәм табигый: көн аралаш**
**ул исерек йә салмыш.**
**Шулчак шатлыгы арышка**
**бәя күк арта аның:**
**Берәүнең кашын җимерә,**
**икенченең—яңагын.**
**Ә иң мөһиме—стабильность**
**безгә барыбер килде:**
**Кесә хәзер дә буш менә,**
**моңарчы да—буш иде...**
**Тукта, шире карыйк, дустым,**
**син кыбырсыйсың—яшь ич,**
**Әнә кичәге заффирмы**
**бүген хан кебек яши...**
**Дириктыр һәр авыл саен**
**яңа кибетен ача,**
**Бригадир да... Ләкин бусын**
**сөйләмим, холкы начар,**
**Килер бер көн!—Сабаннардан**
**башын күтәрер ир-ат:**
**«Кыйммәтле шәрабларга күк**
**безгә дә җитәр чират».**

**Йә, тартып бетердем... син дә**
**Аллаһтан шуны сора...**
**Ә әлегә—гафу—минем**
**мал астын кырасым бар.**

# ТАТУЛЫК ТА, ГОРУРЛЫК ТА КИРӘК!

...Троллейбустан чыгыйм дип ишеккә таба күченеп маташканда киерелеп утырган бер юан хатынның чәченә җиңем белән ялгыш кагылып киттем. Гадәтемчә, түбәнчелек белән: «Простите,»—дидем. Җавап итеп хатын, кып-кызыл симез иреннәрен шапылдатып: «...мать! Какой беспардонный!»—дип кычкырды.

Ачуым дөрт итеп кабынып китте. Мин бит, аны әдәпле кешегә санап, гафу үтенеп торам! Хәзер үзеннән дә җиллерәк итеп җавап бирәм!

Беренче теләгем шундый иде. Ләкин икенче мизгелдә, үземне кулга алып, чыгу ягына юлымны дәвам иттем. Чөнки:

—үзегенә үткәзеп мыскылларлык сүзләрне күп белсәм дә, аларны телемнән ычкындырырга горурлыгым да, кечкенәдән тәрбияләнгән ихтирамлы холкым да рөхсәт итми миңа;

—тупас сүз әйтергә җыенган мәлдә «корбан»ымның йөзенә карыйм да, ул нинди сөйкемсез булса да ирексездән аның эчке дөньясына кереп киткәндәй булам. Бәлки, ятим, кырыслыкта үскән бәндәдер бу, назлы сүзләрне ишеткәне дә, әйткәне дә юктыр. Бәлки, кризис сәбәпле эшеннән куып чыгарганнардыр аны. Бәлки, ире эчәдер, йә баласы наркотикларга һәвәсләнгәндер.—Менә, башыма шундый уйлар килә дә, кызганып, авыр сүз әйтүдән тыелып калам;

—аннан соң, үч алуның кемгә нинди файдасы бар? Ул, минем нервыларымны какшатып, гомеремне берничә сәгатькә кыскартты да ди, ә аның гомерен кыскартуда миңа нинди мәгънә бар?

Менә шундый уйлар кыска гына вакыт эчендә узып китә дә башымнан, чираттагы тупаслыкны җавапсыз калдырам. Мине белгән кеше аңлый моны. Белмәгәннәр—мескен, телсез, бозау дип уйлыйдыр, бәлки.

«Бәйдән ычкынган» бәндәләргә шундый мөнәсәбәт бер миңа гына хас сыйфат түгел ул. Гомумән, татар гаиләсендә тәрбияләнеп үскән һәм тиешле дәрәҗәдә аң-белем алган һәр кешенең сүзе уйларын узып йөгерми, шуның өстенә әйләнә-тирәдәгеләргә ягымлылык ата-аналарыбыз тарафыннан каныбызга сеңдерелгән безнең. Балачагыбыз динсез чорга туры килсә дә, безнең буын рухи азыкны гасырлар буе ныгыган шәригать кануннарының, әхлак принципларының корып бетәргә өлгермәгән тамырлары аша алып үсте.

Хәер, рус телен үз телем кебек белсәм дә, шакшы сүзләрне «профессиональ» рәвештә әйтергә сәләтем чамалы. Рус теленә генә хас үзенчәлекләрне ачуым килгән чакта бутавым мөмкин дип уңайсызланам. Ә бутасам («ты сама» урынына «ты сам» дисәм, мәсәлән) – абруемны җуям.

Бу, әйе, соңгы елларда татар матбугатында күп яктыртылган тема: совет заманында тәрбия идеологиясе кечкенәдән безне рус культурасыннан, рус сыйфатыннан үрнәк алуга өндәп торды. (Рус культурасы, аеруча әдәбияты, үрнәк алуга чынлап та лаек, тик үрнәк алу процессы үзара, кара-каршы булырга тиеш. Ләкин бүген сүзем бу хакта түгел.) Гадәти көнкүрештә безне әбиләребез кырын эшләребез өчен «урыс» дип тиргәсә дә, рәсми тәрбия йогынтысы гаять көчле булды: милләтара мөнәсәбәтләр, «дуслык» төшенчәсе белән генә чикләнмичә, «өлкән агай»ның казанышларына табыну дәрәҗәсендә булырга тиеш иде. Шуңа күрә руслар арасына эләккән татар малае, аң-белеме, эшчәнлеге җәһәтеннән югарырак торса да, тегеләргә ирексездән олылап карый, ә тегеләр, үзләренең

өстенлегенә ышанып, моның табигый тыйнаклыгын зәгыйфьлек дип кабул итә, шуннан килеп аңа карата түбәнсетүле мөнәсәбәт («Ну что, Наильчик, как дела, мой дорогой татарчонок?»), йә ачыктан-ачык типкәләү, санга сукмау мөнәсәбәте туа. Холкың ни кадәр генә нык булмасын, җәмгыять йогынтысы үз эшен эшли: күпләр тора-бара үзләрен түбәндәрәк кимәлдәге кеше итеп сизә башлый һәм, бу нәтиҗәне тулысынча аңлап, аныклап тәкъбирләргә өлгермәсә дә, тагын да тирәнрәк үз дөньясына бикләнә, шуның белән «агайлар»ны тагын да йөгәнсезләнергә котырта.

Шуның өстенә, «тел киртәсе» дигән нәрсә дә бар. Күпләребезнең бит татар акценты сизелеп тора, һәм бу еш кына әйләнә-тирәдә шаярту катыш мәсхәрәләп көлүгә сәбәп була. Берәү шулай «извиняюсь» урынына «извинаюс» дигән иде, коллегаларына озаклап үчекләү өчен шул җитә калды. Үчекләгән адәмнең тотнаксызлыгы аңа үз-үзен бүтәннәр урынында фараз итеп карарга мөмкинлек бирми инде. Юкса телгә сәләте буенча да, башка сыйфатлары буенча да һич өстен булмавын аңлар иде ул. Юк, аңламый.

Әмма без аңларга тиеш.

Институтның беренче курсында укыганда, Казанга авылдан килгән малайлар, үзара татарча сөйләшә башласак, төркемдәшләребез (шулар арасында үз телен белмәгән татарлар да, хәтта алар аеруча да әле), йөзләрен чытып: «Ах, нинди әдәпсезлек! Без сезнең телне белмибез бит, үзегезчә сөйләшеп, безне санга сукмавыгызны күрсәтәсез!»—дияләр иде. Бәлки, күпмедер дәрәҗәдә хаклы да булганнардыр, ләкин менә шул сүзләрне әйткәндә нигә йөзләренә җирәнү кыяфәте чыга иде икән аларның? Ә безнең тарафтан хәтта шундый очракларда да: «Белмәсәгез, өйрәнегез, татар җирендә яшисез бит,»—дигән кеше табылмады.

Бер рус дустым күптән түгел, минем күңелне күрергә теләп булса кирәк: «Сезнең җырлар арасында да матурлары очрый кайчак,»—дип ычкындырды. Менә сиңа мә! Минем, мәсәлән, фин егетенә андый сүзне әйтергә юләрлегем җитмәс иде, чөнки фин җырларындагы милли төсләр, үзенчәлекләр миңа таныш түгел, шуңа күрә мин ул җырларны яратмыйм түгел, аңламыйм. Финнәргә якынрак яшәсәм, кызыксынып, аңларга тырышыр идем мин ул җырларны, һәм аңлау аркылы матурлыгын да күргәч, ярату да туар иде. Һәрхәлдә, «сезнең кайбер җырларыгыз гына матур,»—дип кимсетергә, валлаһи, башыма да килмәс иде.

Без читләргә түбәнсетеп, ачу тотып түгел, кызыксынып, аңларга тырышып карарга күнеккән. Ләкин бу гүзәл сыйфатыбыз милли горурлыгыбызны, дәрәҗәбезне кысрыкларга тиеш түгел. Безгә, рус дәүләтендә яшәүче татарларга, русча сөйләшүебезнең кытыршылыгын да, «өлкән агайлар»ның әрсезлеген дә тормышта киртә итәргә ярамый. Әдәпсезләр һәр милләттә дә бар ул, ә русларның саны гомумән күп булганга, алар тарафыннан бу аеруча нык сизелә. Моның сәбәбе—бергә яшәгән кешеләр белән кызыксынмау һәм кызыксынырга омтылмау. Берәү (укымышлы кеше, инженер) сорый: «Син кайсы якныкы?»—ди. «Казаннан,»—дим. «Ә-ә, син казахмени?» «Юк,—мин әйтәм,—татар.» « Мин Казанны казах каласы дип уйлый идем,»—ди. «Молодец,»—диюдән башка сүз тапмадым.

Икенчесе, кулын хуҗаларча җилкәмә салып: «Казанда булганым бар, -диде.—Матур шәһәр.» «Матур һәм зур шәһәр,—мин әйтәм,—гасырлар буе Русиянең өченче башкаласы дип санала.» Хахылдап көлде әңгәмәдәшем. Гади тәкәбберлеге ачык мыскыллауга әверелде: «Минем авыл беренче башкала булса, Казаның була ала инде өченчесе.» Соңрак, «Наука и жизнь» журналының утыз еллап элек чыккан бер санын табып, Россия шәһәрләрендә яшәгән халыкның чагыштырма санын күрсәтеп, тарихи мәгълүматлар белән таныштырдым үзен. Шулай да, инде шаярткан булып: «Татар язгандыр бу мәкаләне,»—дип әйтмичә түзмәде ул.

Мин ел саен шәһәребезнең мәдәният сарайларының берсендә үземнең иҗат кичәмне үткәрәм. Рус дусларым бик күп, русча язган шигырьләрем дә байтак, шуңа күрә тамашаны алып бару да өлешчә рус телендә була. Туган телемдә язылган шигырьләремне укыганда аларның русча мәгънәсен кыска гына итеп әйтеп барам, әмма җырларны, билгеле, тәрҗемәсез җырлыйм. Кичәдән соң канәгатьсезлек белдерүчеләр дә табыла: «Концертың әйбәт, ләкин җырларыңны русчага күчермәдең, аңламадык,»—ди берсе. Икенчесе, баш кагып: «Әйе,—ди,—мондый кыланышың милләтчелек була бит инде ул, безгә ихтирамсызлык бу.» «Гаҗәп,—мин әйтәм,—Патрисия Каас, Майкл Джексон җырлаганда тәрҗемә кирәкми, ул ихтирамсызлык түгел, ә татар кыланышы -милләтчелекмени?» «Ну, это разные вещи,»—диләр.

Күп еллар элек, Чиләбедә тулай торакта яшәгән чагымда, мине эзләп бер иптәшем килде. Ишек аша тавышын ишеттем—комендант белән сөйләшә: «Сабиров монда торамы?»—ди. «Фамилиясенә караганда, мондадыр,—ди комендант,—бездә бер генә нацмен яши, шуның турында сорыйсыңдыр.» Моңа кадәр бу сүзне ишеткәнем булмаганга, мин башта аптырап калдым, аның «нацист» сүзенә охшаган булуы йөрәгемне тетрәндерде. Аннары, аңлап, ямансулап елмаеп куйдым: бу адәм өчен татары да, башкорты да, марые да юк икән, барысы да—«нацмен.» Миңа—илнең кайсы гына почмагына барырга туры килсә дә, шунда яшәгән халыкның мәдәнияте, тарихы белән кызыксынып, телләрен әз генә булса да үзләштереп кайтырга яраткан фәкыйрегезгә—мондый ваемсызлык әллә нинди кыргыйлык булып тоелды.

Хәер, андый кешеләр үз мәдәниятләрен дә бик начар белә бугай. Шәһәребез гәзитендә минем рус телендә чыккан парчаларымны укыгач, танышлар: «Синең статьяңны укыдык,»—дисәләр, гаҗәпләнмим, чөнки әдәбият жанрларын белүчеләр безнең заманда күп калмады. Әмма бөек рус классикларын бутаулары исә мине тәмам шаккаттыра. «Гомер буе русларны рус культурасына өйрәтеп яшим,»—дим, шаяртkан булып. Алар оялган булып елмаялар.

Боларны мин кимсенеп, йә ачуым чыгып язмадым. Максатым ни? Бәлки, татар авылында туып-үсеп, зур шәһәрдә яши башлаган берәр малайга үз-үзенә ышанычын, үзенең чын абруен, горурлыгын саклап калырга ярдәме тияр бу язмамның? Бәлки, руслар белән аралашып яши башлаган Илгизләребез, Мидхәтләребез болай ансат һәм тиз генә Илюшалар, Мишкалар булып китмәсләр? Безне язмышыбыз күп милләтле илдә яшәргә дучар иткән, һәм милләтара ягымлылык, татулык белән бергә милли горурлык дигән нәрсәне дә югары тотарга кирәк безгә.

**Ирек САБИРОВ**

---

## Электрон почта да төпсез түгел

Редакциягә әсәрләр, мәкаләләрнең фәкать машинкада басылган яки компьютердан чыккан кульязмалары гына кабул ителә. Бер биттә 30 юл (компьютер текстында да!), бер юлда (сүз араларын да исәпләп) 60 тамга булырга тиеш. Кәгазьнең бер ягы буш кала. Машинка текстының беренче нөсхәсе генә кабул ителә. Компьютер текстының дискеты да булу кулай.

Хатлар исә, жинел танылырлык итеп, кулдан да язылырга мөмкин.

Редакциянең электрон адресына фәкать кечкенә күләмдәге язмалар (хатлар, документлар, фикерләр һ.б.) гына кабул ителә.

Электрон адреска күләме 5 биттән арткан язмалар жибәрелгән очракта, почта аша аның оригиналын (кәгазьгә басылган вариантын) алгач кына әсәр кабул ителгән санала.



Язучыларның әдәби ел йомгакларыннан соң. Тукай клубы. 1964 ел.



Шагыйрь Илдар Юзиев сәхнәдә. 1989 ел.



Язучы, мөхәррир Зиннур Хөснияр.



Язучы һәм җәмәгать эшлеклесе
Мирсәй Әмир (1907-1980).



Күршеләр (уңнан сулга): «Казан утлары» журналының бүлек мөхәррире, язучы сатирик Камил Кәримов һәм «Татарстан яшьләре» газетасының баш мөхәррире Исмәгыйль Шәрәфиев. 2009 ел.

# ГРАММОФОН ТӘЛИНКӘЛӘРЕ НИ СӨЙЛИ?

Татар эстрадасында күнел ачу музыкасының барлыкка килүе һәм кайсы дәвергә каравы, концерт эшчәнлеге башындагы булган үзенчәлекләр, башкаручылар һәм аларның репертуары турында «Казан утлары» журналы битләрендә мин үземнең «Татар җыры–йөз ел элек» дип аталган мәкаләмдә язып чыккан идем инде[1]. Анда йөз ел элек халкыбыз тыңлаган көй һәм җырлар, аларны башкарган җырчылар турында белер өчен төрле чыганакларга мөрәҗәгать итү кирәклеге әйтелде. Алар арасында иң мөһиме, әлбәттә, сүз нииндидер могҗиза аркасында сакланып, бүгенгә көнгә кадәр килеп җиткән йөз еллык граммофон тәлинкәләре турында барды. Граммофон музыкасының меңнәрчә тираж белән чыгарылуы, аны төрле милли басмаларда рекламалау, ул тәлинкәләргә кергән җырлар һәм көйләрнең каталоглары булуы–болар барысы да күп нәрсәләр турында сөйли. Өстәп шуны әйтергә кирәк, төрле чыганаклар, истәлекләр аша без ул чордагы җырчыларның һәм музыкантларның концерт репертуарын, тәлинкәләргә язган җыр-көйләре турында күпмедер дәрәҗәдә белә алабыз. Ләкин ул башкаручыларның, беренче чиратта, безне кызыксындырган җырчыларның тавыш тембрларын, җырлау стиле һәм эмоциональ көйләнешләрен ачыклау өчен безгә, әлбәттә, шул граммофон язмаларның булуы зарур. Чөнки җырның тере яңгыравышы беркайда да теркәлмәгән икән, музыка-башкару сәнгате өчен бу күренеш мәңгелеккә югалган дигән сүз.

Соңгы елларда татар музыкасы язылган граммофон тәлинкәләре белән кызыксынуым үзенең актуальлеген югалтмады, киресенчә, мин яңа дәрт белән эзләнүләрне дәвам иттем. Ул гына да түгел, соңгы ике-өч ел эчендә бу юнәлештә яңа чыганакларга тап булдым, үзем өчен яңа ачышлар ачтым. Иң мөһиме, Октябрь революциясенә кадәр татар музыкасы өлкәсендә граммофонның зур роль уйнавы турындагы караш яңадан-яңа дәлилләр белән баетылды. Казанда һәм башка төбәкләрдә, Мәскәүдә, чит илләрдәге булган чыганаклар белән тирәнрәк танышырга туры килде. Татар мәркәзе Казан шәһәрендә граммофон тәлинкәләренең төрле архивларда һәм фондларда сакланулары турында да шактый мәгълүмат тупланды. Революция чорына кадәр чыккан тәлинкәләр Татарстан Республикасының Милли китапханәсе фондында, Г.Ибраһимов ис. ТӘһСИ фондында, Татарстан Республикасының Милли музее һәм Г.Тукай музее фондларында саклана лар. Татар җырчыларының һәм музыкантларының граммофон тәлинкәләреннән магнит тасмага күчерелеп, соңыннан цифрга әверелдерелгән 30га якын язмасы «Татарстан–Яңа Гасыр» каналы фондында урын алды.

Мәскәү шәһәрендә урнашкан Россия дәүләт фонодокументлар архивының (РГАФД) төп каталогы белән танышу да эзләнүләрне өстәмә чыганаклар белән тулыландырды. Анда XX гасыр башына кагылышлы бик күп санлы татар язмаларының булуы ачыкланды. Илебезнең иң зур архивларының берсе булган бу фондта башкаручыларның исемнәре, аларның репертуары теркәлгән граммофон

[1] Татар җыры – йөз ел элек. // Казан утлары.2008. №10. – С.153-165.

пластинкаларын ачыклау, барлау, безнең өчен татар музыкасы өлкәсендәге башкару сәнгате барлыкка килү дәверен билгеләү юлында, һичшиксез, кыйммәтле чыганак булып торалар.

Эзләнүләр барышында миңа граммофон музыкасының тарихы белән кызыксынган, бу юнәлештә житди эш алып барган, АКШта яшәгән коллекционер Юрий Берников әфәнде белән танышырга туры килде. Аның белән аралашуымның нәтижәсе–граммофон өлкәсендә әлегә кадәр минем өчен билгеле булмаган чыганакларны ачыклау[2]. Шулар арасында–Октябрь революциясенә чаклы Россиядәге граммофон язмаларының тарихын өйрәнү юлындагы житди чыганакларның берсе, дөньяның иң күренекле дискографы һәм «Граммофон Компаниясе»нең тарихын өйрәнү буенча танылган инглиз эксперты Алан Келли төзегән каталог. Аның рус телендә тулы исеме «Полный каталог русских граммофонных записей, сделанных Граммофонной Компанией с 1899 до 1928 года в России и за рубежом« дип атала. А.Келли үзенең 50 елдан ашу гомерен «Граммофон Компаниясе» чыгарган граммофон язмаларының детальләштерелгән дискографиясен төзүгә багышлаган. Озак еллар ул бөтендөнья музыка өлкәсендә абруйлы булган EMI компаниясенең архивларында эшли һәм андагы гроссбухлардагы материалларның күчермәләрен алып, аларны структура ягыннан эшкәртеп дискографияләр формалаштыра. Бу дискография-каталогларны төзү принципының нигезен тел, географик өлкә һәм иң мөһиме, һәрбер граммофон тәлинкәсе турындагы технологик чыганаклар тәшкил итә.

А.Келлиның «Рус каталогы»ндагы безнең өчен аеруча кыйммәтле әйбер, ул да булса, автор анда аерым очракларда язмаларның даталарын көненә кадәр төгәллек белән китерә. Без анда каталог номерлары һәм тәлинкәләрнең матрица номерларын, язмалар сессияләре барган шәһәрләрнең исемнәрен, хәтта жырчыларның нинди аккомпаниаторларга кушылып башкарулары турында мәгълүмат алабыз. Шундый төгәллек белән жыелган материал, башкаручыларның, беренче чиратта безнең татар жырчыларының һәм музыкантларының граммофон музыкасы өлкәсендә эшчәнлекләрен тулыландыру юлында әлегә кадәр билгеле булмаган фактларны ачуы әйтеп бетергесез роль уйный.

Граммофон музыкасы буенча барган эзләнүләр юлында күптән түгел мин үзем өчен гажәеп бер чыганак белән якыннан таныштым һәм... шаккаттым. Безнең илдә генә түгел, ерак чит илләрдәге китапханәләрдә, архивларда, шәхси коллекцияләрдә татар тарихына һәм аның мәдәниятенә кагылышлы материаллар булуын ачыклап, аларны бик озак еллар дәвамында өйрәнәсе бар әле. Озын сүзнең кыскасы, Франциянең Милли китапханәсенең (артабан, ФМК) аудиовизуаль документлар департаментындагы музыкага кагылышлы 550 граммофон тәлинкәсе арасында XX гасыр башындагы популяр татар жырчыларының һәм музыкантларының 1911 елда «ПАТЕ» ширкәте чыгарган ике яклы 27 татар тәлинкәсе булуы ачыкланды[3]. Бу коллекция ярдәмендә безгә татар башкаручыларының моңа кадәр билгеле булмаган граммофон язмалары белән танышуның уникаль бер мөмкинчелеге туды. Монда жырчылар Камил Мотыйгый-Төхфәтуллин, Мәрьям Искәндәрова, Мирфәиз Бабажанов, Хөсәен Йосыпов, Фатыйма Моратова, Нәфисә Позднякова (Пснякова), Хәдичә Гимбитская башкаруында төрле жанрдагы жырларның язмалары тупланган. Татар театр сәнгатенең барлыкка килүе һәм аның үсешен күзаллау юлында бу коллекциядә татар театрына нигез салучыларның берсе, күренекле актер һәм режиссер Габдулла Кариевның тавышы язылган тәлинкәләрнең булуы да безнең өчен куанычлы. Бу язмалар XIX-XX гасырлар чигендә татар жырчыларының һәм музыкантларының башкару эшчәнлеген яңачарак анализларга мөмкинчелек бирә. Шуның өчен дә бу мәкаләдә мин нәк шул язмаларга жентекләбрәк тукталып китүне максат итеп куйдым.

Граммофон тәлинкәләрен өйрәнгәндә безне һәр тәлинкәнең детальләштерелгән мәгълүмат блогы игътибарны үзенә жәлеп итә. Тәлинкәнең этикеткасы үзе дә бер

[2] Монда Ю.Берников әфәндене www.russian-records.com сайтының авторы икәнлеген әйтеп китәргә кирәк.

[3] Bibliothegue nationale de France,departement Audiovisuel (BnF)

кыйммәтле чыганак: анда граммофон ширкәтенең исеме (Диск «ПАТЕ»), патент, каталог һәм матрица номерлары, җырның, көйнең, яисә укылган әсәрнең исеме, башкаручы, яисә башкаручыларның исемнәре, кайчакта аккомпанименты турында да мәгълүмат язылган. Билгеләп үтәргә кирәк, бу мәгълүмати язмалар дискның урта өлешенә, башка граммофон ширкәтләренең тәлинкәләреннән аерылмалы буларак, гравировка ысулы белән язылып, андагы хәрефләр һәм саннар өстән буяу белән буялган булган. Этикетка өстенә кечкенә генә кәгазьгә ФМК архивының номеры беркетелгән. Фондтагы граммофон язмаларның сыйфаты да яхшы гына, граммофон тәлинкәләренә хас булган шытырдау-чыжлаулар анда юк дәрәҗәсендә. Монда «Пате» ширкәтенең заманы өчен бик тә прогрессив булган тавыш чыгару системасы белән эш алып баруы турында әйтеп узарга кирәк. «Пате» ширкәте чыгарган уйнаткычларны фирма исеме белән бәйләп «патефон» дип атаганнар. Башка граммофоннардан ул принципиаль ягы белән аерылып торган. Тавышның дулкыннары тәлинкәнең буразнасына гадәттәгечә горизонталь яссылыкта түгел, ә вертикаль юнәлештә язылып, буразнаның төбендә урнашкан булган. Патефон аппаратына тавыш буразналардан тимер энә аша түгел, ә сапфир ташы беркетелгән мембрана аша җиткерелгән. «Мәңгелек энә» дип атаганнар аны. Ул гына да түгел, башкалардан аермалы буларак, «Пате» уйнаткычының тавыш алдыра торган башы минутына 90-100 тапкыр әйләнгән тәлинкәнең буразнасы буйлап тыштан эчкә таба түгел, ә хәзерге заман компакт дисклардагы кебек уртадан (этикетка ягыннан) читкә таба йөргән. Бу яңа катлаулы һәм чыгымлы технология белән «Пате», беренчедән, үзенең тәлинкәләренең яңгырау сыйфатын күтәргән[4], икенчедән, язмаларының башка конторалар тарафыннан законсыз күчермәләрен эшләүгә киртә куйган, хәзерге заманча әйткәндә «пиратлыкка» каршы чыккан.



*XIX-XX гасырларда кулланышта булган граммофон.*

ФМК фондындагы «Пате» ширкәте тәлинкәләре арасында XX гасыр башындагы җырчыларның иң күренеклесе булган К.Мотыйгый-Төхфәтуллинның язмалары табылуы аеруча кадерле. Ул шәхеснең граммофон музыкасы өлкәсендә байтак эшләгәне безгә мәгълүм. Ә аның иҗатын якыннан өйрәнгәндә миңа беренче чиратта язма чыганакларга, җырчының замандашларының истәлекләренә таянып эшләргә туры килгән иде. К.Мотыйгый-Төхфәтуллинның әлегә кадәр безгә билгеле булган язмаларына килгәндә, алар күп түгел. Алар арасында граммофон тәлинкәләреннән магнит тасмасына күчерелеп Татарстан радиосы фондында җырчының бер көйне төрле сүзләр белән җырлау традициясе калыбында фортепианога кушылып башкарган «Ашказар», «Тәфтиләү», «Баламишкин», «Корсын, балам, бу кала», «Тотса мәскәүләр якаң» җырларының язмалары саклана. Казанның Г.Тукай музеенда, К.Мотыйгый-Төхфәтуллин укуында Коръән аятьләре язылган граммофон тәлинкәсенең булуы да безнең өчен яңгыравышлы кадерле бер экспонат[5].

Ә инде К.Мотыйгый-Төхфәтуллин башкаруында ФМК фондындагы ун язма

[4] «Новости Граммофона» дигән журналның 1908 елдагы март аеның 3нче санында шундый реклама урнаштырылган: «Сенсационная новость «Патефонъ»! Единственная говорящая машина, имеющая мембрану съ постояннымъ сапфиромъ. Нет иголки, нет шума, нет шипения, нет изнашивания пластинки, нет ненормального звука. Мембрана Патэ с вечным сапфиром».

[5] Тәлинкәнең этикеткасында түбәндәге текст язылган: «ZONOPHONE RECORD», изготовлено О-омъ «Граммофон» съ. огр. отв. въ Риге. KAZAN TARTARIAN. Сура изъ Аль-Корана, X-101149, К.Тухватуллинъ; Фатиха изъ Аль-Корана, X-101150, К.Тухватуллинъ.

теркәлгән биш граммофон тәлинкәсе безнен эзләнүдә әйтеп бетергесез дәрәҗәдәге кыйммәтле чыганак. Шунысы кызыклы, тәлинкәләрнең этикеткасында җырчының исеме төрлечә язылган. Икесендә Камиль Мутыги диелсә, калганнарында –К.М.Тухватуллинъ дип куелган. Г.Тукай музеендагы тәлинкәдә–К. Тухватуллинъ дигән язу тора. Төрле шәһәрләрдә үзләренең граммофонга язу эшчәнлеген алып барган компанияләрдә эшләгән техниклар, исәп алып баручылар башкаручының исемен шулай төрлесе төрлечә теркәгән күрәсең.

XX гасыр башындагы басма чыганакларга һәм җырчы турындагы истәлекләргә таянып без К.Мотыйгый-Төхфәтуллин репертуарын, аерым чыгышларының программаларын күз алдына китерә алабыз алуын. *Ләкин* ничек кенә булмасын, җырчының тавышы, тембры, аның башкару стиле һәм төрле жанрларга караган җырлар теркәлгән язмалардан башка аның профессиональ музыка сәнгатендәге урыны турында объектив фикер әйтү кыенрак булыр иде. Ә бит тарихтан билгеле, җырчының иҗатына тискәре караш булмады түгел, булды. Ул караш революциягә кадәр үк башланып, совет чорында, аеруча XX гасырның 30нчы елларында төзә алмаслык кыерсытулар К.Мотыйгый-Төхфәтуллинны үз-үзенә кул салуга китерде. Шуның өчен дә җырчының безнең карамактагы язмалары аның башкару иҗатын берникадәр ачыкларга, бу иҗади шәхеснең эшчәнлегенә дөрес бәя бирергә, нинди дәрәҗәдә аны акларга ярдәм итәрләр дип ышанасы килә.

Истәлекләргә нигезләнеп шуны билгеләргә кирәк: К.Мотыйгый-Төхфәтуллин, гадәттә, үзенең концерт программаларының үзенчәлекле эпиграфы итеп Н.Думави шигыренә «Дөньяда» исемле җырын куя торган була. Җырчының безнең игътибардагы фортепианога кушылып башкарылган «Дуньяда»[6] исеме астындагы язмасы ФМК фондындагы АР-1748 санлы тәлинкәдә теркәлгән. Бу җырда К.Мотыйгый-Төхфәтуллин үзен тормыш кыйммәтләре турында тирән фикер йөрткән, байлар һәм фәкыйрьләр тормышындагы тигезсезлеккә, гаделсезлеккә каршы чыккан кеше булып күз алдына килеп баса. Гимн характерындагы бу җыр түбәндәге юллар белән башланып китә:

*Без килмәдек китәргә, дөньяга,*
*Килдек гомер итәргә шул, вай дөнья.*
*Ләкин тормыш гозурга, дөньяда,*
*Кыен гомер итәргә шул, вай дөнья...*

Композитор, фольклорчы Солтан Габәши үзенең «Татар сәхнәсендә музыка» дип аталган мәкаләсендә татарлар арасында профессиональ җырчыларның килеп чыгуы турында язганда К.Мотыйгый-Төхфәтуллинны «концертчыларның ин элек килеп чыгучыларыннан» дип билгели. Шул ук вакытта С.Габәши, җырчының «күбрәк рус көйләрен алып, шул көйләргә җиңелчә көлке яки көлкегә юнәлдерелгән татар сүзләрен җырлап килде һәм шуның белән татар дөньясына танылды» дип яза[7]. Шуны истә тотарга кирәк, С.Габәшинең бу мәкаләсе 1926 елда, К.Мотыйгый-Төхфәтуллинның иҗаты тарафына совет тәнкыйте уклары ява башлаган чор белән бәйле. Җырчының граммофон язмаларын тыңлаганда ул җырлаган җырларның эчтәлеген өйрәнгәндә, аларны «күбрәк җиңелчә көлкегә» корылган, җиңел-җилпе диеп бер дә кабул итеп булмый. Киресенчә, без шунысын ассызыклап үтәргә тиешбез: сакланган язмаларның барысы да дип әйтерлек, К.Мотыйгый-Төхфәтуллин башкарган җырларның социаль юнәлешле булуын күрсәтә, аларның кыюлыгы һәм җитдилеге дә көн кебек ачык. Монда җырчының публицист, журналист булуы да, аның гражданлык позициясе дә үзенең якты чагылышын таба. Түбәндәге мисаллар да моны ачык дәлилли.

Менә К.Мотыйгый-Төхфәтуллинның «Шәкертләр җыры» мотивына җырланылган «Кечки азан» (№ АР-1748) җырының язмасы. Бу җырда башкаручы

[6] Монда мин җырларның исемнәрен граммофон тәлинкәләрендә кириллицада ничек язылган, шулай бирү дөрес булыр дип уйладым.

[7] Татар театры (1906-1926). Тулыландырылган 2нче басма. Казан: Мәгариф.2003,112 Б.

үзенең Казандагы кичке азан тавышы тәэсире астында туган уйлары белән уртаклаша. Татар тарихындагы фаҗигале вакыйгаларны, ханлыкларның җимерелүен искә алып, «җылый, җылый бирделәр җан, Сөембикә дә Чыңгызхан»,–дип җырлый. Күп нәрсәләр бетте, калмады, тик «калды дингә дошман ишан»,–дип зарлана. Шунда ук ул татарларның таркаулыкларын тәнкыйтьләп, «Юк шул безләрдә берләшмәк, юк бергә-бергә гөрләшмәк»,–дигән үкенечен белдерә. Җырчы кешенең репертуары өчен моннан да тирән эчтәлекле, житди нәрсә бармы соң?

«Ахча–Деньги» (№ АР-441) җырында К.Мотыйгый-Төхфәтуллин акчага табынучыларны, нинди генә ысул белән булса да баерга тырышучыларны, шул акчаны эзләп йөрүчеләрне оста итеп сурәтли, алардан көлә:

*Сатучилар, кибетчиләр, кәрванчилар,*
*Сәне ничек табарга һич белмиләр,*
*Көни, төни йокламаен, сән(е) эзлиләр,*
*Бик күп мәшәкать йөкләрләр, сәнең өчен...*

Җырчы, кешеләр арасында акча өчен гөнаһлы эшләр кылынганын да кискен тәнкыйтьли һәм акча турында «сәнең өчен күп җаннар корбан булыр, канлар ага, яшьләр агар сәнең өчен...»,–дип җырлый.

Шунысы гыйбрәтле, бу шигъри юлларны К.Мотыйгый-Төхфәтуллин музыкаль яктан бөтенләй көтелмәгән калыпта–«көйле китап» мәкаменә музыкасыз башкара. Өстәп шуны әйтергә кирәк, бу «көйле китап» мәкаменең язмасын без XX гасыр башындагы граммофон тәлинкәләрендә сакланып калган яңгыравышлы бердәнбер үрнәк итеп кабул итәбез.

К.Мотыйгый-Төхфәтуллин кроковяк мотивына сатирик-гротеск характерлы «Ишан святой» (№АР-441) җырында, күз алдына китерерлек итеп, фәкать үзенең корсагы турында гына уйлаган, ничегрәк аны тутыру уе белән генә көн иткән «изге» ишан образын тудыра. «Мин симерми кем симерсен, эчем тулы ат мае»,–дип масайган тәкәббер ишаннан көлә.

Татар тормышындагы ямьсез күренешләрдән булган житешсезлекләргә, каршы чыккан тәнкыйтьче-җырчы, XX гасыр башында шәкертләр җырлаган «Беренче сада»[8] көенә «Тюлган шехеръ чайханаси» (№ АР-1747) исемле җырын да граммофон тәлинкәсенә яздырган. Ә менә К.Мотыйгый-Төхфәтуллинның «Кызлар халъ–Положение девиц» (№ АР-440) исемле җырында безнең каршыга кечкенә татар кызларын җәлләгән, сабыйларның киләчәге өчен борчылган җырчы образы килеп баса:

*Безнең хәлләр кызганыч,*
*Һәр эшемез болганыч,*
*Бу хәлләрнең эчендә*
*Кызлар хәле кызганыч.*
*Бичаралар үсәләр,*
*Өч-дүрт яшькә җиткәләр,*
*Шундан соңгый хәлләрдә,*
*Кызлар хәле кызганыч...*

Бүгенге көндә Г.Тукай сүзләренә татар халкының гимны булып яңгыраган «Туган тел» җыры XX гасыр башында популяр булган бер бәет көенә җырланыла. «Сәлим бабай» дип аталган бу бәеттә үткән тормышны искә алып, кеше язмышында үкенечләр, тормышка ашырыла алмаган хыялларның булуы турында әйтелә. Бу бәетне мин оригинал тексты һәм көе белән беренче тапкыр К.Мотыйгый-Төхфәтуллин язмасында ишеттем. Тәлинкәдә ул «Селимъ бабай–Дедушка Селимъ»

[8] Сада – иске фарси. 1) Аваз, тавыш, 2) Шәкертләрнең үзләре яки бүтән автор тарафыннан язылып, шәкертләр телендә йөргән җыр, декламация «Шәкертләр садасы», «Сада әйтү», «Сада җырлау».

(№ АР-439) дип теркәлгән.

К.Мотыйгый-Төхфәтуллинның ФМК фондындагы «ПАТЕ» граммофон язмалары арасында «Тутся маскавляръ яканъ» («Тотса мәскәүләр якан») (№ АР-1747) жырының булуы да жырчы репертуарының житди жырларга бай булганын күрсәткән мисал. Бу жырның бер язмасы белән әлегә кадәр мин таныш идем[9]. Ул язма «ПАТЕ» вариантыннан берникадәр аерылып тора. Көе, жыры шул ук, ләкин жырның каденциясе һәм фортепиано аккомпанименты төрлечә. Димәк, бу жырны К.Мотыйгый-Төхфәтуллин башка ширкәтләрнең тәлинкәләренә дә яздырган. Моңа дәлил итеп язучы Әхәт Гаффарның 80 нче еллар уртасында «Амур граммофон рекордъ (Пишущий Амур)» жәмгыяте тарафыннан яздырылып, Рига шәһәрендә «Граммофон» ширкәтендә эшләнгән граммофон тәлинкәсендә жырчының «Тотса мәскәүләр якан» жырын тыңлавы турында язган мәкаләсен искә алыйк. Анда язучы бер мөһим әйбергә басым ясап үтә: «Арада Г.Тукайның үткер шигыренә чыгарылган жыр жырлану («Тотса мәскәүләр якан») К.Мотыйгый-Төхфәтуллинның сәнгатьтә, Шаһит Әхмәдиев әйтүенчә, һич тә талымсыз, зәвыкъсыз итеп сыйфатламый. Киресенчә, бу–аның үтә зәвыклы, чын милли сәнгать әһеле икәнлегенә дәлил». Чынлап та, бу жырны башкару К.Мотыйгый-Төхфәтуллинның принципиальлеген һәм кыюлыгын күрсәтә. Ә бит Г.Тукайның бу үткер сатирик шигъри юллары 1908 елда, Россиядә кара реакциянең үтә көчле чорында язылган. Ул гына да түгел, цензура бу шигырь турында үзенең документларында «нежелательно» дигән сүз кулланган булуы да билгеле. Шагыйрьнең бу әсәре редакцион төзәтмәләр белән 1911 елда гына дөнья күргән. Ә К.Мотыйгый-Төхфәтуллин әлеге жырны концертларында гына жырлап калмаган, граммофон тәлинкәләре аша да Г.Тукайның иҗаты белән мөнәрләгән тыңлаучыларны таныштырган:

*Ни кыйлырсың, хаҗи абзам, тотса мәскәүләр якаң ?*
*Как ты будешь отвечать там, тотса мәскәүләр якаң ?...*

Әйе, К.Мотыйгый-Төхфәтуллинны бөек Тукайның иҗаты илһамландырмаса, жырчы тарафыннан «ПАТЕ» ширкәтендә шагыйрьнең әсәрләре буенча язылган тәлинкәләр сериясе турында без, мөгаен, бүген сүз алып бара алмас идек.

Күренекле галим И.Рәми «Әдәби сүзлек»ендә 1910-1913 елларда «ПАТЕ» ширкәтендә К.Мотыйгый-Төхфәтуллин башкаруында «Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр ни диләр?», «Кемне сөяргә кирәк», «Эштән чыгарылган татар кызына» («Зиләйлүк» көенә), «Ләззәт вә тәм нәрсәдә?», «Мәгъшукамә» (мәхәббәт шигырьләре) жырлары булуы турында укыйбыз. Шул жырларның кайберләре белән без ФМК фондындагы язмалар аша танышабыз. Алар арасында искә алып үзган «Тутся маскавляръ яканъ» жырыннан башка «Магшукама–Къ возлюбленной» (№ АР-439) һәм «Пар атъ–Пара лошадей» (№ АР-440) жырларының язмалары бар. К.Мотыйгый-Төхфәтуллинның рус композиторы М.Глинканың «Руслан һәм Людмила» операсындагы фарси хоры мотивына башкарган «Магшукама» жыры бик тә үзенчәлекле, колоритлы булып яңгырый. Безнең өчен, шулай ук, жырның каденциясе дә кызыклы: жырчы анда тониканы октавага югары күтәреп тынга куелган тулы яңгыравышлы тавыш белән тәмамлап куя. Бу алымны К.Мотыйгый-Төхфәтуллин «Кызлар халъ-Положение девиц», «Ишан святой» һәм озын көйләрдән булган «Ашказар», «Тәфтиләү» жырларында да куллана.

Ә инде халык арасында да, профессиональ башкаручылар арасында да популяр булган данлыклы «Пар атъ–Пара лошадей« жырына килгәндә, ислам галиме Р. Үтәбай-Кәрими сөйләвенчә, Г.Тукайның бу шигыренә көйне К. Мотыйгый-Төхфәтуллин нәкъ үзе салган.

Шулай итеп, К.Мотыйгый-Төхфәтуллинның граммофон тәлинкәләрендә сакланган репертуарын тыңлаганнан һәм анализлаганнан соң, көчле яңгыравышлы бәрхет тавышлы бу жырчының чын талант иясе булганына ныклап ышанасың.

9 «Тотса мәскәүләр якаң» жыры граммофоннан язылып алынып,цифрга күчерелгән форматта «Татарстан-Яңа Гасыр» радиосы фондында саклана.

Аның күп җырларының фортепиано һәм оркестрга кушылып яздырылуы, җырчының татар концерт музыкасын «культуралаштыру»га табан алып барганын күрсәтә. Моны К.Мотыйгый-Төхфәтуллинның кышкы кыяфәте, европача киенүе дә дә ачык дәлилли: җырчы сәхнәгә һәрвакытта да кара бант белән бизәлгән ак кәгазь якалы кара фрак киеп чыга торган була. Ә К.Мотыйгый-Төхфәтуллинның җырлау манерасы академик юнәлештә рус-европа янгыравына якынлашуы белән характерлы. Хәзерге заман тыңлаучысы күзлегеннән караганда без, К. Мутыги-Тухватуллинны, төрле чагылдыру чараларын үзенә җыйган бай арсеналлы профессиональ җырчы итеп кабул итәбез. Граммофон тәлинкәләрендә сакланып калган җырларны тыңлаганнан соң, җырчының чын мәгънәсендә милли сәнгать әһеле булуы турындагы фикеребезне тагын да ныгытабыз. Шул ук Г.Тукайның «Ләззәт вә тәм нәрсәдә?» шигырендәге «Тик фәкать милләткә хезмәткә мәхәббәт бәндә бар,–Бәнчә, бунда ямь дә бар, ләззәт тә бар, тәм дә бар!»–дигән юлларын җырлаган беренче профессиональ башкаручы К.Мотыйгый-Төхфәтуллинның татар халкының музыка мәдәниятенә чын мәгънәсендә хезмәт иткән зур шәхес булуына безнең бер дә шигебез юк.

ФМК фондындагы «ПАТЕ» язмаларын барлаганда татар җырчылары арасында беренчеләрдән булып граммофон тәлинкәләренә үзенең гармунда уйнавын һәм җырлавын яздырып калдырган җырчы-гармунчы Мирфәиз Бабаҗановның («Троицкий Мирфәйза») да дүрт тәлинкәсе (сигез җыр) булуы ачыкланды. Тәлинкәләрнең этикеткасына аның исеме Мирфейза Бабазянов дип язылган. Аның тавышының югары яңгыравышлы үзенчәлекле контратенор (лат.contra–каршы) икәнен без беләбез. Үз вакытында М.Бабаҗановның уйнавын һәм җырлавын төрле граммофон ширкәтләре яздырып чыгаралар. Башкаручының «Сирена грандъ рекордъ» ширкәте чыгарган тәлинкәләр турында журнал битләрендә мин язган идем инде[10]. М.Бабаҗановның үз уенына кушылып җырлаган сигез язмасы, җырчының репертуарын, манерасын һәм башкару осталыгын ачу юлында тагын да бер зур өстәмә, яңа чыганак булдылар.

Үзенчәлекле җырчының язмаларын тыңлаганда XX гасыр башындагы концерт-башкару практикасына хас булган бер традициянең чагылышын күрәбез. Ул да булса, бер концерт номеры эчендә озын көйне кыска җыр белән бергә бәйләп башкару. Стиле буенча да, эчтәлеге буенча да бер-берсеннән аерылып торган ике, өч җырны, яки көйне үзенчәлекле итеп сюиталы циклга берләштереп башкару үткән гасыр башы музыкантлары һәм җырчылары өчен табигый булган әйбер. Бу башкару традициясенең бер мисалы–Касыйм шәһәрендә М.Бабаҗановның граммофон тәлинкәсеннән магнитофонга яздырып алган «Оренбург бәете»[11]. Бу өч кисәктән торган цикл: салмак бәет көе, кискен контрастлы шаян бию такмаклары һәм күтәренке инструменталь йомгаклау. Шундый җырлардан җырчы-гармунчының язмалары арасында «Подвалъ Зарыфъ» (№ АР-447) җырын мисал итеп китерергә була. Анда татар халкының традицион озын көеннән соң салмак характердагы бер строфалы икенче кисәк янгырый һәм тагын да бер строфалы такмак композицияне түгәрәкләп куя. М.Бабаҗанов башкарган «Аштушъ» (арх.№ АР-449) җыры исә катлаулы типтагы озын көйнең контрастлы стиль үзенчәлекләрен үзенә берләштерә. Шул ук вакытта җырның өченче строфасы тизләтелгән темпта янгырый һәм үзенчәлекле цикл гармун башкаруында бөтенләй икенче көй белән тәмамлана. М.Бабаҗановның «Табмякубъ» (№ АР-447) җырында бу башкару үзенчәлеге ике кисәкне берләштергән озын көй һәм такмакта чагылыш таба. Шул чор музыкантларының телдән-телгә күчеп әлеге традициягә бәйләп йөргән әйтемнәре булган. Озын көйләргә кушып уйнаган, җырлаган кыска көй-такмакларны алар «Монысы закуска булды инде», дип әйтә торган булганнар. Аларның шулай дип әйтүе бу алым белән корылган күнелле концерт номерын тулысынча трактир-ресторан музыкасына каравын күрсәтә. М.Бабаҗановның

10 Татар җыры – йөз ел элек. // Казан утлары,2008. №10. – С.153-165.

11 «Оренбург бәете»,шулай ук «Гыйззәт көе»,«Дүдәк»һәм «Кара урман» җырларының язмалары заманында Касыйм шәһәрендә яшәүче Әхмәт Ишембаевның өендә граммофоннан язылып алынып,цифрга күчерелгән форматта «Татарстан-Яңа Гасыр» радиосы фондында саклананалар.

репертуарын нигездә кыска көй жанрына караган җырлар тәшкил итә. Ике кисәктән торган (җырның үзе һәм инструменталь йомгаклау) «Жигули» (арх.№ АР-448), шул чор җырчылар репертуарын бизәгән «Баламишкин» (арх.№ АР-448) һәм «Пороховой Фатыхъ» (арх.№ АР-449) җырлары. М. Бабаҗановның язмалары арасында башка төрки телле халыкларның җырлары булуы да аның репертуарының киңлеген күрсәтә. Әйтик, архив № 450 нче тәлинкәдә җырчы-гармунчы башкаруында кыргыз-казах җырларыннан булган «Амирханъ» һәм «Ку-Ку» исемле җырлар урын ала.

Мирфәиз Бабаҗановның безгә билгеле булган язмаларына таянып һәм яңа ачылган граммофон тәлинкәләрендәге репертуары белән танышканнан соң, бу җырчының революциягә кадәрле шәһәр музыкаль мәдәнияте мөхитендә калкып чыккан татар эстрадасының үзенчәлекләрен үзенең иҗатында чагылдырган башкаручыларның беренчеләреннән булуында бер дә шик юк.




*«ПАТЕ» ширкәте чыгарган Х.Йосыпов башкаруындагы җырлар тәлинкәсе.*

Шәһәр мөхитендәге төрле катламны канәгатьләндерүче «күңел ачу музыкасы» шул чорда эшләп килгән рестораннарда, кабакларда, паркларда, пароходларда һ.б. җирләрдә яңгыравы мәгълүм. Ул музыканы халыкка җиткерүчеләр арасында үзенең граммофон тәлинкәләре белән популярлык казанган җырчы-гармунчы Хөсәен Йосыповның язмалары да ФМК фондында булуы ачыкланды. Бу башкаручының «ПАТЕ» ширкәте чыгарган кайбер тәлинкәләре Г.Ибраһимов ис. ТӘҺСИ архивында саклануы безгә билгеле. Х.Йосыповның тавышы М.Бабаҗановныкы тибындагы контратенор. Төрле чыганакларны өйрәнгәндә җырчының граммофон өлкәсендә алып барган эшләренең күплелеге ышандырырлык. «ПАТЕ» ширкәтеннән башка Х.Йосыповның тәлинкәләрен «СИРЕНА-РЕКОРД», «ГНОМ-КОНЦЕРТ-РЕКОРД» һәм «ЗВУКОПИСЬ» ширкәтләре чыгарган. Ә инде ФМК фондындагы язмалар, үзенчәлекле җырчының репертуарын ачыклау буенча тагын да бер җитди чыганак булып хезмәт итә. Андагы тәлинкәләрдәге этикеткаларда җырчының исеме Хусаинъ Юсиповъ дип язылган.

Х.Йосыповның репертуарындагы лирик мәхәббәт җырларыннан «Алехи-Валехи» (арх.№ АР-435) һәм «Ашеклэкъ хале» (арх.№ АР-437) үзләренең структурасы белән салмак көйләргә карый. «Ашеклэкъ хале»ндә шундый лирик юллар хәтердә кала:

*Сары сандугач баласы,*
*Йер йеләген ашамый,*
*Кыз баланың акыллысы,*
*Сәүгән йарын ташламый...*

Салмак җырлардан шулай ук «Портъ Артуръ» (арх.№ АР- 451) җырын да билгеләп үтәргә кирәк. «Портъ Артуръ» җыры–рус-япон сугышы вакыйгаларын чагылдырган, шул чорда туплар астында һәлак булган «мөселман туганнар», аларның ятим калган якыннары, балалары турында социаль юнәлештә башкарылган җитди җыр. Мондый җырлар Х.Йосыпов өчен хас түгел, чөнки аның репертуары күбрәк «күңел ачу музыкасы» таләпләренә җавап биргән кыска шәһәр җырлары. Алар арасында дәртле характердагы аккомпанименты белән «Ахали зиляли» (арх.№ АР-1753) җыры, мәхәббәт турындагы шаян «Волковъ сазы» (арх.№ АР-1753), «Акошъ» (арх.№ АР-1752) һәм «Алмагачларъ» (арх.№ АР-1751) исемле җырлар. Х.Йосыпов

башкарган «Троицкий » (арх.№ АР-1752) дип аталган жыр үзенең төзелеше белән «Эрбет»[12] исемле популяр шәһәр жырын хәтерләтә.

Х.Йосыповның язмалары арасында татар-мишәрләрнең типик озын көйләренең булуы да ачыкланды. Ул–«Садучеларь» (арх.№ АР-436) һәм «Азизакей» (арх.№ АР-1751) жырлары. «Кара блотъ» (арх.№ АР-435) жырына килгәндә, анда башка милләт музыкасына хас интонацияләрен үзенә алып, үзенең стиле белән русларның шәһәр романсын хәтерләтә. Ә инде жырчының шулай ук үз уеныңа кушылып башкарган «Гай да тройка»сы (арх.№ АР-451), ХХ гасыр башындагы татар башкаручыларына хас булган рус жырының көенә татар сүзләре белән жырлау традициясенең ачык бер мисалы. Үзенең эчтәлеге белән рус көенә бик тә ятышлы булган бу жырны Х.Йосыпов дәртле табын жырлары стилендә башкара:

*Әйдә, дуслар, утырыйшик,*
*Өстәл өстен тутыйрик,*
*Биш сум тәңкә бер чүп түгел*
*Уйнап, көлеп бетерик...*

*Гыйнвар, фибрал , март, априль дин,*
*Акча бетергән айлар,*
*Биш сум тәңкә бер чүп түгел*
*Гулять итәрбез, әйдәй...*

Х.Йосыпов язмалары арасында бер жыр аеруча игътибарны жәлеп итә. Ул да булса, «Хайрыль Нися» (арх.№ АР-436) исеме астында янгыраган жыр. Бу жырны беренче тапкыр ишеткәндә аның көе миңа бигрәк тә таныш тоелды. Шуннан соң исемә төште: композитор А.Ключаревның «Татар халык жырлары» жыентыгындагы «Күк күгәрчен» жыры көенең бер варианты түгелме соң бу? Ул гына да түгел, композитор Ж.Фәйзи дә бу жырны үзенең «Халык жәүһәрләре»ндә китерә һәм ХХ гасырның 20 нче елларында «Күк күгәрчен» көенең Оренбург татарлары арасында аеруча популяр булуы турында яза. Х.Юсупов репертуарында «Хайрыль Нися»(«Хәйрелниса») жырының булуы, һич шиксез, бу жырның халык арасында «Күк күгәрчен»нән күпкә элегрәк танылган булуы турында сөйли. «Хәйрелниса, Хәмдениса» дигән эндәш сүзләр тора бара, күрәсең, «Күк күгәрчен, сандугачым» дигән сүзләр белән жырлана башлагандыр. Түбәндә Х.Йосыпов жырлаган жырның ике строфасы китерелә:

*Тау башындин тотып алдым*
*Сандугачның баласын,*
*Йыламай, жанием, нәк йылыйсың,*
*Хәйрелниса, Хәмдениса,*
*Йыласаң, дай, каласың.*
*Безнең кырлар кисәкле,*
*Баганасы пичәтле,*
*Без йырламый, кем йырласын,*
*Хәйрелниса, Хәмдениса,*
*Безнең көннәр исәпле...*

Шулай итеп, жырчы-гармунчы Х.Йосыповның репертуарын күпмедер дәрәжәдә ачыклаганнан соң без аның тулысынча шәһәр музыкасы кысаларындагы «трактир-ресторан» практикасына жавап бирүен билгеләп үтәбез.

Франциядәге граммофон язмалары арасында әлегә кадәрле безгә фәкать төрле басма чыганаклар, истәлекләр аша гына билгеле булган, ХХ гасыр башында жыр, концерт эшчәнлеген алып барган татар хатын-кызларыннан беренчеләрдән булган популяр жырчы Мәрьям Искәндәрованың тавышын тәүге тапкыр ишетү минем

[12] Бу жырның исеме данлыклы Ирбит ярминкәсендә чыгыш ясаган татар музыкантларының эшчәнлеге белән бәйле.

өчен аеруча дулкынландыргыч булды. Ә бит бу җырчыны Тукай үзе тыңлаган! 1911 елдагы Әстерханга сәяхәтендә Г.Тукай С.Рәмиев һәм Д.Мөхәммәдовлар белән бергә М.Искәндәрованың концертына барган. Г.Тукайның бу сәяхәтен үзенең истәлегендә чагылдырган В.Алиев, җырчының Касыйм шәһәреннән булып, аның Петербург консерваториясен тәмамлавы турында хәбәр итә. И. Рәмиев исә үзенең «Әдәби сүзлек»ендә икенчерәк төрле яза: М.Искәндәрованың Петербургтагы Федотова дигән ханымның курсларындамы, әллә башка бер музыка-җыр мәктәбендәме укыганлыгы турында бер мәгълүматның күзгә чалынуы турында әйтеп уза. Ничек кенә булмасын, М.Искәндәрованың чынлап та музыкаль белеме булуына шик юк.

«Төскә-биткә чибәр, матур җырлаучы артистканы Әстерхан публикасы бик җылы каршылады. Байлар визит карточкалары, хәтта акча да салган чәчәк бәйләмнәрен сәхнәгә яудырдылар. Ләкин аларның җырчыны үз якларына аударырга маташулары бушка чыкты. Сәгыйть Рәмиев аның белән күрешеп, Габдулла Тукайның да концертта булуын әйтеп өлгергән иде. Җырчы Мәрьям концерттан соң Габдулла Тукай утырган өстәлгә барды. Мәрьямне як-яктан чакырсалар да, ул берсенә дә игътибар бирмәде ... Алар (байлар) җырчының шагыйрьләр белән сөйләшергә теләгәнен аңламадылар...»–дип искә ала В.Алиев[13].

Язучы С.Сүнчәләй «Йолдыз» газетасының 1914 елдагы бер санында чыккан мәкаләдә М.Искәндәровага кыскача гына характеристика бирә. Анда ул җырчының шансонеткалар рәвешендәрәк җырлавын, аның тавышының ярыйсы, хәтта чибәр дә булуы турында яза. «Әллә нинди нәзек, көмеш тавышлы ул. Җырлаганда аның тавышының кайбер урыннары бәгъзан өзелеп, (вальцованныйныкы шикелле), «үзгәреп» китә. Менә шул үзгәрү, үзем бик матур була... Гомумән, Мәрьям ханымның тавышын көмеш тавыш дисәк, мөбалага булмас. Җырларының сүзләре дә матур гына»,–дип хәбәр итә С.Сүнчәләй[14]. М.Искәндәрованың әнә шул «бәгъзан өзелеп, үзгәреп» киткән көмеш тавышы граммофон тәлинкәләре аша йөз еллык вакытны бәйли. Югарыда әйтелгәннәрне дәлилләп, җырчының ФМК фондындагы граммофон тәлинкәләренә теркәлгән репертуарына тукталып китик. Тәлинкәләрдәге этикеткада җырчының исеме Маріамъ-Бано Искандерова дип күрсәтелгән. Димәк, аның тулы исеме–Мәрьямбану. Фондта аның ике яклы өч тәлинкәсендә алты җыр язылган. «Абау жаныйемъ» (арх.№ АР-1749), «Портартуръ» (арх.№ АР-1749), «Бай–Бай» (арх.№ АР-1750), «Берегись Альма» (арх.№ АР-1750) җырларын М.Искәндәрова тынлы оркестр аккомпаниментына кушылып җырлый, ә кырым-татар җырларыннан булган «Дордемъ кеме сулемъ» (арх.№ АР-1754) һәм «Гиль Гиль» (арх.№ АР-1754) җырларын фортепианога кушылып башкара. Җырчының төрле күңел ачу урыннарында, Мәкәрҗәдәге югары класс рестораннарында, Мәскәүнең данлыклы «ЯР» ресторанында эшләве, әлбәттә, аның репертуарына шәһәр музыкасына хас булган күтәренкелек, дәртлелек кебек сыйфатлар кертә. Типтереп яшәгән эре һәм вак буржуа гына түгел, башка катламнарның да тормышын бизәгән күңел ачу музыкасының шундый репертуардан торуы табигый хәл. М.Искәндәрова язып калдырган кырым-татар интонацияләренә нигезләнгән «Бай–Бай» җырында бу музыкаль мөхит аеруча ачык чагыла. Җырның үзенчәлеге шунда: тынлы оркестр озатуында беренче музыкаль җөмләне җырчы, икенчесен–катнаш хор башкара һәм җыр барышында бу алым үзенчәлекле ярыш–кара-каршы әйтеш формасын тудыра. Хор монда башкаручының җырлаган сүзләрен куәтләүче функциясен алып бара. Тынлы инструментларның, аеруча тынлы җиз уен кораллары төркеменең озатуында җырлау, башкаручыдан, әлбәттә, тавышның көчле яңгыравышлы булуын таләп итә. М.Искәндәрова үзенең С.Сүнчәләй характерлаган «көмеш тавышы» белән генә шундый тыгыз яңгыравышлы аккомпаниментка кушылып җырлый алгандыр. Менә «Бай–Бай» җырының ике строфасы:

---

[13] Тукай турында истәлекләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986, 155 Б.
[14] Сүнчәләй С. Әсәрләр һәм хатлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005, 236, 237 Б.

*Җырчы: Сезгә, дуслар, кунакка килдем,*
*Хор:Ляаа, ля,ля,ля—ляляля!*
*Җырчы: Нихәл итеп, зал торасыз?*
*Хор:Ляаа, ляляля, ля!*
*Җырчы: Бик яратсагыз, карагыз,*
*Хор: Ляаа, ляляля, ля!*
*Җырчы: Акчагыз булса сыйлагыз!*
*Хор: Ляаа, ляляля, ля, ля!*
*Җырчы: Тра ля-ля-ля-тра-ля-ля, Тра ля-ля-ля-ля...*
*Сезнең каршыгызда торам,*
*Мин дөньяны күргәнгә шул,*
*Җырлыйсым килеп җырламыйм,*
*Җырлыйм дуслар булганга, шул.*
*Тра ля-ля-ля-ля...*

М.Искәндәрованың «күңел ачу музыкасы»на хас булган сыйфатлары белән сугарылган «Бай–Бай» җырын без чын мәгънәсендәге дәртле эстрада номеры итеп кабул итәбез.

Татар хатын-кыз җырчылары арасында ФМК фондында шулай ук Нәфисә Позднякова (Пснякова), Фатыйма Моратова һәм Хәдичә Гимбитская исемле ханымнар тарафыннан яздырылган тәлинкәләр барлыгы да ачыкланды.

Ул тәлинкәләрдән мин инструменталь ансамбльгә кушылып Н.Поздняскованың Ф.Моратова белән берлектә (дуэтта) язылган «Иҗбулдин» һәм «Әхмәт-Сафа көе» (арх.№ АР-1756) җырларын, Ф.Моратованың «Озын Эрбет», Х.Гимбитскаяның «Уртада җиләс» (арх.№1755) җырларын тыңладым. Шулай ук бу өч җырчы (трио) башкаруында «Аппагуимъ бульбылимъ», «Эха-ха Трипака» (арх.№ АР-1757) һәм «Алма Хрмэ» (арх.№-1760) исемле җырларны да «ПАТЕ» үзенең дискларына яздырган. Тагын да бер тәлинкәдә аноним хатын-кызлар дуэты башкаруында «Ой Деньэ» һәм «Исланбурки» (арх.№ АР-1746) җырлары музыкасыз гына, a'capella яңгырый. Шунысы кызыклы, тәлинкәдә «Исланбурки» җыры «Казанско-татарская народная песня» дип игълан ителә. Инструменталь ансамбль озатылышында хор һәм солист башкаруында рус көенә татар сүзләре белән җырланылган «Ай Дунай» (арх.№ АР-1746) җыры да бик үзенчәлекле яңгырый. Тәлинкәнең этикеткасында бу җырны башкаручыларны «Казанскiй Татарскiй хор» дип билгеләгәннәр.

Әйтергә кирәк, соңгы искә алган хатын-кыз җырчыларның башкару осталыгы, әлбәттә, М.Искәндәровадан кайтышрак. Бу язмаларда башкаручыларның бик югары, берникадәр әче яңгырашлы туры тембры, көйнең схематик рәвештә, кайчак бөтенләй якынча гына башкарылуы, җырчы тавышының бизәкләргә артык бай булмавы, киресенчә, мелодикламациянең өстенлек иткәне ишетелә. Мондый тембрлы җырчылар башкарган көйләрне тыңлаган Г.Тукайның бу мәсьәләдә ниләр әйткәне безнең күбебезгә мәгълүм. Аның «Граммофонда татар җырлары» шигыре бәлки шундыйрак җырлар һәм җырчыларны тыңлаганнан соң язылгандыр. Ләкин ничек кенә булмасын, граммофонда җырлаган җырчылар нинди генә тәнкыйть астында калмасын, алар үзләренең төрле жанрга караган җырлары белән XX гасыр башы шәһәр тормышына хас булган күңел ачу җирләрендәге, кабакларда һәм сыраханәләрдәге татар колагын шактый еллар чыңлатып килгәннәр. Мондый җырчылар да, мондый башкару да, күрәсең, шул чор тыңлаучыларның зәвыкъларыннан чыгып соралганнар, кабул ителгәннәр. Ә бу өлкәдәге коммерсантлар шул җырчыларның граммофон тәлинкәләрен ил буйлап таратканнар.

Шулай итеп, татар музыка тарихын, аның башкару сәнгатен ачыклау юлында яңа чыганакларның табылуы–безнең өчен, музыка өлкәсендә үзләренең эзләнүләрен алып барган кешеләр өчен аеруча мөһим. Татар башкаручыларының граммофон тәлинкәләренә теркәлгән җыр һәм көйләрен ачыклау, ул тәлинкәләрнең кайда, ничек саклануын белешү һәм, ниһаять, ул тәлинкәләрне барлап, андагы язмаларны

заманча итеп эшкәртеп, гасыр тузаныннан чистартып, цифр форматына күчереп тыңлаучыларга, татар музыкасы белән кызыксынучыларга житкерү–безнен алга куелган бурычларыбызның берсе. Французларның үзләренең тарихына кагылышлы материалларны (ә безнең очракта ул чыгышы белән Франциядән булган «ПАТЕ» ширкәте), граммофон пластинкаларын (алар арасында татар музыкасы язылганнары да булуы!!!) үзләренең милли китапханәсендә саклап кына түгел, дөньяга танытулары, безнең өчен, татарлар өчен, үзебезнең мәдәни мирасыбызга булган мөнәсәбәтебез өчен зур бер үрнәк булып кала дисәм дә ялгышмам дип уйлыйм.

**Идрис ГАЗИЕВ**
*Россиянең атказанган, Башкортстанның һәм*
*Татарстанның халык артисты,*
*С.Юлаев исемендәге дәүләт премиясе лауреаты,*
*сәнгать фәннәре кандидаты.*

---

## Хөрмәтле укучыларыбыз һәм авторларыбыз!

**Журналыбыз белән даими танышып баручылар белә булыр: бездә «Казан утлары» архивыннан» дигән рубрика бар. Бу сәхифә байтак еллар гамәлдә булса да, элегрәк елларда материаллар сирәгрәк чыга иде. Соңгы вакытта «архив» активлашты, журналның һәр санында диярлек татар тарихыннан иҗтимагый әһәмияткә ия булган фотосурәтләр басылып килә. Теләгебез—алга таба да рубриканы кызыклырак һәм мәгънәлерәк итү. Бу эшне уңышлы дәвам итү өчен сезнең дә булышлык кирәк. Сезгә мөрәҗәгать-гозеребез шул: үзегезнең шәхси, гаилә альбомнарында яки оешма-учреждение архивларында сакланган кызыклы, тарихи-иҗтимагый кыйммәте булган (әдәбият һәм сәнгатебезнең мәшһүр шәхесләре, истәлекле мәдәни вакыйгаларга караган күренешләр, Казан һәм Татарстан тарихын яктырткан сурәтләр һ.б.) фоторәсемнәрне безгә юлласагыз икән! Шул рәсем турында аңлатма-комментарийларның булуы да шарт, әлбәттә. Без аларны журналда файдаланганнан соң, кире иясенә кайтара алыр идек.**

**Әйдәгез, кадерле укучылар, мөхтәрәм милләттәшләр, кайдадыр киштә-шкафларда, альбом-папкаларда ябылып яткан истәлекле ядкарьләрне яктыга чыгарыйк, халкыбызның рухи елъязмасы сәхифәләре булып киләчәк буыннарга хезмәт итсен алар! Сездән кызыклы фотоматериаллар көтәбез.**

# ОНЫТЫРГА ХАКЫБЫЗ ЮК...

ФӘХРИ НАСРЕТДИНОВНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

РСФСРның һәм Татарстанның халык артисты, Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, татар опера сәнгатенә нигез салучыларның берсе булган Фәхри Насретдиновны узган гасырның илленче еллары башларында ук инде радиодан ишетеп белә башлаган идем. Димәк, аның чишмә суыдай саф, гаҗәеп тавышы бала күнелен дә җәлеп итә алган.

Биш яшемдә мин гармунда, ә өченче сыйныфта укыганда әтиемнең баянында уйный башладым. Шул елларда ук туган хыялым—мәктәпне тәмамлагач Казанга барып, берәр музыка уку йортында укып, профессиональ баянчы булу иде. Ә инде кайчан да булса Фәхри Насретдиновка баянда уйнарга насыйп булыр дигән уй һич кенә дә башыма килмәде. Ләкин язмыш дигән нәрсә кайчакта сиңа бөтенләй уйламаган-көтелмәгән хәлләр дә китереп чыгара икән.

1966нчы елның көзе иде. Казан музыка училищесының 3нче курсында укыган чагым. Ул елларда «Бөек Октябрь революциясе бәйрәме» алдыннан һәрбер оешмада тантаналы кичәләр була торган иде. Безне, училищеның берничә студентын (араларында минем курсташым Вафирә Гыйззәтуллина да бар иде), Опера театры янында гына урнашкан «Стоматология поликлиникасы»на шушындый кичәдә концерт куярга җибәрделәр. Поликлиниканың кечкенә генә залы бар икән, безне шунын янындагы бер бүлмәгә урнаштырдылар. Мин баянымны алып бармакларымны бераз «җылыта» башладым. Бераздан безнең бүлмәгә Фәхри абый килеп кермәсенме! Мин аны театрда һәм телевидениедән күреп таный идем инде, башка студентлар да танып алдылар. Без барыбыз да аягүрә басып аның белән баш иеп исәнләштек. Бу инде безнең өчен, мәгълүм картинадагы кебек, «Явление Христа народу» булды, чөнки беребезнең дә әлегә кадәр аны шулай якыннан күргәне юк иде. Шуннан соң минем төшемә дә кермәгән хәл булды. Фәхри абый яныма килде дә: «Энем, син фәлән-фәлән җырларны беләсенме?»—дип миңа берничә җырның исемнәрен әйтте. Бәхетемә, мин ул җырларның барысын да белә идем (радиодан аның җырлавын тыңлап үсүемнең файдасы менә кайда кирәк булды). «Әйе, беләм»—дигәч: «Алайса, әйдә бу җырларны бер кат үтеп алыйк та, кичәдә миңа уйнарсың»,—дип мине шаккаттырмасынмы! Тамашачы алдында Фәхри абыйга уйнаганда, көтелмәгән шатлыктан мине шундый горурлык хисе биләп алды ки, хәтта каз тәне бәреп чыкканы хәтердә калган. Гомеремдә бик күп җырчыларга уйнаган булсам да, шундый хәл ике-өч җырчыга уйнаганда гына булды. Фәхри абыйның бу кичәдә без яшь җилкенчәкләр белән бергә катнашуына мин гаҗәпләнгән идем, әлбәттә. Ләкин кичәдән соң бер яшь табиб белән сөйләшеп торгач моның сәбәбен аңладым. Баксаң, Фәхри абый монда дәваланырга кергәли икән, шуңа күрә поликлиника җитәкчеләре үтенечен тыңлап, аларга рәхмәт йөзеннән шушы кичәдә җырларга риза булган.

Бу хәлдән соң берничә ай вакыт үтте. Бер көнне шулай радиога Рафаэль абый Ильясов янына кердем. Ул: «Керүең әйбәт булды әле. Фәхри абый синең белән радиога бер өр-яңа җыр яздырырга тели. Менә җырның нотасын да биреп калдырды. Син аны әйбәт кенә өйрән дә, берсекөнгә иртәнге 11 сәгатькә студиягә кил»,—дип миңа нота кәгазен тоттырды. Бу Заһид Хәбибуллинның Нури Арслан шигыренә язган «Казан кызы» дигән җыры иде. Мин бу тәкъдимне, әлбәттә, бик шатланып кабул иттем һәм җырны өйрәнеп әйтелгән вакытка студиягә килдем. Карасам,

анда жырның авторы Заһид абый да килгән икән. Без Фәхри абый белән жырны бер мәртәбә үтеп чыккач болар икәүләшеп жырны ниндирәк манерада башкарырга кирәклеген тәгаенләр өчен киңәшләшә башладылар.

Күренеп тора—бу шаян жыр. Ләкин төзелеше гади такмак кебек дүртьюллыктан гына түгел, ә катлаулырак формада язылган. Шуңа күрә музыкаль ягы да гади генә түгел. Заһид абый үзе дә жор телле, шаян кеше, Фәхри абый да ул яктан төшеп калганнардан түгел. Аларның бу «киңәшләшүен» мин тамаша караган кебек күзәтеп тордым. Әлеге манзараны сүз белән генә тасвирлап булмый, аны үз күзең белән күрергә кирәк иде. Ниһаять, болар уртак фикергә килделәр һәм без Фәхри абый белән жырны шушы килешенгән трактовка белән әйбәт кенә язылып та куйдык. Радиодан яңгырый башлагач, ул тиз арада бик популяр жыр булып китте. Аны бүтән жырчылар да яратып жырлый башлады. Мәсәлән, филармония жырчылары Гали Арсланов һәм Зиннур Нурмөхәммәтов репертуарында бу жыр озак еллар дәвамында Татарстанда гына түгел, ә элекке СССР киңлекләрендә дә яңгырады.



*15 апрель 1976 ел. Уфада опера театрында концерт вакытында.*
*Сулдан уңга: Рамил Курамшин, Фәхри Насретдинов—РСФСРның халык артисты, Тукай бүләге лауреаты, Рәгъде Халитов—КГПИ доценты, Бану Вәлиева—Уфа опера театры солисткасы, Марат Әхмәтов—Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, консерватория доценты (скрипкачы).*

1968нче елның гыйнвар аенда (бу вакытта мин музыка училищесын тәмамлап килә идем) Фәхри абый белән миңа радиога тагын язылырга насыйп булды. Бу юлы ул алты татар халык жырын яздырды, шулар арасында зур башкару осталыгы таләп итә торган «Әлфия» жыры да бар иде. Фәхри абыйның радиога язылу осталыгы үзе бер сәнгать дияр идем. Ул студиягә зур әзерлек белән килә һәм һәр жырны ювелирларча бөтен нечкәлекләрен жиренә житкереп шундый итеп башкара ки, әйтерсең лә аның тавышы гына түгел, ә бөтен күзәнәкләре жырлый. Шуңа күрә дә шушы алты жырны бер сәгать эчендә язылып та куйды. Ә бит кайбер жырчылар бер жырны сәгатьләр буе әвәлиләр һәм ахыр чиктә язмасының сыйфаты барыбер әллә ни килеп чыкмый, чөнки кабатлый-кабатлый тавыш арый һәм төсмерләре дә югала башлый. Тагын шунысын да әйтергә кирәк, Фәхри абыйга уйнавы бик жиңел дә, икенче яктан авырлыгы да бар, чөнки аңа уйнаганда бик игътибарлы булырга, кечкенә генә дә ялгышлык жибәрергә ярамый. Ялгышлык китсә бит туктап жырны яңадан яздыра башларга кирәк, ә бу Фәхри абый каршында минем өчен бик зур уңайсызлык тудырыр иде. Аллага шөкер, мин бу сынауны да уңышлы үттем.

Ул елларда Опера театры артистлары, сирәк-мирәк кенә булса да, Татарстан районнарына һәм Татарстан күршесендәге шәһәрләргә концертлар белән дә чыгып кергәлиләр иде. 3нче курста укыган чакта ук мине әлеге концертларда уйнарга чакыра башладылар. Ул концертларда Фәхри Насретдинов, Рәйсә Билалова, Идеал Ишбүләков, Венера Шәрипова, Фагыйлә Тимерова, Хәдичә Гыйниятова, Әлфия Заһидуллина, Рәйсә Нуриева кебек күренекле жырчылар катнаша иде. Менә шушы концертларның аеруча истә калганы турында бер хатирә. 1976нчы елның апрель аенда без Уфа шәһәренә киттек. Концертларның берсе Башкорт дәүләт

опера һәм балет театрында иде. Ул елларда тамашачының яше дә, карты да чын милли җырларыбызның һәм чын җырчыларыбызның кадерен белә иде әле. Фәхри абыйны һәр җырыннан соң «афәрин-браво»лар белән көчле алкышларга күмделәр. Программа буенча соңгы җырын җырлап сәхнәдән чыгып киткәч алар тагын да көчәя генә төште һәм Фәхри абыйга тагын бер җыр җырларга туры килде. Шуннан соң да әле алкышлар дәвам итте. Бусы инде Фәхри абыйны олылау алкышлары иде. Шушындый хәлне мин 1969нчы елда, нәкъ менә шушы театр бинасында ук, Илһам Шакиров концертында гына күргәнем булды. Концерттан соң сәхнә артына Фәхри абый янына бер апа килеп керде. Баксаң, ул Фәхри абыйның икетуган сеңлесе, РСФСРның һәм Башкортстанның халык артисты Бану Вәлиева икән (менә бу фотога да шул чакта бергәләшеп төшкән идек). Узган гасырның утызынчы еллары азагында Мәскәү консерваториясен тәмамлагач, аны Уфага яңа гына ачылган опера театрына эшкә җибәрәләр. Лирик-колоратуралы сопрано тавышына ия булган Бану апа шунда театрның әйдәп баручы солисты булып 1966нчы елга кадәр эшли. Шуннан соң профессор дәрәҗәсендә Уфа дәүләт сәнгать институтының вокал кафедрасында укыта. 2003 елның мартында, 89нчы яшендә вафат булды. Бу урында шунысын да әйтеп китү мәгъкуль булыр: Апас районының Шәмбалыкчы авылында (Фәхри абый белән Бану апаның туган авылы) Зиннәт Хәйруллин дигән милләтпәрвәр кеше шушы ике мәшһүр авылдашлары хөрмәтенә музей оештыруга ирешкән. Бу изге эше өчен мең рәхмәт аңа.

Мин инде Фәхри абыйның опера сәнгатендәге эшчәнлегенә бәя бирергә җыенмыйм, чөнки бу музыка белгечләре эше. Ләкин аның төрле опералардагы чыгышларын күргән кеше буларак шуны әйтә алам: ул бит уникаль тавышлы бөек җырчы булуы өстенә менә дигән актер да иде әле. Чөнки операда артист бит җырчы гына түгел, ә ниндидер образ тудыручы актер да. Ә инде кая да булса, юлда барганда Фәхри абый мәзәк сөйли башласа, автобус эче, йә вагон купесы кечкенә генә юмор театрына әйләнә дә куя. Тормышта ул гади, ачык һәм кече күңелле бик мөлаем кеше иде. Аның белән, әтиең белән сөйләшкән кебек, рәхәтләнеп сөйләшеп була иде.

Фәхри абый үзенең тавыш төсмерләрен һәм сафлыгын гомеренең азагына кадәр саклый алды. Җәүдәт Фәйзинең Әхмәт Фәйзи шигыренә язган «Зәйтүнәкәй» исемле җырын Фәхри абый башкаруында елленче елларда ук радиодан тыңлаган идем. Ул аны фортепианога кушылып җырлый иде. Ә менә 1983нче елда радиодан шул ук җырны баянчылар дуэтына кушылып җырлаган яңа язмасын ишетеп шаккаттым! Тавышы да сайрап тора, башкару осталыгы элеккесеннән дә шәбрәк дияргә була (бусы инде зур тәҗрибә нәтиҗәсе). Ә бит бу вакытта аңа 72 яшь иде инде! Бу, беренчедән, аның көчле вокал мәктәбенә ия булуы белән аңлатылса, икенчедән, ул тавышын күз алмасыдай саклый белә иде.

1958нче елда Татарстан хөкүмәте әдәбият-сәнгать өлкәсендә иҗат итүче иң күренекле әһелләргә «Габдулла Тукай исемендәге премия лауреаты» дигән исем бирү турындагы карар чыгара. Ул елларда бу исемне, чынлап та, иң-иңнәргә генә бирәләр иде. Җырчылардан беренче булып шушы исемгә Фәхри Насретдинов лаек була. Менә шушы факт кына да күп нәрсә турында сөйли.

Бу елның октябрь аенда Фәхри абыйның тууына 100 ел тула. Әлеге уңайдан үземне борчыган бернәрсә турында да әйтми кала алмыйм. Вафатыннан соң аның исеме хаксызга онытыла башлады. Элеккерәк елларда Рәшит Ваһапов исеме белән дә шундый ук хәл була башлаган иде. Ләкин 1988нче елда аның 80 еллыгын, шуннан соң 90, 100 еллыкларын да зурлап үткәрә башлагач (бигрәк тә аның исемендәге фестиваль-конкурслар барлыкка килгәч) исеме яңадан калкып чыкты һәм аны хәзер яшьләр дә белә башлады. Шундый ук чараларны ник әле Фәхри абыйга карата да үткәрмәскә?! Ул бит андый хөрмәткә мең мәртәбә лаек. Әгәр дә милләт буларак сакланып каласыбыз килә икән, димәк, Фәхри Насретдинов кебек бөек шәхесләребезне онытырга безнең һич кенә дә хакыбыз юк!

**Рамил КУРАМШИН**

*Татарстанның халык артисты*

# БЕРЕНЧЕ ТАТАР БАСМАСЫ

Русия падишаһы Петр Беренченен Кавказ һәм Фарсы иле халыкларына мөрәҗәгать итеп чыгарылган 1722 елгы «Манифест»ы гарәп графикасыннан хәзерге татар теленә күчермәдә киң катлам укучыларга беренче тапкыр тәкъдим ителә. Күренекле галим, татар китабы белгече Әбрар ага Кәримуллин аны җыелма хәрефләр белән басылган беренче татар китап басмасы дип бәяли *(Кәримуллин, 1979. 16-17 бб.)* «Манифест»ның сакланып калган бердәнбер нөсхәсе Россия Фәннәр академиясенең Санкт-Петербургтагы Шәркый кульъязмалар институты мирасханәсендә дип исәпләнеп *(1 фонд, 7 тасвирлама, 23/1287 архив эше)*, эчтәлеге тар даирә белгечләргә генә таныш иде. Мәскәүдәге Россия дәүләт борынгы актлар архивының Г.Я. Кер фондында *(191 фонд, 101 архив эше, 48-49 бб.)* «Манифест»ның икенче нөсхәсе табылды *(Краткий каталог, 1996. С.90-91)*. Әлеге текст шуннан алынды.

Мәгълүм булганча, Русиядә татар басма китабының инде өченче йөзъеллыкны тутырып килүче бай традицияләре, тарихы бар *(Каримуллин, 1974; 1992 һ.б.)*. Әмма гарәп шрифтендә литерлар булмаганлыктан, 1722 елга хәтле җыелма хәрефләр (литерлар) ярдәмендә татарча китап басу эше булмый. Мәсәлән, Петр Беренченең Госманлы Төркиясе белән үзара мөнәсәбәтләргә бәйле 1711 елгы икенче бер манифесты бакыр пластинкага уеп язу (ксилография), ягъни гравюра ысулы белән башкарылганлыктан, әле басма китап дип санала алмый *(Кәримуллин, 1979. 14-15 бб.)*. Шунлыктан, Петр Беренченең Кавказ һәм Фарсы иле халыкларына 1722 елгы «Манифест»ы татар басма китабы тарихында мөһим урын алып тора. Аның яңа табылган икенче нөсхәсенең Россия дәүләт борынгы актлар архивының нәкъ менә Г.Я. Кер фондында саклануы һич тә очраклы хәл түгел. Георгий Яковлевич (Георг—Якобс) Кер (27.07 (07.08.) 1692—05.(16)05.1740)—иҗади эшчәнлеге XVIII гасырның беренче яртысына туры килгән мәгълүм алман (немец) шәркыятьчесе, Шәрык (гарәп, фарсы, төрек) телләреннән тәрҗемәче һәм нумизмат. Ул Алманиянең (Германиянең) Саксония өлкәсендәге Шлейзинген төбәгендә туа, шунда башлангыч белем ала. 1711 елда Шәрык телләре белгечлеге буенча Галле университетын тәмамлый. 1722 елдан Лейпциг университетында өлкән магистр, 1727 елдан шунда гарәп һәм яһүд телләре кафедрасын җитәкли. Вице-канцлер граф А.И. Остерманның шәхси чакыруы буенча, 1732 елның гыйнварында Русиягә, Санкт-Петербургка килә һәм шул елның март аенда төзелгән контракт нигезендә дәүләтнең чит илләр эшләре Коллегиясе каршында гарәп, фарсы һәм төрек телләреннән тәрҗемәче—тылмач итеп тәгаенләнә. Ана шул телләргә яшүсмерләрне өйрәтү бурычы да куела. Шул максатта, Мәскәүдәге Славян-грек-латин академиясеннән махсус китертелеп, алты яшүсмер дә беркетелә (соңыннан аларның бишесе илчелек хезмәтендә файдаланыла).

1735 елда ул Петербург Фәннәр академиясе тарафыннан Петр Беренче оештырган Кунсткамерадагы 4000 берәмлек Шәрык тәнкәләренең (шул исәптән Җучи акчаларының да) тасвирламасын (каталогын) төзергә чакыртыла. Әмма шәркыятьче галимнең 1740 елда вакытсыз вафат булуы сәбәпле, бу эш тәмамланмый кала.

Замандашлары өчен бераз «сәеррәк» булып күренгән, үзенең шәркыять өлкәсендәге белемен барыннан да өстен куйган Г.Я. Кер заманында Русиядә атаклы шәркыятьче галим, күренекле нумизмат, гарәп, фарсы, төрек телләреннән иң яхшы тәрҗемәчеләрнең берсе булып таныла. Ул үзенең актив тәрҗемә эшчәнлеге аша чит илләр эшләре Коллегиясенең Шәрык илләре (Фарсы иле, Госманлы Төркиясе һ.б.) белән язма эш йөртүендә турыдан-туры катнашып, үзеннән соң төрле телләрдә күп

тәрҗемә хезмәтләр калдыра. Аерым алганда, аның Төркия белән Фарсы иле арасында төзелгән тынычлык трактатын, төрек солтанының патшабикә Анна Иоанновнага язган хатын алман теленә тәрҗемә итүе мәгълүм. Ул шулай ук урта гасыр төрки тарихи-мәдәни ядкярләреннән Әбелгазый Баһадур ханның «Шәҗәрәи төрки»ен («Родословная тюрок»)—алман, «Бабурнамә»не—латин телләренә тәрҗемә итә.



*Петр Беренченең Кавказ һәм Иран халыкларына аталган «Манифест»ының беренче бите. Туграга: «Петр Әүвәл бине Алексей—падишаһе Русии» дип язылган.*

Тәрҗемә эшчәнлегеннән тыш, Г.Я. Кер Кунсткамерадагы куфи язулы борынгы тәнкәләрнең, Жучи акчаларының ике томлык кульязма тасвирламасын төзи (тәмамланып житмәгән), үзендә дә аларның бай тупланмасын булдыра. Шулай ук төрле дөнья халыклары телләрендә әлифбалар жыя, аларны өйрәнә, Кавказ, Каспий, Кара дингез буе төбәкләренең карталарын төзеп калдыра, Шәрык телләрен өйрәнү максатында, Русиядә Академия яисә Гыйльми жәмгыять булдыру фикерен алга сөреп, үзе үк аның проектын да эшли һ.б.

Гомумән алганда, Г.Я. Кер Русиянең беренче шәркыятьче галимнәреннән, Шәрык акчалары нумизматы, куфи стилендәге язуларнын борынгы гарәп язмалары икәнлеген ачыклаучы булып исәпләнә. Ул зур эш сәләтенә ия була. Аның Россия дәүләт борынгы актлар архивында һәм Санкт-Петербургтагы Шәркый кульязмалар институты мирасханәсендә саклаучы бай иҗади мирасы да шул хакта сөйли. Шәркыятьче галимнең Россия дәүләт борынгы актлар архивындагы «Манифест»ның икенче нөсхәсе табылган шәхси фондында да (191 фонд) шәркыять, төркият белемнәренә, урта гасыр төрки, татар дәүләтләре яшәешенә кагылышлы шактый күп архив материаллары табарга була. Мәсәлән, «Татар тарихчылары һәм географлары турында хәбәрләр» (130 архив эше), «Кунсткамера тәнкәләре, медальләре һәм аларның күчермәләренең тасвирламасы» (143-176 архив эшләре), «Русиядә Шәрык академиясе оештыру проекты» (4, 11 архив эшләре), «Лейпциг китапханәсендәге гарәп, фарсы, төрек кульязмалары» (22 архив эше), «Бөек Могуллар генеалогиясе буенча материаллар» (92-т архив эше) һ.б.

Беренче татар басма китабының барлыкка килү тарихы да кызыклы. XVIII гасыр башында көчәеп киткән Русия, Балкан ярымутравына чыгу, Кара, Балтыйк дингезләре буйларында ныгып калу максатында, күрше дәүләтләр белән өзлексез сугышлар алып бара. Алтын Урда чорларыннан килгән традиция буенча, Русия Фарсы Иле, Госманлы Төркиясе, Төньяк Кавказ халыклары кебек күрше көньяк дәүләт-халыклар белән тыгыз мөнәсәбәт йөрткәнлектән, бу чорда дәүләттә илчелек

кәгазьләре фарсы, төрек, татар телләрендә дә башкарыла. Моның өчен чит илләр эшләре Коллегиясендә махсус тылмачлар корпусы тотыла.

1711 елда Русиянең Балкан ярымутравына таба һөҗүме Госманлы Төркиясе тарафыннан туктатыла. Ә инде Балтыйк буе җирләре өчен 1717-1721 еллардагы Төньяк сугышында Швецияне җиңгәннән соң, Петр Беренченең игътибары көньяк-көнчыгыш тарафка, Каспий диңгезе буйларына юнәлә. Максаты—Һиндстан, Кытай кебек бай илләргә илтүче кәрван юлларын, Каспий төбәгенең көнбатыш, көньяк-көнбатыш яр буе җирләрен кулга төшерү. Әмма алар бу вакытта Фарсы иле (Иран) кулында була. Җитмәсә, бу җирләр Гөрҗестан (Грузия) һәм Әйястанның (Әрмәнстанның) бер өлешен үзенә буйсындырган Госманлы Төркиясен дә кызыксындыра.

Озакламый бу төбәккә хәрби поход оештыру өчен форсат чыга. Фарсы илендә үзәк хакимиятнең көчсезләнүе сәбәпле, илдә башланган эчке чуалчыклыклардан һәм сәүдә үзәге Шәмәхадә рус сәүдәгәрләренең тауарлары талануыдан файдаланып (бу вакытта Фарсы иленә көнчыгыштан әфганнар—пуштуннар бәреп кереп, алар хәтта ил башкаласына һөҗүм итәләр, ә Төньяк Кавказ халыкларыннан лезгиннар һәм кумыклар Шәмәханы талыйлар), 1722 елның җәендә Петр Беренче гаскәрен Каспий буена юнәлтә. Тарихка Петр Беренченең 1722 елгы Фарсы походы яисә Шәмәха экспедициясе булып кереп калган бу походка ул, кайбер тарихи хәбәрләргә караганда, 22000 җәяүле гаскәридән (пехотадан), 20000 казактан, 30000 татардан, 22000 калмыктан, 9000 атлы гаскәрдән һәм 5000 матростан—барлыгы 106000 сугышчыдан торган гаскәр туплый. (Лебедев, 1848. С.9). Шул рәвешле, генерал-адмирал Ф.М. Апраксин командалык иткән яуның ким дигәндә 28-29 процентын төрки-татарлар тәшкил итә.

Алга китеп шуны әйтергә мөмкин, нигездә Каспий диңгезенең көнбатыш як яр буйлары буйлап сузылган бу поход Русия дәүләте өчен уңышлы тәмамлана. Аның нәтиҗәләре буенча 1723 елда Петербургта Фарсы иле белән Русия арасында солых төзелә. Бу килешү буенча Фарсы иле Бакы (Баку), Дербент шәһәрләрен, Астрабад, Гилян, Мазандеран, Ширван өлкәләрен Русиягә бирергә мәҗбүр була. Үзенең Кавказ артындагы яңа биләмәләрен таныту бәрабәренә, бу яулап алулар белән Госманлы Төркиясе дә килешә. Ләкин бу уңыш кыска вакытлы булып чыга. 1732 елда Фарсы иленең Решт шәһәрендә ирешелгән икенче бер килешү һәм 1735 елгы Ганҗә (Гянджа) трактаты буенча, Русия бөтен саналып киткән шәһәр-өлкәләрне киредән Фарсы иленә кайтарырга мәҗбүр була. Әмма әлеге поход беренче татар басма китабы нәшер ителүгә вә борынгы Болгар җирендәге тарихи һәйкәлләрне өйрәнү-саклауга тәүге этәргеч бирүгә бәйле истәлекле бер тарихи вакыйга итеп карала. Эш шунда ки, Каспий буена барышлый Русия падишаһы Петр Беренче Әстерханга Идел буйлап төшә. Шунда борынгы Болгар җирендәге тарихи хәрәбәләрне дә манзара кыла. Вакыт үтү белән аларның җимерелә, юкка чыга баруын күреп, Казан губернаторына сакланып калган тарихи һәйкәлләрне ныгыту-төзекләндерү чараларын күрергә, каберташлардагы борынгы татар, әрмән язмаларын кичекмәстән укып, күчереп алырга әмер бирә. Әлеге әмер мәгълүм дәрәҗәдә үтәлә дә. Мәсәлән, борынгы Болгар хәрәбәләренең хәзерге Россия дәүләт борынгы актлар архивында саклаучы график рәсемнәре менә нәкъ шул чорда ясалган булса кирәк. Бу шушы җирлектәге тарихи-мәдәни ядкярләрне саклау-өйрәнү юнәлешендә тәүге адымнарның берсе була.

Ә инде 1722 елның 15 (26) июнендә Әстерхан шәһәренә төшеп җитү белән үк Русия падишаһы үзенең поход типографиясендә Кавказ һәм Фарсы иле халыкларына аталган «Манифест»ын бастыра. Ул фарсы, төрек, татар телләрендә нәшер ителеп, аның алман теленә тәрҗемәсе дә мәгълүм *(Лебедев, 1848.—С.4-8)*.

Госманлы төрек телендә «Манифест»ның 1000 данә чамасында бастырылуы билгеле ***(Пекарский, 1862.—С.653)***. Сугышның Фарсы иле җирлегендә алып барылганлыгын истә тотсак, аның фарсы телендәге тиражы күбрәк булуы ихтимал. Күрәсең, «Манифест»ның фарсы, төрек телләрендәге исәбе 3000, гомуми тиражы 5000 чамасы булган *(Голиков, 1838.—С.154-155)*. Әлеге поход типографиясендә басылган нинди дә булса башка басма мәгълүм түгел. 1723 елда исә поход типографиясе осталары Мәскәүгә әйләнеп кайта. Күчереп йөртү авыр булганлыктан, үзләре белән типография станын, гарәп шрифтындагы литерларны гына алалар. Калган җайланмалар барысы да урында кала.

«Манифест»ның авторы һәм Шәрык телләренә тәржемәчесе булып Русиянең беренче шәркыятьчеләреннән Дмитрий Константинович Кантемир (26.10. (6.11.) 1673—21.08. (1.09.) 1723) исәпләнә. Ул—Молдавия (Валахия) хөкемдары Константин Федорович Кантемир белән борынгы бояр нәселеннән булган Анна Федоровна Бантыш гаиләсендә кече ул булып дөньяга килә. Кайбер тарихи хәбәрләргә караганда, бу нәсел башында Кырым татарлары вәкиле тора. 22 ел буе (1688-1710) аманәтче (заложник) сыйфатында Константинопольдә (хәзерге Истанбул) яши. Анда яхшы белем ала. Ул Көнбатыш (грек-латин) белән беррәттән Шәрык белемен дә яхшы үзләштерә, төрек, гарәп, фарсы телләрен камил дәрәҗәдә белә. «Бу господарь—үтә акыллы кеше, киңәшләр бирергә дә бик сәләтле»,—дип бәяли аны Русия падишаһы Петр Беренче *(Походный журнал, 1854.—С.49).* Петр Беренченең 1711 елгы Төрек походында Д.К. Кантемир Русия ягыннан эш йөртә. Әмма поход уңышсыз тәмамлану сәбәпле, ахыр чиктә Русиягә качып китәргә мәҗбүр була. Ул монда кенәз титулы, зур утарлар белән бүләкләнә, падишаһ сараена якынайтылып, Петр Беренченең төрек эшләре буенча киңәшчесе була.

Д.К. Кантемир гыйльми иҗат эше белән дә шөгыльләнә. Мәсәлән, 1716 елның көзендә ул латинча язылып, үзеннән соң кульязмада калган, соңыннан инглиз, француз, алман, румын телләрендә бастырылып, аңа дан китергән «Госманлы йортының күтәрелеше һәм баешы» дигән хезмәтен тәмамлый. Шулай ук латин телендә 1720 елда язып тәмамлаган икенче бер кульязма китабын «Систима китабы яисә Ислам диненең торышы» дип тәржемә итеп булыр иде.

Петр Беренченең 1722 елгы походы вакытында Д.К. Кантемир, Яшерен канцелярия башлыгы П.А. Толстой белән берлектә, гражданлык эшләре белән җитәкчелек итә. Алар өчесе—яу җитәкчесе Ф.М. Апраксин, П.А. Толстой һәм Д.К. Кантемир падишаһ Киңәшен (Советын) тәшкил итәләр. Петр Беренче аңа поход типографиясе белән җитәкчелек итүне дә тапшыра. Шәрык (фарсы, гарәп, төрек) телләрен белү Д.К. Кантемирга походта аеруча мөһим роль уйнарга мөмкинлек бирә. Шунлыктан типография эшен оештыручы да, «Манифест» текстын язып, аны төрле телләргә тәржемә кылучы да шул булып исәпләнә.

Д.К. Кантемир үзе бу походны гыйльми экспедиция буларак та кабул итә. Мәсәлән, Дербентта аны борынгы кирмән үзенә җәлеп итә. Ул кирмәннең үлчәмнәрен, андагы гарәп язулы язмаларның күчермәләрен ала. Аның «Кавказ стенасы турында» дигән гыйльми материаллары «Шәрык коллекциясе» («Восточная коллекция») җыентыгында да урын ала.

Моннан тыш Д.К. Кантемир хәрби экспедиция вакытында көндәлек кульязмалар да алып бара. Аның борынгы Дербентка кагылышлы урыннары аеруча мәгълүматлы һәм кызыклы. Дербентка килгәч, ул Кавказ һәм Төркестанның күп халыклары изгеләштергән каберләрне зиярат кыла, тасвирламаларын биреп, алар турында мәгълүматлар калдыра. Шунда ук Петр Беренчегә «Тарихи Дербентнамә» дигән фарсы кульязмасы бүләк ителгән була. Д.К. Кантемир, кызыксынып, аны тәржемә итәргә алына. Әмма бу эшне ахыргача башкарып чыга алмый, 1723 елда вафат була.

Җыеп әйткәндә, үзенең 1722 елгы Фарсы походы вакытындагы эшчәнлеге белән Д.К. Кантемир Русия шәркыять гыйлемендә Төньяк Кавказ халыкларын өйрәнүгә бәйле яңа тармакка нигез салучы буларак күзаллана.

Петр Беренче идарә иткән чорда үзара тыгыз мөнәсәбәт йөрткән күрше илхалыкларга шундый «Манифестлар» белән мөрәҗәгать итү гадәти хәл була. Аларның эчтәлегендә сәламләү, вәгъдә, үтенеч, янау, кисәтү, боерык, әмер, теләкләр урын ала алган. Болар 1722 елгы «Манифест» текстында да чагыла.

Текст башындагы сәнгатьле рәвештә язылган тугра—«Петр әүвәл ибн Алексей падишаһе Русии»—үзенең эшләнеше буенча, әйтик, Кырым ханнарының мәгълүм туграларыннан калышса да, үзенчәлекле симметрик композиция белән осталарча башкарылган. Шунысы да кызыклы, «Манифест»ның Санкт-Петербургтагы Шәркый кульязмалар институты мирасханәсендә сакланып калган икенче бер нөсхәсендә ул үзенең композицион конфигурациясе буенча берникадәр аерыла. Бу исә поход типографиясендә бер үк «Манифест»ның төрки-татар телендә ике мөстәкыйль басмасы дөнья күрү ихтималы турында сөйли. Шул унайдан «Манифест»ның төрле мирасханәләрдә сакланып

калган текстларын үзара чагыштырма тикшерү дә фарыз. Бу—якын киләчәк эше.

«Манифест» русчадан иске госманлы теленең югары стилендә тәрҗемә ителгән һәм бастырылган. Югары стиль—ул канцелярия стиле. XVIII гасыр башларында бу стиль белән хөкүмәт указлары, фәрманнары, ярлыклары һәм чит ил хөкемдарларына хатлар язылган. Бу чорда Төркия дәүләте белән мөнәсәбәтләр шактый тыгыз булганлыктан (Петр Беренче Төркияне яулап алу нияте белән эш итә), татар тылмач-тәрҗемәчеләре язу-сызу эшләрен шул телдә алып барганнар. Казан ханлыгы чоры язма теленнән бу тел кискен аерылып тора, ул гарәп сүзләре, фарсы гыйбарәләре белән тулы, алар текстның чама белән 90% тын тәшкил итә.

Аерым җөмләләрдә текстны тәрҗемә кылучының татар теленә өстенлек биргәнлеге дә сизелгәли. Мәсәлән: «зурба башларына» («башларыйа» урынына); «пәнәһ буланлар» («пәнәһ уланлар» урынына); «булыныр исә» («улыныр исә» урынына), «симәтдә булынанлар» («симәтдә улынанлар» урынына). Кайбер төрки-татар сүзләре күплек санда фарсы күплек кушымчасы «-ан» белән язылган: мәсәлән: тупчыбашыйан (тупчыбашлары), йөзбашыйан (йөзбашлары). Фарсы изафәсе (нисби бәйләнеш, иялек килеше) шактый мул күзәтелә.

Басма текстның хәрефләре (шрифте) ачык нәсех стилендә эшләнгән, әмма сәнгати камиллек житешми. Гарәп һәм фарсы сүзләре нәкъ шул телләрдәге язылышта бирелгәннәр, х, з, с, т, г, к хәрефләренең нечкә һәм каты әйтелешле вариантлары дөрес һәм урынлы язылган.

Йомгаклап шуны әйтергә була, Русия падишаһы Петр Беренченең Кавказ һәм Фарсы иле халыкларына атап чыгарылган 1722 елгы «Манифест»ы—беренче татар басма китабы тексты—тарихчыларга, язу тарихы буенча эшләүче шәркыятьчеләргә, тел белгечләренә алга таба өйрәнү, чагыштырма нәтиҗәләр ясау өчен кыйммәтле бер чыганак булып тора.

**Рәшит ГАЛЛӘМ,**
*ТФА Ш.Мәрҗәни исемендәге Тарих институты өлкән фәнни хезмәткәре, тарих фәннәре кандидаты.*

**Нәҗип НӘККАШ-ИСМӘГЫЙЛЬ,**
*ТФА Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты өлкән фәнни хезмәткәре.*

## «Манифест»ның хәзерге татар әдәби теленә тәрҗемәсе

*Петр Беренче Алексей улы—Русия падишаһы*[1]

Раббыбызның ярдәме вә Ул—Җиһан Хуҗасының[2] кодрәте белән, Без, Петр Беренче—Бөтенрусиянең императоры, кояш чыгышыннан кояш баешына һәм төньяктан көньякның яртысына кадәр булган җирләрнең мәлиге[3], коры җирләрнең падишаһы вә диңгезләрнең хаканы[4] һәм дә башка вә башка вә башка падишаһларның вә хөкүмәтләрнең хакиме һәм мәликәнә[5] боерыкчысы—шәүкәтле[6] вә бөек, тулы бәхетле вә мәһабәтле, олы мәхәббәтебезгә лаек булган иске дустыбыз бөек дәрәҗәле вә урынлы Шаһ хәзрәтләренең хөкүмәтендә вә хезмәтендә булган гыйззәтле вә хөрмәтле гаскәр башлыкларына, ханнарга, гаскәри бүлекләрнең җитәкчеләренә, җәяүле гаскәр белән

[1] Тугра шәкелендәге язу
[2] Җиһан хуҗасы - Алла
[3] Мәлик – патша
[4] Хакан – император
[5] Мәликәнә - патшаларча
[6] Шәүкәтле – данлы,мактаулы

идарә итүче агаларга, мылтыкчы вә тупчы башлыкларына, солтаннар вә вәзирләргә, бәкләр бәкләренә вә башка житәкче-идарәчеләргә вә гаскәри төркемнәрнең бәкләренә вә йөзбашларына һәм дә фазыйләтле[7] голәмәләр[8], мулла вә хөрмәтле имамнар вә мәзиннәр һәм башка рухани затларга, һәм дә авыл башлыкларына, сәүдә әһелләренә, кәрван вә кунакханә башлыкларына, кибетчеләргә вә һөнәр әһелләренә, аларның өйрәнчекләренә, һәм, гомумән, әһле зиммәгә[9], кул астыгызда булган, Сезгә буйсынган халыкка—һәрберсенә мәртәбәсенә, женесенә вә мәзһәбенә аермастан—үзебезнең сәламнәребезне, рәхим-шәфкатебезне ирештерәбез.

Сәлам соңында, Безнең Падишаһи Указыбыз килеп ирешкәч, Сезнең игътибарыгызга шуны җиткерәбез һәм мәгълүм кылабыз ки: Раббыбыз Гайсә Мәсих[10] Хәзрәтләренең тууына мең җиде йөз егерме беренче елда (һиҗри ел белән мең бер йөз утыз дүртендә) шәүкәтле вә газәмәтле[11] вә мәһабәтле олы дустыбыз вә хөрмәтле күршебез—бөек мәртәбәле Шаһның—фарсы вә гаҗәм[12] җирләре Мәлиге хәзрәтләренең тәхет биләмәсендә булган ләзгә[13] вилаятенең[14] идарәчесе Дауд бәк һәм казый-комык иялэтенең[15] хакиме Соркай исемле кешеләр ул тарафтагы төрле төркемнән булган ничәмә фетнәчел бәндәләрне җыеп һәм җәләлиләр[16] янына кушылып, югарыда телгә алынган олуг мәртәбәле Шаһ дустыбыз хәзрәтләреннән баш тартып, Аның биләмәләреннән булган Ширван мәмләкәтендәге Шәмәха шәһәренә һөҗүм итеп, кылыч астында калдырып, Шаһ дустыбыз хәзрәтләренең ничә адәмнәрен һәлак итеп, шулай элеккеге югары килешүләр вә борынгы гадәтләр буенча әлеге илдә сәүдә белән шөгыльләнгән гөнаһсыз рус кешеләрен дә мәрхәмәтсез үтереп, чиста акчага күчергәндә барысы дүрт йөз көррә[17] (йөз мең рубльгә якын) торган малларын талап алганнар, һәм, шулай итеп, ул килешүләрне бозып, Безнең мактаулы дәүләтебезгә каты зыян салдылар, тынычлыгыбызны боздылар.

Гарчә Безнең Бөек падишаһи Указыбыз буенча Абздархан[18] вәлие[19] ул халыкларны кире кайтарту өчен ул фетнәчеләрнең башлыкларына кат-кат кисәтү җибәрсә дә, һәм, гәрчә без дә сәүдәнең тукталганын күреп, Шаһ дустыбызга берничә тапкыр мәхәббәтнамәле махсус хатлар белән мөстәкыйль илчебезне җибәреп, Сездән ул фетнәчеләрдән хакларыбызны кайтаруны таләп итүне һәм шәригать хөкеме белән эшләрен башкаруны сорап язсак та, күрәсең, Сезнең мөмкинчелек булмау сәбәпле, бу вакытка кадәр һичбер хәрәкәт боерылмады.

Инде, шул рәвешчә тагын ул яман эш кылучыларның золымыннан Безнең рус халкының малына вә канына тиешле хак кайтарылмаган икән, шул сәбәпле зарурый рәвештә шуны тиешле һәм кирәк дип табабыз: Хакның тарафыннан ярдәмнәр үтенеп, сорап вә ялварып, ул гөнаһлы булган фетнәчеләрнең өстенә данлыклы вә җиңүле гаскәребез белән хәрәкәт итүне ният итәбез.

Галәмнәрнең Хуҗасыннан шуны көтәбез, телибез һәм өметтә торабыз ки, иншаллаһу Тәгалә, изге коралыбыз көче белән ул югарыда телгә алынган зыян итүче, зарар китерүче һәм бозыклыкка сәбәпче булган ярамасларның нык итеп хакларын кайтарабыз, эшләрен тулысынча башкарып, гамәлләренә күрә җәзаларын бирәбез.

Инде шәүкәтле, газәмәтле вә мәхәббәтле дустыбыз Шаһ Хәзрәтләренең дәүләт тәхете тирәсенә сыенган хөкүмәт әгъзалары, әһле зиммә (һәркайсы дине-диянәте вә мәзһәбе белән), һәм фарсы, гаҗәм, әрмән вә гүрҗи[20] халыкларына һәм башка

[7] Фазыйләтле - өстенлекле; укымышлы
[8] Голәмә - галимнәр
[9] Әһле зиммә – мөселманнар кул астында һәм химаясында булган христианнар һәм яһүдиләр
[10] Мәсих – миссия үтәүче, Иисус Христос
[11] Газәмәтле - олы
[12] Гаҗәм - иранлы
[13] Ләзгә – лезгин халкы
[14] Вилаять - өлкә
[15] Иялэт - өлкә
[16] Җәләлиләр – Җәләледдин Мәликшаһ дәверенә карауčылар, сәлҗуклар. Биредә – госманлы төрекләре
[17] Көррә - авырлык үлчәү берәмлеге
[18] Абздархан - Астрахань
[19] Вәли – шәһәр башлыгы, губернатор
[20] Гүрҗи – грузин

патшалыклардан килеп, бу вакытта шунда булганнарга, һәм, гомумән, бар халыкка Падишаһанә югары вәгъдә биреп, ул вәгъдәбезне иң югары дәрәҗәдә нык итеп раслап вә дөреслегенә ышандырып, боерабыз: әлеге җирләрдә яшәгән, ватан тоткан һәм сәфәрдә булганнарга—һичбер кешегә һичбер зыян вә зарар булынмас, җаннарына, малларына вә авыл-шәһәрләренә бер кеше дә кул сузмас. Һәм бу хосуста гаскәр башлыкларыбызга һәм барча гаскәри бүлекләрнен җәяүле һәм атлы бүлекчә башлыкларына вә башка житәкчеләргә каты фәрман вә кисәтү боерылды: һичкемгә катгый рәвештә һичнинди рәнҗетү вә куркыту булынмас, әгәр кем дә кем үз ирегe белән шулай кыланса, хөкем ителеп, тиешле җәзасын алыр.

Шул шарт белән сез дә торган урыннарыгызда һәм хөкүмәтегез җирләрендә дуслык йөзеннән тик торасыз һәм талауларны уйлап, мал-мөлкәтегезне йортыгыздан тышка чыгармыйсыз, таркатмыйсыз вә туздырмыйсыз, юкса башкача булса, каршы хәрәкәтегезне ишетсәк һәм белсәк, ягъни ул инсафсыз вә күп кыерсытулар күрсәтүче залимнәргә кушылсагыз, яки аларга ачыктан-ачык йә яшерен рәвештә акча белән, яки ашамлык запаслары белән ярдәм итәчәк булсагыз, яки падишаһанә юмарт вәгъдәбезгә тугрылык күрсәтмичә вә ихтирам итмичә йортларыгыздан вә авылларыгыздан чыксагыз, качып китсәгез—зарурыйлыктан шул тиеш булыр: барыгызны да дошман исәбендә санап, мәрхәмәтсез рәвештә кылыч вә ут белән өстегезгә барып, үзегез һәлак булырсыз, ә мал-мөлкәтегез исә талап алыныр, һәм сез гөнаһларыгыз авырлыгын өстегездә күтәреп, Кыямәт Көнендә ул түгелгән кан Хак Тәгаләнең каршында сездән таләп ителенер.

Шушы рәвешчә үк госманлылар дәүләте[21] тарафыннан килеп, ул җирләрдә сәүдә яки башка изге эшләр белән мәшгуль булган кешеләргә моннан элеккеге падишаһи килешүләребез тәртибенчә һәм тагын бу Югары Падишаһи Вәгъдәбез белән дөресләп-раслап, хөрмәтле затларына боерабыз вә белдерәбез ки: Безнең гаскәрләребез ул тарафка килеп кергән вакытта усаллык күрсәтмичә, каршылык итмичә сәүдәгездә һәм файдалы эшләрегездә барчагыз да әүвәлгечә мәшгуль булып, тыныч күңел белән торасыз, чөнки сезне һәм малларыгызны саклау вә яклау өчен гаскәр башлыкларыбызга һәм башка житәкчеләргә буйсынучыларга Падишаһи Фәрманыбыз житкерелеп, каты кисәтү боерылды: госманлы дәүләте тарафыннан килгән сәүдәгәр халкы тыныч күңел белән торсыннар, үзләренә һәм малларына һәрберсенә рәнҗетү вә куркыту булмасын, һәм шул рәвешчә Бөек Дәүләтләребез арасындагы солых мәңгелек, йөкләмәләребезнең үтәлеше-торышы нык булыр, хосусән, якты вөҗданыбызга ярашлы рәвештә нык саклануына һәм башка хокукларыбызның үтәлеше, иншаллаһу Тәгалә, һич өзелмәячәгенә падишаһи намусыбыз шәһадәт итәр[22]. Һәм шулай ук Бөек Дәүләтләребез тарафыннан дуслыкны саклауның һәм ныклы килешенүнең җиренә житкереләчәгенә шигебез юктыр.

Инде ул Югары Әмер белән боердым ки: барысы да җентекле һәм тулы чагылдырылган ошбу фәрманым тулы кодрәтем белән хәрәкәткә килсен дип, рәсми кулланылышка вә гамәлгә керсен дип, падишаһи мөһерем белән беркеттем. Беркөн Сезгә килеп ирешер һәм таратылыр, «ишетмәдек вә белмәдек» димәгез, шушының белән беләсез, шәриф билгегә ышанасыз. Инде Сезгә даимән сәламәтлек, иминлек насыйп булсын!

*Әҗдарһа[23] шәһәре, Хәзрәте Гайсә елы белән*
*мең җиде йөз егерме икедә, тәммузның[24] 15 ендә.*

[21] Госманлылар дәүләте - Төркия
[22] Шәһадәт итәр – таныклык бирер
[23] Әҗдарһа – Әстерхан шәһәре
[24] Тәммуз – июнь ае

Фирдәвес
Гарипова

# АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

## Ташчишмә (Иске Тазлар) авылы

Ташчишмә авылы район үзәге Олы Әтнә авылыннан 12 чакрымда, жирле үзидарә Советы үзәге Күнгәрдән —61, Арчадан —38, Казаннан 85 чакрым ераклыкта урнашкан.

Тарихи чыганакларда авыл Иске Тазлар исеме белән теркәлеп калган.

Д.А.Корсаков белешмәсендә (XVIII йөз) авылның икенче исеме Мәмәдәли дип бирелә һәм анда 190 ясаклы татар яшәгәнлеге күрсәтелә.

1898 елгы хезмәттә Иске Тазлар һәм Яңа Тазлар авылларында татарлар яшәгәнлеге искәртелә.

Иске Тазлар, Иске Әҗем, Мукшы авыллары яшьләре Тазлар каршы исемендәге җыен бәйрәме үткәргәннәр. Яңа Тазлар, Шура, Шурабаш, Яңа Сәрдә, Яңа Әтнә, Югары Оры, Түбән Оры, Чымбылат, Мамыш, Кышлау, Югары Шашы, Түбән Шашы, Яңа Шашы, Күнгәр, Иске Әҗем, Яңа Әҗем, Иске Тазлар, Олы Әтнә, Кече Әтнә авыллары халкы бергә җыелып июнь ахырында һәм июль башында Мукшы тавы җыенын бәйрәм иткән.

Арча районы Иске Әҗем авылында яшәүче Шакиров Габдрахманнан 1973 елда галим Марсель Әхмәтҗанов Тазлар авылы оешу турында түбәндәге риваятьне язып алган.

Әҗем искерәк авыл булса кирәк. Бер заманны әҗемлеләр урман эченнән төтен күтәрелгәнне күреп, нәрсә бар икән дип барып караганнар. Барсалар, өч кеше бура бурап ята, ди. Алардан:

—Сез кем халкы? —дигәч, тегеләр:

—Без —Тазлар! —дип әйткәннәр.

Әҗем кешеләре авылларына кайтканнар да:

—Анда өч таз бура бурап ята, —дигәннәр. Шуннан бу авылны Тазлар дип атый башлаганнар. Бу авылдан Яңа Тазлар (хәзер Байкал) авылы күчеп чыккач, аны Иске Тазлар дип йөрткәннәр. Совет власте вакытында, «таз» сүзен кимчелек санап, Ташчишмә исеме белән алыштырдылар. Халыкның таз яки пеләш исемен йөртәсе килмәве табигыйдер. Әмма Тазлар атамасы чал тарихка барып тоташа иде бит. Безнең эрага кадәр IV гасырда рим-грек тарихчысы Геродот биек таулар арасында хайван асраучылык белән шөгыльләнгән һәм дала чиясеннән «асхи» дигән эчемлек әзерли торган тазлар (плешивые) халкы яшәгәнлеге турында яза.

Биектау районындагы Кодаш авылы халкын тирә-юньдәге авыл халкы «тазлар» дигән кушамат белән атап йөртә. Әлмәт районындагы Мөгез-Елга авылының икенче исеме —Тазлар. Тазлар суы —Ык елгасының сул кушылдыгы. Башкортстанның Бөрҗән районында Иске Тазлар һәм Яңа Тазлар, Зианчура районында Тазлар

*Дәвамы. Башы 2006 елның 6нчы санында.*

исемле авыллар бар. Себер татарларында да «тазлар» этнонимы очрый. Себердәге тара татарларында әле дә түбәндәге фразеологик сүзтезмә сакланган: «Таслар аймак табышкан, тана суеп сыйлашкан». Түмән өлкәсендә дә Тазлар елгасы бар. «Таз, тазлар» этносы Себер, Алтай, Тува халыкларын формалаштыруда катнашкан. Бу этноним казах, кыргыз, төрекмән, татар һәм башкортларда да бар. Ока суы бассейнында да мондый атамалар очрый.

Бу урында шуна әһәмият бирергә кирәк: Галимнәр фикеренә караганда, кабилә-кавемнәр һәм халык исемнәре хакимлек итүче төркемнәр жинүенә мөнәсәбәтле рәвештә еш алмашынып торуга карамастан, аларның гореф-гадәтләре, традицияләре әлләни үзгәрми. Аерым төрки кабилә-кавемнәрнең борынгы чорда искә алынган атамалары соңгы чорларга кадәр килеп житә, ягъни алар жингән кабилә-кавемнәргә кушылалар һәм үзләре эреп югалган очракта да исемнәрен саклап калалар. Тазлар атамасы белән дә нәкъ шундый хәл булган. Тазлар төрки кабилә-кавемнәр арасында яшәгәннәр һәм соңыннан нугай кабиләләре белән безнең жирлеккә дә килеп урнашканнар. Кыскасы, Тазлар атамасы —безгә борынгы чорлардан калган истәлек ул.

## Тигәнәле авыллары

Исемендә Тигәнәле берәмлеге катнашкан авыллар Алексеевск районында урнашкан. Зур Тигәнәле —жирле үзидарә советы үзәге, ул Алексеевскидан 23 чакрымда. Урта Тигәнәле —жирле үзидарә советы үзәге, район үзәгеннән—18, Түбән Тигәһәле Урта Тигәнәледән —4, Алексеевскидан 20 чакрымда утырган, һәр өч авылда татарлар яши. Тигән Булак —жирле үзидарә советы үзәге булган Родники авылыннан —3, Алексеевскидан 24 чакрым ераклыкта.

Тигәнәле авыллары янында археологлар борынгы һәм соңгы болгар чорларына мөнәсәбәтле авыл хәрабәләре, каберлекләр тапканнар.

XVIII гасыр тарихи чыганагында Зур Тигәнәледә 153 йомышлы татар, 4 керәшен татары, Урта Тигәнәледә (ул икенче төрле Аккозино дип билгеләнгән) 232 йомышлы, 14 керәшен татары, Түбән Тигәнәледә 101 йомышлы, 16 керәшен татары, ә Тигәнәледә чукынган чуашлар саны 60 кеше билгеләнә.

1898 елда чыккан китаптагы мәгълүматларга караганда, Зур Тигәнәле, Урта Тигәнәле (Аккүз), Түбән Тигәнәле авылларында татарлар яшәгән. К.П.Берстель жыентыгындагы мәгълүматлар буенча, Зур Тигәнәледә барлыгы 1861 татар, Урта Тигәнәледә 2497, Түбән Тигәнәледә 1414 татар кешесе исәпләнгән, ә менә Тигән Булак авылында 343 чуаш яшәгән. Авыл аксакаллары сөйләвенә караганда, Зур Тигәнәледә татар, чуаш һәм мордвалар яшәгән. 1811 елда мордвалар Лягушкино (хәзер Родники) авылына аерылып чыгалар. Чуашлар Тигән Булак авылын нигезлиләр.

Авылдан күчеп киткән вакытта Татьяна исемле чуаш хатыны, мөмкинлеге булмагач, китә алмый. Тау битендә аның йорты ялгыз кала. Шул тирәдәге күлне, Татьяна исемен үзгәртеп, Түти күле дип атыйлар. Хәзер дә ул шулай йөртелә.

Аксакаллар сөйләвенә караганда, авылны икегә аерып тора торган елга буенда тигәнәкләр күп үскәнлектән, авыл да Тигәнәле дип аталган. Шулай ук халык арасында «авылга Тиганаев фамилияле кеше нигез салган» дигән фикер дә бар. Бу кешенең ике энесе булып, алар гаилә төзегәч, күршедәге Урта Тигәнәле һәм Түбән Тигәнәле авылларын корганнар. Бу җәһәттән караганда, Зур Тигәнәленең халык телендә Иске авыл дип йөртелүе дә игътибарга лаек. Димәк, авыллар арасында Зур Тигәнәле борынгырак.

Зур Тигәнәлене оештырган Тиганаевны авыл халкы бай кеше булган дип сөйли. Ихтимал, авыл урамының бер очын Морза очы дип атау шул бай морза белән бәйләнгәндер. Чыннан да, элекке заманнарда авылның югары очында морзалар яшәгәнлеге турында истәлекләр сакланган. Авылның түбән очын Кәҗә тавы дип йөртәләр. Бу тирәләрдә элек кәҗә көтүе көткәннәр дип сөйлиләр.

Зур Тигәнәле авылы ике яктан елга белән бүленгән. Елгаларның берсен Әрәмә, икенчесен Инеш дип йөртәләр. Бу инешләр авылдан якын гына жирдә

бергә кушылалар һәм суларын Шонталы елгасына коялар. Шонталы исә Камага кушыла.

Зур Тигәнәле авылы тирәсендә бик матур күлләр бар. Исемнәре халык теленнән төшми: Бути күле, Сандугач күле, Өч күл һ.б. Өч күл янында милли бәйрәм Сабан туе үткәрелә. Авыл янындагы Шалканлы күл тирәсендә элек шалкан чәчә торган булганнар. Авылдан биш чакрым ераклыкта, урман буенда, алпавыт Малафеевның утары булган. Шул тирәдәге күлне хәзер дә Малафи күле дип әйтәләр. Авылның көньяк-көнбатышындагы урман Тигәнәле башы дип атала. Тигәнәле башына барганда кала торган күл элекке вакытларда Әхмәтша исемле бабай тарафыннан буып алынган булган. Авыл халкы, бу исемне бозып, Апач күле дигән атама ясаган.

Өч күл янындарак Ташчишмә исеме алган чишмә челтерәп ага. Исеменнән үк күренгәнчә, ул ташлар арасыннан башлана. Кызганыч, хәзерге вакытта авыл янындагы күп чишмәләр юкка чыккан, чөнки авылның чишмәләр җыелып аккан урынында зур буа —плотина төзелгән. Бу плотина суы астында матур-матур җәйләүләр, болыннар һәм үзәннәр калган...

1994 елның көз аенда Зур Тигәнәледә шатлыклы вакыйга —мәчет ачу булган. Ул авылның нәкъ уртасында, авылның яме һәм күрке булып калкып тора. Әле күптән түгел генә Даһия Хафиз кызы җитәкчелегендә, авылда тарих музее ачылган.

Зур Тигәнәле авылында шагыйрь, драматург һәм прозаик Салих Баттал (Салихҗан Вазих улы Батталов) туып-үскән.

## Тимершык авылы

Тимершык авылы Саба районында, район үзәгеннән —8, Шәмәрдән тимер юл станциясеннән 19 чакрым ераклыкта урнашкан.

Авыл атамасы тарихи чыганакларда еш искә алына. Бу авылда XVIII йөздә 268 ясаклы татар яшәгән.

Тимершык авылы халкы элек июнь ае ахырында күршедәге Иске Мичән, Яңа Мичән, Олы Шыңар, Кече Шыңар, Югары Симет, Түбән Симет, Миңгәр, Сабай, Чулпыч, Түлешкә, Казаклар, Олы Кибәхуҗа, Оет авыллары халкы белән бергәләшеп Шыңар җыены яисә икенче төрле Симет җыены үткәргән.

Авыл кайчан барлыкка килгән? Аны кемнәр нигезләгән?

Өлкәннәр сөйләве буенча, авыл XV йөз урталарында оешкан. Элек бу тирәләр калын урман белән капланып алынган булган. Моны авыл янындагы Хисамби, Чуманай ышналары дип аталган басу-кырлар да күрсәтеп тора. Хәзерге Йомгалак урманы, Зиреклек дип аталган урыннар шул элекке зур урманнардан калган истәлекләр. Бирегә халык Болгар җимерелгәннән соң килеп утырган. Иң беренче булып Тимербашмак исемле кеше үзенең өч улы белән килеп урнашкан. Аның уллары —Хәсәншәех, Кадыйр һәм Тимершәех исемле була. Татарлар килгәнче бу тирәләрдә, имеш, чирмешләр яшәгән. Аларның хатын-кызларын татарлар әкәй исеме белән атап йөрткән. Авыл янындагы Әкәй тавы дигән атама, бәлки, шушы әкәй дигән сүзгә мөнәсәбәтледер. Татарлар килгәч, марилар бу урыннарны ташлап китә. Шулай да авыл халкы арасында мари нәселләре дип йөртелә торган кешеләр әле дә бар. Күрәсең, алар монда калып ислам кабул иткән һәм татарлар белән аралашып беткәннәр.

Тимербашмакның вафатыннан соң уллары Кадыйр белән Хәсәншәех икенче урынга китеп утыралар. Тимершәех шушында кала һәм авыл аның исеме белән Тимершәех дип атап йөртелә башлый. Тимершәех картайгач Әкәй тавына менә һәм шуннан ук ата. «Бу ук кая төшә, мине шунда күмәрсез», — ди. Тимершәех угы икенче тау итәгенә килеп төшә. Хәзерге вакытта Тимершык һәм Миңгәр авыллары арасында бер кабер бар. Бу каберне Тимершәех кабере дип йөртәләр. Аның тирәсе чардуган белән әйләндереп алынган.

# М

**МИҢНЕГУЛОВ** Хатыйп Йосыф улы (12.5.1939, Зәй р-ны Апач а.), әдәбият галиме, филол. фән. д-ры (1991), проф. (1992), ТРның, РФнең атказ. фән эшлеклесе (1994, 2005). 1964 тә Казан ун-тын тәмамлый. 1967 дән ш.у. эшли, 1999-2009 елларда татар әдәбияты каф. мөдире. Хезмәтләре урта гасыр, 19 йөз татар әдәбиятына, аның гарәп, фарсы һәм төрки телле әдәбиятлар б-н бәйләнешләренә, чит илләрдәге татар әдәбияты һәм матбугаты, Г.Исхакый, Г.Тукай иҗатларына карый, әдәби жанрларны да өйрәнә. Урта мәктәпләр һәм вузлар өчен язылган дәреслекләр һәм методик кулланмалар авторы, хрестоматияләр төзүче. С.Сараи, Котб, Ялчыгол, Ш.Зәки һ.б. әсәрләрен матбугатка әзерли (кереш сүз, тәрҗемә, транслитерация, комментарийлар авторы). «Татар әдәбияты һәм Шәрекъ классикасы» («Татарская литература и Восточная классика», 1993) исемле монографиясе ТРның фән һәм техника өлкәсендәге дәүләт бүләгенә лаек була (1995), ТР Язучылар берлегенең Г.Исхакый исем. бүләк иясе (2005). ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Әс.: Дөньяда сүземез бар. К., 1999; Гасырлар өнен тыңлап. К., 2003; Гаяз Исхакыйның мөһаҗирлектәге иҗаты. К., 2004; Чит илләрдәге татар әдәбияты. К., 2007; Записи разных лет (Татарская литература: история, поэтика и взаимосвязи). К., 2010.

Әд.: Хатыйп Миңнегулов турында—О профессоре Миннегулове. К., 2009.

**МИҢЛЕКӘЙ** (Минлекәев) Сахау (Сахаветдин) Кашафетдин улы (7.12.1895, Самара губерниясе Бөгелмә өязе Акбаш а.—17.1.1954, Уфа ш.), шагыйрь. 1906-13 елларда Бәйрәкә а. «Гобәйдия» мәдрәсәсендә белем ала, 1913-15 елларда Добрино а. (хәзер Самара өлкәсе Клявлин р-нына керә) икееллык рус мәктәбендә укый. 1915 тән армия сафларында. 1917 дә полкның солдат комитетына, соңыннан 12 нче армиянең мөселман комитетына сайлана. 1917 дән соң уку-укыту оешмаларында эшли. Гражданнар һәм Бөек Ватан сугышларында катнаша. Укырга омтылышка, мәхәббәткә, табигатькә, тарихи үзгәрешләр чорында татар халкының язмышына багышланган беренче шигырьләрен М. мәдрәсәдә укыганда ук яза башлый. Соңыннан бу шигырьләр «Солдат моңнары» (1918), «Күңелле шигырьләр» (1921), «Кош-кортлар арасында» (1921), «Кызыл гөлләр»(1923) исемле күмәк шигъри җыентыкларга керә. М. балалар өчен дә яза: «Балалар өчен җырлы уеннар» (1921), «Җырлы уеннар» (1923), «Тезмә сүзләр» (1931). 1930 елларда иҗаттан читләшә. «Качкыннар», «Гөлгенә» һ.б. поэмалары басылмый кала.

Әсәр.: Шигырьләр һәм поэмалар. Бөгелмә, 1998; Сабанда. К., 2001.

*С.Г.Сафуанов.*

**МИҢНУЛЛИН** Ким Мөгаллим улы (4.1.1959, Башкортстан АССР ның Илеш р-ны Нәжәде а.), әдәбият белгече, фольклорчы, филол. фәннәре докторы (2002). 1985 тә Казан ун-тын тәмамлый. 1988-96 елларда ТР ФА Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тында; 1996-2006 елларда ТР МК Аппаратында; 1999 дан ТР халыклары телләрен үстерү буенча бүлек мөдире, берүк вакытта, 1996 дан «Татарстан Республикасы халыклары телләре» исемле ТР Законын гамәлгә кертү комитеты сәркәтибе; 2006 дан ТР ФА Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-ты директоры. Хезмәтләре фольклористика (татар җыр поэзиясе тарихы һәм теориясе), социолингвистикага (ТР да тел сәясәте мәсьәләләре) карый.

Хезм.: Шигърият һәм җыр. К., 1998; Басма сүз һәм татар җырлары. К., 2000; Современные этнокультурные процессы в молодёжной среде Татарстана: Язык, религия, этничность. К., 2000 (соавт.).

Әд.: Казанский университет (1804-2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т.2.

**МИҢНУЛЛИН** Роберт Мөгаллим улы (1.8.1948, Башкорстан АССРның Илеш р-ны Нәжәде а.), шагыйрь, журналист, җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1993), Башкортстан Респ-касының атказ. мәдәният хезмәткәре (1998), ТРның халык шагыйре (2005). Казан ун-тын тәмамлагач (1973) «Яшь ленинчы» г-тасы редакциясендә әдәби хезмәткәр булып эшли. 1977-83 елларда «Казан утлары» ж-лында бүлек мөхәррире, соңрак җаваплы сәркәтип. 1983-86 да ТАССР телевидение һәм радиотапшырулар буенча дәүләт к-тында әдәби тапшырулар мөхәррире. 1986-95 тә

*Дәвамы. 2005 елның 4нче саныннан басылып килә.*

«Сабантуй» г-тасының баш мөхәррире. «Татарстан» телеканалында «Шигъри тәлгәшләр» (1976-83), «Ихлас» (1993-95), «Китап» (2008) дигән тапшырулар циклы алып бара. 1995 тән ТР Дәүләт Советында: Мәдәни һәм милли мәсьәләләр буенча даими комиссия рәисе, ТРсы Дәүләт Советы рәисе урынбасары (2000-04), 2004 тән ТРсы законнары текстларын тәнгәлләштерү комиссиясе рәисе. Баштагы чор иҗатында дөньяга, табигатькә янача карашлы лирик шигырьләре «Идел» альманахында, «Казан утлары» ж-лында, «Беренче карлыгачлар» (1970), «Безнең бәйрәмнәр» (1974) дигән күмәк җыентыкларда урын ала; аларның герое—шаян-шук, уйлап чыгарырга хирыс-фантазер, артык кызыксынучан малай. Шагыйрь балалар сөйләменә хас лексиканы, ятышлы гыйбарәләрне бик оста куллана, аларның интонациясен, халәтен ачып бирә («Акбай цирк карый», 1978; «Айга очтык!», 1982; рус теленә тәрҗемәдә «Глядит в окошко человек», М., 1986 җыентыклары). Күп кенә әсәрләрендә көндәлек тормыш хәлләрен сурәтли, өлкәннәр белән балалар арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләрне, сабыйлар дөньясындагы четерекле проблемаларны калку итеп чагылдыра (рус теленә тәрҗемәдә «Мне нужен братишка», 1990; «Дөньядагы иң зур алма», 1992, рус теленә тәрҗемәдә «Ох, уж эти взрослые!», 1993; «Күчтәнәч», 1995; «Алма бабай», 1997; рус теленә тәрҗемәдә «Возвращение», 2000; «Балачакка ешрак кайтыгыз», 2002; «Сөенсеннәр әле сабыйлар», 2002; рус теленә тәрҗемәдә «Мальчик, каких еще мир не видал», 2003 җыентыклары). М. иҗаты балалар тематикасы белән генә чикләнми. Аның иҗатында мәхәббәт лирикасы, туган җир белән бәйле әнкәйләр темасы да зур урын алып тора: «Бәхетле булыгыз!» (1976), «Мәңгелек сәфәр» (1983), «Әнкәйнең ак чәчләре» (1986), «Сандугачның туган көне» (1990), «Талбишек» (1995), «Әнкәй безне Сөннән алып кайткан» (2002) җыентыклары. М. лирикасы тирән фәлсәфәгә корылган, милли мотивлар белән сугарылган. Шигъри теле юмор белән баетылган. Шигырьләре гадилеге, җинел аңлаешлылыгы белән аерылып тора, аларга күренеп торган төгәл, ачык детальләр хас. М. поэзиясенең музыкаль яңгырашлылыгы күп кенә композиторларның да игътибарын җәлеп итә. Аның шигырьләренә композиторлар Р.Яхин, С.Садыйкова, М.Шәмсетдинова, Р.Хәсәнов, Р.Абдуллин, Ф.Әбүбәкеров, И.Закиров, О.Усманов язган җырлар бигрәк тә популярлык казанды. Публицистик, әдәби тәнкыйть мәкаләләре «Шагыйрь генә булып калалмадым» (1998), «Мин—нечкә күңелле сәясәтче»—«Я—сентиментальный политик» (1999) җыентыкларына тупланган. Әсәрләре рус, башкорт, украин, белорус, чуаш, удмурт, мари, каракалпак, инглиз, төрек телләренә тәрҗемә ителгән. ТР сы Балалар фонды рәисе (1988-94). 1990нан ТР Дәүләт Советы депутаты. Татарстан яшьләр оешмасының М.Җәлил исем. (1982), ТР Язучылар берлегенең А.Алиш исем. (1997), ТРның Г.Тукай исем. дәүләт премияләре (1998) лауреаты. Г.-Х.Андерсен исем. Почетлы диплом иясе 1994.

Әсәр.: Уфа-Казан юллары. К., 1998; Сайланма әсәрләр: 4 томда. К., 2004; Әсәрләр: 7 томда. К., 2008.

Әд.: Ганиева Ф. Шагыйрь гомере—аккошлар юлы // Казан утлары. 1998. №8; Рахмани Р. Талантлар нигә төрле? // Мәйдан. 2003. №9; Урманче Ф. Роберт Миннуллин: Шигъри осталык серләре. К., 2005.

*Г.М.Габделхакова.*

**МИҢНУЛЛИН** Туфан Габдулла улы (25.8.1935, Кама Тамагы р-ны Олы Мәрәтхуҗа а.), драматург, публицист, җәмәгать эшлеклесе, ТАССР, РСФСР, Башкортстан Респ-касының атказ. сәнгать эшлеклесе (1978, 1984, 1995), ТРның халык язучысы (2005). М.С.Щепкин исем. театр уч-щесын (Мәскәү, 1961), М.Горький исем. Әдәбият ин-ты каршында Югары әдәби курсларны (Мәскәү, 1977) тәмамлый. Уку елларында рус һәм европа театр сәнгатенең иң яхшы үрнәкләре белән якыннан таныша. Берникадәр Минзәлә драма т-рында (1961-62), Татар академия т-рында (1962-63) актер хезмәтендә була, ТАССР МС каршындагы радиотапшырулар һәм телевидение к-тында өлкән мөхәррир (1963-64), «Чаян» ж-лында әдәби хезмәткәр булып эшли (1964-68). 1984-89 да ТАССР Язучылар берлеге идарәсе рәисе, РСФСР Язучылар берлеге идарәсе сәркатибе, 1994 тән татар ПЕН-үзәге президенты. Беренче әдәби тәҗрибәләре—бер пәрдәле пьесалар, скетчлар, шаян хикәяләр. М.ны драматург итеп таныткан пьесалары: иҗат яшьләре тормышыннан алып язылган «Миләүшәнең туган көне» драмасы (1968 елда сәхнәгә куела) һәм гаиләдәге әхлак проблемаларын үз эченә алган «Нигез ташлары» комедиясе (1968 елда сәхнәгә куела). Язучы драматургиянең төрле жанрларында актив иҗат итеп, күбесе Татарстан, Башкортстан, Казахстан, Үзбәкстан, Чуаш, Марий Эл респ-каларының театр сәхнәләрендә уйналган уңышлы әсәрләр тудырды, кайберләре республика һәм үзәк телевидение аша күп тапкырлар күрсәтелде, театр өлкәсенә караган үзәк журналларда басылып чыкты. Бүгенге көндә М. әйдәп баручы милли драматургларның берсе. Аның драматургиясе жанр, форма төрлелеге, пьесаларының халыкчан образлы, җор телдә язылуы, диалогларның җанлы, табигый яңгыравы, композицион яктан җыйнак-төгәл булуы

белән җәлеп итә. Пьесаларының күбесендә хәзерге заманның катлаулы проблемалары чагылыш таба. М. драматургиясендә стиль һәм идея юнәлешендә ачык чагылыш тапкан проблемаларның берсе буларак шәхес булып формалашуга багышланган пьесалар киң урын алып тора: «Китәр юлың еракмы?» (1975 тә сәхнәгә куела), «Адәм баласына ял кирәк» (1980 елда сәхнәгә куела), «Монда тудык, монда үстек» (1982 елда сәхнәгә куела). Бу юнәлеш бигрәк тә «Миләүшәнең туган көне» (1968 дә куела), «Дуслар җыелган җирдә» (1976 да куела), «Хушыгыз!» (2000 дә куела) трилогиясендә гәүдәләнеш таба. Бу драмаларда тулы буын татар иҗат интеллигенциясенең катлаулы язмышы күзәтелә, җәмгыятьнең кеше алдында җаваплылыгы проблемасы күтәрелә. Икенче бер юнәлештәге пьесаларында инде шәхес буларак формалашкан персонажлар үзәккә алына. «Ир-егетләр» (1971 дә куела), «Үзебез сайлаган язмыш» (1973 тә куела), «Ай булмаса, йолдыз бар» (1977 дә куела), «Әниләр һәм бәбиләр» (1983 тә куела) пьесаларының геройлары—тормышта үз кыйбласын тапкан, тормыш авырлыкларына каршы торырлык, максатчан шәхесләр. Идея-эчтәлек ягыннан бигрәк тә игътибарга лаек әсәре—«Әлдермештән Әлмәндәр» (1976 да куела) фәлсәфи комедиясе. Монда кеше рухы ныклыгының тамырлары ачык күрсәтелә, яшәүнең үлемнән көчле булуына басым ясала. Тагын бер юнәлеш пьесалары—тарихи вакыйгалар һәм тарихи шәхесләргә багышланган. «Ат карагы» (1972) драмасының прототибы—җәмгыятьтәге хокуксызлыкка каршы чыгыш ясаучы, шәхси азатлыгын яклаучы гадәти булмаган тарихи шәхес; «Канкай угылы Бәхтияр» (1974 тә куела) драмасындагы—Е.Пугачевның көрәштәшләреннән берсе. «Моңлы бер җыр» (1981 дә куела) романтик трагедиясенең геройлары—М.Җәлил һәм аның көрәштәшләре; «Без китәбез, сез каласыз» (1986 да куела) драмасының төп герое—халык шагыйре Г.Тукай; «Агыла да болыт агыла» (2001 дә куела) пьесасындагы—шагыйрь Х.Туфан; 1990 елларда М. драматургиясе яңа темалар һәм образлар белән баеды. «Вөҗдан газабы» (1987 дә куела) пьесасында автор җәмгыять строеның алмашуы кеше аңында нинди үзгәрешләргә китерүен ассызыклый; «Илгизәр + Вера» (1994 тә куела) драмасы катнаш никахлар мәсьәләсенә карый; «Шәҗәрә» (1998 дә куела) пьесасы буыннар күчеше проблемаларын чагылдыра. М.ның татар халкының язмышы, тел, мәдәният проблемалары борчый. Ул илдә барган үзгәрешләрнең асылына төшенергә, гасырлар буе дәвам иткән халык традицияләренең, рухи байлыгыбызның югала бару сәбәпләрен аңлатырга тырыша. «Сөяркә» (2001 дә куела) драмасында мәхәббәт һәм бурыч кебек әхлак проблемалары үзәккә алына. «Эзләдем, бәгърем, сине» (2001 дә куела), «Шулай булды шул» (2003 тә куела), «Алты кызга бер кияү» (2006 да куела) пьесаларының геройлары—тормыштан мәгънә эзләп яшәүчеләр. М.—шулай ук Г.Камал, К.Тинчурин традицияләрен дәвам иттерүче үзенчәлекле комедиограф та. Комедияләре форма төрлелеге белән аерылып тора: «Әлдермештән Әлмәндәр» характерлар комедиясе булса, «Яшьлегем—җүләрлегем» (1978 дә куела) һәм «Йөрәк маем» (1997 дә куела) вакыйгалар комедиясе, «Диләфрүзгә дүрт кияү» (1972 дә куела)—водевиль, «Бәйләнчек» (1982 дә куела) һәм «Бажа мал түгел, кәкә туган түгел» (1992 дә куела)—сатирик комедияләр, «Гармун белән скрипкә» (1987 дә куела) һәм «Гөргөри кияүләре» (1995 тә куела)—музыкаль комедияләр. Балалар өчен 20 ләп пьеса, шул исәптән Акбай турында 7 пьеса иҗат итеп («Авыл эте Акбай», «Акбай нигә күңелсез?» һ.б.) язучы балалар драматургиясен дә баетты. М.—җор телле хикәяче, туры сүзле публицист һәм тәнкыйтьче дә. Ул «Дуслык хакына» (1965), «Чишмә җыры» (1968), рус теленә тәрҗемәдә «Милые мои» (1979) исемле хикәяләр җыентыклары, тормыш вакыйгалары турында фәлсәфи уйлар белән баетылган «Утырып уйлар уйладым» (1-3 кит., 1997-2005), «Татарның бер баласы» (2003) көндәлек язмалар авторы. 1985-90 елларда ТАССР ЮС депутаты, 1989-92 дә СССР халык депутаты, 1995 тән ТР Дәүләт Советы депутаты. Ленин һәм СССР Дәүләт премияләре буенча к-т әгъзасы (1990-92), Азия һәм Африка илләре .... к-ты әгъзасы (1985-92). Республика яшьләр оешмасының М.Җәлил исем. (1974), ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт (1979), РСФСРның К.Станиславский исем. Дәүләт (1979) премияләре лауреаты. «Почет Билгесе», «Татарстан Республикасы каршындагы казанышлары өчен» орденнары белән бүләкләнгән.

Әсәр.: Ир-егетләр: Пьесалар.К., 1974; Монда тудык, монда үстек.: Пьесалар. К., 1985; Ай булмаса, йолдыз бар: Пьесалар. К., 1996; Робагыйлар. К., 1999; Сайланма әсәрләр: 10 томда. К., 2002.

Әд.: Молчанов Ю. Драматург и режиссер // Дружба народов. 1983. №11; Әхмәдуллин А. Халыкчан характерларга омтылганда // Сәхнә әдәбияты һәм тормыш. К., 1980; Шул ук. Үзе сайлаган язмыш // Дөреслеккә ирешү юлында. К., 1993.


*А.Г.Әхмәдуллин.*

*Дәвамы киләсе саннарда.*

# ЗЫЯЛЫ МАТУРЛЫК

РИЗВАН ХӘМИДКӘ 70 ЯШЬ

Ул чакта, ягъни узган гасырның сиксәненче еллар башында, Ризван абый Хәмид белән әле якыннан таныш түгел идем. Без фәкыйрегез Казанны «яуларга» килгән елда (1979) ул Мәскәүнең Луначарский исемендәге Театр сәнгате институтында берьеллык Югары курсларны тәмамлап кайта. Аннан кайткач, комсомолның Татарстан өлкә комитетында республика әдәби берләшмәләре һәм түгәрәкләренең җитәкчесе вазифасын башкара. 1981-1983 елларда Ризван абый СССР Язучылар берлеге каршындагы икееллык Югары әдәби курсларда белемен күтәрә. 1984-1985 елларда Татарстан Язучылар берлегенең Чаллыдагы оешмасына җитәкчелек итә. Бу вакытларда мин—студент, «кефир малае» гына әле. Ни хәл итмәк, юлларыбыз Ризван абый белән шул елларда кисешмәгән. Әмма үзе белән таныш булмасам да, иҗатын ярыйсы гына белә идем шикелле. Ризван абыйның 1977 елда язган «Синең урыныңа кайттым...» исемле тәүге драмасын Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры тиз арада репертуарына алып сәхнәләштерде. Артистларның оста уйнаулары белән дә, сәхнәгә куелыш ягыннан да гаять уңышлы килеп чыккан ул спектакльне бик тәэсирләнеп караганым истә. «Китәм инде» (1983) белән дә шундый ук халәт кичердем (Сүз уңаеннан: шушы ике әсәре өчен драматург 1984 елда Республиканың М.Җәлил исемендәге премиясенә лаек булды). Ризван абыйның 1982 елда Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан «Кайтыр идем» исемле беренче китабын йотлыгып укыганымны бүген дә хәтерлим әле. Әдәбиятка, театр дөньясына Ризван Хәмид дигән зур драматург-талант килүен күреп, сөенеп-куанып, шагыйрь Зөлфәт мондый эпиграмма ( әлеге шаян дүртьюллыкны иң әүвәл язучыларның ул вакытта гаять дәрәҗәдә популяр булган «Тынгысыз каләм» дигән дивар гәзитеннән укыдым) язган иде:



*Ризван, Ризван, Ризван,*
*Ризван—гөлнең чәчәге.*
*Татар театрларының*
*Бар әле күрәчәге!*

Чынлап та, драматург Ризван Хәмид тарафыннан язылган бик күп пьесалар, әйтик, «Иске йорт кешеләре» сатирик комедиясе (1979), «Кайтыр идем» (1980), «Каен җиле» (1982), «Китәм инде» (1983), «Айсберг» (1984), «Майның унбишләрендә»

(1984), «Диде кардәш...» (1985), «Ике сәгать—бер гомер» (1985), «Олы юлның тузаны» (1986), «Жиде бажа» (1988), «Хушлашырга безгә иртә әле» (1991), «Исәнлеккә-саулыкка» (1994), «Көзнен сонгы яфраклары» (1996), «Тигезәкләр» (2000) һәм башка драма-комедияләре Г.Камал исемендәге, К.Тинчурин исемендәге, шулай ук Әлмәт, Чаллы, Минзәлә театрлары сәхнәсендә күп мәртәбәләр уйналып, зәвыклы, сизгер күнелле тамашачыларыбызның игътибарын жәлеп итте, ихтирамын яулады. Ул гына да түгел, драматургның аерым пьесалары заманында Казан рус яшьләр театры һәм Димитровград, Сизов шәһәрләрендәге рус театрлары сәхнәләрендә, милли телләргә тәржемә ителеп, Төрекмән, Лак, Кабарда дәүләт театрларында, Сибай башкорт театрында куелып, зур уңышлар казанды.

Инде Ризван абый белән ныклап танышуыбызга (әүвәлтен башлар кагышып яисә үтешли генә куллар кысышып булса да кителгәндер барыбер дип уйлыйм) килик. 1986 ел. 17 май. Бу көнне бик яхшы хәтерлим. Әле кичә генә «Яшь ленинчы» гәзите редакциясендә гап-гади бер корреспондент идем, бүген исә СССР Әдәби фондының Татарстан бүлеге директоры вазифасында тәүге эш көнем. Ризван абый—Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары (ул вакытта рәис Туфан абый Миннуллин иде). Аның эш бүлмәсендәге өстәл янында, кара-каршы утырып, гәпләшәбез. Дөресрәге, күпчелек ул сөйли, эшне ни-нәрсәдән башларга кирәклеген аңлата, киңәшләр бирә, ә мин, баш кагып, «әйе-әйе» дигәләп, тыңлап утырам. Менә шул көннән башлап бүгенгәчә без, Ризван абый белән икәү, дустанә мөнәсәбәттәбез.

Ризван абый Хәмиднең байтак каләмдәшләре белән үзара гәпләшүен бик еш тыңлап торганым булды. Мәсәлән, Илдар абый Юзеев белән. Бер караганда алар бер тигез дәрәжәдәге каләм әһелләредәй, бер-берсен хан заманыннан бирле белгән дуслардай сөйләшәләр сыман. Икенче караганда исә, Остаз белән Шәкертнең үзара шаян-төртмә сүзләр әйтешә-әйтешә, бер үк вакытта кызыклы да, мәгънәле дә гәп коруларын аңлыйсың. Ризван абый, хатирәгә бирелеп, балачагын, иҗат дөньясына тәүге адымнарын ясый башлаган чакларны исенә төшерә:

—Әдәбият белән бишенче сыйныфта укыганда кызыксына башладым. Дилбегә буе озын «поэма» яздым да, батырчылык итеп, шуны «Ялкын» журналына жибәрдем. «Мәче белән тычкан» иде бугай исеме. Шулкадәр жиңел язылды ул. Әгәр шул юлдан киткән булсам, базар көнне бәясе өч тиен дә тормаган тагын бер графоман пәйда булган булыр иде. Ярый әле, Илдар абый, бәхетемә, сез туры килдегез. Үзегез дә хәтерлисез булыр, сездән, журналдан шундыйрак эчтәлектәге хат килде: «Ризван энекәш, бик жиңел язгансың син моны. Авыррак яза башлар өчен бик күп укырга, өйрәнергә кирәк әле сиңа!» Менә шул сүзләрегез айнытып жибәрде мине. Рәхмәт сезгә, Илдар абый, бүтән һөнәр сайла, энекәш, димәгәнегез өчен!

Илдар абый тыйнак кына елмая.

Икенче бер олпат әдип белән, әйтик, Мәгъсүм ага Хужин белән Ризван Хәмиднең гәпләшүе—үзе бер спектакль. Нинди генә темага сүз башласалар да, ахыры барыбер ут чыгарып бәхәсләшү белән тәмамлана. Ризван абый белән Мәгъсүм абый кайчандыр «Чаян»да бергә эшләгәннәр (Ризван абый бу журналда башта фельетончы, соңрак хатлар бүлеге мөдире сыйфатында жиде еллап хезмәт куя). Яшь аермасы шактый булса да, бер-берсенә «син» дә «син» дип кенә эндәшәләр. Күренеп тора, болар—азау ярган дуслар, очрашсалар, үзара бәхәсләшмичә тынычлана алмыйлар. Бәхәс—бу икәүне ижатка дәртләндерүче бер алым гына. Алар моны үзләре бик яхшы белә. Бераздан, суынып, бер-берсенә «Сау булып тор, Мәгъсүм абый! Исән-сау очрашканга кадәр, Ризван!» диешеп, бик жылы саубуллашып, фатирлары тарафына юл тотачаклар. Кайтып, өстәл янына утыруга, каударланып-ләззәтләнеп илһам белән мөлдерәмә тулган каләмнәрен кулларына алачаклар. Әлегә исә Ризван абый янә сүз ала:

—Бер мәзәк сөйлим, Мәгъсүм абый, тыңла. Өч галим мәгарәдә йөргәндә борынгы кылыч тешле юлбарыс сөякләренә юлыга. Берсе әйтә: мин моның скелетын кабат жыеп бирә алам, ди. Икенчесе әйтә: ә мин скелетына кабат тән үстерә алам, ди. Өченче галим шуңа жан өрә алуын әйтә. Юлбарыс терелә дә өчесен дә тотып ашый. Без, Мәгъсүм абый, нәкъ әнә шул галимнәргә охшаганбыз: берәүне күкләргә чөеп мактый-мактый юлбашчы итеп күтәрәбез дә... ул безнең башларыбызны ашарга тотына...

—Ризван, син башта Мәгъсүм абыенның акыллы фикерен ишет...

Бәхәскә җирлек бар, ике дус ипләп кенә сүз көрәштерергә керешә.

Ризван абый—аяклы энциклопедия: белмәгән нәрсәсе юк. Рәссам Фәрит Муллахмәт белән очрашсалар, ана рәсем сәнгате буенча тиз генә дәрес биреп ала. Шагыйрь Ркаил Зәйдулла белән көрешсәләр, берсен-берсе бүлдерә-бүлдерә, җәһәт кенә тарихның барлык катламнарын актарып чыгарга өлгерәләр.

Бервакыт Ризван абыйдан: »Тиктомалдан гына драматург булып китмәгәнсендер инде. Берәр сәбәп яисә этәргеч-мазар булгандыр бит?!»—дип сораган идем. Ул болай дип җавап бирде: «Башкортстанның Ярмәкәй районы (Ризван Мирхәбибулла улы Хәмидуллин шушы районга кергән Усман-Ташлы дигән авылда 1941 елның 24 октябрендә колхозчы гаиләсендә туа.) гәзите белән элемтәгә кергәч, көлтә-көлтә шигырьләрем басылды. Әмма бу мине һич кенә дә канәгатьләндермәде. Ни өчен дигәндә, миндә чын шигырь язуга караганда, мәртәбәле шагыйрь булу теләге көчлерәк иде. Әдәбият минем өчен түгел икән, башка юл сайларга кирәктер, дип уйлый башлаган идем инде, ниһаять, бер очраклы хәл драматургияне үз жанрым итәргә этәрде. Туган авылыбызга ничектер бер театр килеп төшкән иде. Спектакльне карыйм—йөрәкне парә-парә телгәли генә бит теге. Юк, әйбәтлеге белән түгел, ясалмалыгы һәм пүчтәклеге белән! Клубта ике-өч минут та утыра алмыйм, ташлап чыгып китәм дә... тагын кереп утырам: сихерлелеге тарта, ә начарлыгы күнелне биздерә. Шунда үз-үземә сүз бирдем: драматург булачакмын, ләкин бүтәнчә язачакмын. Шул антымда тордым шикелле...»

Бүгенге көндә драматург Ризван Хәмиднең кырыклап пьесасы бар. Азмы бу, күпме? Классиклар белән чагыштырганда, сан ягыннан бик тә аз, әлбәттә. Мисалга испан драматургы Лопе де Веганы (1562-1635) гына алыйк. Ул ике меңнән артык пьеса язып калдырган, шуларның биш йөзләбе басылып чыккан, дүрт йөзләбе әле дә уйнала. Ул бар әсәрен дә шигырь белән иҗат иткән һәм бер генә пьесасына да тәүлектән артык вакытын сарыф итмәгән...

—Ходай белсен, ничек эшли алгандыр ул моны!—дип, гаҗәпләнеп әйтеп куя Ризван абый.—Татар драматурглары хәлендә булса, белмим, ни генә кыра алган булыр иде икән Лопе де Вега. Заманында, сүз куешкандай, барлык испан театрлары гел аның әсәрләрен генә куйганнар. Хәтта атаклы «Дон Кихот»ның авторы Сервантесны да сәхнәгә якын китермәгәннәр, ә уйналмаган драматург күп яза алмый. Бу җәһәттән килгәндә, үземне язмышым тарафыннан нык рәнҗетелгән автор дип санамыйм—әсәрләремнең күбесе, тфү-тфү, сәхнә күрде. Үзем бик канәгать калган спектакльләрем бар: шуларның иң беренчесе—Камал театрында Марсель Сәлимҗанов куйган «Синең урыныңа кайттым...», аннары—Чаллыда Фаил Ибраһимов куйган «Тигезәкләр», соңгысы—Фәрит Бикчәнтәев бик шәп итеп сәхнәләштергән «Курчак туе». Бу пьесаны без Мансур Гыйләҗев белән икәү бергә Гаяз Исхакый әсәрләренә нигезләнеп иҗат иткән идек.

Драматург Ризван Хәмиднең күпчелек пьесалары авыл турында, авылның фаҗигаи хәле, шул авылда көн итүче катлаулы язмышлы кешеләр хакында. Әдипнең тарихи темаларга язылган әсәрләре дә байтак: әйтик, «Ак тамырлар иле», Казан ханлыгы җимерелү фаҗигасен гәүдәләндергән «Хан кызы», «Шекә пәриләре» трагедияләре... 1991-1992 елларда Ризван абый телевизион нәфис фильм өчен «Тукай» дигән күләмле сценарий язды. 1993 елда шагыйрь Рөстәм Мингалим белән бергә «Идегәй» дигән кинодрама язып тәмамлады. «Язды», «язып тәмамлады» дидем, болай дип бер дә юкка әйтмәдем, чөнки ул вакытларда әлеге әсәрләрнең язылу барышыннан һәрдаим хәбәрдар булып тордым. Ризван абый көн саен Язучылар йортына, дустыбыз Рөстәм абый Мингалим янына килә иде. Рөстәм абыйның әдәби консультант вазифасын башкарган чагы. Минем дә шул бинада «Салават күпере» журналханәсендә эшләгән мәлем. Сөйләшәләр, кинәш-табыш итешәләр, фикерләшәләр, әсәрнең язылган кадәресен энә күзеннән үткәрәләр, язылася өлешне планлаштыралар. Мин—шул очрашуларның шаһите. Шуңа күрә «Идегәй» күз алдымда язылды, дисәм дә хата булмас.

Ризван абый Хәмидне остазым дип саныйм. Гомумән, бүген сәхнә тоткан драматургларыбызның күбесе (М.Гыйләҗев, Р.Сәгъди, Х.Ибраһим һ.б.), Ризван

абыйның иҗатына югары бәя биреп, үзләрен аның шәкерте итеп исәпли. Чордаш каләмдәшләре Туфан Миңнуллин, Батулла, Рөстәм Мингалим, Гәрәй Рәхим, Марсель Галиевләр дә аның талантының зурлыгын таныйлар дип беләм. Минемчә, Ризван Хәмид—драматургиянең бөтен нечкәлекләрен фәнни дәрәҗәдә белеп, аның асылын тирәнтен аңлап-тоеп, сәхнә кануннарын югары кимәлдә үтәп, уйлы-фикерле укучы-тамашачылар өчен сыйфатлы пьесалар иҗат итүче әдип.

Яшь чагында бик күп һөнәрләр үзләштергән, әйтик, тимер игәүләгән, аяк киемнәре теккән, радист булган, чаңгы бөккән, чабата кайтарган, фокусчы-иллюзионист (шуны драматург төп һөнәре итәргә уйлаган хәтта!) һәм гипнотизер булып гастрольләрдә йөргән Ризван Хәмиднең гадәти тормышта бик тә кызыксынучан шәхес икәнен дә әйтеп китәргә кирәктер. Ул тарихыбызны һәрдаим өйрәнә, сөйләм телебездән төшеп калган иске сүзләрне барлый, драматургиягә, театрга, сәхнәгә кагылышлы сүзлекләр төзи...

—Һәр иҗатчының үз лабораториясе була,—ди драматург.—Минем дә шундыйрак эш ысулым бар: сөйләмнән төшеп калган сүзләрне табу-барлау, фәнни кысаларга сыймаган сүзлекләр төзү шуның тышкы чагылышыдыр. Боларны мин бары тик бер максат белән—иҗатымда кирәк булганга гына эшлим. Әйтик, «сүзлекләр»не һәр пьеса өчен сюжетың күзаллый башлауга аерым-аерым төзим—алар, гадәттә, әсәремнән дә озынрак булалар. Онытылган сүзләргә килгәндә, табигый процесс аркасында төшеп калмаган ич аларның күбесе—телебез ярлылансын өчен махсус «оныттырылганнар». Кайчак, нигә инде әллә ниткән сүзләр кулланалар, без белгән сүзләр генә җитмимени, диләр—шул ямьсез күренеш корбаннары әйтә моны. Өйрәнсеннәр, кабат исләренә төшерсеннәр, ана телебезнең никадәр бай икәнен белсеннәр! Борынгы тарихыбызны өйрәнүемнең сәбәбен бер генә җөмлә белән аңлатам: халкына файдалы буласың килсә, аның үткәненә ешрак борылып кара, әмма алдагыны да онытма—муеның бөтенләй артка таба каерылып катуы мөмкин...

Шактый еллар элек, узган гасырның җитмешенче елларында, «Идел» яшьләр лагеренда яшь иҗатчылар семинары барган чак. Өч аерылмас дус—Фаил Шәфигуллин, Зөлфәт һәм Ризван Хәмид—тәнәфес вакытында үзара гәпләшеп йөриләр икән. Бу өчәүгә карап, Разил Вәлиев, шаяртып, болай дип кычкырган имеш: «Әй, матур егет!» Аның тавышына бары Ризван абый борылып караган ди... Язучы халкы теленә кергән әлеге мәзәк хәл чынлап та булгандырмы, юктырмы, хикмәт анда түгел. Хикмәт шунда: Ризван Хәмид—тышкы кыяфәте, үз-үзен тотышы, сөйләү рәвеше, гомумән, бар холык-фигыле белән зыялы, матур кеше. Мина калса, аның барлык пьесаларыннан да матурлык, зыялылык, яктылык бөркелеп, сибелеп тора сыман. Шагыйрь Рөстәм Мингалим әйтмешли: «Ул шулайдыр әле—уйласаң ».

Нәкъ шулай.

**Ләбиб ЛЕРОН**

## Марсель Зариповка 80 яшь



Марсель Харис улы Зарипов 1931 елның 23 октябрендә Татарстанның Сарман районы Янурыс авылында укытучылар гаиләсендә туа. Балалык еллары шул районның Петровка авылында уза, шунда җидееллык мәктәпне тәмамлый. 1946-1951 елларда Петровка спирт заводында эшли. 1951-1955 елларда Хәрби диңгез флотында хезмәт итә. Армиядән кайткач, «Татнефть» берләшмәсенең бораулау кадрлары мәктәбендә укып, электромонтер һөнәрен үзләштерә һәм нефть промыселларында эшли. Шушы елларда аның җирле һәм республика матбугатында беренче мәкаләләре күренә башлый. 1958 елда М.Зариповны Әлмәт шәһәр газетасына әдәби хезмәткәр итеп чакыралар. Шушы вакыттан алып ул—профессиональ журналист һәм язучы. 1962-1966 елларда ул «Советская Татария» газетасының нефть районнары буенча үз хәбәрчесе булып эшли. Бу елларда экстерн тәртибендә өлгергәнлек аттестатына имтихан тота һәм Казан дәүләт университетының рус теле һәм әдәбияты факультетын читтән торып тәмамлый.

Аның беренче хикәяләре һәм очерклары («Дед Матвей», «Новенький», «Сюрприз», «Портрет», «Чужой медовый месяц») республика һәм җирле матбугатта басылып чыга. Ул кечкенә мәкаләләрдән соң документаль һәм матур әдәбият әсәрләре яза башлый. М.Зарипов—«Девятая высота», «Жнецы», «Чужой медовый месяц», «Летняя командировка», «Ордер на квартиру», «Звездный час Нижнекамска», “Вершины”, «Выгодный оборот», «Черное сокровище», «Поучительные ютешки», «Сок с росы небесной», «Год на пасеке», «Бремя престода» исемле китаплар авторы. Рус теленә ул Әмирхан Еникинең «Әйтелмәгән васыять» («Завещание», 1966), Гариф Ахуновның «Артышлы тау буенда» («За горой Артыш», 1973), Нурихан Фәттахның «Әтил суы ака торур» («Итель-река течет», 1978), Вакыйф Нуруллинның «Аккан су юлын табар» («С ношей гору не обходят», 1982) һәм башка татар язучыларының әсәрләрен тәрҗемә итә.

Марсель Зарипов әдәби иҗат белән шөгыльләнсә дә, журналистика өлкәсен дә читкә тибәрми. Ул чирек гасыр «Советская Россия» газетасының Татарстан буенча махсус корреспонденты булып эшли һәм анда республика тормышына багышланган, үткен икътисад һәм социаль мәсьәләләрне күтәргән күпләгән мәкаләләр бастыра.

Журналистика өлкәсендәге уңышлары өчен Марсель Зарипов Татарстан журналистларының Х.Ямашев исемендәге, Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премияләренә лаек була. Ул—Татарстанның һәм Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре.

1970 елдан Марсель Зарипов—СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы.

Танылган журналист, язучы Марсель Зариповның бу көннәрдә—олуг юбилее. Аны ихластан тәбрик итәбез, саулык-сәламәтлек, яна иҗат уңышлары телибез.

## Мансур Шаһимәрдәновка 60 яшь



Мансур Мәгъсүм улы Шаһимәрдәнов 1951 елның 27 октябрендә Балык Бистәсе районы Кече Әшнәк авылында туа. Бала чагы һәм үсмер еллары Олы Елга авылында үтә. Урта мәктәпне тәмамлагач Казанга килеп, кооператив техникумында һөнәри белем ала, тормыш юлын сәүдә өлкәсе белән бәйли, төрле төбәкләрдә, Казанның сәүдә оешмаларында сатучы, тәэминәтче һәм сәүдә белән бәйле башка эшләрдә эшли.

Күп каләм ияләренә хас булганча М. Шаһимәрдәнов та мәктәптә укыганда ук әдәбият белән якыннанрак кызыксынып каләм тибрәтә башлый, матбугатта беренче хикәяләре узган гасырның 70 елларында күренә.

1992 елда «Казан утлары» журналында авторның «Кеше күнеле—карурман» исемле повесте басыла, 1995 елда исә Татарстан китап нәшриятендә аерым китап булып дөнья күрә. М. Шаһимәрдәнов иҗатына заманның әхлакый проблемаларын кыю яктырту хас. Әлеге тема аның «Татлы агу» («Казан утлары», 1998 № 11-12) романында да киң яктыртыла. Ул сюжетны композиция ягыннан гади, әмма төгәл итеп кора белә, персонажларның сөйләме үзенчәлекле.

2004 елда сайланма хикәяләрен туплаган «Без әле шулай яшибез» дигән икенче китабы нәшер ителә.

М. Шаһимәрдәнов—1999 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

---

## Авторлар игътибарына

Редакциягә кульъязма җибәргәндә түбәндәге мәгълүматлар булу мәҗбүри:

1. Фамилиягез, исемегез, әтиегезнең исеме
2. Яшәү урыныгыз
3. Туган ел, ай, көнегез
4. Паспорт мәгълүматларыгыз
5. Дәүләт пенсия страховкасының страховка таныклыгы номеры
6. ИНН номеры
8. Вертикаль портрет рәвешендәге яхшы сыйфатлы фоторәсемегез
7. Телефоныгыз (шәһәр кодын да күрсәтеп)



***Фәнзил Галиев,***
*Мамадыш районы,*
*Шәдче авылы мәктәбе.*

# МӘХӘББӘТ ХАТИРӘСЕ

ХИКӘЯ

Бүген минем күңелдә уйлар әйләнде, буталды, тугланды. Чөнки мин бүген бер кызны очраттым. Сөйләргә микән, сөйләмәскә микән бу хисләрне Илһамга?! Юк, әгәр ул дөрес аңламаса? Әй, аңламастыр инде, әнә бит футбол карарга утырды. Ярар, соңыннан сөйләрмен. Юк, сөйлим дип бер башлагач, сөйлим инде. Әллә сөйләмимме? Футбол карарга утырган кеше мәхәббәт турында ни аңласын ди инде. Ярар, футболы беткәч сөйләрмен. Ә хәзер ятып торыйм әле. Аһ, йоклап та киткәнмен бит, әтием әйтмешли, черем итеп. Ярар, тартып-сузып күпме йөреп була, сөйлим дә ташлыйм хәзер! Әнә, футбол да беткән. Ярар, бер тирән итеп сулыш алам да... Аңламаса аңламас инде, ярамаган тагын, сөйлим инде.

—Һәй, Илһам, дустым, тыңла әле!—дидем мин аңа һәм сөйли дә башладым.—Бүгенге көн сихри көчкә бай иде. Мин бер чибәр кызны күрдем. Һәм... һәм...— Ярар, монысын әйткәч, кире чигенеп булмый инде, сөйләргә туры килер.—Аны күрүгә йөрәгем түрендә бер кыл чиртеп алды. Бу хәл мине телсез калдырды. Мин кузгалмыйча, тын да алмыйча аңа карап тордым. Чөнки ул минем күземә туп-туры карап, ниндидер сихри көч белән сихерләп куйды. Янымнан тиз-тиз генә атлап үтсә дә, бу мизгел миңа бер сәгатьлек кебек тоелды. Чөнки ул бик салмак кына атлап, чәчен төрле якка сибеп, миңа карап елмаеп, күз кысып китте. Һәм минем күңелемдә ул чибәр кыз нәкъ минем өчен генә туган, мине бу матур кояшлы көнне сихерләр өчен дигән хисләрдә яндым. Әй, дустым, әллә мин гашыйк булганмын инде дигән уй мине ничектер үзенә тарта. Әйе, мин гашыйк булганмын, дустым. Ләкин ул чибәр кызның исемен генә дә белмим шул мин. Һәй, Илһам, тыңлыйсыңдыр бит мине? Мәйтәм, миңа аның белән танышырга кирәк. Белмисеңдер бит ул чибәр кызны?

—Бәлки, беләмдер дә,—диде Илһам, миңа йокымсыраган йөзен борып.—Ә син аны сурәтләп күрсәт, күзе нинди төстә дә, чәче, йөзе нинди формада?

—Соң каян белим инде мин аның күзе нинди төстә икәнен? Күзенә карау белән электрга тоташкан кебек булдым бит. Чәче чем кара, йөзе түгәрәк, алма кебек кызарып пешкән, ә иреннәре... яңа пешкән чия төсендә.

—Һәй, синең һаман шул романтика булыр инде. Син аермачык, төп-төгәл итеп әйт. Милициягә күрсәтмә биргән кебек,—диде Илһам. Мин аның шаяртканын, минем алда кыланганын сизгән идем инде.

—Ярар, белмисеңдер,—дидем дә интернаттан чыгып киттем. Урамда җәйге айлы кич иде, йолдызлар да ничектер бик якты җемелди. Шундый төндә йолдызларга карап шул чибәр кыз белән бергә серләшеп утырасы килә бит минем. Ә Илһамга һаман шаяртырга гына булсын. Юк инде, бу кызны аңа бирмәм, болай да бу тирәдәге бөтен кыз аның учында бии... Тәк, Чулпанга шалтыратырга кирәк, ул белми калмас. Бу йөгерек күзле кызый мәктәпнең штаттан тыш директоры кебек бит безнең. Хәзер, сорыйбыз. «Алло, Чулпан, сәлам. Син яңа килгән берәр кыз күрмәдеңме, ну, белмисеңме? Килмәдеме яңа кыз, дим. Килде, дисеңме, ә кем исемле соң ул? Нәрсәгә дип, кирәк инде, кирәк. Ну, танышырга иде үзе белән. Әйт инде, исеме ничек? Ә, Гүзәл дисеңмени. Гүзәл! Гүзәлем минем! Ә, юк, мин болай гына, уйланып киткәнмен. Кара әле, Чулпан, син безне таныштыра алмыйсыңмы? Син булдырасың бит инде андый эшләрне. Кайчан? Иртәгә, ярар, килештек. Сәгать җидедә дисеңме, ярар. Паркта очрашырбыз. Ярар, сау бул.»

Уау, шәп булды әле бу! Мин иртәгә сәгать җидедә ул кыз белән танышачакмын! Гүзәл бик матур исем. Мин аның исемен белдем, ә ул минекен белмидер әле. Димәк, бергә—ноль, Илһам әйтмешли. Тәк, очрашуга барганда нинди кием киим микән? Кәчтүм-чалбардан барсам? Юк, кит инде, бу бит деловой очрашу түгел. Әнә, яңгыр да ява. Күлмәк-чалбар, димәк, зонтик та кирәк булырга мөмкин.

Һәй, яңгыр яуганда кем паркта очраша инде. Яңгыр яумасын дип кенә телисе кала. Ярар, аңа хәтле әле укырга барасы бар. Директор әле укудан соң да алып калыр. Класс тәрәзәсен ваткан өчен. Ну бу Илһам, җиллләтәм дип тәрәзәне ачып куйды да. Кызлар әйткәч, мин барып ябарга дип тотынган гына идем, тәрәзә аска төште дә китте бит, рамы черегән булгандыр инде. Ә Илһам, куркак малай, шул арада чыгып та сызган. ... Ух, укырга барырга да вакыт җиткән. Илһам инде мәктәпкә киткән. Уятмаган да бит. Беләм мин аны, кызлардан өй эшләре күчерергә чаба ул... Бүген укулар бик озак барган төсле тоелды. Хәзер кайтырга да, сәгатъ җиде тулганны көтәргә генә кала. Их, Гүзәлем, багалмам, тиздән очрашабыз, көт кенә, гүзәлем, көт кенә... Тик аңа нәрсә дип әйтергә икәнен уйлап бетермәдем бит әле. Каушап калмасам ярый инде. Каушамам, каушый торган егетләрдән түгелмен.

...Ярар, кузгалыйм. Егетләр алданрак та барырга тиеш бит әле. Юлда чәчәк тә аласы булыр.

Килеп җиттем, хәзер мәнә тынычлап көтсәм дә буладыр. Тик кайда соң ул тынычлык? Элек кайда икәнен дә белмәгән йөрәк «дөп» тә «дөп» күкрәккә тибә...

Әнә ул, әнә минем чибәр кызым, Гүзәлем! Миңа таба атлый. Мәнә ул минем янга килеп тә җитте һәм... үтеп тә китте! Ул мине танымады, ахрысы. Мәнә ул эскәмиягә килеп утырды. Янына барып утырсам, ни булыр икән? Ярар, утырдым. Ах, ул бик чибәр. Бу Гүзәл хәтта теге көнне очраткан Гүзәлдән дә гүзәлрәк... Хәзер нәрсә дип танышырга инде? Ай, кулындагы мороженые җиргә төшеп китте. Мин аны иелеп алдым да, пөхтәләп сөрттем дә, чүп савытына ыргыттым. Ә Гүзәл миңа сәер генә карап куйды да, акрын гына «Рәхмәт» диде. Их, ничек танышып китәргә инде? «Бүген хәтта парк та бик матур күренә» дип сокланганны кычкырып әйткәнмен бит: Гүзәл «Әйе» дип әйтеп куйды. Тагын нәрсә диярга микән? Уйлап-уйлап утырдым да, юри генә моңлы итеп сузып җырлап җибәрдем. Җырлап бетергәч, Гүзәл миңа карап «Бик матур җырлыйсың икән. Бу минем иң яраткан җырым»—диде. Мин, танышырга мөмкинлек туды дип уйлап, «Ә синең исемең ничек» дип сорап куйдым. Ул «Гүзәл» диде. Аннары, бераз торгач, «Нигә?» дип сорады.

—Юк, болай гына. Ә минем исемем Дәүләт була. Көлмә, зинһар, миңа бу исемне бабам кушкан. Әле русча әйтсәң, бигрәк кызык: Давлат була, дидем. Гүзәл рәхәтләнеп көлеп куйды да:

—Юк, мин синең исемеңнән көлмәдем, шаяртуыңнан көлдем,—диде.

Мин шулчак тәмам кыздым.

—Мин исемеңнең Гүзәл икәнен белә идем инде,—дидем.—Чөнки мин беренче күрүдә үк сиңа гашыйк булдым.—Гүзәлгә берни дә әйттермичә мин һаман сүз арты сүз өстәп тордым:—«Хәтерлисеңме? Мин ашханә янында басып тора идем. Һәм шунда сине очраттым. Бик озак сокланып карап тордым мин сиңа. Чөнки син шундый чибәрсең. Ә син ничектер мине күрмичә,тиз-тиз атлап ашханәгә кереп киттең. Гүзәл, мин сине яратам, һәм бу чәчкәләр дә сиңа иде, гүзәлем!

Гүзәл бераз кызарды да:

—Мин дә сине шунда ук ошаттым бит,—диде. Мин онытылып китеп сүзсез калдым. Менә, ичмасам, мәхәббәт! Ул бер мизгелдә безне кавыштырган, бер җепкә бәйләп куйган!

—Кызык,мин синең белән танышa алмыйча газапланып беттем. Төшеп киткән мороженыеңны да каушап чүп савытына аттым.

—Мин дә аны оялудан төшереп җибәрдем бит...

Гүзәл белән без ярты ел очрашып йөрдек. Тик Гүзәл бер көнне миңа елап килеп керде. Һәм үзләренең күчеп китәчәкләрен әйтте.

—Ник, Гүзәл,ник? Безгә аерылырга туры киләчәкмени?—дидем мин сыкрап. Аннары: Мин дә синең белән күченеп китәм!—дип кырт кистем.

Гүзәл тагын да ныграк елый башлады һәм:

—Америкагамы?—дип куйды.

Мине бу сүз шок хәлендә калдырды.

Ул вакыттан соң күп көннәр, айлар үтте. Бу вакыт арасында бер генә тапкыр да очрашмадык. Ичмасам, телефоннан да сөйләшә алмадык, номеры үзгәргәндер инде. Мин бик сагынсам да түздем. Ә менә минем гүзәлем ничекләр итеп түзгәндер?

Әйе,бу мәхәббәт дигәнең бер мизгелдә кавыштыра да, аера да икән ул.

Мин бу хәлләрне беркемгә дә сөйләмәдем.Һәм сөйләмәм дә, ахрысы.

---

*Саимә Ибраһимова*

## «АГЫМ УҢАЕНА ЙӨЗ!»

Биш-алты яшьләрдә булганмындыр,күрше-күлән яисә берәр читрәк кеше керсә, өйдәгеләр, безнең Саимә укый белә, гәзит укый дип мине алга төртеп чыгаралар иде. Кулыма берәр гәзит кисәге тоттыралар да, мин хәреф тануымны исбатларга тиеш булам. Укырга мин барыбер сигез яшемдә генә кердем. хәреф таныгач,нигә шундук мәктәпкә илтмәгәннәрдер?

Теләнче Тамак мәктәбендә икенче сыйныфны бетергәч, Рәхимә апам мине Чистай шәһәре аркылы Алексеевск районының Ромодан дигән авылындагы «Большевик» совхозына, Зөләйха апамнарга илтеп куйды. Ромодан авылында урыс мәктәбе генә. Саимәнең өченче сыйныфка керәсе бар дип кенә татар мәктәбе ачсыннармыни!?

Бер авыз сүз урысча белмим. Бик тырышам инде. Ботаника, тарих дигән фәннәр керә. Нихәтле текст сөйли белергә кирәк. Ятлыйм!

Адәм рәтендә күчтем инде дүртенчегә.

Каникулга чыккач, әнкәйләрне күрәсе килә башлады бит! Алар Мөслим районында. Зөләйха апа илтә алмый,яшь баласы бар.

—Берүзең кайтасыңмы соң?—диделәр миңа.

—Кайтам!—дидем мин уйлап та тормыйча,әйтерсең лә Мөслим мин Ромоданнан керосинга барып йөри торган өч чакрымдагы «ферма» дигән җир!

Мине Чистай пристаненә хәтле ияртеп җибәрердәй кеше табылды. Йөк машинасына утырып китүем хәтердә. Пароходка дигән билетны кулыма тоттырды да озатучы абзый,Чаллыга хәтле кайтучыларны сораштырып,мине шулар янына утыртты.

—Баланы Чаллыда алып төшәрсез инде, аннары ул Мөслимгә китә,—дип, китеп барды.

Кай вакыт икәнен хәтерләмим инде,пароход шактый юл алгач,минем йокы килә башлады. Дүртенче класста булгандыр инде безнең урын. Эскәмиягә утырып,башымны бер капчыкка терәдем дә:

—Мине уятырсыз инде,—дидем дә,йоклап та киттем.

Уяттылар. Ул чакта автобус дигән нәрсәнең исеме дә юк иде. Анда-монда китүче машиналар туктый торган җиргә бардык. Минем юлдашлар минем якка түгел. Аларның да мине тизрәк утыртып җибәрәселәре килә. Юк кына бит Мөслим ягына машина!

—Балакай,бер дә булмаса,син Минзәләгә юл тот,аннан Мөслимгә китәргә уңайрак булыр,—диделәр болар.

Чыннан да,озакламый Минзәләгә баручы машина килеп чыкты. И сөенүләрем! Ничәмә-ничә авыллар үтеп,барып җиттек Минзәләгә. Әле бит аның белән генә эш бетми,ары китәргә кирәк.

Тагын машина үтә торган юл өстендә таптанып тору. Ярый әле җәйге көн озын,тиз генә кич булып,караңгы төшәргә ашыкмый. Шулай да барасы юл ерак бит әле—кайчан Мөслимгә барып җитәсең дә,кайчан Вәрәш Башы дигәненә. Әлегә ярый,шул якка юл тотучыларга ияреп йөрим.

Ниһаять. «Мөслимгә!» дип бер йөк машинасы килеп туктады. Ике апа,бер абзый кеше һәм дә мин әрҗәгә менеп урнаштык. Анда ниндидер алам-салам, капчыкише нәрсәләр бар иде,җайлап утырыштык. Утырып та,яткан сыман да кайтылды,йокыга кителгәндәй дә булган шунда. Сәгать чутын белмим инде,бер заман «Җиттек!» диделәр.

—Менә,кызым,шушыннан алга таба,Ык күперенә барып җитәсең дә,күперне чыккач,Иске авыл дигән авыл булыр,шуннан Вәрәш Башына таба китәсең,—шулай диделәр юлдашларым.

Кешеләр йөреп тора. Бер түтәйдән күпергә ара еракмы, дип сорадым. Бер чакрымлап булыр,диде. Бу миңа ерак сыман тоелды да,тагын берәүдән Ык буена төшә торган юлны сорадым. Ыкны йөзеп кенә чыкмакчы булам. Йөзә беләм. Зур да бит инде,дүртенчегә күчтем. Тизрәк әнкәйләрне күрәсе килә инде. Яр буена төшеп чишендем. Кулымда юлга дигән азык төенчеге дә булгандыр инде. Күлмәк белән бергә йомарлап тоттым да кереп киттем суга. Ык елгасы күргән-ниткән нәрсәм түгел,тирәнме-суыкмы—белгән юк. Башта сай булды,ерак кына бардым су эченнән атлап. Менә бер мәлне тирәнәя башлады: билдән булды,күкрәктән,талпынып китеп йөзә башладым. И йөзәм,и тырышам, чыгып җитеп кенә булмый бит теге якка. Агым көчле,хәлем бетә башлады... Бер заман яр башыннан:

—Агым уңаена йөз,каршы йөзмә!—дип кычкырдылар.Шуны ишетүгә агым җаена йөзә башладым да,Аллаһның рәхмәте белән озакламый ярга чыгып җиттем.

Ул чакта мин бу нәрсәне уйлый белмәгәнмен: кычкырдымы-кычкырды берәү яр башыннан. Ә хәзер менә ничек дип уйлыйм: кем минем суга батып барганымны аргы ярдан карап торсын да кайгыртып кычкырсын ди? Берәү дә карап тормаган мине анда,Хозыр Ильяс булган ул!

Яр буена чыктым. Каршыда—куаклык,әрәмәлек,сазлык. Ансат кына Иске авылга кереп китә торган түгел. Барыбер шул күпер аркылы чыккан юлдан барырга кирәк. Авылга җиткәнче шактый вакыт үтте. Кайбер капка төбендә йомарланып яткан этләрне күреп шомлана калдым. Ырлап каршыңа чыга башласалар... Озын гына бер урамлы бу авылны чыгып киттем дигәндә генә бер апа очрады да,аннан:

—Вәрәш Башына еракмы?—дип сорадым.

— Ерак шул әле, алты чакрым диләр инде аны,—диде апа.

Юл тау буе сыман җирдән бара икән. Бик матур. Тар гына юл. Моннан машина йөрми торгандыр. Сул кулда, түбәнлек җирдә, куаклар үсеп утыра. Чут-чут итеп кошлар сайрый. Тирә-як тып-тын. Атлыйм да атлыйм. Артта да, алда да кеше заты күренми. Озакламый әнкәйне,абыем Габдулла белән сеңлем Сафияне күрү сөенеченнән кош кебек очам. Арыганым да әлләни сизелми.

Менә килеп җиттем инде Вәрәш Башына. Авыл башында буа кебек нәрсә бар икән. Анда казлар каңгылдаша. Салам өемнәре кебек нәрсәләр күренә. Нинди кеше килеп чыгар да,этләр очрамагае дип курка-курка гына барам. Ул да булмады,каяндыр бер малай килеп чыкты да,артымнан бара башлады.

— Әй,кызый,кая барасың?—дип кычкырды бу миңа. Аны-моны җавап бирмичә генә атлавымда булдым. Килеп кыйнап ташламагае дип тә куркам үзем.

Авыл хәтле авылын «кулга төшергәч»,өен генә табасың инде аның. Очраган бер кешедән сорый-сорый таптым инде әнкәйләр яшәгән йортны.

Капкадан кердем. Чиста гына,яшел үләнле ишегалды. Тавык-чебеш булганын хәтерләмим инде. Кайсысы килеп чыгар дип йөрәгем дөп-дөп итә. Иплән кенә ишеккә киләм. Килсәм,ишектә йозак! Менә сиңа мә! Инде нишләргә? Тәрәзәдән карыйсы иттем. Анда бит әдәми зат бар! Абый өйдә икән бит.

—Абый!—дип эндәштем.—Нишләп өстеңнән бикләделәр? Әнкәй кайда?

Абый ятып кына торам дип яткан да йокыга киткән. Әнкәйнең барасы җире булган да бикләп чыккан.

Ул арада әнкәй дә кайтып керде. Күрештек, сөенештек. Ничек кайттың да ничек кайттың дип сораштыра башладылар. Озакламый Ибраһимоваларның кыз балалары берүзе кайткан диган хәбәр бөтен авылга таралып,мине күрергә килә башладылар.

---



*Алмаз Мансуров*

## Сине сайладым

Барлык кызлар арасыннан,
Мин бит сине сайладым.
Гашыйк булдым... Аннан инде
Үземнеке санадым.

Тик дусларым һаман канга
Гел тоз салып торалар.
Имеш, кызларга ышанма—
Сүзне шуңа боралар.

Һәм мин шулчак сине яклыйм,
—Гөлкәем андый түгел,
Яратыр ул, әйтмәсә дә
Бу хакта әле бүген.

Аннан ялгыз чыгып китеп,
Кичке урамны урыйм.
Йолдызларга карап торам,
Шул чакта сине уйлыйм.

Мин яратам сине! Әйе...
Күңлем сине сагына!
Тагын нәрсә эшлим икән
Шул мәхәббәт хакына?

## Син төш булдың, ахры...

Кан тамыры буйлап очкын булып,
Чәчрәп аккан сөю хисеннән
Баш әйләнә...
Татлы агу тәме...
Шул сөюдән кабат исерәм.

Хәтереңдәме, синең күзләреңә
Шашып, онытылып карадым.
Күңелемнең кайнар хисе белән
Керфекләрең назлап тарадым.

Син төш булдың, ахры... Ул назларым
Югалдылар хыял таңында.
Мин уяндым бүген. Тынычландым.
Йә, елама, мине сагынма!

Син иреклe шәхес. Дөнья иркен,
Юллар төрле, төрле киләчәк.
Кисешсәләр юллар, очрашырбыз,
Тәкъдир кушса, булса күрәчәк.

Ә хәзергә аек акыл белән
Йөрәгемне бер кат урадым.
Син төш булдың...
Ул бәхетле булыр
Дип төшемне шуңа юрадым.

Мин уяндым. Сүнмәсә дә хисләр,
Ычкындырды инде богаулар.
Җуләрлек тә китте, булмас хәзер
Сөясеңме диеп сораулар.

***

Йөрәк никтер артык тыныч бүген,
Мин дә тыныч, хәтта хыял да...
Тормышыбыз вак мизгелләр безнең,
Мизгелләрне бергә җыям да,
Синең белән бәйләләрен сайлап,
Тезеп куям күңел түренә...
Кемнәргәдер бу ошамый, ахры,
Күңелемә җилләр үрелә.

Салкын минем бүген җаным, тәнем,
Хыялларым, салкын йөрәгем...
Җилгә генә кирәк минем хисләр,
Серләремне аңа сөйләрмен.
Йөрәк никтер артык тыныч бүген,
Салкынлыктан ул да оеган.
Кояш кайда? Бер җылы нур кирәк!
Кояш инде күптән баеган.

Бер карасаң, сүзләрем дә көлке,
Хисләрем дә көлке барысы.
Хәтта көлке, мескен булып кала
Йөрәктәге сөю ярасы.

Тик шулай да, яшим әле... Яшим!
Ничек йөрәк барсын онытсын?
Салкын тәнем, җаным, хыялларым,
Йөрәгемне кемнәр җылытсын?

*Алисә Зарипова*

# ИКЕ КАНӘФЕР

*Барысы да яхшы булыр дип яшәүче Сөмбелгә багышлыйм.*

Гадиләне тәүге күрүдә үк яраттым мин. Аның күзе дөньяга балаларча самимилек, бераз хыялый хәйләкәрлек белән карый иде. Иң мөһиме, ул һичкайчан вакыйгалар агышына кул селтәп, «әйдә, ярар»га гына яшәми. Менә шул чая, шук кызны тормыш мәхәббәт белән сынаган, әмма сындыра алмаган.

Бу мәхәббәт тарихын автобус туктальшыннан башлап китик әле. Гадилә, университетының тарих факультеты студенты, иптәш кызының туена кайтырга автобус көтә. Кемнәр генә үз гомерендә ниләр генә көтмәгән, бераүләр көтә-көтә картайган, кемнәрдер көтүнең мәгънәсезлегенә төшенеп, барысына төкереп яши биргән. Ә безнең автобус килгән һәм матур туташ аңа җайлап кына утырып юлын дәвам иткән. Хәзер сөйләнәчәк хикәяне Гадиләнең үзенә тапшырам. Сердәшеңә күңел яраңны ачсаң хәлең җиңеләеп китә дип әйтәләр, тыңлаучыга исә гыйбрәт, сабак та булыр дип өметләнәм.

«Тормыш мине кешеләр белән аралашудан шатлык табарга өйрәтте. Шуңа күрә кая гына бармыйм, әйләнә-тирәмдә гел аралашырга яратучы, минем белән сөйләшергә теләүчеләр табылып тора иде. Автобуска килеп кергәч тә, янәшәмдәге егетнең минем белән танышып сөйләшергә теләве гадәти тоелды. Җай гына сөйләшеп кайттык. Иптәш кызымның авылында төшеп калганда егет «Мин сине барыбер табам!,—диде. Мондый сүзләрне беренче кат кына ишетмәгәнгә, мин дә, «тап соң», дидем дә, юлымны дәвам иттем. Иптәш кызымның шат йөзен күрүгә Казаннан кем белән ничек кайтуым оныттылды. Яшьлек бит ул җилбәзәк холыклы, ни эшләсә дә яхшы, ни булса шуңа риза, яраларын мәче төсле бер ялый да төзәтә. Туйлар шаулап-гөрләп узды, ә икенче көнне иртән мине капка төбендә бергә кайткан егет көтеп тора иде.

Мин күләргә дә, еларга да белми алдына чыгып бастым, чөнки калада минем биш ел бергә йөргән егетем бар, ә бу ялгышлык белән минем яныма утырып кайткан егет «свиданҗега» чакырып маташа. Холкым туры булганга, егетем барлыгын, аның белән дусларча гына сөйләшүемне аңлатырга тырыштым. Ә егетнең үз туксаны-туксан. Әйдә, барыбер Казанга кайтасыңдыр, дустың буларак, алып барып куям, диде. Бу юлы ул үзенең кем булуы, гаиләсе, тормышы турында сөйләп барды.

Фәрит әти-әнисенең өченче, төпчек уллары икән, гуманитар педагогик университетның физика-математика факультетын тәмамлап, хәзерге вакытта үз авылларында укытучы булып эшләүче егет. Җәйләрен абыйлары белән балта осталары булып та йөри икән. Һәм иң соңыннан минем дингә мөнәсәбәтемне сорады. Мин нәрсә дип әйткәнемне төгәл хәтерләмим, чөнки минем өчен, кеше күңеленнән ышанса, аны тыштан кычкырып йөрергә, бигрәк тә икенче көнен генә таныш кеше белән бу турыда сөйләшеп барырга кирәктер дип санамый идем һәм хәзер дә шул фикердәмен. Фәрит елмаеп кына куйды да, башкача дәшмәде. Шушы очрашудан соң ул мине гел универстеттан каршы ала, илтеп куя торган булды. Эшләрең бардыр бит, көн дә килеп йөрисең, диюемә, «Синең өчен мин барысына да әзер»,—дип җаваплый иде. Нинди кызның күңеленә мондый озатып йөрүләр ошамас икән? Күбебез әгәр егет ярата икән, көнли, синең һәр адымыңны белеп торырга тырыша, дусларың белән кызыксына дип уйлыйбыз. Бу, бәлки, дөрестер дә, әмма иң мөһиме, егет сине хөрмәт итәргә, сиңа ышанырга тиеш икәнен онытабыз, дөресрәге,

җиде кат күкләрдә йөзгәндә моңа игътибар бирмибез. Шулай итеп, мин биш ел яратып йөргән егетемне ташлап, яңа гыйшыкка бөтен барлыгым белән чумдым, эредем, юкка чыктым...

—Мин сине яратам, Гадилә.

—Мин дә сине яратам, Фәрит. Бәлки, кинога барырбыз?

—Син телисең икән, барыйк соң. Әмма минем анда бер тапкыр да барганым юк.

—Кит инде, биш ел буе студент тормышыңны укып кына уздырдыңмы?

—Әйе.

—Арткы рәттә кызлар да кочаклап утырмадыңмы?

—Син ни сөйлисең, Гадилә!..

—Үзең мине яратам дисең, бер генә чәчәк тә бүләк иткәнең юк.

Икенче килгәндә Фәритнең кулында чәчәкләр иде.

—Болар сиңа, Гадилә.

—Фәрит, нигә син ике канәфер алып килдең?..—соравым җавапсыз калды.

—Әллә бер дә чәчәк бүләк иткәнең юк инде?..—бу соравыма да җавап булмады.

Әлеге хәлләрне кайта-кайта уйлыйм хәзер миң, чыннан да, мәхәббәттән сукырайган булганмын икән дим. Йөри башлаганга ике ай булды дигәндә мин яулык яптым. Фәрит белән танышканчы әбием кечкенә вакытта өйрәткән догаларны да онытып бетергән идем, биш вакыт намаз укый башладым. Кешене яратасың икән, аңа җаның-тәнең белән ошарга, ярарга тырышасың. Әмма ярарга тырышу белән үз-үзеңне җуюны бутарга ярамый икән. Юк, яулык ябуны тәнкыйтьләп әйтүем түгел. Кеше Аллага әкренләп, җентеклəп әзерләнгәннән соң гына килә. Ә мин, гипнозланган төсле, Фәрит ни кушса, шуны эшләп, уйламыйча шундый зур адымга бардым.

—Әйдә, өйләнешик, Гадилә!

—Без бит әле ике ай гына таныш...

—Элек озак йөрешмәгәннәр.

—Бәлки, никахлашып кына куярбыз?..

—Өйләнешик. Миннән качарсың күк тоела.

—Кая качыйм ди мин?..

—Син ризамы?

—Риза...

Танышуыбызга өч ай дигәндә, без өйләнештек. Әнием: «Ашыгасың, кызым, ялгышасың бит»,—дип торуга карамастан, мин бәхетле идем. «Үзе егылган елмас»,—дип, аны тынычландырдым, чөнки егылмам төсле иде.

Музейда бер экскурсия вакытында: «Менә шушы Сарытау авылында туган инде бу олпат шәхес»,—дигән сүзләрне ишеткәч, их, бер генә барып күрәсе иде шул авылны, дип уйлап куйган идем. Менә шул авылга килен булып төшеп киләм. Телефоным шылтырый, анда Гадел (биш ел йөргән егетем): «Гадилә, алтыным, ялгышасың бит, чыкма аңа кияүгә, кайт миңа кире»—ди. Шушы мизгелдә, аның сүзләренә җавап булып, башымнан «Нишлисең син, Гадилә? Синең язмышың түгел бу!»,—дигән фикер уза. Ләкин акылның соңгы омтылышы да җавапсыз кала, мин телефонны өзеп куям да, бәхетле киләчәгемә карап елмаям.

Мин килен булып төшәсе йортның капкасы кыйшайган, буяулары кубып беткән иде. Мин моңа сөю тулы күз белән карап, бергә яңа тимер капка куярбыз, дип уйладым. Ул вакытта, ничек инде өч балта тотарлык уллары бар йортта шундый капка була ала, дигән уй килеп тә карамады башыма.

Туйда минем дусларым утырмады. Иремнең сүзенә каршы килә алмадым, Коръән кушмый, имеш (ай-вай, алай микән, дим хәзер), ике яктан да туганнар гына килеп, кечкенә генә мәҗлес уздырып алдык. Мин барыбер бәхетле идем. Миңа Аннан башка беркем кирәкми иде. Мөгаен, гашыйк булганнар мине аңлар.

Туйдан соң мин баш-аягым белән гаилә тормышына чумдым, һәм үзем кияүгә чыккан кешене чынлап торып күрә башладым, һәм мин үзем ачкан

дөньяга көннән-көн шакката идем.

Ул, беркайда да эшләмичә, әти-әнисе белән төп йортта яшәп ята икән бит. Әнисен Алланың җирдәге «урынбасар»ы дип уйлый. Аны эшләтергә тырышуларым «урынбасарның».

—Нигә син минем улыма кычкырасың?—дигән сүзләре белән тәмамлана иде.

Кибеттән бернәрсә алырга ярамый. Барысын да өйдә пешерәбез. Көн саен ипи,камыр ризыгы һәм башкалар,һәм башкалар...

Ул саран икән бит! Моңарчы ике канәферне наданлык кына дип уйлап йөргәнмен, алар бит—иң арзанлы чәчәкләр! Кинога барып та акчасын туздырмаган ул. Авылдагы кызлар, аның гаиләсен, үзен белгәнгә күрә, аның тарафына күтәрелеп тә карамаганнар... Ә мин җүләр...

Эшенә дә түзәрсең, тик җаныңа тимәсеннәр, сүз белән рәнҗетмәсеннәр икән сине. Көннәр буе җыештырасың,ашарларына әзерлисең,ә Ул әнисе белән көнбагыш чиртә-чиртә сериаллар карый. (Бусын да Коръән кушкан микәнни?) «Урынбасар» аны яшәргә өйрәтә,мине бик иркәләмәскә ди. Талашкан очракта, гел ул җиңеп чыга...

Сабый туды... Мәхәббәтем җимеше. Дилә исемле нәни,йомшак кызым! Мин аның өчен дөньяларны үзгәртерлек көч тойдым үземдә.

Ә ирем сабый җанлы ата түгел! Кызына бер көлмәк,бер уенчык алыр өчен күпме ялынырга, ялварырга кирәк иде аңа! Монысы гына аз икән. «Урынбасар» аңа кызың үзеңнән түгел,дигән,һәм ул моңа ышана. Чынлыкта, кызымның йөзләре, бармакларында аның чалымнары ярылып ята... Мин рәнҗеп елыйм... Сабыемны күтәреп әниләргә кайтып китәм дә, бала хакы дип кире киләм...

—Атасы,әйдә,кредит алып үзебезгә йорт сала башлыйкмы әллә?

—Кредит алу хәрам,ярамый.

—Кызыбызга йогурт кына алып кайтчы кибеттән.

—Өйдә сыер нигә?

—Кибетнеке матур савытта,тәмле дә,кызыбызның күңеле булыр иде...

—Карармын.

Кичкә кечкенә савытлы бер(!) йогурт кайта...

—Әни сине пенсиясен сорый дип әйтә. Алай эшләмә икенче.

—Син көне буе өйдә,сорамаганны беләсең бит.

—Юк,син сорагансың,әни әйтә.

—Син бит барысын да күреп-ишетеп торасың...

—Син үз әниеңә ышанасыңмы?

—Әйе.

—Мин дә ышанам.

—Нахак бит...

Мин илереп елыйм... Минем тормышым мондый булырга тиеш түгел иде, бу мин түгел, мин аягүрә йоклыйм дип үз-үземне битәрлим. Түземлек бир, бер Ходам,дип ялварам. Биредә кызым да ничектер йомылып,тып-тын гына яши. Багалмама әле бер яшь тулып кына килә...

Шулай яши торгач,язгы бер җилле көнне кайнанам мине куып чыгарды... Баламны күтәреп чыгып киттем... Гомерем булса,кире кайтмам,бәхетемне бу йортта калдырма,дип,Ходаема ялварып,барысын кичереп,барысын калдырып, бар ишекләремне ябып... Киттем...

Хәзер кызым балалар бакчасына йөри,рәхәтләнеп бии,җырлый,сөйләшә... Минем бар максатым аны бәхетле итү. Аның йөзендәге елмаюны гына күрү дә мине җир йөзендәге иң бәхетле кеше итә.»

Гадиләне мин авылга кайткан саен күрәм. Дилә дә матур кыз булып үсеп килә. Алар икесе дә тормышның ямен табып, матур итеп, сөенепләр яши. Йөзләреннән елмаю китми...

*Кайтаваз*

## «САУБУЛЛАШТЫК ТА, БӘХИЛЛӘШТЕК ТӘ...»

9нчы санда Дания Гарәфиева-Шәрипованың «Жеффи һәм Йомшакбикә» дигән язмасын укыгач, мина бик тә монсу булып китте. Күренекле галимебез, тарих фәннәре докторы, профессор Жәмил Гыйльманов искә төште (мине анын энесе дип уйлаучылар бар, ләкин без фамилиядәшләр генә). Бер тапкыр Жәмил ага мина үз башыннан кичкән бер хәлне сөйләде. Сөйләгәндә елады ул. Минем дә күзгә яшь килде. Моннан соң шактый вакыт үтте, егерме ел элек Жәмил ага үзе дә дөнья куйды, истә калганны гына яза алам инде. Дания сенелгә рәхмәт, язарга форсат чыкты, юкса анысы да бөтенләйгә жуелачак иде бит.

Жәмил Гыйльманов 1945 елгы Япония белән сугышны рота командиры булып төгәлли. Кайтып китәр алдыннан сугышны бергә кичкән аты янына килә (атның исеме онытылган). «Мин китәм бит, аерылабыз инде»,—ди ул. Ат, тавыштагы моннан һәм хужасының хәл-халәтеннәндер инде, барын да аңлап ала һәм бик тә монсу иттереп кешнәп куя. Жәмил абый озаклап анын ял кылларын аралый, башын, муенын, гәүдәсен сыйпый. 15 минутлап бара бу саубуллашу. Ахырдан офицер, «Сау бул! Бәхил бул!»—ди. Чөнки исән хәлдә бүтән очрашмаячаклар бит инде... Ат шунда анын жилкәсенә башын сала да, эре-эре яшь тамчылары агызып елый башлый. Жәмил абый да күз-яшь түгеп елый... Жәмил абый китеп баргач, ат бик тә монлы тавыш белән, үксегәндәй итеп кешнәп жибәрә...

Авторның «бу эт белән бу мәче кебек яши алсын иде әле күпләр» дигән сүзе дә уйландыра. Чыннан да, башка жан ияләренә бик тә түбәнсетеп, кимсетеп карыйбыз түгелме? Хис, саф кичерешләр жәһәтеннән алар бездән калышалар микән сон? Ә адәм балаларына хас акыл табигатькә дә, аларның үзләренә дә каза арты каза китереп тора бит. Шул ук Японияда Хиросима һәм Нагасаки шәһәрләрен кешеләре белән бергә кайнар көл-тузанга әйләндергән атом бомбаларын гына искә төшерик әнә...

**Әмир ГЫЙЛЬМАНОВ,**
*социология фәннәре докторы.*

---

*Халык әйтсә, хак әйтә*

### Ялкау булма!

*Ялкаулык—байлыкның кызы, ярлылыкның анасы.*
*Ялкауның башында план күп була.*
*Ялкау утырып йоклый, ятып эшли.*
*Ялкау эшне бик эшләр иде дә, вакыты юк.*
*Ялкау егет яр тапмас.*

# СКАНВОРД

мәчет корылмасы

мамык чистарту тарагы

күңел тешенкелеге



европеоид б/н негроид кушылганда туа

кыса

Г. Тукайның әкиятпоэмасы

түшкә

шөбһә

Тукай псевдонимы

хат (иск.)

һөҗүм

өйләнгән егет

Г. Тукай әнисе исеме

З. Яруллин әсәре

депутат Кабаева

басым берәмлеге

өченче нота

кашне

нота

революционер ... Якуб

аттагы пар колга

«арзан» яшелчә

запас акча (валюта)

төс

Польша әфәндесе

титул

Мадридның футбол клубы

Тукайны тәрбияләгән карчык

бик тозлы су

6 нчы нота

рус язучысы Андроников

хәрби чин

мәдхия

явымтөшем

Г. Тукай әтисе исеме

Су анасында

малай-...

ат чәче

**Зөфәр ХИСАМОВ** *төзеде.*
*Буа.*

## Орбиталь станциядәге «куян»

Советлар Союзы заманында «Знание» җәмгыятенен идарәсе космонавтика казанышларына багышланган семинарларны ел саен диярлек уздыра иде. Анда космосны өйрәнүче галимнәр һәм космонавтлар белән очрашулар да һәрчак булып торды. Космосны гизеп кайткан бөркетләрне тынлаганда аларның барысы да диярлек җор холыклы, сүзгә тапкыр һәм бик шаян егетләр икәнлеге сизелеп тора иде. Соңыннан алардан берсе, космоста 96 тәүлек булган Георгий Гречко белән халыкара конференциядә якыннан танышу һәм берничә кат иркенләп гәпләшү дә насыйп булды.

Олпат галим һәм космонавт, шактый олы яшьтә булуына карамастан, шундый ук шаян һәм юморны ярата торган кече күнелле шәхес икән. Берчак аңа хәрби комиссариаттан повестка килә, анда барлык орденнар һәм медальләрен тагып төшкән фотосын да алып килергә кушылган була. Гречконы беркайчан да андый регалияләрне нинди тәртиптә тагарга тиешлеге кызыксындырмаган икән. Танышлары вестибюльгә чыгарга да анда Л.И.Брежневның бөтен костюмын биләп торган орден-медальле рәсемен карарга киңәш биргәннәр. Георгий Михайлович шулай эшләгән эшләвен, әмма аның генсекныкы шикелле бай коллекциясе булмаган. Шуңа күрә, бүләкләрнен барысы да диярлек сул якта туплану сәбәпле, портретта симметрия дигәнең бөтенләй юкка чыккан. Костюмының сул ягы асылыныбрак торган фоторәсемне күрсәткәндә үзе дә рәхәтләнеп көлгән иде.

Космик очыш вакытында да мәзәк хәлләр булгалый икән. Кайчагында, орбитадагы эш вакытында, киеренкелекне бетерү өчендер, бәлки, космонавтлар үзләре дә шаярырга һәм Җирдән торып аларга ярдәм итүче танышларын да шаяртырга яраталар икән. Иң җиллесе 1973 елда «Скайлэб» орбиталь станциясе экипажында Оуэн Гарриотның шаяртуы булгандыр, мөгаен. Ул космоска диктофон алып менә. Тасмага аның хәләл җефете әйткән, алдан әзерләп куелган фразалар язылган була. Көннәрнең берендә, Очышларны идарә итү үзәгендә дусты Роберт Криппен кизү чакта, орбиталь станция белән Үзәк арасында бик кызыклы әңгәмә була.

—«Скайлэб», бу—Хьюстон, җавап бирегез.

—Исәнмесез, Хьюстон,- дип, хатын-кыз тавышы белән җавап бирә станция—бу—«Скайлэб».

Каушап калган «Җир»дән сорау килә:

—Кем сөйләшә сон?

—Сәлам, Боб,—дип җавап бирә станция,—мин Хелен булам, Оуэнның хатыны.

—Нишлисең син анда?—дип, телен көчкә генә әйләндереп сорый аптыраган Роберт.

—Менә егетләргә ашарга алып мендем, әле яна гына пешердем, бик тәмле!—дип «тынычландыра» аны орбитадан килгән тавыш.

Идарә үзәге бер минут чамасы тавыш-тын чыгармый, аннан элемтәне бөтенләй өзеп тә куя. «Җир»нен нервылары чыдамагандыр, мөгаен.

**Ким ШАКИРОВ**

---

*«Ак җилкән»гә хат язу өчен адрес:*
*420066, Казан, Декабристлар ур., 2, «Казан утлары», «Ак җилкән».*
*Электрон адрес E-mail: kazanutlari@yandex.ru*

Фәнис
Яруллин

# ХӘТЕР ТӨПЛӘРЕНДӘ УТЛЫ КҮМЕР

КӨНДӘЛЕКЛӘР

## 1985

**1 гыйнвар.** Яңа елның яңа көне. Беренче көне. Быел Яңа елны каршылау кызык кына булды. Телевизорны төзәтеп житкермәделәр тәки. 31е көнне уйламаган жирдән бөтенләй ят кешеләр килеп керде. Моннан 20 еллар элек минем янга килеп йөргән Люция исемле кызның апасы белән жизнәсе. Роза һәм Фәрит Яруллиннар. Кызык кына: исеме дә, фамилиясе дә туры килүен әйт әле. Минем дә Фәрит Яруллин дигән абый бар иде. Аларның бер шампанскийлары бар иде, дүртебезгә аны эчтек. Алар Яңа ел каршылаганчы утырмадылар. Аннары Рәшит Әхмәтҗанов безне чакырырга керде. Карарга телевизор булмагач, без рәхәтләнеп риза булдык.

Без кергәндә Рәшитләрдә ике баласы белән Сәмига бар иде. Шуның бәләкәй баласы, мине күтәреп керткәнне күргәч: «Нишләп сезне күтәреп керттеләр?»- дип йөгереп янга килеп житте. Нәрсә дип аңлатасың инде балага. «Мин бит исерек, шуңа мине күтәреп йөртәләр»,—диярге туры килде. Ышанды бала. Ышанмыйча, исерекләрне күргәләгәне бардыр инде. Бервакыт Кызылъярда да кунакка баргач бер бәләкәй бала: «Абый лай-лай иткән»,—дигән иде. Бу анын: «Абый исерек»,—дигән сүзе икән.

Шулай итеп, Яңа елны Рәшитләрдә каршылап, иртәнге 3ләрдә генә кайттык. Кайткач та йоклап булмады. Бик арытса, бигрәк тә йоклап булмый шул.

Яңа елның беренче көне бик матур тәмамланмады. Бөтен кәефне тагын шул К. бозды. Тик кенә утырганда тотынды бу чүкеч белән батарейга кагарга. Ярты сәгать каккандыр. Түшәмдәге штукатуркалар коела башлады. Өстәгеләрнең яшь ярымлык малайлары йөгергәнгә батарея кага дуңгыз. Көн дими, төн дими. Бүген аптырагач участковый милиция чакырырга туры килде. Гомердә бер мәртәбә дә милициягә мөрәҗәгать иткән юк иде. Кудряшев дигән кеше икән. Объяснительный язып, кул куйдырып китте. Иптәшләр судына бирербез, диде. Иптәшләр суды белән генә К. кебек дуңгызларны акылга утыртып буламы соң?! Кулдан эш төшә шушы сволочъ аркасында. Бүген ничә тапкыр йөрәк даруы эчтем инде, ярдәм итми. Нурсөянең дә куллары калтырый. Милиционер: «Сез бер дә жалоба бирмичә азындырып бетергәнсез аны»,—ди. Кешечә генә аңлашып булмасмы дип күпме тырышып карадык. Юк, кешечә сөйләшеп була торган хатын түгел бу. Хәзер йокларга ятарга курка башладык инде, кайчан кага башлар икән дип бөтен нерв күзәнәкләре көтеп тора. 54нче квартирда яшәүче Романовлар да, чарасын күрегез, юкса балабыз нерв

*Дәвамы. Башы 1нче санда*

авырулы була безнең дип заявление бирделәр. Моннан соң тагын да ныграк котыра башлармы. Хәзер анардан дөньядагы бөтен әшәкелекне дә көтәргә була инде. Юньле булса ул ирен психбольницага салмас иде. Үзе кереп мактанды бит: «Мин аңа аракыга бер пачка йокы даруы салып эчерәм дә, аңкы-минке йөри башлагач, белая горячка дип врачлар чакырам»,—ди.

**13 гыйнвар.** Бүген радиодан минем шигырьләрне бирделәр. СССРның халык артисты Ш.Биктимиров укыды. Ярты сәгатьлек тапшыру булды. 23 шигырьне укыды. Нишләп минем шигырьләрне укырга уйлагандыр. Күрәсең, минем «Танышлар арасында» дигән җыентыкны укып утыргандыр да, шигырьләр ошап киткәндер. Радио кушуы буенча түгел, үз теләге белән эшләнгән эш бит бу.

Кичә телевизорны төзәтеп алып кайттык. Телевизорсыз яшәү дә бик күңелсез. Озын кышкы кичләрне ничек уздырып бетерәсең. Гел генә радио тыңлыйсы да килми. Туктаусыз эшләп торып та булмый, эшләр өчен көн житә.

Кичен Рәшит белән Луиза керделәр. Бәлеш пешереп алып кергәннәр. Эчәге бәлеше.

**14 гыйнвар.** Ура! Китабым чыгып житте. Бүген авторский экземплярларын алып кайттык. Бер китап та болай ел башында ук чыкмый иде әле. Каты тыш белән чыккан. «Туган көн бүләге» чынлап та минем туган көн бүләге була инде.

Рәшит Гобәйдуллин шалтыратты. Минем «Туган көненә» дигән шигырьгә көй язган. Шуны үзенә бүләк итәргә телим, ди. Бик әйбәт.

Нурсөя машинканы алып китте төзәттерергә. Галимҗан абый Алишевка яна китабымны язып бирдем. Беренче автограф.

Бу арада гел әйбер төзәттерү әле.

**17 гыйнвар.** Шатлыклар да күбәеп китте, хәерлегә булсын. 13ендә радиодан шигырьләрне укыганнар иде, 14ендә китап чыгып житте. Бүген миңа «Татарстанның атказанган культура работнигы» дигән исем биргәннәр. «Социалистик Татарстан»ның бүгенге санында указ бар. Биш кешегә бирелгән: Р.Мостафинга, Г.Афзал, М.Рәхимов, Р.Батулла һәм миңа. Сөенечле хәбәр, әлбәттә. Иртән Илдар абый Юзеев шалтыраткач, ышанмый тордым. «Татарстанның атказанган культура работнигы»на сәлам»,—дип шалтыратты. Аннары берәм-берәм башкалар—Кояш Тимбикова, Рәдиф, Рәшит, Рашат, Рәфикъ Юнысов, Рафаэль Мостафин шалтыраттылар.

Кичә Рәшит Гобәйдуллин дигән җырчы килгән иде. Ул минем «Туган көненә» дигән шигыремә көй язган. Беренче җыры икән. Мин аны әллә композитор Рәшит Гобәйдуллинмы икән дип уйлаган идем. Аларның исем-фамилияләре генә туры килә икән.

Кичә тагын 50нче квартирда шаулашып, эчеп утырдылар төне буе.

**21 гыйнвар.** Бу төндә сәгать бергә хәтле шакылдады теге дуңгыз. Тагын йоклап булмады. Әле берничә көн элек кенә милиция кереп сүгеп чыгып киткән иде үзен. Хәзер торба какмый, нәрсәләрнедер дөбер-шатыр китерә, идәненә әллә нәрсәләр ыргыта. Бөтен нервыны ашый инде бу безнең. Чара күрергә ныклы гына законы юк. Аерым-аерым бар подъезд шуны сүгә, ә кул куярга дигәч һәркем тайпылып калырга тырыша.

**25 гыйнвар.** Кичә Нурсөя елап кайтып керде. Китап нәшриятына, 86нчы елга дигән кульязманы редакцияли башлаганчы алып кайттырып, карап чыгыйм дигән идем. 16 табаклык китапны башта 10 табакка калдырганнар иде. Хәзер инде планнар расланып беткәч, 10 табак планга керде дип тынычлангач, яңадан ике табакны кисеп ташлаганнар. Нурсөя шоковый состояниегә килгән, аннары директор янына кергән. Ә тегесе: «Фәниснең 10 ел эчендә болай да 8 китабы чыкты, синә мондый сорау белән керергә оят»,—ди икән. Бер китапны икегә, өчкә бүлеп чыгаргач, китап исәбе җыела инде ул. Ике-өч елга бер 20-25 табаклык китабымны чыгарсалар, мин ел саен алардан 3-4 табаклык китап чыгаруларын сорар идеммени? Житмәсә, директор: «Без китапларның ничек сатылуына да карыйбыз»,—ди икән. Нәрсә-нәрсә, минем китапларны начар сатыла дип булмый инде. Бер генә кибеттә дә юк алар. Синең

китапларының каян табарга мөмкин дип күпме хат килеп тора.

Бик яхшы обоймада йөргән язучыларның 7-8 ел элек чыккан китаплары кибеттә ята. Бер авторның (исемен язмыйм) кибеттән 3-4 китабын алып чыгарга була. Әле алар минем китаплар кебек юка, начар тышлык белән дә чыкмаган.

Язучының иң авырткан жире—теләгәнчә китап чыгара алмаудыр. Нурсөя минем үземә караганда да ныграк борчылып йөри бу китап өчен.

**29 гыйнвар.** Нурсөя бүген больницага китте. Ул да гел авыртынып йөри. Әле умыртка сөяге, әле аяклары сызлый. Бөерләрен әйткән дә юк. Кичә йокларга яткач, бөтен ашаганын косты.

Минем дә кичә нишләптер йөрәк бик авыртты. Төшкә кадәр әллә ничә тапкыр бик әшәке итеп чәнчеп-чәнчеп алды. Хәтта Нурсөя барасы жиренә чыгып китә алмый торды.

Бераздан соң Зәкия апаларга почта аша календарьлар салып кайтты. Кибеттән яна китапларны күпләп алдык. Сигнальныйлары чыгып нәкъ бер ай үтүгә кибеткә килеп житкән. Кызлар шалтыратты.

Бу көннәрдә «Тозлы тамчы»ны өр-янадан төзеп маташтым. Иске шигырьләрне алып ташлап, күбесе урынына яңаларын куйдым. 14 табаклык китапны сигез табакка калдыру өчен күпме тунарга туры килде кульязманы. Әле үземдә яна шигырьләр ике табак бар иде. Кыскасы, 16 табактан 8гә калдырырга туры килде. Дөрес, әле мин аны, «бәлки»гә өметләнеп, 10 табаклык итеп әзерләдем.

**1 февраль.** Нурсөяне больницага салырга направление биреп жибәргәннәр. Ашказанында язва булмагае диләр. Направлениене 29ында алып кайтты. 30ы көнне Баян жизниләргә шалтыраттым, барып әйткәннәрдерме әнигә. Кайчан килер, кем китерер әле аны. Нурсөя ныклап чирләп китсә мин нишләргә тиеш инде? Алла белсен. Мине бит чит-ят кеше генә карый алмый.

Төрле яктан кыса язмыш. Финиш якынлашамы? Финиш фажигале булмаса ярый да.

**4 февраль.** Кичә әни килде. Самолет белән берүзе генә килгән. Анда аны алып килешер кеше дә юк шул. Абый билен кузгаткан, Баян жизни күзенә операция ясатып больницада ята, Вәсилә апа Нәдиясе янына киткән, ансы бала табып больницада ята. Фаиз жизни Себергә, Рифләр янына китәргә билет алган.

**8 февраль.** Өченче көн Хәләф абый Гарданов шалтыратты. 16нчы мәктәптә синең кичәнне үткәрергә жыеналар, шул укучыларга берничә сүз әйтсән, магнитофонга язып алып китәр идем, ди. Бүген шуларга әйтер сүзне һәм берничә шигырь әзерләп куярга кирәк булыр.

Кичә Миләүшә килеп өч сәгать утырып китте. Үзенең ничек иргә чыгуын, ничек итеп сугышып торуларын, аны (ирен) төрмәгә утыртуын, аннары анардан аерылуын, иренең квартирын ничек итеп көч-хәл белән үзенә яздыруын, хәзергесе вакытта иренең ике еллык лечениедә икәнлеген көне-сәгате белән бер вакыйгасын да калдырмыйча сөйләп чыкты. Бәлки, безнең тормыштан берәр нәрсә язарсың, ди.

Нурсөя больницадан һәркөн диярлек шалтыраткалап тора. Керү белән кан басымы күтәрелгән, нервылары да бик какшаган. Ашказанының авыртуы бәлки нервыдандыр, дигәннәр. Нервылары бик шәптән түгел шул, мина килгән вак-төяк уңышсызлык өчен дә үземнән ныграк борчыла.

**10 февраль.** Нурсөя кичә температурить итә башлаган. Палаталары бик кызу икән. Форточканы гел ачык тоталар, ә Нурсөя тәрәзә янында ята. Шунда салкын эләктергән. Болай да йомшак кешегә күп кирәкмени? Инде исән-сау терелеп чыга гына күрсен. Күнелгә шом да йөгереп үтә. Алла сакласын. Бер килгәнгә килә ул. Бер снаряд чокырына бүтән снарядлар да гел төшеп тора.

**12 февраль.** Нурсөянең больницага кергәненә икенче атна китте. Температурасы һаман төшми икән әле. 38,4. Үзем чирләгәндә арурак. Мин инде үләргә тиеш дип уйлыйсың. Нурсөя чирләгәндә жанны төрле шикләр борчып тора. Больницада бит анда әллә нинди чирләр эләктерүең мөмкин. Кергәндә температурасы юк иде бит.

Анда һәрвакыт шул форточканы ачу-ачмау мәсьәләсендә бәхәс бара. Гомумән, больницада тормышның начар ягы ачыграк күренә. Авыру кешедә эгоизм калкып чыга. Һәркемгә үз чире ин авыр тоела. Медперсонал эшләргә тиешле эшен көттереп, ялындырып эшли. Шулай итеп алар үзләреннән башка тормыш бармый дигәнне аңлатмакчы була. Больницада «сыйныф»ларга бүленү аеруча күзгә нык ташлана. Түрәләр ванналы, туалетлы люксларда түш киереп йөри, гади кеше саф һава суларга зарыгып ята. Туалетка керергә чират көтә.

Йокларга яттым исә, күңелне уйлар били. Аннары инде йоклармын димә. Җитмәсә, бүген теге өстәге хатын кичке 8дән нәрсәдер дөмбердәтергә тотынды. Аннары кухня батареясын дөмбәсләп алды.

**19 февральдә** «Казан утлары»ның узган елгы саннарын тикшерү була. Миңа да чакырып кәгазь җибәргәннәр. Әгәр бара алсам, нәрсә әйтер идем икән?

1. Журналда юмор юк дияр дәрәҗәдә. Батулланың төрле артистлар-язучылар турындагы мәзәкләре генә юморга сусауны баса алмый.

Бу нәрсәдән килә соң? Үзендә юмор булмаган кеше башкаларны да аңламыйдыр, күрәсең. Проза бүлегендә хикәяләр С.Шәмсигә керә. Анарда юмор юк та юк инде ул. Ә бит үзе бик гыйлем кеше.

Баш редактор Р.Х., гомумән, көлә белә микән?

2. Зур әдәбиятка кагылышы булмаган нәрсәләр күп басыла башлады. Мисалга Зөфәр Фәтхетдиновның «Тайна стоит жизни», «Ак жигули эз югалта» әсәрләрен атау да җитә. Беренчесе китап булып басылып чыккач журналда басылды. Башкаларның әсәре китап булып чыкса, журналга кергән булса да бик тиз сызып ташлыйлар. Димәк, баш редакторга нәрсәсе beләндер ярaган бу автор. Әсәренең әйбәт булуы белән түгел, әлбәттә. Р.Х. аның әсәре кат-кат басылырлык әйбер түгел икәнен аңламаслык кеше түгел.

3. Журналның барлык редколлегия членнары үзләренең чүп-чарларын тутыралар.

4. Хикәяләргә игътибар юк. «Батырлык дәвам итә» конкурсына бер җүнле хикәя дә чыкмады әле. Конкурсның, бәлки, девизын кинрәк алырга кирәк булгандыр. Гомумән, нык уйланылган конкурс түгел. Бездә бит эштә яки хәрби хезмәттә күрсәткән батырлык кына санга сугыла. Ә рухи батырлык, җаннан бәреп чыккан кешелеклелек, тыйнак кына эшләнгән матур эшләр батырлыкка саналмый. Чөнки рухы белән бөек кешеләр тыйнак була. Ул үзенең матур эшләрен кешегә сөйләп йөрми.

**13 февраль.** Нурсөянең һаман температурасы бетми. Кичә 38,8ләр булган. Минем бервакытта да температурам булмый дип йөри иде. Бүген ана кипкән кура җиләге белән карлыган илттердем. Разил Вәлиевка шалтыраткан идем, машина биргән, Камил Кәримовны җибәргән. Алар илтеп кайттылар. Җитмәсә, больницада карантин. Беркемне кертмиләр. Передача гына алалар.

Нурсөя бүген рентген узган. Уникеле эчәгендә язва дигәннәр. Ашказанына караганда да начаррак инде бусы. Әле ашказанын нәрсә диярләр тагын. Чүп өстенә чүмәлә.

Үземнең дә берничә көн бөтен тән өшеп, юешләнеп тора. Әллә берәр әйбер язарга тотынырмынмы дигән идем, кәеф тә юк, тазалык та.

Нурсөя больницага киткәннән бирле өйләр суык. Бөтен җылыны алып китте. Бүген «Бушлык» дигән бер шигырь язып куйдым.

**16 февраль.** Нурсөянең температурасы төшкән, ләкин кан басымы югары икән әле. Көн саен шалтыратып тора. Кичә колагына «Яруллин» кебегрәк фамилия чалынып киткән дә, мине дә больницага китергәннәрдер дип коты очкан. Мин әле быелгы гриппны өйгә кертми генә уздырам бугай. Тфү, тфү, үземә күз тидерә күрмим тагын.

**20 февраль.** Туфан белән Рөстәм Мингалимов килгән иде. Минем теге атказанганлыкка диплом һәм значогын китергәннәр. Берәр рюмка коньяк белән

моны юдык. Кич белән радиодан минем яна китапка күзәтү тапшырдылар. 18 февральдә «Социалистик Татарстан»да шигырьләр чыкты. И.Юзеев шалтыратты, әйбәт шигырьләр, диде. Әле Ш.Маннапов белән сөйләшкән идем, ул да Язучылар союзында да әйбәт шигырьләр сайланган дип әйттеләр, диде.

Нурсөя әле һаман больницада. 18нче февральдә «Башкисәр»не башлап куйдым. Яңа повесть. Яза-яза, бәлки, исеме үзгәрер.

**24 февраль.** Бүген сайлау көн. Кичә Фәридә Фатыйховна, Генадий Васильевич Емельянов һәм ГИДУВ профессоры Гарт Валиевич Еникеев белән доцент Исаак Самуиловичлар килде. Аннары хатыны Асия белән Рәфикъ Юнысов һәм Диләрә килделәр. Туган көн белән котлап шампанский һәм чәчәкләр алып килгәннәр. Үземнең коньяк бар иде. Аны Рәфикълар килгәнче бушаткан идек инде. Аңа күрше Әхтәм абый да «ярдәм итеште». Нурсөя генә һаман больницада. Шатлыкларны шатлык итәргә ул юк.

**26 февраль.** Нурсөягә дүртенче атна китте. Ансыз ямансу шул. Башлаган повестымны кыенлык белән булса да дәвам итәм. Башлаганда бик шәп әсәр туар кебек иде, хәзер инде артык әһәмиятсез, вак нәрсә булып тоела. Бернинди кәефләргә карамыйча дәвам итәргә дип үзенне нигытып тормасаң, ялкаулык почмактан чакырып кына тора.

Кичә әни ике бармагын пешерде. Чәйнекне сусыз куйган да шунда пешергән. Картайган инде, колагы да катыланып бара. Акыл елгырлыгы да юк. 77дә бит инде. Мин анардан 30 яшькә кече булып та мактанырлык рәт юк. Бөтен нәрсәне онытам.

23 февраль көнне Фәридә Фатыйховналар алып килгән чәчәкләр бик шәп булып ачылды. Һәр сабакта чынаяк хәтле 5 чәчәк. Сабагы камыш кебек. Нинди чәчәк икән бу? Бакчага утыртырга кирәк моны.

**12 март.** Нурсөя һаман больницада. Эч поша. Исән чакта чыга аламы? «Башкисәр»не язам. Әйбәт кенә бара. Көндәлеккә тотынырга вакыт юк. Бер-ике көн чирләп тә алырга туры килде.

**25 март.** 21 мартта Нурсөя больницадан чыкты. 19 мартта повестьны тәмамладым. Нурсөя машинкада баса башлады. Иртәгә әни китә.

Көннәр матур тора.

**1 апрель.** 29 март көнне врачлар килеп китте. Больницага кермисенме, диләр. Кермим, дидем. Өйгә килеп уколлар ясарга булдылар. Пока кокарбаксилаза кадый башладылар. Больницага кереп бераз дәваланып чыксаң да ярар иде, ләкин анда үзем генә ята алмыйм. Ә Нурсөя әле генә чыкты. Тагын минем белән дә ятса, бөтенләй аяктан егылыр. Әле дә күләгәсе генә калган.

Кичә Нурсөя белән Фәридә тәрәзәләрне юдылар, өйләр жыештырдылар. Көннәр әле бик жылытмый. Төннәрен 3-4 градус салкын, көндезләрен шунын кадәр жылы. Урамда кар эреп бетми. Кичә һәм өченче көн бик шәп кар яуды. Нурсөя повестьны машинкада баса. Кемгә биреп укытырга икән? Турыдан-туры «Казан утлары»на гына илтеп бирергәме?

Хәзер бер әйбер дә язып булмас инде тиз генә. Башта берни юк. Әз-мәз шигырь язылса гына.

Повестым бер караганда бик әйбәт сыман, икенче караганда бөтенләй ошамый башлый. Үз әйбереннe дөрес бәяләп булмыйдыр, күрәсең.

**9 апрель.** Бүген уролог Галина Александровна үзенең сестрасы Надя белән килеп киттеләр. Чакырмаган идек. Ярый Нурсөя өйдә чак иде. Нурсөяне Нурихан Фәттахларга жибәрергә тора идем. Повестьны укып чыкмасмы дигән идем. «Казан утлары»на илткәнче әйбәтрәк язучы күзлегеннән үткәрсәң начар булмас иде.

Врач прозерин—10 укол һәм тагын эчә торган нинидер бер дару бирде. Эчәгеләр бик начар эшли башлады.

**12 апрель.** Нурсөя Н.Фәттахларнын өен тапмый кайтты. Без аныКиров районында дип уйлый идек, ул Нагорный поселыгында икән. Анда хәтле барып йөрмәссең

инде, дидем. Бәлки, Аяз Гыйлаҗевтан укытырмын әле.

Прозерин уколы аллергия бирә, ахры. Күздән яшь, авыздан селәгәй ага. Йокыны китергән төсле итә. Авырайта. Маңгайлар, чәч төпләре тирләп чыга. Өч укол алдым инде, өчесендә дә шулай итте. Тышка чыгарга аның ярдәме тидеме, кечә җайлырак чыктым. Бер сәгать эчендә эчне бушатып булды. Әгәр шуңа ярдәме тисә, уколы авыр булса да түзеп карарга туры килер. Кинәт кенә сулышны буып, йөрәкне туктатмаса.

Бүген «Үлчәнү» дигән бер шигырь яздым. Соңгы куплеты бик ошап җитми әле. Бәлки, ансы артыктыр. Әлегә торып торсын.

Көннәр һаман салкын. Бүген кар явып тора. Кайбер елларда «Космонавт көне»нә җылы җәй җитә иде. Гагарин очкан елны мин район больницасыннан авылга кайткан идем. Авыл эчендә юллар төшкән, халыклар күлмәкчән йөриләр иде. «Космонавтлар көне»—1961 елның 12 апреле—минем өчен дә истәлекле көн. Шушы кайтудан янадан район больницасында ятмадым. Авылда 1962 елның июненә хәтле яттым, аннары Казанга алып киттеләр. Казанда «Иске клиника» дип йөртелә торган республика больницасында 1963 елның июленә кадәр яттым, аннан Бәкер курортына җибәрделәр. Аннан кайткач, 6нчы больницага салып тордылар. Анда бер ай яттым һәм сентябрь аенда квартир бирделәр. Больницаларда газап чигеп йөрүләр шуның белән тәмамланды диярлек.

Казан больницаларында—ГИДУВта, 6нчы да, республиканскийда, обком больницасында һәм Горький урамындагы травматология институтында ятарга туры килде. Барлыгы күпме ятканмын икән, санап карыйм әле. 1958 елның 17 июлендә егылдым һәм 1959 елның 9 маена хәтле Красноярскийда яттым. Анда 10 ай, районда Урыссуда—3 ай. Баулыда—1959 августыннан 1961 апреленә чаклы. Димәк, 1ел да 8 ай. Казанда республиканскийда 3 ел да 9 ай, обком больницасында 2 тапкыр 2 ай = 4 ай, ГИДУВ та 1 ай, 6нчы да—1 ай, Горький урамында—3 ай. Барлыгы 4 ел ярым булды бугай әлегә. Ләкин өйдә ятканда да шул ук «кара сакал» арттан калмый бит.

**21 апрель.** Кичә температура булды—38,7. Бүген иртән 37,5. Уколлар ясап бетерүгә минем гел температура була икән. Былтыр да шулай булган иде.

Өченче көн М. килеп китте. Кәефе бик төшкән. Романын «Казан утлары»на чиратсыз кертмәгәннәр. Туфанга бик ачуы килгән. Туфан ана: «Әдәбият ул трамвай түгел хатын-кызларны алдан үткәрергә»,—дигән. Бик дөрес әйткән. Минем авыру булып та бер әйберемне дә алданрак бирә алмассызмы дигәнем булмады.

**22 апрель.** Температура бетеп җитми әле. Кичә кич 37,9 иде, бүген көндез 37,4. Бүген ике шигырь язып куйдым.

Туфанга шалтыраттым. «Теге көнне кофеларыңны алдык та качтык, акчасын бирергә җыелышта идең»,- дим. «Ярар, күчтәнәч булыр,—ди.—Мәскәүдән алып кайткач, күчтәнәч инде ул»,—ди. «Синең күчтәнәчләреңне күп ашадык инде»,—дип карасам да, акчасын китермәскә кушты.

Көннәр җылынып маташа. Бүген 8-10 җылылык. Быел болай җылытканы юк иде әле.

16 сы көнне Душанбегә һәм Янгиюльгә китаплар салдык. Былтыргысын алганга да җавап килмәгән иде.

Хәзер төрле җирдә шигырь бәйрәме башлана. Бүген И.Юзеев шалтыратты. Аның белән сөйләшеп тордык бераз. Кырлай якларына бер барып кайтасы килә, дидем. «Мин моны тәртеп куйыйм әле»,—диде.

**25 апрель.** Көннәр матурланып маташа. 10-12 җылылык. Өйләр кызу. Тәрәзәләрне ачык тотабыз. Шуннан салкын тия. Кичә дә бераз температура бар иде.

Кичә Тависә исемле бер хатын килде. Бөгелмәдән. Моннан 20 ел элек без аның белән Бәкер курортында бергә булганбыз. Ана ул вакытта 18 яшь булган. «Мин сезнең палатага кереп сүзсез генә утыра идем»,—ди. Малаена Фәнис исеме кушкан. «Минем бу Фәрит кияүлеккә ин соңгы кандидатура иде,—ди.—Башка кеше янына

свиданиегә барган җирдән үзләренә чәй эчәргә дип алып керде дә, «мин, инәй, өйләндем» дип әйтте»,—ди. Бу керүдән калуын калмаган әле Тависә ана хатын булып. Ләкин ана чыгарга сәбәбе булды инде, ди.

Тагын кич больницада ятканда килеп йөргән Әминә исемле кыз килде. Ул тоже бөтен тәнне сыпырырга, массажларга ярата иде. Нурсөя өйдә булгач алай сыпыргалап утырмады инде. Кияүгә чыккан. Балалары юк.

**2 май.** Бүген Нурсөя быел беренче тапкыр бакчага китте. Кичә 19 градус җылы иде. Өйдә чыдап булмаслык кызу. 30 градус. Шәрә ятам. Йөрәк шартларга житешкән. Форточкадан кергән һава гына җитми. Өйләргә ягалар.

Агачларның бөреләре ачылып килә. Безнең тәрәзә каршындагы каен бүтән агачлардан алдарак яшәрә. Мине сөендерергә телидер инде.

**3 май.** Кичә Нурсөя редиска һәм кишер чәчеп кайтты. Бүген дә бармакчы иде, авыртынды, бара алмады. Көн матур үзе. Бик четер кояш булмаса да, җылы. 17-18 ләр. Һава ниндидер дымык. Авыр. Өйләргә һаман ягалар. Төнлә бер дә йоклап булмады. Йөрәк урынына утлы күмер кыстырып куйган кебек төн буе пешерде.

Иртән 8нче яртыда ук бер апа шалтыратты. Сез генә миңа ярдәм итә аласыз, мөмкин булса, килеп үз хәлемне сөйләр идем, ди. Нурсөя әйтә, берәр әйбер язган пенсиядәге укытучыдыр, ди. Юк, мин әйтәм, сөйләшүенә караганда әз белемле кешегә ошаган, тавышына караганда иллене узган кешедер, дим. Кыска буйлы, төскә карарак хатын булырга тиеш, дим. Бөтен ягы мин әйткәнчә туры килде, бары тик кара хатын түгел, сары иде. Яше 54 тә икән. 5 нче трестның 1 СМУ сында маляр-штукатур булып эшли. Бригададан чыгарганнар, квартир алырга әллә кайчаннан бирле 1нче булуга карамастан һаман квартир чиратымны чигерәләр, ди.

Мин. Сезгә ничек ярдәм итә алам соң?

Ул. Сез бит пьесалар да, хикәяләр дә язасыз. Менә минем шушылай хаклыкны таба алмавым турында берәр пьеса йә хикәя яз.

Мин. Минем хикәя сезгә ни файда бирер соң?

Ул. Кешеләр укыр. Әнә сезнең «Бәйрәм кунаклары» дигән хикәягез нинди кызыклы бит.

Мин. Сезгә газетага барырга кирәк, апа. Яки эшләгән җирегезгә барыгыз. Язучылар сезгә ярдәм итә алмас.

Ул. Мин газетага да, судка да бардым инде, файдасы юк. Менә Туфан Миннуллинга хат язган идем, шуны укып кара әле. Аңа җибәрсәм, бәлки пьеса язар. Аның «Бәйләнчек» дигән пьесасы шундый кешеләр турында бит.

Мин. Туфанның вакыты юктыр, апа, ул бит хәзер Союз председателе.

Ул. Алайса, Туфан миңа ярдәм итә дә итә инде.

Мин бу апага язучыларның үзләренең дә фатир таба алмый интегүләре турында сөйли башладым. Ләкин ул минем сүзләремне тыңлап та бетермичә, Туфан янына китте. Туфан бу апага нәрсә дигәндер, ансын сорашкан булмады.

Бүген пенсияне керттеләр. 30 сумга арттырганнар. Бернинди волокитасыз. Үзем дә сизми калдым. Хәзер 150 сум булды. Җиңү бәйрәменә әйбәт бүләк.

**5 май.** Кичә Нурсөя белән икәүләп чирләдек. Күңел болганып, костырып үтерә язды. Көндез мин башлаган идем, эстафетаны Нурсөя алды. Сквозняк кирәкне биргән, ахры. Һаман өйгә ягалар. 30лардан артып китә. Бөтен тәрәзәләрне, балконны ачып ташлыйбыз. Шул бөерләргә бәрә. Ә бөергә салкын тидеме, укшыта, костыра башлый. Нурсөянең бакчага барырлык та рәте юк. 2сеннән соң бара алмый әле. Ә көннәр кызу тора: 25-27 градус җылылык. Агачлар шушы ике-өч көн эчендә яфрак ярып җибәрделәр. Дөнья матур. Ә без үлә язып ятабыз. Моннан бер атна чамасы элек Аяз Гыйлаҗевка повестьны укымассыңмы дип шалтыраткан идем. Бик теләп риза булган иде, килеп алмый әле. Бәйрәмнәр узсын инде, дигән иде. Кеше киләсе булгач, Нурсөя хәтта кибеткә дә чыгып китә алмый. Бу ике ай эчендә врачларның да визитлары ешайды. Уйламаганда киләләр дә керәләр. Ватан сугышы инвалидларын һәм аларга тиңләштерелгән инвалидларны җиңү бәйрәменә кадәр диспанзирация

уздырырга кушылган икән аларга.

Кичә Бөгелмәдән теге Тависә шалтыратты. «Бәкер курортында чакта Сез «Зәңгәр чәчәк» дигән шигырь укыган идегез. Ул зәңгәр чәчәкләрне Сезнең өчен арыш арасыннан мин җыеп алып кайта торган идем, тик, бирергә кыюлыгым җитмәгәч, ашханәдә эшләүче кызлар аша бирдерә идем. Хәзерге җыентыкларыгыздан шул шигырьне һич таба алмыйм»,—ди.

Минем хәзер моннан 22 еллар элек язган дәфтәрләрне актарып утырасы килми шул. Җыентыкларыма кертмәгәч, димәк, ул бик шәп булмагандыр инде. Йә аның исеме башкачадыр. Зәңгәр чәчәк образы минем кайбер шигырьләрдә бар инде. Ләкин кайсы шигырь кемне күз алдында тотып язылгандыр? Хәтерләмим.

**7 май.** Бакчага бүтән барган юк. Нурсөя чирләп йөри. Кичә мин беренче тапкыр урамга чыктым. Машинаның аккумуляторын алып чыгып кабызып карадык. Кайсыдыр төшеннән бераз май аккан. Көннәр май башыннан бирле матур тора. Кызу. 25-27 ләр булды. Бүген 21-23. Без бакчага барсак суыта инде ул. 9ларында барырга ниятләп торабыз.

Аяз Гыйлаҗев килеп повестьны алып китте. Аның белән бәйрәм хөрмәтенә бераз төшердек. Ул «әйбәт» кенә булып кайтып китте.

Район башкарма комитетыннан килеп Җиңү бәйрәме белән котладылар.

**8 май.** Көннәр суытты. 10-12.

Врачлар килеп китте. Аларны бәйрәм белән котлап 1 пачка конфет һәм берничә лимон биреп җибәрдек. Нурсөя чирләп ята иде. Башы әйләнеп. Аяклары да бик сызлый. Елдан-ел начарлана бара. Авыртынмаган көне юк. Аның чирләве минем үземнең чирләвемнән дә яманрак.

**11 май.** Аяз Гыйлаҗев шалтыратты. Повестьны укыган. 7 майда алып киткән иде. Әйбәт, повестың белән котлыйм, диде. Ләкин ахырын башкача бетерергә кирәк, диде. Нурсөя алардан кульязманы алып кайтты. Квартирларының шәплегенә исе киткән. Хатыны Нәкыя ачык кеше икән, кыстый-кыстый чәй эчереп җибәрде, ди. Хәзер повестьның азагын уйлап ятам. Озынга сузмыйча гына бетерергә иде. Бер дә озын әйберләрне яратмыйм.

«Казан утлары»ның 3-4 саннарында Газиз Кашаповның «Язмышыңа ышан» дигән романы чыкты. Бик сыек әйбер. Бу авторга карата мәхәббәтем бетә башлады. Ә бит мин, ана зур өметләр баглап, «Сәмум җиле»нә рецензия язып чыккан идем. Соңгы әйберләрендә автор һаман түбәнәя бара. Бәлки, миңа гына шулай тоеладыр. Мин анардан артыграк өмет итәмдер. Һәркем дә үзеннән биеккә сикерә алмый бит.

**12 май.** Көн салкын һәм яңгырлы. Әшәке җил. 10нан артык түгелдер. Бакчага барып булмый. Әллә ни омтылыш та юк.

Узган төн кайбер районнарда 3 градуска кадәр салкын булган.

Безнең тюльпаннар һаман чәчәк атмый.

**17 май.** Бүген повестьны Аяз Гыйлаҗев укыганнан соң яңадан эшләп чыктым. Аяз абый белән сөйләштем, хәзер Нурсөя шуны яңадан аларга илтә китте. Тагын ни дияр.

**21 май.** Бүген «Казан утлары»н укып яттым. Х.Камаловның прозасын бик яратмый идем, «Безне өйдә көтәләр» романы ярыйсы булыр төсле. Әле 4нче санда башы гына килде. Ләкин сугыш турындагы әсәрләрдә В.Быковныкы кебек тыгызлык, киеренкелек юк. Сүз күп. Бу әсәрдә дә шул нәрсә сизелә. Күпсүзлелек безнең күп язучыларыбызның уртак чире инде ул.

**23 май.** 21 майда Әлмәт театрының баш режиссеры Рөстәм Абдуллаев килгән иде. «Бай эти»не худсоветта укыганнар. Хәзер, шуларның киңәшләрен искә алып, пьесаны яңадан эшләп ятам. Кую-куймау әле билгеле түгел. Режиссерга ошарлык килеп чыкса, куярлар инде. Ләкин пьесаны аныңча эшли башлагач, кызыклы урыннары төшеп кала. Шулары кызганыч. Ачу килә. Күп әсәрләр үзең теләгәнчә чыкмый. Китап бирсәң, йә эчке рецензия язучыга, йә редакторга кайсыдыр җире ошамый. Һәркем үзен хаклы дип саный. Үзеңчә генә эшләсәң, әсәрең дөнья күрми.

**3 июнь.** М.Шигинның «Новый мир» журналында чыккан сугыш чоры көндәлеген укып яттым. Шәп! Ни хәтле мактансак та, рус әдәбияты бездән алдарак бара.

Май ахырында янадан бер китап әзерләп нәшриятка илттердем. Ике повесть. Киләсе елда мине бөтенләй китапсыз калдырырга уйлыйлар бугай. Башны әйләндермичә генә шул шигырь китабына риза булып ятсам, үзебезгә дә эш кимрәк була иде.

Әле менә «Бай эти»не машинкада басып ятабыз. Авылга кайтылса, Әлмәткә сугылып Абдуллаевка биреп китәргә исәп. Бәлки, тагын берәр кат эшләргә туры килер әле. Өр-яңа уйлар, фикерләр килеп тора.

Бер кечкенә повестьлык сюжет та башта әйләнгәләп йөри, күзгә кергәч тотынып карарга булыр дип торам.

**2 июль.** 6 июньнән 29 июньгә кадәр авылда булып килдек. Без авылга кайтканда кар яуды. Чистайдан Кызылъярга чаклы ап-ак кар иде. Көннәр суык һәм янгырлы торды. Урамнар пычрак. Ярый әле Кызылъярның бер урамына бераз юл салганнар, югыйсә кереп булмас иде. Авылда һәркемнең коймаларын буяталар, урамны рәткә кертәләр. Баксан-күрсәң, безнең авылда авылларны төзекләндерү буенча берничә районның берләштерелгән семинары була икән. Койма буяу түгел инде бу—күз буяу. 15 июньдә семинар булып узды. Мин дә бардым. Семинар узу белән төзәтелеп бетмәгән юллар, буялырга өлгермәгән коймалар турында оныттылар. Ә бит ярыйсы гына эш эшләгәннәр. Авыл эчендә бер юл салып куйсалар, пычрактан котылырлар иде. Югыйсә кызлар клубка резин галоштан баралар.

Авылда күп кенә яңа йорт салынган. Кирпечтән. Колхоз салган. Чишмә суы кергән югары очка. Мәктәп, идарә һәм югары оч халкы чишмә суы эчә. Ләкин төп линиягә чишмә суын тоташтырмаганнар. Типтәр очында ярлар һаман ишелә, ныгыту турында уйлаучы юк. Колхоз председателе Рәшит Сабиржановны күреп сөйләшергә туры килмәде. Язучы халкының күзенә чалынмауны хубрак күрә бугай.

Кайткач, авыл мәктәбендә очрашу уздырдык. Йөзләп кенә кеше бар иде. Мәктәп 320 укучыга исәпләп салынган, 140 бала укый. Укучылар Баулы мәктәбенә ныграк тартыла. Чөнки безнең авылда укып чыкканнар әллә кая керә алмый.

Авылда эчү дә кимүгә бармый. Кибеттән кочак-кочак аракы шешәләре күтәреп чыгалар. Урамда кыек-мыек йөрүчеләр житәрлек.

**10 август.** Бу айның ункөнлеге бик әйбәт: коры һәм кызу. 33ләргә житә. Урыпжыю өчен заказ белән эшләнгән кебек. Алай да, вакытында урып-жыя алмасалар, «Һава торышының начар торуы сәбәпле» диярләр әле.

Бу кызу көннәрдә өйдә ятарга туры килде. Чөнки киләсе елда чыгачак китапны рецензиядән соң эшлисе бар. Бакчада кулга каләм тотасы килми, күбрәк урамда ятасы килә. Организм ял сорый, күрәсең. Бу китапка Фәүзия Бәйрәмова белән Аяз Гыйлажев рецензия язган. Бәйрәмова «Кыйгак, кыйгак каз кычкыра» повестен теткән генә. Мондый нәрсә әдәбиятка керергә тиеш түгел, бу врачлар эше, фәләнфәсмәтән дигән. Бездә үзебезнең татар әдәбияты кануннарыннан әз генә читкә чыксаң да, «бу ярыймы икән соң» дип куркып калалар. Чит ил әдәбиятларын укымыйлар, үзебезнең кабыгыбызда бикләнеп яшибез. Бөтен кеше язган нәрсәләр турында язсаң гына әйберләр тоткарлыксыз, шома үтә. Ә минем мең кеше язганны мен дә беренче булып кабатлыйсым килми. Безнең әдәбиятның союз күләмендә ныклап яңгыраш ала алмавы да бүтәннәр язып туйган нәрсәләрне кабатлаудан, күрәсең. Күтәргән темаң, күрсәтергә теләгән проблемаларың яңа булмагач, осталык кына коткармый. Ә минем «Кыйгак, кыйгак каз кычкыра» әсәремдә монарчы безнең әдәбиятта чагылмаган тема күтәрелә: хатын-кызны авыр эш үз асылын югалтып ир-атка әверелдерүе турында. Менә шуны анларга теләмиләр. Аларга Г.Әпсәләмов әсәрендәге Гөлшаһидә кебек образлар кирәк.

Хәзер шушы рецензияләрдән соң кульязманы эшләп ятам.

Аяз Гыйлажевның рецензиясе бик төпле, әсәрне анлап язганлыгы күренеп тора.

Кичә бер кызык хат килде әле. «Туган көн бүләге» дигән китаптагы «Хужа» хикәясен бер укучы бик «шәпләп» анализлаган. Бер биттә ничә сүз, нинди сүз ничә тапкыр кабатлана, күпме өтер, күпме нокта барын санап чыккан. Илдар Юзеевка да шундый хат җибәрдем дигән.

**20 август.** Ниһаять повестьларны рецензиядән сон карап чыктым. Күп эшләргә туры килде. Кичә нәшриятка илттердем. Бүген Ш.Рәкыйпов шалтыратты. Бикә Рәхимовага бирергә уйлыйбыз кулъязманны, диде.

**2 сентябрь.** Җәй күренмичә дә үтеп китте. Бакчаларда ямь бетеп бара. Август ае бик җылы торды. Ләкин китапны эшләп өйдә ятылды, бакчага да 2-3 тапкыр гына барылды. Бакчада «Новый мир»нын 6-7-8нче саннарын укып яттым. Ю.Рытхэунын «Магические числа» романы ошамады. Вообще, быел бу журналда әйбәт әйбер юк әле. Алты номерга сузылган «И поджег этот дом» да ис китәрлек түгел.

Р.Юныс безнен авыл турында «Ярлар ишелмәсен» дигән мәкалә язган «Татарстан яшьләре»ндә. Ләкин ярны ныгыту өчен агач утыртырга чакырудан узмаган. Ишелеп барган ярны агач утыртып кына туктатып буламыни? Монда проблема тирәндә, бу мәктәп балалары хәл итә торган мәсьәлә генә түгел.

Яр буенда, безнен бакча артында колач җитмәслек унике өянке үсеп утыра, әле аста вак таллык иде. Һәр яз саен бозлар ярны кимерә торгач башта вак талларны, аннары берәм-берәм безнен өянкеләрне суырып ала башлады. Болай барса, бер ун елдан бәрәнге бакчасын да алып китеп берәр дингез төбенә салыр.

**4 сентябрь.** Кичә бакчада карарга дип транзисторный телевизор алып кайткан идек, эшләми. «Электроника 404». Тышкы кыяфәте матур гына, ләкин сыйфаты начарнын аръягына чыккан. «Частота кадров» ручкасы эшләми. Үз антеннасы белән күрсәтми. Тышкы антеннага тоташтырсан гына бераз күрсәтә. Анда да үлле-мәлле генә. Бүген бакчага китешли мастерскойга сугылырга исәп. Нурсөя, мин нәрсә алсам да неудачно була, бүтән берни алмыйм дип йөри. Безнен илдә бөтен нәрсә шулай инде ул дип аны тынычландырырга тырышам. Ләкин ашкынып коммунизмга барган илнен юньле әйбер эшли алмавына ачу килә.

**8 сентябрь.** Кичә Бикә Рәхимовага шалтыраткан идем. Китапны редакцияли башлаган. Повестьлар турында фикерем әйбәт, ди. Бер-ике генә анлашылмаган сүз бар, аларын янына баргач хәл итәрбез, ди. Көзгә кереп, бераз күнел басылгач, юбилей китабын әзерли башларга булыр. Дөресен әйткәндә, ул әзер диярлек инде. Янадан төзеп чыгасы гына. Шигырьләр күп. Бераз сайлаштырасы, бүлекләргә аергалыйсы, бүлекләргә исем куясы, эчтәлек төзисе кала. Шигырь китабын төзү бик мәшәкатьле эш. Көчне күп ала. Ярый әле Нурсөя бар. Кабат-кабат машинкада басулар анын өстендә.

*Дәвамы киләсе саннарда*

*Кадерле укучыларыбыз!*
*Бу көндәлек язмалары сезгә ошыймы? Аны укыганда нинди хисләр кичерәсез?*

# ЖУРНАЛГА ЯЗЫЛУ ДӘВАМ ИТӘ

Хөрмәтле укучыларыбыз!

1 сентябрьдән 2012 елның беренче яртысы өчен вакытлы матбугатка язылу башланды. «Казан утлары»ның индексы **73210** (физик затлар өчен), **16262** (юридик затлар өчен). Татарстанда ярты елга язылу бәясе физик затлар өчен **272 сум 94 тиен** , юридик затлар өчен **309 сум 30 тиен.**

Журналга язылуны җиңеләйтү максатыннан абонемент үрнәген тәкъдим итәбез. Шушы квитанцияне кисеп алып, анда үзегезнең тулы адресыгыз, исем-фамилиягез һәм язылырга теләгән айларны күрсәтеп, үзегез яшәгән җирдәге элемтә бүлегенә тапшырырга кирәк.

«Казан утлары»на язылырга онытмагыз!

**Ф.СП-1**

Почта России

**АБОНЕМЕНТ на ~~газету~~ журнал** **73210** (индекс издания)

***«Казан утлары»***
(наименование издания)

количество комплектов:

на 20 12 год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

Куда
(почтовый индекс) (адрес)

Кому
(фамилия, имя, отчество)

---

ПВ | место | литер

**ДОСТАВОЧНАЯ КАРТОЧКА**

на ~~газету~~ журнал **73210** (индекс издания)

***«Казан утлары»***
(наименование издания)

| Стоимость | подписки | ____руб.____коп. | количество комплектов: |
|---|---|---|---|
| | переадресовки | ____руб.____коп. | |

на 20 12 год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

Куда
(почтовый индекс) (адрес)

Кому
(фамилия, имя, отчество)

# Ictimagi-mədəni tormışıbızdan
# Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

### МАКСАТЛАРНЫ АЧЫКЛАУ

ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов парламентка еллык Юллама белән мөрәҗәгать итте.

Юлламада республиканың социаль-икътисади үсешенә җентекле анализ ясалып, Татарстанны нәтиҗәле үстерү өчен максат һәм бурычлар куелды. Алга таба эшчәнлекнең өстенлекле юнәлешләре итеп мәгариф һәм сәламәтлек саклау өлкәләрен яңарту, икътисадның инновацияле үсеш юлын дәвам иттерү, кооператив элементларнең глобаль челтәрен булдыру, авыл җирендә эшмәкәрлекне үстерүгә төрле юллар белән ярдәм итү, транспорт үсеше, Татарстанда төрле милләт вәкилләренә тигез һәм лаеклы мөмкинлекләр тудыру һ.б. аталды.

Республика башлыгы үз чыгышында 2011 елның бөек шагыйрь Габдулла Тукай елы буларак узуына басым ясап, аның шагыйрь мирасының актуальлеген, туган телне, мәдәниятне саклау мөһимлеген күрсәтүен аерым ассызыклады.

### ТАТАРСТАНДА МӘСКӘҮ КӨННӘРЕ

25 августта Татарстанда Мәскәү көннәре үтте. Шушы уңайдан Казанга Россия башкаласыннан мэр урынбасары А.Горбенко җитәкчелегендәге рәсми делегация килде.

Зур мәдәни программа М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрында башланып китте. Тантананың йөзек кашы исә В.Спиваков җитәкчелегендәге данлыклы «Виртуозы Москвы» дәүләт камера оркестры чыгышы булгандыр.

Кунаклар шулай ук Универсиада авылында, «Тулпар» спорт комплексында булды, Җиңү паркындагы Мәңгелек утка чәчәкләр салуда һәм «Булгария» теплоходы фаҗигасендә һәлак булучылар истәлегенә Мәскәү хөкүмәте исеменнән венок куюда катнашты. Аннары кунаклар Мәскәү белән Татарстан арасында сәүдә-икътисади, фәнни-техник һәм мәдәни хезмәттәшлек турындагы килешүне тормышка ашыру чаралары планын үтәү кысаларында «Энергияне нәтиҗәле кулланучы квартал» районын карады.

Татарстанда Мәскәү көннәре Г.Камал театры бинасы алдындагы мәйданда «Токио» төркеме концерты белән тәмамланды. Җавап визиты белән Мәскәүдә Татарстан көннәре ноябрь аенда узачак.

### УНИВЕРСИАДА ӘЛӘМЕ КАЗАНГА КАЙТТЫ

Кытайның Шэньчжэнь шәһәрендә Бөтендөнья студентлары Универсиадасы тәгәлләнде. Универсиада әләме Казан мэры Илсур Метшин кулына тапшырылды. Шул рәвешле Казан рәсми рәвештә Универсиада башкаласына әверелде.

Кытай Универсиадасында Россия спортчылары, мәйдан хуҗалары кытайлардан гына калышып, 2нче урынны алды. Алар 132 (42 алтын, 45 көмеш, 45 бронза) медаль яулады.

Татарстан вәкилләре дә күрсәткечләрен яхшыртты. 2 ел элек Сербия Универсиадасыннан безнекеләр ике алтын медаль белән кайткан иде. Бу юлы исә 1нче урыннар саны 10га җитте.

Хәзер төп бурыч—Универсиаданы Кытайдан калышмаслык итеп оештыру. «Барысы да яхшы булыр дип уйлыйм»,—диде Универсиада дирекциясе башлыгы Владимир Леонов.

### КАДЕРЛЕ КУНАКЛАРЫБЫЗ

22 сентябрьдә Татарстанда Башкортстан Республикасы Мәдәнияте көннәре ачылды.

Ул М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрында тантаналы төстә үтәчәк. Чараның кунаклары арасында Башкортстан Республикасы Президенты Рөстәм Хәмитов, Башкортстан Республикасы Премьер-министры урынбасары Сергей Афонин, Башкортстан Республикасы Премьер-министры урынбасары—авыл хуҗалыгы министры Эрнет Исаев һәм башкалар бар иде. 2011 ел Башкортстан Республикасында Милләтара татулыкны ныгыту елы дип игълан ителгән. «Без Татарстан халкына мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә үз казанышларыбызны күрсәтергә телибез»,—дип ассызыклады Башкортстан мәдәният министры урынбасары Ранис Алтынбаев.

### СӘЙДӘШ БӘЙРӘМЕ

20 августта Югары Ослан районының Кызыл Байрак авылында мәшһүр композиторыбыз Салих Сәйдәшев истәлегенә багышланган сәнгать бәйрәме булып үтте. Тамашачыларны «Совет Армиясе маршы» белән дирижер А.Сладковский җитәкчелегендәге Татарстан дәүләт симфоник оркестры каршы алды. Сәйдәш аланында Милли музеебыз хезмәткәрләре тарафыннан әзерләнгән, композиторның тормыш һәм иҗатына багышланган күргәзмәне тамаша кылырга да мөмкин иде. Республикабыз Мәдәният министрлыгы, Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры Сәйдәш бәйрәмен быел 11нче мәртәбә үткәрде.

### ДАГСТАНДА ДА БЕЛӘЛӘР

Татарстанның халык шагыйре Ренат Харис Рәсүл Гамзатов исемендәге әдәби премиягә лаек булган. Әлеге зур бүләкне ана рус теленә тәрҗемә ителеп бастырылган «Певчая ночь» шигырьләр җыентыгы өчен тапшырганнар. Бүләкләү тантанасы традицион рәвештә Махачкалада үтә торган «Дни белых журавлей» халыкара бәйрәм кысаларында узган. Быел әлеге чара 25 елга беренче тапкыр ЮНЕСКО канаты астында үткәрелгән.

### ИСЛАМ ТЕРРОРГА КАРШЫ

«Ислам террорга каршы» митингында катнашучылар С.Сәйдәшев һәйкәле янына «Мөселман яшьләре тынычлыкны сайлый», «Мөселманнар көч куллануга каршы» дигән шигарьләр белән чыкты. Чараны оештыручы Татарстан Диния нәзарәте һәм мөселман яшьләр берлеге халыкның игътибарын террорчылык проблемасына юнәлтергә, исламның тыныч һәм толерант дин булуын аңлатырга теләде. Акциягә башкаланың дини һәм дөньяви уку йортлары студентларыннан кала Әлмәт һәм Түбән Кама яшьләре дә җыелган иде. Митинг барышында 2004 елның 1 сентябрендә Төньяк Осетиянең Беслан шәһәрендә булган куркыныч фаҗигадә һәлак булганнарны да искә алдылар.

***

Самарада «Русча-татарча сөйләүлек» («Русско-татарский разговорник») дөнья күрде. Самара эшмәкәре Ильяс Шәкүров барлык чыгымнарны үз өстенә алган. 5000 данәдә чыккан китапны халыкка бүләк итеп таратачаклар.

123 биттән торган сөйләүлеккә, 125 еллыгын да истә тотып, бөек шагыйребез Габдулла Тукайның да шигырьләре кергән.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Беренче биттә:* Шәһри Болгардагы Кара төрбә.

*Дүртенче биттә:* язучы **Рөстәм Галиуллин**.

ТМ
татмедиа




## «Татмедиа» журналлары — һәр көн укыр өчен

**ЖУРНАЛЛАРГА ЯЗЫЛУ ПУНКТЫНЫҢ БЕРДӘМ ТЕЛЕФОНЫ:**
**(843) 222-09-79**



Рөстәм Галиуллин

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)